# КАЗАН УТЛАРЫ

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*

## Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Газинур МОРАТ. Чыраг тотып якты эзләгәннәр... *Шигырьләр*. ....3

Марат КӘБИРОВ. Башка авыл кешесе... *Хикәя*. ....9

Фәндидә ХАРРАСОВА. Күрелмәгән юлны кичкәндә. *Поэма*. ....17

Марат ӘМИРХАНОВ. Яугирә. *Роман*. ....25

Флюра НИЗАМОВА. Тау юлыннан төшеп киләмен... *Шигырьләр*. ....78

Хисаметдин ИСМӘГЫЙЛЕВ. Таш Түккән – сихри бożра. *Роман*. ....82

ЯҢА ИСЕМНӘР

Гөлзилә ФӘХРЕТДИНОВА. Аяз иде юкса кичә... *Шигырьләр*. ....129

«СЕЗ ИҢ ГҮЗӘЛ КЕШЕ ИКӘНСЕЗ!» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Рифә РАХМАН. Гади вакланма. *Повесть*. ....132

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Маһир ГАБИЛОГЛУ. Әрмән-Армен – Шушаник мәхәббәте. *Хикәя*.
*Русчадан Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА тәрҗемәсе.* ....147

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Зиннур МАНСУРОВ. Тынычсыз хиссият балкышы. ....157

ХӘТЕР

Рафис КОРБАН. Дәвамчысын калдырып китте. ....164

Рухия АХУНҖАНОВА. Легендар Миңлекамал *(М.Әмирнең «Миңлекамал» пьесасындагы төп герой Миңлекамалның прототибының кызы Гәүһәр ханым белән әңгәмә)*. ....169

ФӘН

Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. Номгон ташъязмасы: XXI гасырның иң олы ачышы. ....176

ИДЕЛ БУЕ БОЛГАР ДӘҮЛӘТЕНДӘ ИСЛАМ ДИНЕН КАБУЛ ИТҮНЕҢ 1100 ЕЛЛЫГЫ

Илдус ЗАҺИДУЛЛИН. Татар сәүдәгәрләре ислам динен тарату системасында. ....179

ГАЗИЗ ТАВЫШЛАР

Бездән соң да яшәп калачак *(Мөхәммәт Садриның тууына – 110 ел )*. ....188

Арабызда кебек әле дә *(Айдар Хафизовның тууына – 80 ел).*
*Сәхифәне Нәсим АКМАЛ алып бара.* ....189

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

КАЗАН УТЛАРЫ
*№ 5 (1207) 2023*

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*
**Ирада Әюпова**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Ркаил Зәйдулла**
**Илгиз Зәйниев**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Айдар Сәлимгәрәев**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Данис Шакиров**
**Ленар Шәех**

---

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**
*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**
*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Рафис Корбан.**
*Мөхәррирләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Гөлия Сәлахова.**
*Сайт мөхәррире:* **Ләйсән Зарипова.** *SMM-белгеч:* **Алинә Хәбибуллина.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер)**.**
*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

---

✉✉: Редакция адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип – 222-05-50 (өст. 1617).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1267), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 28.04.2023, график буенча 28.04.2023, басылып чыгу вакыты 05.05.2023
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ С-1071. Тираж 5698.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2020 елның 13 ноябрендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79467.
Индекслар: ПО277 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен),
П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
12+

© «Казан утлары», 2023 ел



Газинур
Морат

# ЧЫРАГ ТОТЫП ЯКТЫ ЭЗЛӘГӘННӘР...

## Гомер

...Бу сәфәрдә алышынып тора
Гел ике төс – йә ак, йә кара...
Шуңа, ахры, гөнаһын да кылдык,
Булдык бугай бераз тәкъва да.

Шайтанны да шат кылдырдык шулай,
Иман китердек бер Хакка да.

## Әйткән шагыйрь...

Каннан кансызланган дәвер килгәч,
Әйткән шагыйрь бер көн, таң калып:
Дон Кихотлар кабат туар булса,
Кентаврга йөрер атланып...

## Татар аты

Тарихларда аңа җанияләр,
Җиһангирлар йөргән атланып.
Кыйтгалардан кыйтгаларга җилеп,
Ил корышкан татар атлары.

Вакытларны кичкән татар аты...
Ул һаман да шулай атала.
Без генә ул җилдәй җилдерәбез,
Атланышып агач атларга.

---

Газинур МОРАТ (1959) – *шагыйрь, публицист; Татарстанның халык шагыйре. «Кош хокукы», «Ике икең биш була», «Күзге учак кузлары» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

## Дәрья эзләү

Апрель гөрелтесен тыңлый-тыңлый,
Уйдык-уйдык карлар ята көйрәп.
Алгысынган гөрләвекләр буйлап
Дәрья эзләп йөзә кәгазь көймә...

## Язгы бер хатирә

Чал инешең ташыганда
Ник өзелмәсен үзәк?!
Малайчакка кайттым кабат,
Бозлар киткәнен күзләп.

Малайчагым, кулын изәп,
Яшерде яшьле күзен.
Бозда ага-ага китте
Әллә ул, әллә үзем...

## Тальян

Сыздыр әле, Сатый,
«Сакмар»ны бер, –
Шулай юанганнар элгәре.
Татар йөрәгенең ни уйлавын
Әйтеп биргән тальян телләре.

Сыздыр әле...
Безнең йөрәкне дә
Нинди генә уйлар телмәде?!
Телдән калган халыкның да хәлен
Әйтеп бирер тальян телләре.

## Диктант

Хакимнәр дә, хадимнәр дә җыйнау
Язу яза... – шундый заманы.
Сүз сүрүен сүтеп, хәтердә бер
Казгануның юктыр зарары.

Шөкер, әнкәйләргә хат юлларлык
Телләребез әле тере лә.
Бер куаныч, бер юаныч хәзер
Яза белү анаң телендә.

## Җанисәп

Исәйсәк тә, хәтта ишәйсәк тә,
Без һаман ким... Хәлләр – кичәге...
Бу дөньяда татарның соң әллә
Юк та микән төгәл исәбе?

Элгәрләрнең гаярь аргамагы
Әле җилгән, әле сөрлеккән...
Әллә безнең җанның сан-исәбе
Дәүләти бер олы сер микән?

Безнең маңгайга да, яшертен, дип
Әллә инде мөһер сугылган?..

Татар башы исән чыккан хәтта
Сугым сараеннан, сугымнан...

Саналганда хәтта сыналабыз.
Бу – тарихи безгә ишарә.
Исәйсәк тә, ишәйсәк тә, без – ким...
Ут күршеләр генә ишәя.

Күк астында, хәер, һәр кавемнең
Исән калу – бар уй-исәбе...
Ә татарны күпме санасаң да,
Беркем белмәс төгәл исәбен.

## Нәүруз

...Башта түрк булган. Димәк – терек!
Тереклекнең төбе – төркидән.
Тарих кичеп, әлмисактан бирле
Чөйязулы уртак тел килгән.

Кыйтгаларны кичә-кичә килгән,
Җилеп килгән җилле атларда.
Дөнья тоткан... Ә дөньяда, никтер,
Оныткан үз хакын хакларга.

Үзе юкса күпме ил-кыйтгага
Үз тамгасын уеп калдырган.
Күпме кавемнәрнең шәҗәрәсе
Төртеп чыккан төрки тамырдан.

Тарих тәгәрмәчен әйләндергән
Татар аты – шундый дан алган!
Кайсы гасырларның сатанасы
Шул атларга менеп атланган?!

Кайсы гасырларның сатанасы
Шул атларга тышау кидергән;
Бар җиһанда бөре уянганда,
Вакыт угын артка чигергән?

Бу җиһанда хаккы зур түркнең –
Хак урыны аның түрдәрәк.
Җилбер-җилбер Нәүруз җиле исә, –
Үз елыбыз булсын мөбарәк!

Нәүруз җиле исә җилбер-җилбер...
Атта җилеп Яңа Көн килә.
Шау бөредә җиһан... Димәк – тере!
Тереклекнең төбе – төркидә.

## Сары йорт

*Адлер Тимергалин рухына*

Юлбашчылар юл яздырган чакта,
Ватан язган чакта акылдан,–
Кара чорларда да, чыраг тотып,
Якты эзләүчеләр табылган.

Чыраг тотып якты эзләгәннәр
Җәһәннәмнән, Дию өненнән.
Ә илләрдә көннәр әверелгән
Тоташ Варфоломей төненә.

Иләмәннәр илне мәңге килмәс
Якты киләчәккә әйдәгән.
Газиз ватан үзе биниһая
Шыксыз сары йортка әйләнгән.

Сары йортка ябып саргайтканнар.
Азлар белгән – кайда чын, ялган...
Томанасы – гыйлем иясенә,
Гыйлемлесе җүләр саналган.

Бер мыскал да якты кермәсен дип
Томаланган тәрәз-ишекләр...
Күккә ашасы җан шул мәхшәрдән
Исән чыккан икән ничекләр?!

Күккә ашасы бу җаннарны соң
Нинди фәрештәләр саклаган?
Нинди генә кара дәвердә дә
Гали затлар булган, ак калган!

Ак калганнар – кара яксалар да,
Ак калганнар – кара йокмаган...
Сантый хаким булса, хәкимнең дә
Башы чыкмас сары йортлардан.

Юлбашчылар юл яздырган чакта,
Юлдан язган чакта халыклар,
Чыраг тотып, якты эзләүчеләр
Һәрчак булган, һәрчак калыккан.

## Туу

Төн карасын куа-куа, гаярь
Әтәчләр дә, ахры, алҗыган, –
Шыпырт кына таң капкасын ачып,
Көнгә кереп килә бар җиһан.

## Бакый

Башкайларын илнең ташлар баскан.
Мәңгелекнең өне килә таштан.
Кол Галигә тартым итеп уйган
Вакыт сурәтен ул яңабаштан.

## Хөкемдар

Ул әйткән сүз генә гел дөрес була,
Көрсие дә алтын йә көмеш була.
Шул көрсидән мәтәлеп төшкәч кенә,
Илләрдә бер галәми көлеш була.

## Сәүдә

Сатулашып, дөнья куа-куа,
Әманәтләр кала казага.
Сәүдә итә белү сәнгатьтер ул,
Әйләнмәсә илең базарга.

## Күпнокта

Күпноктадан мәгънә эзләп
Адарынган дәүләттә
Әләк язу маһирлары
Мәләк була, гадәттә.

## Әпипә

Чын асылга кабат кайтыр өчен
Безгә әле озак тәпиләргә...
Кеше кубызына биегәнче,
Биик үзебезнең «Әпипә»гә.

## Җырсыз дәвер

Бу болгавыр заманадан да без
Калалмадык бугай җыр отып.
Күшексә дә, өшәнсә дә,
Җанны
«Гөлҗамал»лар торыр җылытып.

## Сүз

Иң хак сүзләр Кодрәт Иясенең
Вәхи булып иңгән уедыр.
Шагыйрь сүзе пар канатлы булса,
Кабер ташларына уелыр.

## Юану

Учагыбыз дөнья җылытамы,
Чырагыбыз сүнеп барамы,
Газиз әнкәйләрнең кочагында
Без барыбер сабый баладыр.

## Алтайда, таланган курган эргәсендә

Тарихларга чаклук, әйтерсең лә,
Гел вәхшилек кенә кылганнар.
Хәтәрләрдән кисәтергә теләп,
Хәтер булып ауный курганнар.

## Җиһангир кабере

Сигез гасыр сер саклый ул,
Серен белә бер Тәңре.
Татарның йөрәгендәдер
Җиһангирның кабере.

## Идегәй

Бу – күкләрнең әллә каргышымы,
Әллә элгәрләрнең ялгышы?..
Туган белән туган даулашып та,
Хәл кылынган халык язмышы.

## Иген үссә генә...

Телләрдә гел таҗлы зәхмәт кенә,
Әҗәл хозурында көн дә без.
Әмма кырда иген үссә генә,
Исән-аман калыр дөньябыз.

## Көй

Тарихларда кем чаң какты,
Кем – сазында уйнады...
Җанны айкаган көй генә
Көйләр көйсез дөньяны.

## Камилә Вәлиева

Күздән яшь китергеч гүзәллеккә
Бер без генәмени җан аткан?!
Камиллекнең чиген билгеләргә
Күкләр татар кызын яраткан.

## Безнең юл

Сөешкәндә күкләр чүгеп куя,
Биегәеп китә түшәмнәр...
Ә безнең юл ахирәткә чаклы
Үкенечләр белән түшәлгән.

## Алтын көз

Алтын көз – җанның иң ямьле,
Иң гамьле мәледер ул.
Сөюнең иң ачысы да
Татлы вә тәмледер ул.

## Аппагым

Утлар янам... Сулар сибеп кенә,
Юк, сүнәсе юктыр бу утның.
Син соң миңа никләр очрадың да,
Мин соң сиңа никләр юлыктым?

Сабыр гына сызып ята идем
Миңа язган гомер ызанын,
Сулык-сулык бәгырь сызганын да
Ишетәм күк хәзер, и җаным.

Ишетәм күк синең һәр уеңны,
Һәр ымыңны – шундый хәлдәмен.
Сөю касәсеннән хәмер эчкән
Бер дивана микән әллә мин?

Кем аңласын хәлен дивананың, –
Ишетәм күк керфек какканың.
Сине генә сөяр өчен Җиргә
Килгәнмен мин, ахры, Аппагым.

Күзләреңне алма күзләремнән,
Кулларыңны алма кулымнан.
Бергә генә үтеп китик әле
Бу гомернең борма юлыннан.

Кыл урталай бүлеп ашарбыз бер
Оҗмахларга кертер алманы...
Сиксәндә дә сөюнамә язган
Гаташ хәлен мин дә аңладым.

Безне зырылдаткан зилзиләләр
Әле шашты, әле басылды...
Бер сөюең мең савапка торыр,
Сөя алсаң җуеп башыңны.

Бер сөюең мең савапка торыр,
Бәхет чиксәң татлы газаптан.
Бу – айнымас шыр дивана булган,
Дип сөйләрләр, бәлки, азактан.

Син соң миңа никләр очрадың да,
Мин соң сиңа никләр юлыктым?
Утлар янып ятам... Сулар сибеп,
Юк, сүнәсе юктыр бу утның.



Марат
Кәбиров

# БАШКА АВЫЛ КЕШЕСЕ...

ХИКӘЯ

**1**

«Сабантуй күрке – көрәш» дип әйтсәләр дә, бала-чага көрәшкән вакытта тамаша кылучылар бик күп булмый. Мәйдан тоткан малайларның дусишләре, туган-тумачалары, көрәшнең чын җанатарлары гына җыела. Алары да ярыйсы гына була, тик концерт караучылар белән чагыштырырлык түгел. Хәзер бит әллә нинди мәзәк уйлап таптылар: һәр Сабантуйга диярлек берәр сәхнә йолдызын чакырып кайтаралар, авыл халкы шулар чыгышыннан ерак китәлми, кушылып җырлый, бии, рәхәтләнеп күңел ача. Авыл сәхнәсендә мондый тамашаларның гомергә дә булганы юк, шуңа җыр-моңга сусаган халык ел буена җитәрлек рухи ләззәт алып калырга тырыша бугай. Ләкин көрәш мәйданына өлкәннәр чыгуга хәтта концерт караучылар да сирәгәя төшә, ә инде «Сабантуй батыры» өчен көрәш барганда, артистлар янында беркем дә калмый һәм концертны вакытлыча туктатып торалар.

Бу юлы да шулай иттеләр. Сабантуйдагы бөтен халык көрәш мәйданын тирәләп алды. Гадәттә, көрәш ахырына өч батыр кала һәм аларның өчесе дә авылныкы була торган иде. Быел алай килеп чыкмаган, мәйданда калган батырларның икесе генә таныш иде.

Озын буйлы, таза гәүдәле Зариф – ел саен батыр кала торган кеше. Аның көч-куәтле икәнен мәйданга чыкмаган чагында да чамалап була: куллары көрәк кебек, беләкләрендәге кан тамырлары да кайберәүләрнең бармак калынлыгы булып ташып тора. Нинди генә гайрәтле кеше булса да, мактанып, борын чөеп йөри торган гадәте юк. Авыл халкының хөрмәтен казанган абруйлы узаман, кыскасы.

Икенчесе Хәйдәр исемле, ул монда ялгыш кына килеп эләккәндер сыман тоела. Юка гына гәүдәле, кыска буйлы. Аны беркем дә көрәшче дип уйламый. Яшьрәк чагында күрше авылга барып, андагы егетләр белән бәйләнешеп китсәләр: «Әнә, башта иң кечкенәбезне җиңеп карагыз», – дип,

Марат КӘБИРОВ (1970) – *шагыйрь, прозаик; Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. «Онытма таңнарны», «Мәхәббәт яңгыры», «Китап» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

гел шуны чыгара торган булганнар. Ә бу инде ничәүләшеп каршы чыксалар да, алып кына ора икән. Тегеләр шундук койрыкларын кысарга мәҗбүр була: «Иң кечкенәләре шундый булгач, тазарак егетләре бигрәк хараптыр боларның», дип уйлыйлар икән.

Хәйдәр көчле булуы өстенә бик җитез дә, әмма Зариф белән көрәшкән чакларында гел икенче урынга кала. Көрәшнең бөтен нечкәлекләрен дә беләм дип уйлаучылар моңа бераз гаҗәпләнә: «Юри бирешми микән?» – дип шикләнә дә торган иде. Ә авылның очлырак теллеләре һич икеләнүсез сөйләп йөри: «Беренчелекне Зарифка калдыра ул, теге бит амбар мөдире, шуның өчен моңа ашлыкны чутламый бирә». Чама тартып карасаң, Зариф чынлап та амбар мөдире инде, ашлык тараткан чорда ул артык вакланып тормый, утыз-кырык кило артыграк киткәндә дә, кул гына селтәп куя. Теләсә кемгә түгелдер инде ул, кешесенә карап кынадыр. Авылда абруе зур булуның бер сәбәбе, бәлки, шуннандыр да. Бәлки, алай да түгелдер, кеше сөйләгәннең барысына да ышана башласаң, күзең дә сукыраерга мөмкин.

– Өченчесе кем соң? – дип пышылдаштылар яңарак кына мәйдан янына килүчеләр. – Бер дә таныш-белешкә охшамаган.

– Берәрсенең туганы микән әллә?

– Читтән кайткан адәм бугай…

– Башка авыл кешесе кебек… Берәүгә дә охшатырлык түгел…

Башка авыл кешесенең батырлар арасында булуы аз гына сәер иде. Чөнки авыл Сабантуйларында, гадәттә, андыйларны төрле сәбәпләр белән төшереп калдырырга тырышалар. Хәтта ахырга калса да, өченче урыннан да югарырак иттермиләр. Һәрбер хәрәкәтен «Хәрәмләште!» – дип кенә торалар да арып хәлдән тайганчы көрәштерәләр, теге тәмам күңеле төшеп, кул селтәргә мәҗбүр булганчы кыланалар. Бу бик дөрес нәрсә түгелдер инде, ләкин авыл халкының беренчелекне читтән килгән батырга биреп җибәрәсе килми. Үз авылыңны ким-хур итү шикеллерәк нәрсә бит инде. Акылы булган адәм башка авылга барып, батыр калу турында уйлап та карамый инде шуңа күрә. Ә бу…

Бу әллә ни пәһлеванга да охшамаган иде. Уртача буйлы, уртача гәүдәле. Һәрхәлдә, Зариф янында мескен генә күренә. Уң аягына бераз гына аксаган да сыман. Судьясын әйтер идең инде, шуны ахырга кадәр калдырмаса, ни булган. Әгәр Зарифка юри бирешүе хак булса, моны Хәйдәр алып кына орачак иде. Хәйдәр башка авыл кешесен атып бәрсә, Зариф Хәйдәрне аркасына салса – көрәшнең нәрсә белән тәмамланачагын күз алдына китерү бик кыен түгел.

– Быел көрәшне карап та торасы юк икән, – дип пышылдашты мәйдан тирәли җыелган кешеләрнең бер ише. – Кемнең ничәнче урын алачагы, кемнең батыр калачагы болай да билгеле!

Бер карасаң, алар хаклы иде. Мәйданның иң төбендә үк Зарифның туган-тумачалары, дуслары-әшнәләре җыелып баскан. Алар күп. Көрәш башлану белән көч биреп: «Зариф! Зариф!» – дип кычкырачаклар. Көндәшләре көчлерәк булып чыкса, судья белән бәхәсләшергә тотыначаклар, «теге хәрәмләште, син күрми калдың, яңадан көрәштер», – дип, күз дә ачырмаячаклар. Мондый күренеш ел саен диярлек кабатлангач, хәтта кемнең кайчан нәрсә әйтәчәген дә чамалап булырлык иде. Судья бик намуссыз кеше булмаса да, ул монда гына хөкемдар, ә тормышта Зарифка һәм аның туганнарына һәр адымда диярлек бәйле кеше иде. Аның берсүзсез

гадел хөкем чыгаруына бик ышаныч юк. Аннан соң, Зариф үзе дә ни җитте көрәшче түгел, булган кеше, ныклы, шомарган… Шуңа күрә көрәштә кемнең батыр калачагы берәүдә дә шик тудырмады.

Ләкин беркем дә китәргә ашыкмады. Нәтиҗәсе алдан билгеле булса да, көрәшнең барышын күзәтү һәркемгә кызык шикелле иде.

– Хөрмәтле авылдашлар! Килгән кунаклар! Барыбыз да көрәш мәйданына җыелабыз, – дигән аваз ишетелде багана башына элеп куелган тавыш көчәйткечләрдән. – Сабантуйның иң киеренке мизгелләре якынлаша. Тиздән Сабантуй батыры исеменә алышу башлана. Быелгы бәйгенең өч узаманы сезнең каршыгызда…

Көрәшчеләрнең исем-атын игълан иттеләр. Менә монда да кемнең ничәнче булачагы чагылып киткән төсле тоелды. Бөтен мактаулы исемнәре, биләгән вазифасы, ничә тапкыр Сабантуй батыры булуын искә төшереп, Зарифны атадылар. Ул инде мондый нәрсәләргә күнегеп беткән иде, алгарак чыгып, төрле тарафка борыла-борыла баш иде. Бу вакытта көрәш мәйданын төреп алган дус-ишләре шау-гөр килде. Әле ул урынына барып баскач та, көр тавышлар белән:

– Зариф! Зариф! – дип кабатлап тордылар.

Тавышлар тына төшкәч, Хәйдәрне игълан иттеләр. «Авылыбызның уңган тракторчысы… Үрнәк әти… Иң оста көрәшчеләрнең берсе…» Шул рәвешле бик матур сүзләр әйтсә дә, сөйләүченең тавышы бераз сүлпәнрәк иде. Бик нык гөрләшүче дә, исемен кычкыручы да табылмады. Хәйдәр дә алгарак чыгып, баш иде. Сыек кына алкышладылар.

Ә таныш түгел кешене игълан итү бөтенләй коры килеп чыкты:

– Сабантуй кунагы, башка авыл кешесе… Харис…

Харис та алгарак чыгып баш иде. Тик аңа беркем дә кул чапмады. Берәү дә шаулашмады. Бары тик тамашага җыелган халык өстендә:

– Башка авыл кешесе… Башка авыл кешесе… – дип, төрле хисләр белән пышылдашкан авазлар гына кайнар чәйнектән чыккан пар шикелле ургылып торды. Авыл халкы чынлап та кайный иде бугай. Башка авыл кешесенең шушы Сабантуй көрәшенә килеп кысылуы, ардаклы батырлар арасында күкрәк киереп басып торуы гайре табигый хәл, әрсезлек, хәтта бераз мыскыллау да шикелле иде. Чынлап та шулай бит инде. Ул бит җиңәргә тели. Шул җиңүе белән: «Сезнең авылыгызда Сабантуй батыры булырлык та ир-ат юк бит…» – дип әйтергә тели.

Ләкин кешеләрнең күңелендә өмет бар иде әле. Авыл халкы аның беренче алышта ук чалкан төшеп, башын иеп чыгып китүен көтте. Менә шул очракта гына аны гафу итәргә мөмкин булыр иде.

## 2

Көрәшнең үз алымнары булган шикелле үк аның белән идарә итүнең дә төрле ысуллары була. Гасырлар буена камилләшеп шомартылган андый ысулларны читтән карап кына аңлап та бетерә алмыйсың, аңлаган хәлдә дә синең белән исәпләшеп торучы табылмый, көрәш мәйданындагылар гомум шау-шуга ышыкланып, барысын да үзләренчә хәл итә дә куя. Бөтен халык беренчелекне үз авылдашларына бирергә теләгәндә, моның бер кыенлыгы да юк.

Өченче урын өчен башта Зариф белән Хәйдәрне көрәштерделәр. Билләреннән алышып, беркадәр әйләнгәләп йөргәч, Зариф көндәшен җиргә чәпәде. Чистага. Бу шулкадәр тиз һәм көтелмәгәнчә булып тоелды, хәтта Сабантуй батырының җанатарлары да берни әйтә алмый калды. Бары тик судья җиңүченең кулын күтәргәч кенә, дәррәү кубып кычкырышырга тотындылар:

– Зариф! Зариф! Безнең Сабантуй батыры!..

Аннан соң Хәйдәр белән башка авыл кешесен чыгардылар. Менә монсында инде шаулашу көчле булды. Әле генә Зарифка дан яудырып кычкырышкан кешеләрнең барсы да Хәйдәргә дәрт бирергә тотынды:

– Хәйдәр! Хәйдәр! – дигән тавышлар тирә-юньгә яңгырап торды. Әллә шулардан күңеле үсеп, әллә бүтән сәбәп белән Хәйдәр бу юлы бөтен җегәрен салып көрәште. Ул җитез дә, кискен дә иде. Берничә тапкыр көндәшен тезләренә утырта язып калды, тик тегесе дә төшеп калган түгел, шундук диярлек тегенең куеныннан шуып чыкты да үзе һөҗүм итте.

– Хәйдәр! – дип кычкырды халык. – Хәйдәр, әйдә, бирешмә!

– Манчырга кирәк килмешәкләрне!

– Уң ягыннан кер, – дип кычкырды кайсыдыр. – Уң аягына аксый ул…

– Хәйдәр, әйдә, сыла җиргә сырты белән!

Хәйдәр көндәшенең тез артына сул аягын китерү белән тегесе тайчанып калды да ике тезе белән дә аяклары арасына кереп кысып тартты. Күтәреп алды. Һәм таяныр җир эзләп, аякларын чәбәләндергән Хәйдәрне җиргә салды.

Халык бер мизгелгә «Аһ!» итеп куйды. Бу юньлелек түгел иде. Димәк, башка авыл кешесенең өченче урынга гына риза булып китәргә теләге юк, димәк, ул аларны тоташ авыллары белән хурлыкка калдырырга маташа. Үзе шуны аңлый микән ул? Әллә шуны да белмәслек дәрәҗәдә томана микән?

Башка авыл кешесенең кыяфәтендә мыскыл итү яки кимсетергә тырышу галәмәте юк иде. Ул җитди, әмма тыныч. Уң аягының тездән аскы өлешен уалап алды да җирдән сикереп торган Хәйдәр янына килеп, кул бирде. Хәтта кочаклагандай итеп, аркасыннан да кагып куйды. Шулкадәр ике йөзле булып була икән! Бөтен халык алдында җиргә атып бәр дә соңыннан кул биреп, аркасыннан как, имеш. Сабый баланы юаткан шикелле бит инде бу! Хәйдәрнең буе кечкенә булгач, нәкъ шулай тоелды да. «Үс әле, энекәш, тәҗрибә тупла…»

– Хәрәмләшә килмешәк! – дип кычкырды кемдер.

Шуны гына көткәндәй, мәйдан янындагылар бер тавыштан күтәреп алды:

– Әйе, хәрәмләште…

– Монсы исәпкә керми!

– Яңадан көрәшсеннәр!

Бераздан бөтен халык бер булып такмакларга тотынды:

– Яңадан! Яңадан! Яңадан!

Мәйдандагы судьялар баскан килеш кенә кочаклашып, сүз берләшеп алдылар да әлеге икәүне кабаттан көрәштерергә булдылар.

– Хәйдәр! Хәйдәр! – дип дәртләндерде кешеләр бер авыздан.

– Бирел, килмешәк! Сиңа бүтән чара юк! – дип кычкырды кемдер.

– Хәйдәр, күрсәт шуңа безнең авыл күген!

– Ыргыт үз авылына кадәр!

Ләкин башка авыл кешесе бирешергә уйламый иде. Хәйдәрнең

һөҗүмнәреннән ул җиңел генә сакланып килде дә теге бераз хәлсезләнә башлагач, кинәт хәрәкәт ясап күтәреп алды һәм көндәшен җиргә салды.

– Тагын хәрәмләште! – дип кычкырды берәү. – Ике тапкырында да, көрәштән төшереп калдырырга кирәк.

– Яңадан көрәшсеннәр!

– Яңадан! Яңадан!

Кыяфәтенә караганда, Хәйдәрнең яңадан көрәшергә исәбе юк иде бугай. Ул салмак адымнар белән ары-бире йөренә, кулларын селтәп, тирән-тирән сулыш ала. Башка авыл кешесе дә беркадәр арыган сыман. Ә көрәшне тамаша кылучыларга нәкъ шул кирәк иде дә. Хәйдәр белән көрәштереп, килмешәкне тәмам хәлдән тайдырырга, шуннан соң гына Зарифка каршы чыгарырга. Менә шул вакытта беләчәк ул бүтән авылга барып, батыр калырга маташуның ни бәягә төшкәнлеген.

– Кайдан килеп чыккан соң бу нәмәрсә? – дип, үзара пышылдашты ике хатын. – Кем керткән аны монда? Көрәшсен иде үз җирендә. Ә бу – безнең авыл бәйрәме.

– Белмим инде, берәрсенең туганы түгел микән?

Халык арасыннан кулга тиярдәй дулкын булып шул пышылдау узды: «Берәрсенең туганы түгел микән?» Бу гади генә сорау түгел иде. Бу «авылдагы берәр абруйлы кешенең туганы түгелме?» – дигән шикләнү иде. Һәм бөтенесе дә диярлек башка авыл кешесенә игътибар беләнрәк күз салды, таныш чалымнар эзләде, читтән кайтучылар да аның кемлеген ачыкларга тырышты. Тик көрәшченең шәхесе ачыкланмаган килеш калды. Түгелдер инде, беркемнең дә туганы була алмыйдыр мондый адәм актыгы. Әнә, авылның иң абруйлы кешеләре мәйдан читендә кайнаша. Туганнары булса, яклашырлар иде.

– Хара! Служак! Синме соң бу? – дип кычкырган исерек тавышы ишетелде Дошман кушаматлы кешенең. – Ниужели, син исән, ә? Хара?

Дошман Әфганда хезмәт итеп кайткан ир-егет, вакыт-вакыт салгаларга яратса да, бөтенләй үк абруйсыз кеше түгел иде. Тик аны да ишетергә теләүче табылмады. Аның сүзләрен яңа дулкын булып, тирәннән кубарылган шау-шу күмеп китте:

– Яңадан! Яңадан!

Көрәшчеләр дә, авыл халкы да игътибар бирмәгәч, Дошман башта тыгыз чылбыр булып мәйданны тирәләп баскан халыкны аралап, көрәшчеләр янына узарга маташып карады, барып чыкмагач, ачы бер чиркану белән чыраен сытты да бишмәт кесәсендәге чәкүшкәсен капшап, якындагы агачлыкка кереп китте. Ә тавышлар яңгырап торды:

– Яңадан көрәшсеннәр!..

Яңадан көрәшү озакка сузылмады. Башка авыл кешесе бераз җай эзләп йөртте дә Хәйдәрне аркасына салды. Халык хәтта кычкырырга да өлгерми калды.

– Маладис! – дип куйды бер карт. Һәм күршеләренең кырын карашын тоеп өстәргә мәҗбүр булды: – Өч тапкыр чистага салды бит. Күпме көрәштерергә була инде? Башка авыл кешесе дигәч тә…

Ләкин аның белән вакланып торучы табылмады. Халыкның игътибарын Сабантуй батыры булу өчен көрәш тартып алды.

– Бераз ял иттерсәләр дә ярар иде, – дип мыгырданды теге карт. – Зариф күпме хәл җыйды, ә монысын арытып бетерделәр… Элек алай булмый торган иде…

Аның сүзенә беркем дә игътибар итмәде. Бер аягы белән гүрдә торган бабай нәрсә әйтмәс инде? Мал асрамый, кош-корт тотмый, бер ялынычы да юк. Аның сүзен сөйли башласаң… Тормыш дигәнең Сабантуй мәйданы белән генә бетми бит әле ул, монда һәр гамәлең, һәр сүзең мөһим. Һәр мизгелең көрәшкә тиң… Монда һәр кеше үзе өчен көрәшә иде…

– Зариф! Зариф! – дигән авазлар белән дөнья тулды.

– Килмешәк, бирел тизрәк!

– Күккә чөй килмешәкне!

Көрәшчеләр мәйдан уртасында җай гына әйләнә бирделәр. Кинәт Зариф көндәшен тартып алырга омтылды. Тегесе җиңел генә тартылды да якын ук килеп, Зарифны күтәреп алды. Һәм артка чигенеп баш аша ташларга итте. Тик Зариф сазаган көрәшче иде, җиңел генә юл куймады, кисәк кенә хәрәкәт ясады да көндәшенең күкрәгенә төште.

Авыл халкының бер өлеше «Аһ!» итеп куйды. Башка авыл кешесе булса да, аның күкрәгенә төшү яраган эш түгел, бу тыелган алым һәм үз көчсезлегеңне тану шикеллерәк тоела.

– Элек булса, моның өчен штраф сугарлар иде, – дип куйды баягы карт. Тик мәйданны сырып алган төркем үзенекен кабатлады:

– Зариф! Зариф! Маладис! Булдырдың…

### 3

Башка авыл кешесе элеккедән озаграк ятты. Торып утыргач, күкрәген уалап алды, аннан соң юка кара чалбары аша уң аягын капшап карады. Торып басу белән диярлек тагын көрәшергә куштылар.

– Һуш җыярга да ирек бирмиләр бит… – дип уфтанды теге карт. – Соң, көрәш шулай буламыни инде?

– Патриотизм тойгысы юк синдә, бабай. Үзебезнең көрәшче өчен тырышырга кирәк… – дип, каршы төште күршесе. Ул арада тагын шау-шу купты:

– Зариф, манчы килмешәкне!

– Үз авылына ыргыт!

Тавышлар көчәйде, тавыш көчәйгән саен сүзләр аңлаешсыз була барды. Шул ыгы-зыгы уртасында батырлар тарткалашты. Башка авыл кешесенең арыганлыгы сизелә иде инде, ул элекке кебек үк елгыр түгел, иренеп кенә хәрәкәт итә… Шулай дип кенә торганда, кисәк хәрәкәт ясап, Зарифның аяклары арасына керде дә мизгел эчендә аны җиргә алып сылады. Менә сиңа мә! Бер мизгелгә авыл халкы өнсез калды. Мәйдан өстендә чебен очканы ишетелерлек тынлык урнашты. Шул тынлыкны ертып, баягы картның шат тавышы ишетелде:

– Ма-ла-дис!

Шуннан барсы да кинәт һушына килгәндәй, кабатларга тотындылар:

– Зариф! Зариф!

Башка авыл кешесе бу юлы да Зариф янына килеп кулын бирде, аркасыннан кагып куйды.

– Хәрәмләште! Яңадан көрәшсеннәр! – дип кычкырды кемдер. Мәйдан тирәли тыгыз боҗра хасил итеп баскан әшнәләр төркеме күтәреп алды:

– Яңадан! Яңадан!

Тавышлар гайрәтле булса да, бөтен авыл шаулашмады хәзер. Кемнәрдер

икеләнә иде бугай. Ләкин судьялар халык фикеренә каршы төшмәделәр. Батырларның кулына кабат сөлге тоттырдылар.

Башка авыл кешесе бөтенләй әлсерәгән кебек тоелды. Шул кирәк иде аңа. Белсен иде үз урынын. Читкә китеп әлләкем булырга тырышып йөрмәсен. Авыл кешеләренең күңелендә өмет уты кабынды. Быел да үзләренең батыры җиңеп чыгачак. Бу кадәр хәлсез көрәшчене хәзер теләсә кем җиргә алып сылый ала. Судьяларга да тел тидерерлек түгел инде, үзләренең эшен яхшы беләләр. Халык та бердәм. Менә шундый бердәмлек белән үзеңнекеләрне яклаган очракта бернинди чит дошман да куркыныч түгел. Бер-береңөчен шулай терәк булып яшәргә кирәк. Бердәмлектә көч дип юкка гына әйтмәгән инде борынгылар.

Менә шундый ләззәтле уйларга бирелеп, «Ура!» кычкырырга җыенып кына торганда, башка авыл кешесе Зарифны күтәреп алды да аркасы белән җиргә салды. Кинәт. Моның ничек килеп чыга алуын Зариф үзе дә аңламыйча калды бугай, чалкан яткан җиреннән торып утыргач та, тирә-ягына каранып, аптырап озак кына торды. Аннан соң башын чайкап куйды да сөлгесен кабат кулына урап, мәйдан уртасына чыкты.

– Яңадан көрәшсеннәр! – дип шаулаштылар мәйдан тирәли баскан кешеләр. – Яңадан! Яңадан! Яңадан!

Тавышлар сыеграк ишетелсә дә, судьяларга карар кабул итү өчен җитәрлек иде. Алар үзара сөйләшеп алдылар. Икенче мизгелгә багана башындагы тавыш көчәйткечләр дөньяны яңгыратты:

– Хөрмәтле авылдашлар! Һәммәгезне дә көрәш мәйданына чакырабыз. Иң хәлиткеч мизгелләр башлана. Сабантуй батыры өчен иң хәлиткеч, иң соңгы алыш…

Һәм алар батыр калу өчен дәгъва кылган ике көрәшченең дә исем-атын яңгыраттылар. Халык җиңел сулап куйды һәм мәйданга төбәлде. Бу юлы артык шаулашмадылар. Соңгы алыш булгач, аның һәр мизгелен күреп калырга кирәк шикелле тоелды. Хәтта мәйданны чолгап алган төркем дә бераз таркала төшкән кебек булды. Алар да кычкырышудан туктап, мәйданга текәлделәр.

Ике батыр бер-берсенә каршы басып бил алышырга әзерләнде. Зариф бар булмышы белән үз эченә чумган, бөтен көчен, бар белемен бер ноктага туплап, соңгы алышны җиңү белән тәмамларга әзерләнә кебек иде. Ә Харис ул кадәр үк җитди түгел, ул кара чалбарының уң балагын уалап алды да тураеп басты һәм сизелер-сизелмәс елмаю белән кулындагы сөлгесен җайлый башлады. Нәкъ шул вакытта тынлыкны ертып, ачы итеп кычкырган хатын-кыз тавышы ишетелде:

– Тукта! Нишлисең син, чатан тәре!

Халык бер мизгелгә генә шул якка карап алды да мәйданга төбәлде. Судья инде көрәшкә әмер биргән, батырлар бер-берсенең биленә сөлге салып, акрын гына әйләнә башлаган иде. Әлегә артык тарткалашмыйлар да, икесе дә көндәшенең сизгерлеген җуйган чагын көтеп, сабыр гына җай эзлиләр. Ә халык тын да алмый күзәтә. Кычкырышучылар да тынып калган, чөнки барсы да сизеп тора: бу – иң соңгы, иң хәлиткеч алыш. Көрәшне моннан да артыгракка сузу мөмкин түгел.

Хатын-кыз тавышы тагы кабатланды, тик аңа игътибар итүче табылмады. Ләкин мәйдан тирәләп баскан кешеләр чылбырын ярып, теге хатын көрәшчеләр янына бәреп керде:

– Тагын качып киткән… Аңламагач, аңламыйсың инде син, ә! Кирәкми миңа синең көрәшең, кирәкми батыр калуың. Миңа синең исәнлегең кирәк… Үзең кирәк! Харис, димен, ишетәсеңме мине?

Уртача гәүдәле ханым көрәшчеләр арасына керергә җай эзләп, кычкырына-кычкырына, алар тирәли әйләнә башлады. Читкәрәк алып китәргә дип, терсәгеннән тоткан судьяны читкә этеп җибәрде дә ниндидер җай туры китереп, Харисның ботларыннан эләктереп алды:

– Тукта, җаным… Үтенәм!

Бу көрәшчеләрнең кискенләшеп киткән мизгеленә туры килде. Башка авыл кешесе сул аягы белән авыл батырының тез артына керергә омтылды, тик уң аягыннан кемдер эләктереп алуын тоеп тыелып калды, бер мизгелгә игътибарын җуйды, ә ул арада Зариф үзе аның аяклары арасына кереп күтәреп алды да көндәшен җиргә чөйде.

– Хар-рис! – дип кычкырды хатын, бар гәүдәсе белән аның уң аягына асылынып. – Тукта!

Тик соң иде инде. Хатын бер мәлгә иренең аягына ияреп өскә күтәрелде дә кинәт ычкынып китеп лап итеп җиргә барып төште. Әмма шундук сикереп торды да мәйданда чалкан яткан ире янына ташланды, тик кулыннан нидер төшеп китеп аякларына бәрелде. Хатын аны тиз генә күтәреп алды да бер мәлгә исәңгерәп калды. Коты очып кычкырып җибәрде. Аның кулында сыңар аяк иде. Иренең уң аягы…

Харис яткан җиреннән тиз генә сикереп торды да титаклый-титаклый хатыны янына килеп, аның кулындагы протезны алды. Икенче кулы белән хатынын кочаклады. Хатыны бер мизгелгә аңа сарылды да кинәт читкә тайпылып, йодрыклары белән аның күкрәген төяргә тотынды:

– Көрәшмисең бүтән беркайчан да… Ярамый бит сиңа… Ярамый, аңлыйсыңмы! Мең үлемнән калган кеше бит син… Нүжәли Сабантуй көнне мине тол итәсең килә, ә!.. Яратмыйм сине, күралмыйм!.. Кайда кадәр качып китсәң дә, табачакмын. Син кирәк миңа. Сабантуй батыры түгел…

Харис хатынын назлап кочаклап кына, якындагы утыргычка утыртты да тегесе бераз тынычланып, өс-башын төзәтә башлагач, протезын киеп куйды. Тирә-юньдә бар нәрсә дә тынып, бер мизгелгә тукталып калган кебек иде. Беркем бер сүз әйтмәде. Бер хәрәкәт ясамады. Көрәш башланганнан бирле кычкырышкан кешеләр дә, судьялар да тынсыз калып, шушы икәүне күзәтте.

Соңгы иң хәлиткеч алышта җиңелсә дә, Харис бар булмышы белән балкый иде. Ул тирә-якны күздән кичерде дә сизелер-сизелмәс кенә баш иеп куйды. Һәм әле булса тиргәшүдән туктамаган хатынын кочаклап, мәйданнан чыгып китте.

– Хәтта бүләген дә бирмәдек… – диде бераздан баягы карт. – Башка авыл кешесе дигәч тә…

– Әйе, бүләген бирергә кирәк иде, – дип җөпләде кемдер.

– Батыр  инде бу, чын батыр…

Тик Харис күздән югалган иде инде. Аңа Сабантуй батыры булу да, бернинди бүләк тә кирәкми, ул үзенең көрәшә алуы белән бәхетле иде. Һәм шундый якты мизгелләр бүләк иткән көрәшчеләргә, авыл халкына чиксез рәхмәтле иде.



Фәндидә
Харрасова

# КҮРЕЛМӘГӘН ЮЛНЫ КИЧКӘНДӘ

*Ленинград блокадасын өзүгә 80 ел тулуга багышлана*

ПОЭМА

*СССР Дәүләт оборона комитетының 1942 ел 25 мартында чыккан 1488 санлы карары нигезендә, белеме 7-8 класстан да түбән булмаган 19 яшьтән 25 яшькәчә булган йөз мең комсомолканы Һава һөҗүменә каршы оборона гаскәрләре сафына хәрби хезмәткә чакыралар. Ай ярымлык курслардан соң шуларның алты меңе Ленинград фронтына җибәрелә.*

Архив мәгълүматларыннан

*Дорогой жизни шёл к нам хлеб,*
*Дорогой дружбы многих к многим.*
*Ещё не знают на земле*
*Страшней и радостней дороги.*

Ольга Берггольц

***

Терсәкләнеп чыклар яра-яра
Шуышабыз. Сызылып таң ата.
Көндезләрен кояш, ә төннәрен
Юлдаш булып безгә ай калка.
Алтмыш чакрым! Әйтү генә җиңел –
Барасы да әле барасы...
Болар гади чакрымнар түгел,
Яшәү белән үлем арасы.
Баштан сыйпап үткән җәйге җилкәй
Ялан иңләп, алга җилдерә.
«Ауга» чыккан «Рама» утыннан да,
Ул бик җәһәт качып өлгерә.
Ә без исә башны ия төшеп
Төртеләбез сусыл үләнгә.
Яшел болын хәлгә кергән кебек
Яшереп тора безне бер мәлгә.
Төркем башы тешен кыса биреп,
Үзалдына гына үртәнә:
«Сизенгәннәр, сагалыйлар, каһәр,
Кабат төнне кирәк көтәргә...»
Онытылган, бүген мин бәгъзеңә,
Унсигез яшь тула ләбаса,
Янәшәмдә генә барган Вера
Мине тәбрик итеп кул кыса.

Фәндидә ХАРРАСОВА (1954) – *шагыйрә, Башкортстанның атказанган матбугат һәм мәгълүмат хезмәткәре; «Тормыш кайтавазы», «Фазыйләтем – минем асылым», «Сандугачлар таңны уяткан мәл» һ.б китаплар авторы. Башкортстанның Кушнаренко районында яши.*

Вера белән күптән түгел генә,
Курсларда чакта таныштык.
«Сугыштан соң очрашырбыз», – диеп,
Адресларга тиклем алыштык.
Сеңлесенә охшатып ул мине
Сөеп куя кайчак аркамнан.
Дустым күңеле хушланганын күреп,
Сабый кебек мин дә шатланам...
Унтугыз яшь аңа. Шомырт-кара күзләр,
Зифа буй-сын, толымы – аркан!
«Типтәр каны бардыр синдә», – диеп
Сүз аралаш мин дә шаяртам.
Иң өлкәне – Зоя. Егерме яшь.
Төркем  башы. Безнең  командир.
Без шуышып үтәр чакрымнар,
Безгә ят та, аңар – туган җир.
...Комсомолың хак көрәшкә дәшкәч,
Базнат итеп кем соң карышсын,
Нәфис кулларыбыз үзләштерде
Сугыш коралының барысын.
Угланнарын алгы сызыкка ук
Дәшеп алгач Ватан-Анабыз,
Без кыз-кыркын – угланнарга алмаш,
Ленинградка менә барабыз.
Шофёр да без, санинструкторлар  да,
Телефонист, радист, сапёр да...
Сайланмадык, сугыш таләп иткән
Һөнәр чөнки болар  барысы да.
Аэростатлар белән эш итәчәк
Кызлар гына бераз һавалы.
Кораллары гади генә түгел,
Ә гелийлы һава шарлары.
Өч мең метр биеклеккә кадәр
Күтәрәчәк кызлар аларны.
Аэростатлар фашист бомбасыннан
Саклаячак мәшһүр каланы.

*15 июль, 1942 ел.*

***

«Мессер»ларның үкерә моторлары,
«Вульф»лары җирне каезлый,
Ышыкланыр урын  табалмыйча
Яныбызга  ятып, җил  елый...
Бу мәхшәрдә тетрәнүдән бигрәк
Чарасызлык җанны  актара.
Илбасарның «Эрика»сын  көйләп,
Гарасат тик кора тантана.
Тантанага куәт бирә әҗәл,
Камилләшкән аның коралы.
Чалгы асып йөрми ул хәзер,
Җанны кыя ядрә, нибары...

*17 июль, 1942 ел.*

***

...Иртә таңнан фашист очучысы
Корбан эзләп тәмам азынды,
Һәр тибрәнгән үлән, куакка ул
Бертуктаусыз кургаш яудырды.
Җиргә сеңәр булып елышабыз,
Чытырдатып йомам күземне,
Әбкәемнең догаларын укыйм, –
Ничек саклыйм тагын үземне?!
Алда кинәт нидер гөрселдәде
Һәм утлы шар балкып шартлады,
Шул мәл Вера миңа ыргытылып,
Үз гәүдәсе белән каплады...
Чалгы кискән болын чәчәге күк
Актарылган кара туфракка
Кыелып төште аннан... Тимер ярчык
Телгәләгән тәннән кан сарка.
Гомер бирәү, әмма яу кырында
Ничә гомер бергә үрелә,
Үрелә дә, берсе берсен аяп,
Каршы чыга шулай үлемгә.
Югалтулар йөрәк аша уза
Һәм сызыла бара бәгырьгә:
Ут эчендә туган аркадашлык
Туганлыктан якын – гомергә!
Яңа көнем – Вера озайткан гомер!
Ул әйтерсең һәрчак янымда.
Алкымыма яшьләр тыгыла һәм
Дошманга үч кайный канымда...
Бишенчебез инде һәлак булды,
Телмәрләрсез генә хушлаштык,
Исемнәрен сиңа тапшырабыз
Елъязмаңа теркә, әй, вакыт...
Шуышабыз, җил дымлана төшә,
Димәк, якын Волхов елгасы.
«Тиздән Кобона, – ди Зоя  шулчак, –
Бер төн генә кала барасы...»
Кобона ул – авыл. Камаудагы
Кала белән бәйли Ватанны.
Утыз чакрым булган шушы ара
«Яшәү юлы» диеп  аталды...
Без, ниһаять, менә Ладогада –
Ленинградның капка төбендә.
Күл биредән караганда никтер
Диңгез кебек шомлы күренә.
Ни үкенеч, табигатьтә инде
Хозурланыр ямьнәр сүрелгән.
«Яшәү юлы» дигән кичүдә без
Санинструкторлар бүгеннән.
Әбкәм әйткән сират күпере дә
Кичү белән бугай бер очтан.

Тик монысы инде дөньялыкта –
Кылдан нечкә, үткен кылычтан...
*20 июль,1942ел.*

***

Паром, баржаларда күлне иңләп,
Бәйләдек без каршы ярларны.
Илдән, мирдән килгән икмәк белән
Ач калага гомер ялганды.
Икмәк килү берчак тоткарланды,
Фашист ала дигәч каланы,
Тәү чиратта завод, техниканы
Ил түренә озату каралды.
Әмма ачлык тоткарлана белми,
Үз корбанын көн дә чүпләде.
Ул корбаннар кара исәп белән
Биш йөз меңгә җитте бер мәлне...
Икмәк хәстәрләде кала үзе,
Кул кушырып көтеп тормады.
Кырлар исе аннан килмәсә дә,
Җир җылысы аңа сеңмәсә дә,
Ул Әҗәлдән безне йолалды...

...Эшче куллар кирәк булгач бардык
Пекарняга без дә ярдәмгә.
Авызыңа алмас нәрсәләр дә
Бара икән кайчак тәгамгә.
Кәгазь ясый торган целлюлоза,
Обой ябыштырыр он, тагы
Эшкәртелгән ылыс сыгынтысын
Куша-куша камыр тугланды.
Юктан шулай барны булдырганчы,
Җан тирен дә, әйе, күп түктек.
Тамак, диләр, тәмугка да кертә.
Без тәмугка тәмам күнектек...
Төн үткәргәч таңнан юнәләбез
Ладогага – «Яшәү юлы»на.
Җиңү көне килер дигән өмет
Әлегә тик җанда җылына.
Гарипләнгән кала, җимерек йортлар,
Нева яклап салкын җил исә.
Аямыйдыр сугыш, төпкә җигә.
Нәфис затлар идек югыйсә...
Хәлсез картлар, чандыр яшүсмерләр
Икмәк өчен чират тезелгән.
Үлем белән яшәү арасында
Барган алыш түгел җиңелдән...
*2 август,1942 ел.*

***

Нинди көй бу? Әсәрләндек кинәт,
Иелгән баш артка чөелде.
Әҗәл булып Әҗәл аптыраштан
Туктап калды, ахры, чигенде.
Моң авазы гүя ташкын булып
Ялмап алды чиксез җиһанны,
Онытылды кебек ачлык, михнәт,
Өмет  уты җанда уянды.
Тетрәндереп җанга кагылды ул,
Күзләрдәге яшьне сөрттерде,
Юк, без юкка чыгар халык түгел,
Рухыбызны имләр көч инде!
Җимерелсә дә кала, тез чүкмәде,
Угъланы бит чыккан алышка,
Бу җиденче симфония, тыңла(!),
Ләгънәт укый канлы сугышка.
Газаплардан туган тантанадыр
Бүген шулай канат кагына.
Шостакович, синең әсәрең бит
Тәүге адым җиңү таңына!
Репродукторлардан агылган моң
Чыккан бит ул безнең күңелдән,
Шатлык тулы аваз – кичәге көн,
Нәфрәтле өн исә бүгеннән...
«Сират  күпере»н инде җырлап кичтек,
Яңгыратып көрәш җырларын.
Йөзен ачкан кояш юлыбызга
Озата барды сибеп нурларын.
Мондый симфония тынып калмас,
Сискәндерер гамьсез Җир шарын.
Ут эчендә яратылган моңга
Киртәләр ул юктыр, мөгаен...
*9 август, 1942 ел.*

***

Иртә таңнан репродукторларда
Ольга Берггольцның тавышы:
Аның чыгышында чал каланың
Тын алышы, йөрәк кагышы...
«Ленинградка яный һәлакәт,
Төн йокысыз, көнен ут йотып,
Курку, ялварулы күз яшенең
Нәрсә икәнен без оныттык...»
Таня Савичева көндәлеген укып
Ишеттерде шуның өстенә:
«Үз кайгың, ди, чигеп, гаип була,
Бәла килгәч илең өстенә.
Бала күңеле дә моны аңлый,
Ни күрсә дә, инде ул түзә...
...Ятимнәрне тылга озатабыз,
Дулкыннарда баржа талпына.
Тәрбияче кызкай ана коштай
Барсын җыйган канат астына.
Уттан чыккан нәни кошчыкларның

Канатлары, ярый, көймәгән,
Тик кечкенә шушы йөрәкләрдә
Күпме михнәт, газап төйнәлгән.
Иң кечкенәсенә бары өч яшь –
Саша җимерек йорттан табылган,
Тәрбиячесенең итәгенә
Сабый ике куллап, тагылган.
Итәкне ул таянычы күрә,
«Әни» диеп, ахры, сыена,
Анакае соңгы сулышында
Алган булган улын куенына...
Игезәкләр әнә: малай һәм кыз,
Ап-ак берет киеп алганнар.
Җитәкләшкәннәр дә моңсу гына
Дулкыннарга карап баралар.
Дүрт-биш яшьлек бер кечкенә кызчык
Алар белән баскан янәшә,
Башкаларда аның кайгысы юк,
Ул – курчагы белән сөйләшә.
Башкалары – хәлсез нарасыйлар
Изрәгән сәер тынлыкта,
Тибрәндерә биреп сабыйларны
Безнең баржа алга юл тота.
Һәркайсының язмыш аянычлы,
Түгеләсе яше түгелгән,
Ил өстенә килгән афәт яше
Күренми ул, саркый күңелдән.
Ул яшь, әйе, ядрәдән дә хәтәр,
Ачы ләгънәт булып бу чакта
Ватан угланына кодрәт өсти,
Илбасарның рухын какшата.

...«Яшәү юлы» якын ара түгел,
Таң сызыла, шөкер, төн үтте,
Дулкын чайпалуын баса төшеп
Ишетелә шомлы гөрелте.
Шлиссельбург яклап, күкне каплап,
Килеп ята фашист өере –
«Мессершмитлар»! Безнең кызлар тизрәк
Пулемётларына йөгерде.
Сызгырышып төшкән бомбалардан
Күлнең төбе күккә эленде,
Кыя кебек күтәрелгән ташкын
Безне йомычкадай чөерде...
Бәргәләнгән сабыйларны шул мәл
Көчле дулкын ярсып ялмады,
Су өстендә ак беретлар белән
Уенчыклар йөзде аннары...
Агач баржа сык(ы)рана торгач,
Дулкын сыртын кармап утырды
Шуны гына көтеп торганнардыр –
Рамалар «эшкә» тотынды.
Мондый вәхшилектән дулкын янә
Күтәрелә биреп шашынды,
Палубада ятып калганнарны
Кочып алып, күлгә ташыды...
Сабыйларның җансыз гәүдәләре
Каплап алды тоташ су өстен...
Кешелекнең йөзен каралтырлык,
Чал тарихка керер канлы көн...

*12 сентябрь, 1942 ел.*

***

«Мәрзия, дим, кызым, йә, тор инде!
Соңга каласың бит мәктәпкә!»
Әни тавышы бу. Көн дә иртән
Ул уята мине, гадәттә...
«Әни, синме? Әни, син исәнме?» –
Куанычым сыймый эчемә!
«Мәрзия , йә, уян!» – кемдер шунда
Мине күктән җиргә төшерә.
Күзем ачсам – дустым Камәрия
Сөртеп тора яшьле күзләрен:
«Өзгәләнеп әниеңне дәштең,
Еладым, – ди, кызый, түзмәдем».
Әниләрен барысы сагыналар,
Хат язалар аннан бергәләп.
Миңа гына инде хатлар килми,
Көннәр үтә җанны телгәләп...
Әбекәем вафат, җир куенында
Фаҗигане, ярый, күрмәде.
Гомере буе бәндәләргә бәхет,
Имин тормыш, саулык теләде...
Әти һәлак булгач әни көйде:
«Минем урын, диде, фронтта».
Курсларга озаткач та, ашыгып
Китеп барган тизрәк, мин юкта.
Ул хирург иде, алтын куллы!
Кирәк алар монда, аңлыймын...
Ни үкенеч, бүген минә бары
Истәлекләремне барлыймын.
Курскидан килде соңгы хаты,
Җан өшеткеч хәбәр соңыннан –
Әниләрнең госпитален фашист
Утка тотып, көлгә очырган.

Ышанмый тик күңел барыбер,
Юаткандай төшкә керә гел.
Казармада тынлык. Кызлар йоклый.
Кояшлы көн әле тумаган.
Кызчыкларны шундый авыр сынау
Көтәдер дип кем соң уйлаган?!

*5 октябрь,1942 ел.*

***

...Дулкын килә өскә кыя кебек.
Менә-менә ялмап алачак.

Ак күбеккә ярсып төрә-төрә,
Упкынына мине салачак.
Йа Ходаем, зинһар, коткар мине
Әбкәм догалары хакына!
Дулкын шиңә, чигә-чигә минем
Чәчләремне тарый сак кына...
Күзем ачам, ак халатлы апа
Басып тора минем янымда,
Көлемсерәп баккан күзләрендә
Якты көннең яме чагыла.
«Сөбханалла! Кайттым дисең инде?»
«Сез кем, апа, кайттым мин кайдан?»
«Гаҗәп түгел, һушсыз яттың бит син,
Кайттың, сеңлем, теге дөньядан...
Маладис син, күпме баланы бит
Газраилдән алып калгансың!
Кочагыңа алып нәниләрне
Палубага, диләр, аугансың.
Ядрәләрдән тишкәләнгән идең...
Бала гына бит соң үзең дә.
Бу каһәрең бөреләнеп килгән
Чәчәкне дә утта көйдерә...
Маша түти булам. Санитарка.
Госпитальдәсең син, гүзәлем!
Әҗәл белән бер ай алыштыгыз,
Күз ачуыңа шундый кинәндем».

*10 ноябрь, 1942 ел.*

***

...Ул мәхшәрне онытырлык түгел,
Күз алдында тора бүген дә.
Шартлаулар һәм елау, ыңгырашу
Кайтаваздай колак төбендә...
Балаларны ул көн Кобонага
Озатырга кичен кузгалдык.
Төнгә каршы дошман күзенә бик
Чалынмабыз диеп юрадык.
Күрми буламы соң, күлне алар
Тәүлек буе айкап торалар...
Өскә яуган бомба «яңгыры»ннан
Ладогада купты туфаннар...
Катер батты, безнең мескен баржа
Зилзиләнең калды иркендә,
Уңга-сулга атып бәрә-бәрә
Ташкын аны йөртте типкендә.
Янәшәдә генә шартлады ул,
«Ятыгыз!» – дип, алга ыргылдым.
Балаларны кочагыма алып,
Палубага, әйе, егылдым...
Утлы кисәү өтеп алдымыни,
Аркам буйлап әрнү йөгерде,
Сорау телеп үтте зиһенемне:
«Чү! Һушымны җуям түгелме?»

...Таң атканда, ярый, катер килгән,
Кемгәдер «SOS» безнең юлыккан,
«ЯК»лар килеп исә, «Мессер»ларның
Арт сабагын, диләр, укыткан.
Бу фаҗига бер күренеш кенә,
Ә гаскәр бит өч ай алышты;
Камалышны өзмим диеп, дошман
Аяк терәп, шактый карышты.
Кырып салып халкын, каладан ул
Чүп өеме ясап куймакчы.
Җәһәннәмгә әверелдереп күлне,
«Яшәү юлы»н тәмам җуймакчы...
Илбасарның саранчадай явы
Туктатмасак ары китәчәк,
Артыннан тик күмер, көл калдырып,
Уралыма барып җитәчәк.
Мондый фаҗигане күз алдына
Китерәлмим хәтта мин бүген;
Сөеп баккан газиз җиркәемне
Фашист итекләре изүен.
Горур Урал, тау-далалар иле,
Салаватның изге төяге,
Ватан өчен гомерең фида кылу –
Безгә аның көрәш үрнәге.
«Туган җирем, бирче миңа кодрәт!
Ил ярасын кирәк имләргә,
Париж алган бабаларым рухы
Дәшә миңа: «Мен, ди, иярге!»
Чал гасырлар аша эндәшәмен:
«Әй, Салават, бирче кылычың,
Селтәним бер, җирдә җан кыючы
Илбасарның тамыры корысын.
Ил батыры шунда аваз сала:
«Сугыш бит ул – сезнең эш түгел,
Бала багу, нәсел дәвам итү
Бурычыгыз сезнең, бел, сеңел!»
«Юк, – димен мин, – безне ил чакырды:
«Басыгыз» дип, көрәш сафына!
Гомерләрен корбан итте кызлар
Җирдә яшәр дәвам хакына...
Бик еш кына шулай күңелемнән
Сүз юллыймын яугир угъланга.
Аның рухы – безнең тамырларда,
Һәр алышта шул рух уяна...

*15 ноябрь, 1942 ел.*

***

Буйсындыралмассың, бел син, фашист,
Ни күрсәк тә димен, чыдармын,
Кулым әгәр корал тоталмаса,
Тешем өзәр чәйнәп бугазың,
Рухи тәгам, сулар һавага тиң
Җан бишеге илнең бу кала.

Фашистларга әгәр бирсәк аны,
Ил-Ватаннан безнең ни кала?!
Ил язмышы, халкым киләчәге
Бүген менә безнең кулларда,
«Эх, яшисе иде, яшисе» дип,
Йөрәк кенә әрнеп сызлана..

*20 ноябрь, 1942 ел.*

***

Университетның тарих факультеты
Бинасы да – дәва учагы,
Гыйлем түгел, гомер эсти монда
Хирургның ялтыр пычагы.
Фәнгә хезмәт иткән апакайлар
Китмәгәннәр, һәрчак янәшә,
Без – сызланып яткан кызчыкларга
Җан җылысын шулар өләшә.
Юа алар, җыя, дәвалый да,
Кирәк икән – тора кизүдә,
Сезне сафка бастыралсак, диләр,
Өлешебез керер җиңүгә.

*1 декабрь, 1942 ел.*

***

...Саташулы көннәр белән төннәр
Әкренләп артка чигенә,
Тәрәзәләр инде суык бөркә,
Кыш сулышы җирдә сизелә.
Палатада бишәү, мин – алтынчы.
Ут эченнән алар бары да.
Янәшәмдә Нина атлы кызкай,
Маша түти һәрчак янында.
Хәле авыр, бик еш ыңгыраша,
Күкрәгендә икән ярасы.
Яу кырында ауган. Санитарка.
Ул – кичәге мәктәп баласы.
Шомлы булды ул төн, иртәгесен
Хәлен белим дисәм – ни күрәм!
Җан тетрәнгеч: һушсыз яткан кызның
Бармакларын күсе кимергән.
Маша түти яшен сөртә-сөртә
Бармакларын бәйли Нинаның:
«Азга гына ташлап киткән идем,
Кай арада булды бу, җаным...»
Аннан инде башын кага биреп,
Раслап куя: «Кирәк мәчеләр!
Бер чара да инде ярдәм итми,
Үрчегәннән болар, үрчиләр...
Күсе нәрсә, адәми зат бүген
Үз кавемен ашый, чирканмый,
Һушым китте күреп, кичә берәү
Урам мәетләрен ботарлый.
Күсе мәлгунь исә тәмам азды,
Тереләргә хәзер уктала.
Өерләре белән йөриләр бит,
Трамвайлар хәтта туктала...
Тәнне кинәт калтырану алды,
Күсе өере... мәет ашыйлар...»
Әкияттәге явыз персонажлар
Күз алдыма килеп бастылар...
Агарындым бугай, Маша түти
Күз салгач та хәлгә төшенде,
Сүзне кабат мәчеләргә борды:
«Яңалык, – ди, – шундый иш(е)телде,
Имеш, бер эшелон мәче килә,
Ярославльдән үк калага.
Безгә дә, дим, бер әмәлен табып
Кирәк берсен алып калырга».

*5 декабрь,1942 ел.*

***

Югалтабыз, һаман югалтабыз...
Нина белән бүген хушлаштык.
Маша түти күзен сөртә-сөртә:
«Пискаревка, – диде, – озаттык».
Сирәгәя шулай сафларыбыз,
Ишеттем мин әле тик кичә,
Һәлак булган безнең Зоябыз да –
Төркемебездән калдык берничә...
Тудык, үстек, яшәп өлгермәдек...
Утта көеп туа иртәбез.
Килер көндә без – югалган буын,
Бер-бер артлы, менә, китәбез...
Истәлекләр калсын! Көндәлеккә
Хәтеремдәген шуңар барлыймын,
Тарих битләренә һәммәсе дә
Кереп бетмәс чөнки, аңлыймын.
Дөньялыктан югалсак та, телдән
Җуелмабыз диеп ышанам.
Эх, күрәсе иде җиңү таңын,
Туар бит ул җиргә бер заман?!
...Яз булыр ул... Күкрәк киерә биреп
Җиңүчеләр кайтыр авылга...
Сыйныфташлар кайталмаганнарны
Искә алыр басып табында...
Алмагачлар шау чәчәктә булыр,
Дим буйлары ямьгә күмелер,
Кайгы сөремнәрен йөздән юып,
Шатлык яше генә түгелер!
Кыр күршебез Зифа апа исә
Мине уйлап, авыр көрсенер,
Кайтмагачтын Илшатына инде
Башка йорттан килен төшерер.
Тормыш матур булыр, ышанам мин,

Шуның өчен бит кан түгелә!
Шул бәхетле иртәгәсе өчен
Бүген күпме гомер өзелә...

*20 декабрь, 1942 ел.*

***

Шөкер, инде аякка да бастым.
Йөреп кердем бүген урамнан.
Кыш та быел зәһәрләнеп килгән,
Дошман кебек, ала бугаздан.
Җимереклекләр инде бик күренми,
Кар астында калып баралар.
Җаннардагы җәрәхәтләрне дә,
Булса икән җуяр чаралар...
Дәва курсың беткәч – тылга, диеп,
Табиб беркөн хәбәр җиткерде.
Карышачагымны белгәнгәме –
Яңгыратты сүзне кискенле:
«Сыңар үпкәң күпкә түзәр, димә,
Сулый-сулый дары төтене».
«Юк, китәлмим, – дидем, – дошманнан мин
алалмадым әле үчемне.
Атам, анам өчен, һәлак булган.
Яшьлек өчен – канга батып туган,
Кызлар өчен – кырда ятып калган,
Ленинградны яклап башын салган!
Үч кандырыр, беләм, һәр көнне
Көтә мине «сират күпере».

*25 декабрь,1942 ел.*

***

Хушлашабыз соңгы көне белән
Үтеп барган елның, бигайбә.
Алышларың, сагышларың белән
Тарих битләренә күч әйдә!
Чәй табыны әзерләгән булдык
Өләштеләр ирис кәнфите,
Яңа елның бәсен күтәрергә
Шул кәнфит тә безгә бик җитте.
Ильич лампалары тоткарлыксыз
Уникегә тиклем сүнмәде.
Таң алдыннан янә ишетелде
«Мессер»ларның каты гүләве...
Ленинградның мәшһүр сарайларын
Бу вандаллар юкка чыгарган.
Эрмитажның җимерек залларында
Куыш уйный җилләр бу заман.

*31 декабрь-1 гыйнвар,1943 ел.*

***

Ярославль «аучылары» килгән,
Дигән хәбәр таңнан таралды.
Ярославльдән үк? Нинди аучы?
Беркем берни аңлый алмады.
Маша түти килеп кергәч кенә
Ачыкланды кебек барсы да,
Кочагыннан аның соры мәче
Сикереп төшеп баскач каршыга.
«Йә түрдән уз, әнә апаларың,
Дошман һөҗүменнән сакларсың,
Сунарчылар нәселеннән бит син,
Ышанычны, димен, акларсың!»
Маша түти сөйләгәннәр, ахры.
Сорыкайга барып иреште,
Биләмәсен туктап исни-исни,
Кәсебенә шундук керешге.
Төне буе бездә «алыш» барды,
Ырылдау һәм чинау тынмады.
Кая йоклау, кызлар беребез дә
Кымшанырга хәтта кыймады.
Бугазланган күселәрне «аучы»
Өйеп куйган ишек төбенә.
Безне яклар, саклар көч табылгач
Тынычлана төште күңел дә.

*5 гыйнвар, 1943 ел.*

***

«Дүрт аяклы хәшәрәтне җиңдек
Чират – ике аяклысына!
Маша түти соңгы хәбәрләрне
Җиткермәкче бүген бар(ы)сына:
«Ленинград, Волхов фронтлары
Камалышны икән ермакчы,
Һөҗүм өчен көч туплыйлар, имеш,
Дошманнарны ерак кумакчы.
Түземсезлек белән көтеп алдым
Обход ясап йөргән докторны.
Сергей Ильич мине тыңлагачтын
Башын чайкап бераз тын торды:
«Күрмәгәнне тизрәк күреп калыйм,
Дип ашыгасыңмы? Ярый соң,
Выпискаңны мин әзерләп куям,
Төш узгачтын кереп алырсың...»
Бүген менә юлга җыенамын,
Бар(ы)сы белән инде хушлаштык.
«Камәрия көтә мине, кызлар,
Ладогада кышкы юл ачык...»

*10 гыйнвар, 1943 ел.*

***

«Автобус бар, «полуторка» әнә,
Сайлау мөмкинлеге бар сиңа...»
Коменданттан озак кыстатмадым,
«Полуторкага, дим, мин риза».

...«Сират күпере»ндә тукталыш юк,
Боз юрганы тетрәп торган чак.
Юлдан әгәр ялгыш тайпылдыңмы –
Талымсыз күл сине йотачак.
Тайпылганны үзең сизмисең дә,
«Рама»лар куып килгәндә,
«Полуторка»ң белән убыласың,
Котылырга юк бер әмәл дә.
Юлы озын, вакыт кыска монда,
Сынау аша синең һәр көнең,
Озайтабыз яшәү сәгатьләрен –
Каланың һәм илнең гомерен.

*11 гыйнвар, 1943 ел.*

**Ахыр сүз**

Әбекәй аны кулдан төшермәде,
Укый иде кайчак безгә дә,
Дускаеңнан калган истәлек ул
Кадерледер, беләм, кемгә дә.
Хәле авырайгач беркөн әбекәм,
Дәшеп алды мине янына:
«Гозерем бар, – диде, – син, Гөлсара
Ленинградка тиеш барырга.
Кала тарихының музее бар,
Тергезелде бугай, ачылды.
Бу хакта бит үзең хәбәр салдың,
Гәзиттә дә бугай, басылды.
Мәрзиянең көндәлеген, кызым,
Шунда илт син, шунда урыны.
Тагын сиңа бер исемлек бирәм,
Төенчегем чишеп ал шуны.
Исемлектә, кызым, – безнекеләр,
Ленинградка җибәрелгәннәр.
Унсигездәгеләр, йә унтугыз –
Әле яңа пешеп килгәннәр.
Милләтнең бит күпме асыл кызы
Ватан өчен бирде гомерен.
Бүгенгәчә сау булсалар алар
Бизәр иде илнең иң түрен.
Исемлек зур, әйе, барысы да
Кала өчен салды башларын.
Исемнәрсез җирләнгәннәр хәтсез,
Мин – шуларның хакын хакладым...
Ладоганың төбен кабер иткән
Мәрзиямне яздым иң тәүдә.
Кемгә ярдәм кирәк, авырсынмый,
Ул җигелде һәрчак мичәүгә.
Күз алдымда тора кабинадан
Соңгы тапкыр кулын изәве...
Шул китүдән кире кайтмады ул,
Күл үзендә аны җирләде.
«Яшәү юлы»н кичкән чакта, кызым,
Кыенсынма, эндәш син аңа:
«Исемең дип, күңел түребездә,
Мәңге онытылмассың ил барда!
Ахирәтең Камәриянең дә
Сине сагынып үтте гомере.
Исемеңне әниемә кушкан
«Мәрзия»ле, диген һәр көне...»

***

Ни хәлең бар, шанлы Ленинград,
Инкыйлабның мәшһүр бишеге?!
Үзгәрешләр эзсез узмадылар,
Алышынды хәтта исемең.
Тик дәһшәтле еллар авазыдай
Җуелмас ул исем күңелдән,
Үткәннәрнең кадере арта төшә
Караганда вакыт үреннән.
«Яшәү юлы» аша килә̀м сиңа,
Камалышның салган эзеннән,
Әбкәм сөйләгәннәр бер-бер артлы
Калкыналар хәтер күзеннән...
Исбатлаулар монда кирәкмидер,
Дәлилләр дә – һәрбер әйткәнгә
Биредәге яшәү өчен алыш
Әверелгән бар да һәйкәлгә...
«Беркем онытылмый, бернәрсә дә!» –
Бергольцның шигъри юллары...
Кабер ташларына гына түгел,
Күңелләргә языйк без аны!
...Әманәтен үтәп әбкәемнең,
Мин музейга карап юл тоттым.
Гомер өзелсә дә – хәтер яши,
Уяулыкка өндәп ил-йортны...

Марат
Әмирханов

# ЯУГИРӘ

РОМАН

***

Тарих һижри 275 сәнә, ягъни милади белән 888 елның кышы искәрмәстән килде. Бердәнбер көнне таң алдыннан кипшенергә дә өлгермәгән җиргә куе булып кар ява башлады. Ява да ява. Фәкать офык читендәге өркәч тауларның гына бу хәлгә исләре китми, тәкәббер әтәчтәй элеккечә кукраеп утыруларын беләләр.

Кешеләр борчуда. Күпләр ашыга-кабалана, чатырларын җыярга тотынды. Мал-туар тотучылар гына икеләнүдә, бәлкем, җылытыр әле, җәйләү ачылыр дип, өметләрен өзәргә ашыкмыйлар.

Ходаем, рәхмәтеңнән ташлама!

Чиратсыз кыш исә кешеләрнең бу үрсәләнүләренә битараф, бернигә карамый тын гына үз эшен эшли бирә.

Бану бикәнең генә бу хәлләрдә гаме юк, аның үз хәле хәл. Менә өченче көн инде өч яшьлек төпчек кызы – җан алмасы, Хөсникамалы урын өстендә азаплана. Тәне ут кебек яна бәгырькәйнең, кипкән курадай коп-коры.

Апалары Хөснеруй да, Хөснеҗамал да хастасын сулышлары белән суырып алырдай булып, кибеп ярылырга җитешкән иреннәренә су тигезеп торалар.

Бану белән Ярмәк өч кызына да бердәй яңгырашлы охшаш исем сайладылар. Хөсне (хөсен) матурлыкка, күркәмлеккә ишарә.

Хөсен вә җәмал иясенә
Күп тәсадеф кыйлдым.

Дөрестән дә, бу нәни әһле мөслимәләр әти-әниләренә охшап, чибәр һәм ягымлы булып үсеп киләләр.

– Аһ... анаем... аһ...

Вакыт-вакыт ишетелгән бу хәлсез сыкрану Бану бикәнең йөрәгенә энә булып кадала.

– И Ходаем, үземнең җанымны гына алсаңчы...

– Бикә, тәүбә-тәүбә диген, бала үлеме токымны өзми, ана заты исән булганда, Ходай аңа икенчеләрен насыйп итә, – диде имче абыстай, – барысы да Аллаһы кулында, болай өзгәләнергә ярамый.

---

*Ахыры. Башы узган санда.*

– Бигрәкләр дә кызганыч бит...

– Чир ул, бикә, тән эчендә яшәүче тагын бер тән. Догаларыбыз булышлыгында безгә шул тәннең күңелен күрү, уртак тел табу лязим.

Ул хастаның баш очына басып, им-том шөгыленә кереште.

– Ак атлы булат кылычлы ап-ак ук садаклы ак күн кисә. Йомшак хаста кире кит, яман хаста кире кит. Кара булат кылычлы, кара ябынчалы, кара казак садаклы, кара күн кигән яман хаста кире кайтып кит. Без сиңа тимибез, син безгә тимә. Яхшылык илә үтенәбез, чык бу баланың тәненнән, чыксаң бу баланың тәненнән, ни теләсең, шул булыр. Чык-чык-чык!

Абыстай ошбу мөрәҗәгатен тоташтан тугыз мәртәбә кабатлады. Үзенә дә авырга туры килде, ахры, тирләп бетте.

Файдасы гына күренмәде. Аны табиб алыштырды, сырхау кызга төнәтмә эчерде. Аннан зыян гына килде, бикәч чак тончыгып харап булмады.

Тышта ак япмалы төн. Көзге тупламаларындагы вак мал тынычсызланыпмы-тынычсызлана, тилебәрән орлыгы ашагандай, бертуктаусыз башларын бутыйлар, йөткерәләр, кагыналар. Аларга сак этләренең чиный-чиный өрүләре кушыла. Шунда ук анасын сагынган ниндидер бер яшь бозау өзгәләнә.

Җиһан хәрәкәттә: һәр җан иясенең үз мәшәкате, үз борчулары.

– Аһ, анаем, аһ...

Ярмәк тә кайткан иде инде, кызын япмасына төреп, күтәреп алды да, көйли-көйли, ишекле-түрле йөрергә тотынды.

Ул яраткан Аллабызның расуле Муса Кәлим,
Кулына тотты таягын, өстенә килде келәм.
Тур тавында Хак сүзен ишетеп булды кәлим.
Хөрмәтең әйталам, мең телем кылсам телем.
Тумышында утка төште, чыкты аннан көймәде.
Ике рәт төште суга, булды сәламәт ул сәлим...

Йа, Раббым! Ма ля гайне рәәт вә ля... Күз күрмәгән, колак ишетмәгән могҗиза!

Хөсникамалның маңгаена, ниһаять, суырып алырдай булып көткән тир бәреп чыкты, япмасы да манма су булды...

Кар туктады. Хаста тәннең дә миһербаны килде, җылы урынын ташлап, китеп барды.

Хөсникамал тиз тернәкләнде. Инде өзелә, инде өзелә дип, куркуга төшкәннәр иде бит. Аллаһы боерса, озын гомерле булыр.

Бану бикә сөенеченнән күпләп-күпләп сәдака өләште, мохтаҗларга ризык, кием-салым таратты.

Ул шулкадәр шатлык-куанычта иде ки, кызын нишләтергә белмичә сагыз булып ябышты.

Ни гаҗәп, бу чама чигеннән ашкан хис-тойгыга кызчык үзе йөгән салды. Инәсенең чираттагы давыллы өянәгеннән соң, күз очлары белән генә көлемсерәп әйтте:

– Анаем, мине болай чупыгдатып үпмә инде, – диде, – синең уг үпмәкләгеңне мин багыбег күлмәк итәге белән когытам бит.

Бану йокыдан уянгандай әсәрләнеп, артына чүмәште. Күр, төпчеге анасын өйрәтер дәрәҗәдә акыл җыеп килә түгелме соң?

Кызчык әткәсенең дә колагын үрә торгызды.

Иркәли-иркәли:

– И бәләкәчем минем, ничек ябыктың, йөзеңдә бер борының гына утырып калды, – дип такмаклый-такмаклый сөйгән иде дә, тегесе:

– Нәмә, атаем, чигләгәнче ике богыным баг идемени? – дип шаккатырды.

Бу үзгәрешне апалары да абайлап алды, әлбәттә.

– Анаем, ни булган ул безнең сеңлебезгә, бер сүз әйтер хәл юк, кисә дә куя, – дип, Хөснежамал да инәсенә зарланып торды.

– Ничек кисә?

– Юри генә, елак, дип ирештергән идем, миңа маңгай өстеннән генә карап куйды да:

«Мин бит, апам, атаем-анаем алдында гына җылаймын», – диде.

Шаяртып кына, нигә безнең алда да еламайсың, дигән идем:

– Сезнең алда җыладың ни, җыламадың ни, багыбег ишетмисез, – дип, авызымны каплады.

Хак, Хөсникамал терелгәннән соң һәр әйткән сүзенең төмен табып, шуннан рухи ләззәт алып, үзенә бер илһами омтылыш белән сөйләшә башлады.

Бу икенче могҗиза иде. Хаста тән, Газраилдан аермалы буларак, гомерен өзмәде, ыруының киләчәге хакына аны чир богавыннан үзе теләп ычкындырды.

***

Бер-бер артлы көннәр-атналар үтә торды, сиздермичә генә җәй дә йөзен ачты. Җәй елның иң күркәм фасылы. Аны һәр җан иясе көтеп ала. Чөнки җәй – яшәешнең асыл вә гүзәл мизгеле. Тик җәй ул сугыш-орышларның да яңа көч белән кабынган чагы.

Болгар да болардан хали түгел. Соңгы вакытта Төньяк-көнчыгыш Русенең тернәкләнүенә бәйле рәвештә бакырбашларның һөҗүме ешайды. Орыш алымнары да үзгәрде. Хәзер алар элеккечә уптым илаһи ябырылмыйлар, аз санлы, әмма яхшы коралланган, чыдам һәм йөгерек токым атларга атланган югары әзерлекле маңлайбаш гаскәри төркемнәре оештырып, урын һөҗүме ысулын шактый уңышлы кулланалар. Төн пәрдәсенә ышыклана-ышыклана киләләр дә, кирәген алып, күздән дә югалалар.

Болгарлар өчен әлеге алым яңалык түгел-түгелен. Кара диңгез буенда, Кавказ тарафларында яшәгән чорларында аны үзләре дә үз итәләр иде. Идел төбәгендә вазгыять башка, шуңа күрә ул акрынлап, күз уңыннан югалып бара иде инде.

Мәгълүм ки, һәр гамәл бигайри хак гамәл тудыра. Болгарлар да илнең мөһим юнәлешләрендә Кыргын яу дип аталган җәһәт хәрби йөзлекләр булдырдылар.

Көннәрдән бер көнне төн уртасында Ярмәк угланны да йокысыннан уяттылар.

– Бакырбаш явы килә, ишле күренәләр, безнең көч белән генә туктатып булмас, ярдәм кирәк, – диде чаптар яугир.

– Үзем барам, сәргаскәр төркемен аякка бастырыгыз, – дип, ул җансакчыга әмерен җиткерде дә, тиз-тиз генә киенеп, бил каешының бер ягына булат кылычын, икенче ягына хәнҗәрен такты. Сөңгесен дә алмак иткән иде дә, кире уйлады, ахры, кагылмады.

Ул арада янына Бану бикә килеп басты. Ап-ак эчке күлмәктән генә иде. Күз карашы белән хатынының җыерылып менгән итәгеннән башларын төрткән ымсындыргыч шәрә тезләрен, оядагы кош балаларыдай сулыш көенә калкынып-калкынып уйнаклаган тыгыз күкрәк алмаларын, озынча нәфис муенына уралган ефәктәй шома алтынсу-саргылт чәчләрен сыйпап узды да, кочагына кертте...

– Чү, углан, әүвәл дошманнарны җиңеп кайт әле, – дип, иренең үбәргә үрелгән иреннәрен учы белән каплады. – Бәйрәмне шуннан соң ясарбыз.

– Мине былбылымның кайнар кочагыннан мәхрүм иткән өчен ул мәлгуньнәрдән үчемне бише белән кайтармасам, – диде углан, – исемем Ярмәк булмасын!

– Мин ышанам, арысланым, – дип, Бану ирен үбеп алды. – Хәерле юл!

– Бәйрәмгә әзерләнә башласаң да була, мин озакламам, – дип, Ярмәк ишек катына атлады.

– Углан, көбәңне кимәгәнсең, – дип, Бану аны туктатмак иткән иде дә:

– Миңа көбәсез уңайрак, – диде Ярмәк һәм чатырдан чыгып китте.

Җәйге төн аны җиләс һавасы, күктә җемелдәшкән шаян йолдызлары белән каршы алды.

Акбүзат йолдыз,
Күкбүзат йолдыз,
Тимерказык бер ялгыз.

Тимерказык ялгыз-ялгызын, әмма ул Күк аркасы. Юл күрсәтүче.

– Киттек туп-туры Тимерказыкка карап, – диде Ярмәк. – Безне җиңү көтә.

Бара-бара төн пәрдәсенең кыйбла як читенә алсу төс ятты һәм акрынлап, яктылыкка әверелде. Тимерказык та пыскак учактай сүнә-сүнә, шул яктылык эчендә эреп, күздән югалды.

Җиһанга сугыш-орышлы яңа көн аваз салды. Орыш инде кызып килә иде. Чапкынның әйтүенчә, болгарларның хәле шәптән түгел иде. Бөҗра эчендә калганнар. Чүкепме-чүки бакырбашлар, селтәнергә дә ирек бирмиләр. Югалтулар да шактый булырга охшый.

Ярмәк килә-килешкә бер төркем яугирләрен үз уңышлары белән мавыгып китеп, уяулыкларын югалта барган бакырбашларның арт тарафына җибәрде. Алар шуннан һөҗүмгә күчәргә тиешләр иде. Үзе маңлайбаш тупламасы белән рәтләрне очлы сөңгедәй ера-ера, туп-туры орышның үзәгенә омтылды.

Аны, беренче чиратта, воевода кызыксындыра иде. Ул аны байрагыннан танып алды. Кызгылт йөзле, бастырыктай юан вә көчле куллы, славяннарга гына хас алпамша кыяфәтле гаскәри икән. Атланган аты да үзе кебек мул гәүдәле, сөренмәс тояклы толпар. Өстәвенә, ушлы да иде булса кирәк, воевода шушы болгавыр һәм кысан яу кырында да нәкъ кирәкле урында, нәкъ вакытында пәйда була. Күренеп тора, чын орышчы. Кулындагы кылычы ялт-йолт уйный. Һич тә бушка селтәнми, селтәнгән саен бер баш җиргә тәгәри. Һәм шуннан тәм табып, үз гамәлен үзе хуплап, үзенә бер канәгатьлек белән кычкырып-кычкырып куя:

– Оп-пана!

– Оп-пана!

Мондый орышчы белән кылыч чәкештерү үзе бер мавыктыргыч имтихан лабаса!

Ярмәк воеводага якынлашты. Воевода исә болгарларга ярдәм килүен күреп алган иде инде, хәлне ныклап аныклау өчен читкәрәк талпынып, орыш эченнән чыкты да ярдәмчеләренә әмерләрен җиткерде.

Орыш яңа рәвеш алды. Ярмәк бәрелеш уртасында калды, дәгъвачысын икенче дулкын йотты. Мин синнән барыбер үчемне кайтарачакмын әле дип, күңеленә беркетеп куйды углан.

Аның кылычы да яшен ташыдай уйнаклапмы-уйнаклый. Әйләндерә-әйләндерә турый юлбасарларны, гүя тегермән куласасы. Сәргаскәр үрнәге калганнарга да дәрт өстәде. Бакырбашлар яу кырын ташлап китә башлагач исә тагын да канатланып киттеләр.

– Җирәнсакал, ха-ха!

– Күтәр үкчәңне, әй, туң колак!

– Җиңү! Җиң-ү-ү-ү...

Тик бу куанычлы авазлар озакка сузылмады. Ник дисәң, бакырбашларның чигенүе хәйләле алым, пәрәвез оясы кору гына булган икән. Бер арада, орыш кыры сагыздай сузылгач, капылт кына борылып, һөҗүмгә күчмәсеннәрме! Тора-бара үзара буталышып беттеләр, кайда дошман, кайда үзеңнекеләр – аеру авырлашты. Орыш гап-гади куышуга әверелеп калды. Тиз арада яугирләрне бер учка тупларга кирәк иде. Шул очракта гына кыргын яуга исәп тота аласың.

Ярмәк бу вазифага да үзе алынырга мәҗбүр булды. Атын ары борды, бире борды, кычкыра-кычкыра тамагы карлыкты.

– Берләшергә, берләшергә-ә-ә!

Бер өзгәләнүендә кисәк кенә тавышы киселеп китмәсенме!

Үзен-үзе белешкәндә, ул үзе дә, яралы аты да җирдә ауныйлар иде инде.

Шөкер, бар җире исән-сау. Исән-сау анысы, ләкин бер өер бакырбаш чолганышында. Күренеп тора, әсир итмәкчеләр. Сәргаскәр – табышлы әсир. Шуңа күрә сагаеп кына, алны-артны карап кына селтәнәләр. Шуннан файдаланып, Ярмәк кылычын кынысыннан суырып чыгарды да, уңга-сулга карамыйча кереште тегеләрне йомычка урынына очыртырга.

– Дык-дык, дык-дык!

Бер сулыш-ыргымда дистәгә якын баскынны кырып салды.

Инде маңгайга бәреп чыккан тир тамчыларын сыпырып төшерсәң дә ярыйдыр...

Их, углан, болай ваемсыз булырга ярыймы соң, күз кырые белән генә булса да, тирә-ягыңа багып куярга иде бит.

Хәер, бәлкем, җитешми генә калгандыр, монысы инде караңгы, һәрхәлдә, өлгермәде, кулбашын воевода очырган сөңге җәрәхәтләп узды.

Бар көчен җыеп, тормак итте, ләкин өстенә ябырылган бакырбашлар ирек бирмәде, тиз генә аркан белән бәйләп, атка тактылар да орыш кырыннан алып чыгып та киттеләр.

Ярмәк углан воеводаны алданрак күреп алса әгәр, әлеге фаҗига булмый да калган булыр иде, дип фаразлады бәгъзеләр.

Тик, ни кызганыч, «әгәр»ләр күпкәрәк җыела шул. Әйтик, көбәсен кими орышка китүе, Бану бикәнең сүзенә колак салмавы. Моңа орышны оештырудагы хата да килеп кушыла, тупланманың таркаулыгы...

Бу дөньяда бернәрсә дә очраклы рәвештә генә барлыкка килми. Әнә шул «әгәр»ләр аны зарурилык кысасына кертеп, тәкъдир дәфтәренә терки.

Адәм сөйли, Ходай көйли.

Силки мәлик бу хәбәрне патшаларга хас булганча, эчендәге тышка чыгармый гына, тыныч кимәлдә кабул итте. Итчән зур йодрыгын йомгак рәвешенә кертеп кысты да:

– Башы-ахыры шул булсын, – диде.

Аннан Бану бикәне чакыртып алды.

Хатын-кызның зирәклеге – тойгыларында. Ул шатлыкны да, кайгыны да алдан ук сиземләү күәсенә ия. Һәм ялгышса да, бик сирәк ялгыша.

Ирен озатуга Бану бикәнең күңеленә дә ниндидер тынгысыз корт кереп оялады. Көне буе ярсулы йөрәгенә урын таба алмыйча ут йотып йөрде. Әле дә мәлик катына аяк басуга:

– Шәһит киткәнме, әсир төшкәнме? – дип сорады.

– Әсир, – диде мәлик, – үз тупланымны иярләргә боердым, сәргаскәрне һичшиксез азат итәчәкбез.

– Углан вазифасын үземә йөклә, падишаһ, – дип, бикә Силки алдына килеп тезләнде. – Мин аны үзем йолып алачакмын.

Мәликнең саламдай саргылт керфекләре генә җилпенеп торды, сүзе чыкмады.

– Зинһар!

– Син бит, бикә, күптән яугирлектән киттең бит инде, – диде мәлик. – Балалар үстерсәң...

Шундый кыбырсык вә какшамас тәвәккәл ханымнар була ки, андыйларны җаннары авызларына килсә дә, туктатырмын, димә. Бану бикә дә шундый чигенүне белмәүче үзсүзле зат иде.

– Ярар соң алайса, падишаһ, мин үз җансакчыларым белән китәм, – дип, тырт-тырт чыгу ягына атлады.

– Тукта, бикә, туктале, әйдә, синеңчә булсын, – дип кайтып төште мәлик. – Тик кара аны, орыш уен эш түгел, вакытында поса бел, поссаң торып баса бел, акылыңны җуйма.

Көн инде кичкә авышкан иде, күләгәләр озынаеп, кояшның куянга атланган чагы. Җиләс, дымык кич. Арыган-талган тәннәргә ял биреп, күтәренке күңел белән тынычланып, хозурлык ала торган вакыт. Баскыннар нәкъ менә шул халәттә иде. Шулай булмыйча, җиңү яуланган, ганимәте дә мул булыр, болгар – бай халык.

Воевода мөлдерәмә тулы хәмер чәркәсен иреннәренә тигезәм дигәндә генә:

– Кара яу! – дип сөрән салды тау башында сакта торучы күзәтүче. – Киләләр!

– Алып ташлагыз ул саташкан дундукны, – дип шаркылдап көлде воевода һәм зур канәгатьләнү белән хәмерен авызына койды.

– Ах, хорошо же как!

– Воевода, юлда тузан болыты, – диде ярдәмчесе, – яу бу.

– По коням! – дип акырды салмыш воевода. – По коням!

Ләкин бу исерек башлар җитешкәләгәнче, Бану бикә тупланы куптарган болыт өермәдәй җәелергә өлгергән иде инде.

Мәхшәр: кем атына менәрлек хәлдә түгел, кем урыныннан кузгала

алмый, кычкырыш-бакырыш. Алай да, воевода үзен кулга ала алды. Бикә-углан аны җилфердәгән әләменнән абайлады. Тезгенен шул тарафка тартты.

Алыптай гәүдәле, бер сугуда нәсел үгезен дә аяктан егардай көчле воевода белән йөзгә-йөз очрашу үзе бер дуамаллык иде. Җитмәсә, колагында әле булса мәликнең «акылыңны җуйма» дигән кисәтүе яңгырап тора.

Тик орыш орыш инде: ашкындыра, ярсыта, ялгыштыра, сукырайта... Аны тузынулы вә мәрхәмәтсез зилзилә белән генә чагыштырырга мөмкин. Бизмәнгә салып үлчи дә, ни белән бетәсен тәгаен генә шәрехли дә алмыйсың.

Воеводаның кулында Ярмәкне җәрәхәтләгән озын саплы сөңге. Өстәвенә, ул күпне күргән тәҗрибәле орышчы, сөңге чәкешендә аңа тиңнәр санаулы гына.

Бикә-угланның да бик үтемле өстенлеге бар анысы. Ул яраткан каһарманы зөлфәкар Айтулы үрнәгендә үзе дә мәргән осталыгына ирешкән яугирә ләбаса. Мәргәннең күзе генә мәргән булмый, үзе дә мәргән була, диләр. Ул нәкъ шундыйлардан иде.

Хәмердән бәбәкләре чалшайган воеводаны бикә сөңге аралыгына якын җибәрмәде. Шулай да, бакырбаш бер ыргым ясап алды-алуын.

– Оп-пана!

Бу куркыныч ыргым түгел иде. Әмма Бануны уятып җибәрде. Тиз генә җәясенә еракка оча торган сәрп угын саплады да кылдай тартылган җәбеннән ычкындырды...

– Әлгаязе билла!

Беренче ук артыннан икенчесе, аннан өченчесе очты һәм воеводаның чүмәләдәй гәүдәсе тәгәрәп, җиргә мәтәлде...

Бану бикәнең төп максаты воеводаны юк итүдән бигрәк, ире Ярмәкне эзләп табу, азат итү иде. Тик ул бакырбашларга эләккән әсирләр арасында да, тоткарлау яугирләре арасында да юк иде.

– Яралылар арасындадыр, бәлки, – диде Бану. – Табуга миңа хәбәр итегез.

Көн инде төгәлләнеп килә иде. Кояш алсу төс кергән челтәр болытларны сүнеп баручы сүрән нурлары белән капшап узды да Бөркет тавы артына төшеп югалды. Җиһанның эңгер-меңгер пәрдәсенә төренер чагы җитте.

Моның исә сәргаскәрнең эзенә төшүне катлауландыруы мөмкин иде.

И Аллаһым, Синә гына гыйбадәт кылам, Синә гына сәна-хәмед кылам, хәзерендә мин Синең ярдәмеңә мохтаҗ, Синең турылыклы колың, минем насыйп җәмәгатем Ярмәк угланга юл күрсәт, һидаятеңне ач. Раббым...

Сөлек янып бетәргә өлгермәгән бер чатыр янында туктап калды. Бану бикә шул ук мизгелдә күктән атылган йолдыздай җиргә сикерде. Ул Ярмәкнең камзулын абайлап алган иде.

– Арысланым, менә мин, былбылың, сине алырга килдем, – диде Бану, – борчылма, үзем дәвалармын, аякка бастырырмын...

Ул Ярмәгенең чәчләреннән сыйпамак булып иелгән иде дә, шул ук мизгелдә аңын югалтып, янәшәсенә ауды.

– Аһ!

Гәүдә башсыз иде.

Яугирләре аны, йөзенә салкын су коеп, урыныннан торгыздылар...

– Бикә-углан, сәргаскәрне кайда җирләргә боерасыз?

Бану үзен кулга алырга тырышты, чөнки орыш кырында шәһит киткән яугирне елап-кайгырып җеназаламыйлар. Барысына да мәгълүм, орыш кырында баш салу яугир өчен үзе дә бер хөрмәткә лаек язмыш ул.

– Аның урыны Кала тау башында, шунда күмәбез, – диде Бану.

Туплан, сәргаскәрне гүргә иңдереп, җиңү белән кайтты.

***

Бану атна-ун көн күзгә-башка күренмәде, вакытын далада үткәрде, Кыз күленә барып, пар аккошларны күзәтте, рухи таянычы Айтулы истәлеген яңартты, гыйбадәтләр кылып, сөекле иренә догалар юллады...

Сагышы гына басылмады.

Гореф-гадәт, шул исәптән шәригать тә шәһидләр хәтерен хәсрәткә төреп, кайгы эчендә януны хупламый. Ә Бануның йөрәге исә бу чикләүләрне кабул итми. Арысланының сөю-иркәләүләрен, кайнар кочагын, көч-гайрәтен тоймыйча, шулардан ләззәт кичермичә ничек яшәмәк кирәк?

Уй, уй, уй...

Сөлек хуҗабикәсенең хәл-халәтен аңлый иде булса кирәк, һәрхәлдә, бикә үзе моңа тулысынча ышана: киңәшләшә, эчен бушата. Әле дә аргамак йөрешен җайдагының күңелендә саркыган моң-сагыш калебенә ярашлы рәвештә юргалауга күчте.

Бу халәттә ул зәңгәр күктәге канат та какмыйча очучы мәгърур бөркет-кошны хәтерләтә. Күр, әнә, җәнәбе ничек сак вә тигез юргалый, ялында гына булса да, ник берәр бөртек кылы селкенеп карасын.

Бану бикә, гүя бишектәге нарасый, тынычланып, оеп китте, бәллү-бәллү тибрәлүдән хәтта күзләре дә йомылды...

Һәм илаһи могҗиза! Алдында сөекле ире Ярмәк пәйда булмасынмы? Ашыга иде, күрәсең, атын куалый.

– Арысланым, мин сине сагындым, – дип, Бану гомер булмаганны толпарын камчыларга кереште. Ә тегесе тыңламый, чыгымчылый...

– Юкка тырышма, мин бит инде бакыйда, барыбер куып җитә алмассың, – дип аваз салды Ярмәк.

– Мин сиңа үпкәле, – диде Бану, – яшәргә дә яшәргә иде бит әле.

– Гомерем болай да санаулы гына калган иде инде, – диде Ярмәк, – монда миңа әйттеләр, ниндидер сәбәпләр аркасында вафаты фарыз инсан исән кала икән, Газраил фәрештә аның урынына иң якын кешесенең җанын кыя. Миңа да кызыбыз Хөсникамалның терелүе алып килде бу үлемне. Тик мин Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләгә бик рәхмәтлемен. Ул мин колына яугирләргә лаек мактаулы әҗәл, шәһитләр үлемен насыйп итте.

Газраил җаным алганда еладым тәгать өчен,
Вакыт бирелде Аллаһыдан, булды яшь озынлыгы...

– Арысланым!

– Мин инде хәзер күңелдә генә, былбылым, яхшылык эшлисең килсә әгәр, хәтеремне сакла, Арысланың хакына, балаларым хакына...

Төш идеме әлеге манзара, күңелендәге хисләр кайтавазы идеме, Бану

бу халәтенең төбенә төшенеп тормады, йокымсыравыннан арынуга, атын Силки мәлик төрбәсе ягына борды.

– Мин сине, бикә, үзем дә чакырырга тора идем, килүең бик вакытлы булды әле, – дип, көлеп-елмаеп каршы алды ул аны. Күренеп тора, кәефе яхшы, карашы да ниндидер серле томанга төренгән.

Бу Бануга ошамады, шуңа күрә үз-үзе белән генә сөйләшкәндәй:

– Мин ятимәнең ни кирәге чыкты икән, – дип куйды.

– Монда миңа тынгы бирмиләр, бикә, ике-өч мәртәбәле углан синә өйләнергә рөхсәт сорый, – диде мәлик шул ук күтәренке кимәлдә. – Вакыты җитсен әле дип, кире бордым, шулай да әзерлән, берәрсенә фатихамны барыбер бирергә туры килер. Синең әле алма кебек вакытың.

Бану мәликнең бу сүзләрен аны бүлдермичә генә тыңлады, чөнки падишаһ алдында иләт зат үзен тыйнак һәм ихтирамлы тотарга бурычлы. Аннан китереп, ул бит аны кайгырта, алдагы тормышының да күркәм булуын тели. Үзе бер дәрәҗә.

– Падишаһым, мин бик рәхмәтлемен, – диде басынкы гына. – Минем үтенечемне дә тыңласаң иде.

– Сөйлә, тыңлыйм.

– Падишаһым, мин ирем Ярмәк углан янына күченеп китәргә хәл кылдым, шуңа фатихаңны бирсәң бик рәхмәтле булыр идем, үтенеп сорыйм...

– Ни сөйлисең, бикә? – дип, мәлик бикәгә җөмләсен тәгалләргә дә ирек бирмәде. – Акылыңа кил!

– Мин акылымда, – диде Бану. – Ярмәк углан күмелгән Кала тау үзәнлегендә биләмәмне булдырып, шунда йорт-җир торгызырга, төпләнеп яшәргә телим.

– Ух, куркыттың, бикә, – дип җиңел сулап куйды мәлик. – Әлләниләр уйлап бетердем.

– Без бик яратыша идек...

– Беләм, – диде мәлик, – ифрат игелекле гамәл уйлап тапкансың, ризалыгымны бик теләп бирәм, кор, төзе, рәхәтләнеп яшә. Яучыларны да кире борырга ярамас...

Мәлик бер-ике йотым ширбәт эчеп куйды. Бу әңгәмәнең тәмам икәненә ишарә иде.

Бануның гына йомышы төгәлләнмәгән иде әле, күзләрен төймәләндереп, уйланыбрак торды да:

– Падишаһым, мин ул корылманы мәмләкәтебезнең иминлеге хакына кальга итеп төзергә ният иттем, – диде. – Ярдәмгә дә өмет итәм.

Мәлик касәсен куеп көлемсерәгән итте дә:

– Хәерчегә якты чырай күрсәтсәң, ямаулык сорый, – диде.

– Бу бит, падишаһым, турыдан-туры дәүләт мәнфәгатьләренә кагыла...

– Кальга төзү чатыр кору гына түгел, бикә, – диде мәлик хакимнәргә хас җитдилек белән. – Әүвәл осталар, төзүчеләр белән киңәшергә, урын сайларга, исәп-хисап ясарга кирәк. Әлегә бу коры ният кенә.

– Ният – ярты гамәл ул, падишаһым, – диде Бану. – Өметем бик зур, зинһар өчен...

– Мин әйттем, хәзергә хуш, бикә!

***

Бану бикәнең күңеленә таракан кердеме, янса-яна, батса-бата, тыеп туктатам, димә инде, тынгысызның-тынгысызы. Мәлик яныннан чыгуга, сарайның төзелешмәне Мансур останы эзләп китте. Ул урынында юк иде. Биләр авылы янындагы язгы ташкын зыян салган кальганы торгызу эшләре белән мәшгуль, ди. Туры шунда юнәлде.

Ул аның белән таныш түгел иде, башта, сорашып белешкәннән соң, берара читтәнрәк күзәтеп торды. Какча гәүдәле, маймылларча озын куллы, торна муенлы, җитез йөреш-тырышлы кеше икән. Җиң сызганып, коллар белән беррәттән эшләп йөри. Шуңа күрә булса кирәк, эшеннән бүлүне өнәмәде, чыраен сытып кына:

– Ни йомыш? – дип белеште.

Бану аңа кыскача гына хәлне аңлатып бирде.

– Эшем болай да муеннан, – диде төзелешмән, – булдыра алмыйм.

– Мин падишаһыбыз кушуы буенча килдем, – диде Бану.

– Мин үзем дә мәлик хезмәтендә, ул боерыгын кеше аша бирми, йөзгә-йөз бирә, – дип, төзелешмән ялганны бик тиз тотты.

Авырткан башка тимер таяк, бикә еламый йомшармас сагыш эчендә калды.

Нишләргә, кая барып бәрелергә, кемнең аяк астына барып егылырга?

И Раббым, ошбу ятим тол җефетеңне вә турылыклы колыңны ярдәмеңнән калдырма, һидәятеңне ач, и Раббым...

Ишетте Раббысы колының ялваруын, ярдәм бөтенләй көтелмәгәнчә килде. Җир тишегеннән генә чыккандай ниндидер кемсә янына килеп басты да:

– Ихтималдан ихтираз, кардәш, әвене янган кешедәй кара коелгансың, бер-бер ярдәм кирәкмиме? – диде. Аннан: – Бәтәч, танымый да торам, Бану бикә син икән әле, – дип, иләк авызын ерды.

Бануның да йөзе җыерылды, чөнки ошбу кемсә Ярмәк өстеннән йөргән Өрестәм углан иде. Яудан тоташ өч тапкыр җиңелеп кайтканнан соң, Ярмәк аны йөзбаш дәрәҗәсеннән унбаш вазифасына төшергән иде. Кеше буларак та өнәми иде. Авызы сүздән бушамый дип, чыраен сыта иде.

Ярдәм, әлбәттә, кирәк, бик кирәк. Тик бу кешегә чишелү дөрес булырмы?

– Төзелешмәнгә сүзең үтмәгән булырга охшый, бикә, бәлане кайгырып җиңеп булмый, мин аның җаен беләм, бәлки, сиңа да булыша алырмын, – диде углан.

Үче юкка ошый, бәлки, чыннан да, ачылыргадыр?

Озын сүзнең кыскасы, Өрестәм бәк барысын да җайлады, Мансур бәкне ризалаштырды.

Иртән ул шыбыр-шыбыр яуган яңгыр тавышыннан уянып китте. Йөрәге өзелеп төшә язды, бу яңгырда төзелешмәнне юлга чыгарырсың, көт. Их, иртә уңмаган кич уңмас, кич уңмаган һич уңмас, ди, хак икән. Ул чатыр тәрәзәсеннән тышка күз салды.

Анда, анда... Рәхмәт төшкере, Мансур бәк белән Өрестәм углан аны ат менеп көтеп торалар иде инде. Күрәсең, җансакчылары хуҗабикәләрен уятырга ирек бирмәгәннәр.

Бануның эче-тышы шатлык белән тулышты. Сабыйдай тәмле-тәмле күз

яшьләрен йота-йота, тиз генә киенде дә атылып диярлек чатырдан чыкты. Аты иярләнгән иде инде, очып кына кунды.

Мансур бәк үз уйлары дулкынында тибрәлә, авызы йомык. Ә менә Өрестәм углан? Ярмәге әйткәнчә, авызы сүздән бушамый. Тишек авыз, сирәк теш дип, Бану аны көлемсерәп хуплады гына. Аралашучан, ярдәмчел кеше икән, рәхмәт.

– Мөхтәрәм бикә, беләсеңме, – диде каз куыгыдай кабарынкы иреннәрен чыпылдатып. – Июль аеның яңгыры патша сараена тора бит ул.

– Яңгыр – патша сарае, алар арасында нинди уртаклык булыр микән? – диде Бану, җиңелчә генә елмаеп. – Белмим...

– Зерә, – диде углан, бәбәкләрен әйләндергәләп, – зерә, риваять исә киресен рас итә. Менә тыңла. Бер патша бик шәп сарай салдырган, ди. Бәя кую өчен бу түрәләрен җыйган. Тегеләр аптыраште калган. Шунда патша йомыш йомышларга килгән бер игенчене күреп алган да:

– Синеңчә, сараем күпмелек торыр? – дип сораган.

– Июль аеның бер яңгырына да тормый, – дип әйтеп салган игенче агай.

Патшаның кәефе китеп, бу ни дигән сүз, дип галимнәренә тикшерергә кушкан. Тегеләр исәпләп карагач:

– Игенченең сүзе дөрескә килә, июль аеның бер яңгыры уңыш бирү ягыннан ошбу сарайдан зуррак байлык бирә, – дип, хөкем чыгарганнар.

– Дилбегәңне җыя төш, углан, лыгыр сатуың белән мактаулы июль яңгырына тышау салдың бит инде, – дип, ниһаять, Мансур бәк тә сүз кыстырып куйды.

Чыннан да, баш өстендә генә кояш яктысын күрсәтеп алды. Болытларның да бирешәсе килми иде әле, әлбәттә, шундук тегене янә кочакларына керттеләр. Алай да, көчләр нисбәте кояш файдасына үзгәрде. Чөнки кояшка күптәнге әшнәсе җилбикә ярдәмгә килде, пыран-заран китереп, болытларны таулар артына куып алып китте.

Күккә галиҗәнап кояш хуҗа иде инде. Бану төркеме Ярмәк сәргаскәр күмелгән җирдән, ягъни Кала тау итәгеннән кузгалып китеп, бер чакрым чамасы елга буйлап көньяк-көнбатышка таба баргач, күптән түгел генә әлеге фаҗигале сугыш булып узган ялан аша икенче елга ярына килеп туктады.

– Менә килеп җиттек, бәк, инде синең фикереңне ишетәсе килә, – дип, бикә төзелешмәнгә мөрәҗәгать итте.

Аның фикере килгәндә үк тәгаенләнгән иде булса кирәк.

– Кальга өчен менә дигән урын, каршы яктагы таулар дошман юлында табигый киртә булачак, бистә өчен дә уңайлы, – диде. – Төзелеш кирәк-яракларына килгәндә, әнә, урман өскә аварга тора, бу бик отышлы.

– Шулай ук ашау-эчүгә дә кытлык булмаячак, – дип, Өрестәм углан да төзелешмәннең бәясен куәтләде. – Күрегез, үзләре авызга керәм, дип тора бит.

Ул куаклар арасыннан килеп чыккан поши гаиләсен абайлап алган иде. Ата поши төптән тармакланып киткән зелпе тамырларыдай чуалган мөгезен җилпеп куйды да, бу минем биләмә, монда эзегез булмасын дигәндәй, калын тавышын чыгарып, мөгрәгәндәй итте.

Түмгәк башын суза төшеп, ана поши да аңа кушылды.

Бала пошиның гына кешеләрдә гаме юк, сикергәләп-сикергәләп уйнаклап алды да авызын әнисенең имчәгенә төртте.

– Бу якта кош-корт та күп, – дип, ризык темасын дәвам итте Өрестәм. – Мин үзем аккош итенә мөкиббән, берәр килүебездә мөхтәрәм бикә аккош ите белән дә сыйлар, дигән өмет тә бар.

– Үз гөманлавым буенча да, бу урын кальга таләпләренә туры килә, бәк, – дип, Бану пошилар өзгән сүз җебен ялгап җибәрде. – Агач-таш та җитәрлек, ныгыту баганалары өчен дә, саклагыч коймалар өчен дә, буралар өчен дә, күреп торасың, еракка йөрисе юк. Ә менә, Өрестәм углан, сиңа аккош итенә нәфесеңне сузмаска киңәш итәр идем. Аккош ул безнең нәсел-ыруыбызның талибелхак мәзһәбе, аны кыерсытучы бәндәгә арабызда урын юк.

– Мин сиңа, бикә, Биләр кальгасы үрнәгендә сызым-сурәтләр белән ярдәм итәрмен, – дип, Мансур әңгәмәне үз эзенә кайтарды. – Төзүче көчләр җитәрлек булганда, кальганы ике елда төгәлләргә мөмкин дип саныйм...

– Бер елда, бәк, – дип төзәтте аны Бану, – мәлик тә ярдәм кулын сузмый калмас, Аллаһы боерса...

Мансур торна муенын тырпайтыбрак торды да:

– Болары, дөрестән дә, Аллаһ кулында, ә иң беренче сиңа төзү-кору эшләренең нечкәлекләрен белүче кулай җитәкче табарга кирәк.

– Бану бикә, эзләп тә азапланма, барыбер миннән дә отышлырак җитәкче таба алмассың, – дип, Өрестәм Бохар мәчеседәй күкрәген кабартты. – Мин кул астындагы адәмнәрне, бәк шаһит, җен урынына эшләтә беләм... һәм дә, бикә, үтәмәсәм күзем чәчрәп чыксын, бүгеннән... юк-юк... хәзер үк Аккош итеннән баш тартам...

– Халыкта, теле булмаса, карга күтәреп китәр иде, дигән гыйбарә бар, бикә, тик бу безнең озын телле угланыбызга кагылмый, – дип, Мансур бернинди уен-шаярусыз кулдашын хуплавын белдерде. – Ходай аңа тел белән бергә осталык та биргән.

– Минем шартым бер генә, бәк, кальга бер елда төзелеп бетәргә тиеш, – диде Бану шундый ук җитди итеп. – Кальга сөекле ирем Ярмәгемнең гомере өзелгән көндә капкаларын ачарга тиеш.

– Ярмәк углан бик бәхетле ир булган икән, – диде Мансур. – Синең кебек мәрхәмәтле хәләл җефет, белмим, бу дөньяда башка бар микән?

Болгар илендә кальга төзүнең рәтен бик яхшы беләләр. Шулай да мәлик фатихасын Бану бикәнең үҗәтлеген исәпкә алып кына биргән иде. Әйдә, юанып кара инде, барыбер ярты юлда ялыгырсың, кальга төзү хатын-кыз кулыннан килә торган эш түгел, дип фаразлаган иде. Шуңа күрә ярдәм итәргә дә ашыкмады.

Әмма бер вакыйга аның фикерен үзгәртте.

Хәл болай булды. Урман ягыннан 15 аршын тирәлегендәге ике рәт чокыр инде казылган, чокырлар буенча 10 аршин биеклегендәге тышкы балчык өемнәре күтәрелгән, саклану сызыгын гына тәгаенлисе калып бара иде. Аның озынлыгы 250 аршин һәм ул елга ярларын тоташтырып, киек-җәнлек тә үтеп керә алмастай ныгытылган тоташ коймага әверелергә тиеш.

Гадәттә, койманың баганалары имән агачыннан булып, араталарына такталар беркетелә. Бу эшне тизләтә, әмма такта тиз чери, еш алыштырырга туры килә иде. Шуңа күрә бикә саклану сызыгын фәкать имән баганалар гына утыртып коруны мәгъкуль санады.

Бу яңалык иде. Үзе дә төзелештә куна-төнә ятты. Чөнки баганалар күп

кирәк, аларны әзерләү өстәмә көчләр табуны таләп итә. Өрестәм углан турыдан-туры төзелеш эшләре белән мәшгуль булса, үзе кирәк-ярак юнәтү белән шөгыльләнә иде. Шул сәбәпле ул күзәтчелеген агач аударучылар яныннан башлый иде.

Бу көнне соңарыбрак, төш вакыты җиткәндәрәк кенә килгән иде. Йокысы йокы булмады, төне тынычсыз үтте. Йөрәген нидер тырнап тора, күңеле урынында түгел иде.

Ботаклары киселеп, кайрыларыннан арындырылып, очланып, җиргә кагар хәлгә китереп, тәгәрәтергә уңай булсынга калкулыкка таудай өелгән бүрәнәләрне күргәч кенә йөзе ачылып китте, эченә җылы йөгерде.

– Маңгай тирен чыгарып эшләгәнсез, мин бик канәгать – дип, остазны да мактап алды.

– Кем эшләми, шул ашамый, бикә, – диде тегесе казан тирәсенә җыелган колларга ишарә итеп, – рәхмәтеңә рәхмәт.

– Төрттерүеңне аңладым, остаз, төш вакыты икән бит, тамагыгызны туйдырыгыз, – дип, бикә җансакчысы китергән атына атланды. Һәм иярдә хәлдә генә:

– Оныта язганмын, яхшы хәбәрем дә бар, – диде. – Кальганы төзеп бетергәч, мин синең карамактагы колларыңның барысына да ирек бирәчәкмен, мәлик тә каршы түгел.

– Менә монысы...

Остазның сүзе өзелде. Кыямәт купкандай кинәт кенә нәрсәләрдер дөбер-шатыр ава-җимерелә башлады. Гөрселдәү, ярылу, сыну, шартлау, шыгырдау... Колакны тагын әллә нинди шомлы бәрелү-сугылу тавышлары чатнатты. Аларга кешеләрнең чарасыз йөрәк өзгеч авазлары да килеп кушылгач, дөнья пәри туена әверелде, тирә-як йомычкадай чәчрәгән кәсле балчык кантарлары, өермәле тузан болыты эчендә калды...

Бу мәхшәр сәмум гарасаты шикелле ничек искәрмәстән генә башланган булса, шулай искәрмәстән генә тынды да.

Ә манзара коточкыч иде. Үзән канга манчылган бүрәнәләр... һәм дә... колларның шул бүрәнәләр ташкыны изеп-чәрдәкләп үткән мәетләре белән тулышкан иде.

Фаҗига фаҗигане ияртә бит ул. Төнен салынып бетеп килгән мәчет бинасы янып, көлгә әйләнде, сизми дә калдылар.

Кешелек шулай яратылган ки, дошманлык аның канында. Кан авазы, иртәме-соңмы, барыбер бер уяна. Дошман дустан ярала, дип, бик дөрес әйтә мәлик. Ә үз чолганышыңдагы дошман яу чабып килгән дошманнан күпкә куркынычрак. Аның кара ниятен, эчендә йөрткән фәхеш уйларын алдан белә алмыйсың.

Багана бүрәнәләре өеме мәрәкәсен оештыручыларны таптылар анысы. Урманны үз биләмәсе итәргә йөргән бәкнең кырын эше булып чыкты ул. Берничә колны сатып алып, ирек бәрабәренә аларны шушы җинаятькә этәргән мәльгунь.

Мәчеткә үчләнгән бәндәнең генә эзенә төшә алмадылар. Итәк-җиңен бик оста җыеп йөрүче тәҗрибә иясе булган, күрәсең.

Кальга – хәрби корылма. Куркыныч янаган вакытта хакимнең, югары даирәнең саклану вә сыену урыны. Шуңа күрә аңа игътибар зур. Әлеге

фаҗигале вакыйгалардан соң киләчәктә халык теленә «Кала тау» исеме белән керәчәк әлеге кальга төзелешен Силки мәлик, бистәләрен дә кертеп, дәүләт карамагына алды.

***

Идел-Чулман буе Болгар дәүләтенең кануни мәмләкәт булып оешуын дөнья җәмәгатьчелегенә җиткергән IX гасыр азагына якынлашты. Гомер уза. Ярмәк сәргаскәрнең шәһит булып китүенә дә унике ел үтеп китте. Моңарчы Бану бикә яучы-сораучыларны якын китермичә барча эш-гамәлләрен ире истәлегенә багышлап яшәде. Кызы Хөснеруй хәзер үз баласын сөя. Бүген менә уртанчысы – Хөснеҗамал да ир куенына керде. Шөкер, үз дәрәҗәләренә тиң нәсел-кавем ияләре белән туганлаштылар.

– Кызым, син дә буй җиткердең инде, – диде Бану төпчегенә. – Тиздән уналты, ә уналтысы тулган кыз энә өстендә бии, дия иде анаем-бикә.

– Кем бии, кем биеми, андый кайгым юк әле, анаем, – диде Хөсникамал ваемсыз бер гафиллек белән. – Башка көенечләр дә җитәрлек әле монда.

– Җә, нинди көенечләр борчый минем һәр ягы җитеш төпчегемне? – дип, Бану кызына төрттерүле караш ташлады. – Әйт, анаң да белеп торсын.

Бикәч уенны кабул итте, хәйләкәр генә елмаеп:

– Төпчегеңнең бер юньле-башлы аты калмады, ә кемдер кызына гарәп токымы аргамагы бүләк итәргә сүз биргән иде, – диде.

– Ул бикәчкә әйт, уналтысы тулгач, дигән шарты барын онытмасын, – диде Бану шул ук кимәлдә.

Кыз йөгереп килде дә иркә песи баласыдай, әнисенең куенына кереп:

– Анаем, ул шартны онытып торыйк инде, ә? – дип мырлады, – дусларым алдында «Кала тау» хуҗабикәсе кызының аргамагы дигән дан үзе ни тора?

– Уен-көлке, чабыш-куыш мәнфәгатьләренә гарәп аргамагы «Кала тау» хуҗабикәсе өчен дә кирәгеннән артык купшылык, – диде Бану кызын алдыннан төшереп. – Әлегә булганы җитеп торыр.

– Кызың чабыш-куыш яшеннән узып бара бит инде, анаем, – дип күзләрен почмакландырды Хөсникамал, – аргамак миңа бөтенләй башка максаттан кирәк. Гамәл өчен.

– Ягъни-мәсәлән?

– Әүвәл – аргамак, гамәл – аның арты.

Үземә охшап үзсүзле, дип уйлап куйды Бану. Үзем дә киребеткән кыз булып үстем, җигенә җиткәнче ата-аналарым өстеннән төшми идем.

– Теләндең тәки, – диде көлемсерәп. – Ярар, инәкәңнән булсын яхшылык, иртәгә утарга барып сайларбыз.

– Ә нигә иртәгә, безне, иртәгәсен алдан киртәлә, дип өйрәттең, – диде кыз, ирennнәрен бөрештереп. – Әйдә, алдан киртәлик.

Бану төпчеген сүзсез генә күзләре белән сөзеп алды да урыныннан кузгалды. Кызы, сөенеченнән ай кебек балкып, артыннан теркелдәде.

Хөсникамалның күзе анасының Сөлегенә тартым Кытай ефәгедәй елкылдык шома йонлы, сузынкы гәүдәле, көрәнсу төстәге йөгереккә төште.

Сайлый белә бикәч, дип, актачы кызны эченнән генә хуплап куйды.

Бану бикә аннан да уздырды.

– Гамең бар икән, бикәч, Буракка охшаш толпар сайладың, – диде.

– Тавис төсендә, ялтырап тора, нурлы... Йөгән-каешлары кызыл якут, мәрҗән, ак энҗе, алтын белән бизәлгән...

– Акбүз атка җиз камчы, ди, анаем, минем Тависыма да үзенә тиң дирбия кирәк инде, – дип, вазгыятьне үз ягына каерып куйды сылукай. – Буракның, әнә, йөгәне ак энҗе белән алтын катнашкан затлы каештан...

– Тавис?

– Әйе, анаем, Тавис, толпарыма әле генә үзең шушы исемне куштың ич, бик рәхмәтлемен, анаем...

– Ай-һай, кызым, буең җитсә, айны да учлап алыр идең, синнән юк котылу чарасы...

– Бану бикә кызы инде, анаем...

Төпчек бала болай да иркә үсә. Ә Бану кызын төпчек булудан бигрәк, атасы Ярмәк угланга охшаганына күрә аеруча якын итә иде. Хөснеруй илә Хөснеҗамал кыяфәтләре белән үзенә охшаган. Гөләндәм буй-сын, аксыл йөз, алтынсу-саргылт төстәге калын чәч, киеренкерәк чөймә борын...

Хөсникамал нәкъ этисе сыңары, күмердән коелган. Тәүге тапкыр күргәндә, Бану бикәч Ярмәк угланны шулай бәяләгән иде. Тора-бара ошбу кыяфәт ир-атка карата матурлык үрнәгенә әверелде. Дөрес, яугирләрне, барыннан да элек каһарманлыгы, ил-ватанга, якыннарына тугрылыгы өчен ихтирам итәләр. Шулай да, асыл затларыбыз матурлыкка мөкиббән. Чөнки анабыз Хәвва токымы Күкнең бишенче катыннан килгән нурлар яктылыгында яши. Ә Күкнең бишенче каты кызыл алтыннан бар ителгән, фәрештәләре хур кызлары сурәтендә. Матурлыкка, гүзәллеккә омтылыш менә шуннан килә.

Хөсникамал җиз көзгедәй ялтыраулы карасу-кызгылт йөзе, купшы иреннәре, яшькелт түгәрәк күзләре, килешле буй-сыны белән һәрчак Ярмәк угланны исенә төшереп, бикәнең хәтерен яңартып тора иде.

Бервакыт чираттагы тасма тел яучы күңелен эретеп тә бетергән иде инде. Шулай булмыйча, күпме салкын түшәктә ялгызың гына аунарга мөмкин? Назга, иркәләү-яратуларга сусаган тол хатынның бу талпынуы бик табигый хәл ләбаса! Шунда чатыр ишеге уемында Хөсникамалның сыны пәйда булды. Һәм барысы да элекке эзенә төште. Яучы буш кул белән кайтып китте.

Тависны үзенә ияләштерү, бер-берсенең холкына ярашу ай ярым чамасы вакытны алды. Шуннан соң гына Хөсникамал гамәл кимәлендә анасына биргән вәгъдәсенә тугры калып, яландагы күнегү үзәненә чакырды.

Монда барысы да әзер иде инде. Чатыр корылган, чабышкы биләмәсе әйләндереп алынган, кулдашлар, булышчы даирә җитеш, учак кабызулы, мәрә-корылмалар урынында.

Бану тамашага Өрестәм (ул хәзер күренекле тупланбаш) угланны да ияртеп килгән иде.

– Таскакка менегез, – диде Хөсникамал. – Күзәтү уңайлырак булыр.

Күз киемендәге алтынсу-саргылт яланга нурларын сибеп, кояш та сәлам бирде. Шушы якты нурлар, иртәнге салкынча һава, күк зәңгәрлеге – барысы бергә укмашып, тирә-яктагы ташлы тауларны, яфраклары коелган шәрә агач-куакларны, гүя сагым бождрасына төрделәр, кулыңны суз да тотып кара.

– Сугыш-орышсыз ялан нинди матур икән, – диде Өрестәм, – тыннар ачылып китте...

– Киләләр, – дип бүлде аны Бану бикә. – Киләләр!

Ул калкулык сыртына менеп килүче җайдак кызларны шишәкләре елтыравыннан абайлап алган иде.

Менә үзләре дә күренде. Атлар җайдакларның һау-һаулавына дәртләнеп, тупырдаша-тупырдаша, җан-фәрманга сөлектәй сузылып чабалар. Тирә-якка шыбырдап яуган яңгыр бозыдай балчык кисәкләре генә сибелә.

– Әллә-лү, әллә-лү!

– Һай-һай-һай!

– Һоп, Тавис, һоп!

Толпар хуҗабикәсенең ниятен тезген селкүеннән үк аңлап алды, күрәсең, тагын да җитезрәк алдырта башлады. Башкалар да тоташ дулкындай аңа кушылды.

– Чыннан да, кызлармы соң болар? – дип, углан бәбәкләрен киерде һәм кысан таскак эчендә берара таптанып торды да: – юк, кызлар түгел бу, ышанмыйм! – диде.

– Бу әле баласы гына, углан, мичтә булыр анасы, – дип шаяртты бикә. – Килсеннәр, күрербез.

Тезем якынлашты. Чабышкыларның гыж-гыж килеп сулыш алулары инде колакны ярып керә башлады.

Шунда тезем каршында төрле арада, төрле ераклыкта саламнан кешегә охшатып ясалган карачкылар калкып чыкты.

– Кылыч!

Хөсникамал әмерен яңгыратты да, чабып килгән кызулыкта бер дошман-карачкының гәүдәсен урталай ярып та төшерде. Бүтән кызлар да шул ук гамәлне башкарды.

Карачкылар урыннарын алыштыра башлады. Орыш кызды. Тик орышның бер төп шарты бар: карачкыны бер килүдә һәм бер кизәнүдә юк итәргә кирәк. Ә бу зур осталык сорый.

– Юк, кызлар түгел бу, ышанмыйм, юк, – дип, Өрестәм углан туктаусыз урынында таптанды.

Карачкылар, ниһаять, авып бетте.

– Мәрә!

Монысы инде чираттагы бирем.

Шундук карачкылар урынында тәмек-мәрәләр пәйда булды. Ә садакта ун ук. Менә җайдаклар чабып килгән җайга төз колаклы аткыюч укларын яудырырга тотындылар. Шул ук таләп: бер килү, бер кизәнү.

Укларын сибеп бетергәч, мәрәләрен таскакка киберделәр. Өрестәм углан бик тырышып, бик җентекләп, бармакларын бөгә-бөгә тишек санады. Ун җайдак, ун ук, була барысы йөз тишек.

– Кәкре җәядән туры ук, – дип көлде бикә, – ничек, тишекләр җыеламы?

– Ничек кенә әле.

Җайдаклар атларына бераз ял биреп, тирләрен катырганнан соң, киемнәрен алыштырып, коралларыннан арынып, янә күнегү сызыгына бастылар.

Әлеге күнегүләрнең турыдан-туры хәрби хәзерлеккә катнашы юк иде булса кирәк, чөнки шигарь ук үзгә:

Җәт бул, кызу тот,
Күбәләктәй очып кун!

Бу юлы туташлар осталыкларын тасак каршында, яланның ашъяулыктай тигез урынында күрсәттеләр.

Әүвәл пар-пар тезелешеп бастылар. Үзләре дулкынланамы-юкмы, ерактан абайлый алмыйсың, ә менә атлары үрсәләнепме-үрсәләнә: таптаналар, пошкыралар, кешниләр. Тәмам йөрәкләре ярсыган.

Хөсникамал парына ым какты да аваз салды:

– Күбәләк!

Дәррәү кузгалдылар.

– Әллә-лү!

Бануның күзләре Тависка текәлгән. Аргамак та үзен сокланып күзәтүчесе барын сизгәндәй яны-яны белән генә кыбырсып-биеп китте. Үзенең чибәр дә, көчле дә икәнен белә иде ул, әлбәттә. Ләкин бу ярыш та, бәйге дә түгел, монда барыннан да элек күреклек, сол вә сабырлык зарур.

– Әллә-лү!

Тигез ыргым белән чапкан йөгерекләр кабыргага-кабырга алымына күчте. Шунда ике җайдак бер сулышта бер-берсенең ияренә күбәләктәй очып кунды.

– Һоп!

Бу берничә мәртәбә кабатланды.

– Юк, кызлар түгел бу, – дип пышылдады Өрестәм углан, – ышанмыйм...

Бикә аны ишетмәде, чөнки икенче пар урыныннан кузгалган иде инде.

Шулай чират-чират барысы да ат алмашу осталыкларын күрсәтеп чыкты.

Чакырылган бу ике кунак җил җиллэтеп тояк каккан атлардан җиргә сикереп, шул ук мизгелдә ияргә очып менү күнегүләрен дә бик ошаттылар.

– Юк, кызлар түгел бу...

Соңыннан янә яугир киемнәрен кигән туташлар таскак янына килеп бастылар.

– Хөрмәт!

Аргамаклар тезләрен чүкте.

Бу аларның сәламләве иде.

– Рәхмәтебезне без шулай ук толпарларыбызның һөнәре аша җиткерәбез, – дип, аңлатма бирде Хөсникамал. – Ә хәзер кулдашларым белән таныштырып үтәм. Без үзебезне асылташларга тиңлибез, шуңа күрә кушаматларыбыз да шуларга тиң.

– Зәркән, анысы мин үзем булам. Инде игътибарыгызны башка асылташ туташларга, киләчәкнең иң оста яугирәләренә юнәлтегез: Алмаз, Якут, Зөбәрҗәт, Энҗе, Ахак, Фирзә, Бриллиант, Рубин, Сапфир.

Исемнәре чыккан һәр җайдак, иярендә тураеп басып, башын иде.

– Ә хәзер табын... рәхим...

– Азга гына, сабыр, зинһар.., – дип сөйләнә-сөйләнә, Өрестәм углан таскактан җиргә сикерде. – Шишәкләрегезне салыгыз әле, зинһар...

– Углан сезнең туташ булуыгызга шик белдерә, – диде Бану канәгатьле елмаю белән. – Күрсәтегез йөзегезне.

Өрестәмнең ике күзе дүрт булды. Аның каршында тулган айдай якты йөзле, ачык битле, боз сөңгеседәй чәчрәннәп, балачактан чыгып кына килүче үсмер кызлар басып тора иде.

Түрә биеклегенә күтәрелгәннән соң биштәренә салып куйган тел куәсе ачылганын да сизмичә калды кунак углан:

– Бәрәкалла-бәрән сыйрагы, кәҗә койрык күтәрә дип, сарык та койрык...

Бикә аны вакытында тыеп калды.

– Нәрсә, углан, аптырашмы әллә? – дип, бармак янады.

– Аптырашкынамы, бикә, мең төрле уй, катты баш, яртым үлде яртылаш...

– Нилектән?

– Безгә дигән ырыс-дан төшеп калган тырыстан булып чыга бит әле, бикә, безгә, ир-атларга, чүплек кенә кала түгелме соң?

Ул Зөбәрҗәт атлысыннан:

– Сиңа ничә яшь? – дип сорасы да итте.

– Уникем тула инде, – диде Зөбәрҗәт, чатнатып. – Фирзә миннән дә бәләкәйрәк.

Кыз бармагы белән күршесенә төртеп күрсәтте.

– Зөбәрҗәт миннән унбиш көн алданрак туган, – дип ачыклык кертергә ашыкты тегесе. – Бары унбиш көн...

– Остазыгыз зур тәҗрибә иясе булырга охшый, – диде янә тупланбаш халәтенә кайткан углан төпченүен дәвам итеп. – Сер булмаса, исемен әйтегез әле.

– Зәркән инде, – дип, чырык-чырык көлеп куйды Зөбәрҗәт, – кем булсын.

– Ниятебез падишаһыбызга үзебезнең башкалардан остарак та, өлгеррәк тә, көчлерәк тә икәнебезне дәлилләп күрсәтү, – дип, Хөсникамал үзе дә әңгәмәгә кушылды.

– Шуннан ни-нәрсә була?

Хөсникамал бу көн кебек ачык лабаса дигәндәй, угланга күз очлары белән генә карап алды да:

– Билгеле инде, кызларның мөстәкыйль хәрби тупланын оештыру, орышларда катнашу, – диде. – Син дә, углан, безнең якка бассаң иде.

– Мин сезне бүгеннән үз төмәнемә алырга әзер.

– Рәхмәт, углан, моны падишаһыбыз Силки мәлик үзе генә хәл итә ала.

– Монысы алайса, Кала тау хуҗабикәсенә кагыла инде, – диде углан баядан бирле, төпчегемне мөгаллиме дөрес мактый икән дип, сокланып күзәтеп утыручы Бануга ым кагып. – Мәликкә бикәбезнең сүзе үтә, дип беләм.

Хөсникамал өзәңге бавын рәтләбрәк тотты. Аннары ияренә чумыбрак утырды да башын чөя төшеп, үз фикерен җиткерде.

– Бикәбез безнең, углан, күптәннән үз вазифасын үтәп, офык артында калган Кала тау хатирәләре белән юанып, шул хатирәләр хозур-тышавында яши шул инде ул, – диде. – Заманадан калмау һөнәр түгел, замананың алдыннан бару – һөнәр, ди акыл ияләре. Мәмләкәтнең киләчәге алга карап яшәүгә бәйле, дип беләм. Бу инде бөтенләй башка тәрәккыят.

Кызының бу көтелмәгән нотыгы Бану бикәнең һушын алды.

Әүвәл аксыл йөзендә кызгылт тимгелләр бәргәләнде, ясмык уемлы озынча ияге чыбыркы очыдай черт-черт дерелдәп куйды, аннан тулы иреннәре чалшаеп, кашлары дуга рәвешендә маңгаенда катып калды. Шуннан соң гына авызыннан әпә сөйләменә охшаш ярым-йорты сүзләре сытылып чыкты.

– Һы... ал-аймы... кара... һы... маңка... Кала таумы... Кала тау... Болгарның ас-ы-л улы... Ярмәк... сәргаскәр... мәңгелек һәйкәл...

Хөсникамал үзе дә таң калды. Юк, ул үзен гаепле санамый. Ник дисәң, Бану бикә үзе дә сүзен үлчәп сөйләүчеләрдән түгел, күңелендәгесен, кешегә ошыймы-ошамыймы, турысын бәреп әйтә торган зат. Кызларын да үзләрен сүзләреннән ким күрсәтмәскә, хак сүзне әйтүдән курыкмаска өйрәтеп үстерде. Бу үзе чәчкәнне уру гына иде.

Шулаен шулай, әмма җаны кебек яраткан ире Ярмәк углан истәлеге барысыннан да, хәтта балаларыннан да өстен шул. Әлеге изге хатирәгә ул моңарчы да кер тидермәде, алга таба да тидермәячәк.

Кыз бала әнисенең өзгәләнүләрен тыныч кына күзәтеп тора аламы соң, Хөсникамал да күңеле тулып, бикәгә килеп сарылды.

– Анаем, кирәкми, анаем...

Бану бикә калебендәге барча күзәнәкләр дә юеш йонга сарган тигәнәктәй ачу белән тулышкан иде. Ул үзен-үзе белешмичә кан баскан күзләрен кызына акайтып карап алды да, аны бар көченә читкә этәреп, ияренә сикерде. Ат тояклары күтәргән тузан болыты эченнән хәвефле сүзләре генә ишетелеп калды.

– Күземә күренәсе булма, бәддога сиңа, бәддога...

Ана белән баланың юллары аерылды. Бану бикә Кала тауга кайтып егылды. Хөсникамал әбисе Хәдичәгә барып сыенды.

Күңелле булып башланган көн әнә шулай бик күңелсез тәгәлләнде.

Бану бикә төне буе, керфек тә какмыйча, кызының һәр сүзен күңел иләге аша үткәреп, уйланып ятты. Үпкәле иде ул кызына, нык үпкәле. Үпкәле булмыйча, газиз атасының яд-хәтерен саклаучы һәйкәл-корылманы чүплеккә чыгармак итә ләбаса. Бу бит соң дәрәҗәдә мәнсезлек. Моны гафу итеп була димени?

Күр, нәрсә, ди? Заманадан калмау һөнәр түгел, заманaның алдыннан бару – һөнәр, имеш. Бер караганда, ошбу сүзләргә тел-теш тидерә алмыйсың, хак сүзләр. Дөресен генә әйткәндә, киләчәк гаме вакыт-вакыт аның үзенең күңелен дә борчыштырып алгалый. Әйтик, билекләрнең һәрберсе тезгенне үз ягына каера, шул сәбәпле, мәмләкәтнең бөтенлегенә зур зыян килә. Дөрес, ошбу хасият-тоемлау әле оядагы бала кош халәтендә генә, канатланырмы ул юкмы, монысы Аллаһ кулында. Ә яшьләр, шигырьдәгечә, «тәрәккый вә тәгали юлларына улалым кадим» икән бит: кыюлар, тәвәккәлләр, гыйлемлеләр һәм дә үзсүзлеләр.

Дөрес, үзсүзлелек ягыннан ул үзе дә чигенә торагннардан түгел. Бәлки, уздырып та җибәрәдер әле. Шулай булмаса, буй җиткереп кенә килүче кызының сүзләренә бәддога укымас иде.

Бу хәл күпме дәвам иткән булыр иде икән, әйтүе авыр, бер хәвефле вакыйга аларның үпкәләрен юып төшерде.

Беркөнне йөреп торган җиреннән кинәт кенә ире Бәхтиярнең нәкъ еллыгында Хәдичә бикә егылып үлде.

Кайгы берләштерә бит ул. Кыз белән ана да, һични булмагандай, бернинди аңлашуларсыз сөйләшеп-аралашып киттеләр.

Мәрхүмәне күмү-җирләү йолалары ахырында Бану Хөсникамалны чакырып алды да:

– Кызым, бер яңалык беләсең киләме? – диде.

– Килә, анаем, бик килә.

– Мин махсус сезнең өчен Кызлар каласы төзергә карар кылдым, падишаһыбыз да хәер-фатихасын бирер, дип уйлыйм.

– Афәрин, анаем, – дип, Хөсникамал әнисен кочып алды, – бөек зат син!

***

Бану бикә кальга биләмәсен мәчет манарасыннан карап күзәтергә ярата. Бу юлы кызы Хөсникамалны да ияртте.

Хөсникамал теләгенә иреште, падишаһ аңа кызлар тупланы оештырырга шәрәфле рөхсәтен бирде. Ул хәзер – тупланбаш. Нәкъ бер ел элек кальганы төзеп бетерү уңаеннан якты бер көзге көндә яугирләр Силки мәлик алдында имтихан тотып, аңа ни-нәрсәгә сәләтле икәннәрен тамаша рәвешендә күрсәткәннәр иде.

Бүген дә кояш алтынсу-саргылт җиһан киңлекләренә шифалы нурларын мул сибә, күк юып чыгаргандай чип-чиста, шул чактагы кебек үк иртәнге салкынча һава битләрне иркәли...

Тирә-якны, әйтерсең лә, уч төбенә утыртып куйганнар, кальга корылмалары күзгә тәгәрәп кереп тора. Хөсникамалның эзләнүчән үткен карашы иң әүвәл дугадай бөгелгән биек тау сыртын, каршы яктагы кызыл ярны сыйпап узды, җәһәт кенә ике елга куенына сарылган борынга охшаш калку утрауны капшап алды, аннан янә әлеге мәһабәт тау киңлекләренә әйләнеп кайтты да шул тарафта тукталып калды.

– Анаем, син – искиткеч зирәк бикә, мин синнән көнләшәм, – диде, – теге вакытта...

Бану күз карашын өзми генә кызының кулын кайнар учына кертте.

– Теге вакытлар артта калды инде, кызым, үзең әйтмешли, алга карап яшик.

Төпчек өчен ул үзе дә сөенү хисләре кичерә иде. Анасының ни өчен тәүге корылма итеп мәчет салдыруын, ни өчен еш-еш манарага күтәрелү сәбәбен сизеп-тоеп алган бит, бәгырь.

Әйе, ошбу гамәлләр Ярмәге хакын хаклап башкарылды һәм башкарыла. Чөнки аның җәсәде нәкъ шул каршы як тау өстендәге җир куенына иңдерелде. Ул һәр көнне мәрхүм иренең хәтерен яңарту өчен манарага менә, рухына дога юллый.

Манарадан төшкәч, алар зәркән остаханәсенә юл тоттылар. Кальга истәлегенә бикә икесенә дә затлы алкалар эшләтергә сөйләшкән иде.

Остамән, уа аркалы кәтәнә Йосыф, гадәттәгечә, авыз эченнән фәкать үзенә генә мәгълүм көйне көйли-көйли, күзләрен алдындагы эшләнмәсенә чекрәйткән, керүчеләргә игътибар да итмәде. Ул хатын-кызлар арасында патшаларга тиң белекле зәркәнче иде. Кулы белән төймә генә коймый, диләр андый осталар турында. Ә ул, чыннан да, ничек кенә коя әле! Чин гүзәлләренә кадәр бил бөгә аңа. Билгеле инде, борыны чөюле. Алай да, останың бу кыланышларын күрмәмешкә салыналар. Хәтта, әнә, Бану бикә булып Бану бикә дә борчырга базмыйча, бушавын тыныч кына көтеп утыра.

Кулдашы останы айнытмак булып, колагына нидер пышылдаган иде дә:

– Сукыр түгел, күрәм! – дип кенә җибәрде.

Хөсникамалга бу дорфалык таш-кыядан купкан кар кантары кебек тәэсир итте булса кирәк, шул ук мизгелдә шартлап ярылды да:

– Оста, җәле, торып бас, синең алда – Бану бикә, хәзер үк йөзеңне сөр!

Йосыф утырган килеш кенә кызга аңгыраебрак карап бакты.

– Башыңны тәгәрәткәнне көтәсеңме? – дип, Хөсникамал җансакчысының кылычына үрелде.

Йосыфның кикриге шиңде, атылып диярдәй кальга хуҗабикәсе алдына килеп тезләнде.

– Хөрмәтле бикә... гафу... күрмәгәнмен... гафу...

– Моннан соң безне капкаңны ачып каршы ала торган бул, – диде яугирә, – ә хәзер йомышыбызны тыңла.

Кызының бу кызулыгы останы гына түгел, Бану бикәне дә җилкеткән иде, озак кына ничек сүз башларга белмичә аптырабрак торды.

– Бездә әзер яка чылбырлары, асылмалар, тезмә, үрмәләр бар, – дип, ярдәмгә килде оста. – Теләгәнең сайлагыз.

– Без чигә алкасына бирем бирергә килдек, – диде Бану.

– Баш өсте, бикә, алтын-көмеш тә, асылташларыбыз да җитәрлек...

– Бишенче кат Күк төсендәге кызыл алтыннан, – диде Бану. – Анда фәрештәләр хур кызлары сурәтендә, тел төбемне аңлыйсыңдыр, алкаларның нәфис, затлы, нурлы булулары шарт. Кашлары яшел якуттан булсын.

Йосыф башын кашып куйды, чөнки бикә Күк катындагы асыл матдәләр турында сүз алып бара, җир йөзендә аларга тиңнәрен, ай-һай, табу мөмкин түгелдер. Каршы да килә алмыйсың, әнә, яугирә кыз кылычына тотынырга гына тора. Әйдә, беткән баш беткән... Хәер, ул кызыл алтыннарны үзләренең дә күргәне юк бит әле аларның. Шулай булгач...

– Баш өсте, бикә, – диде оста бөкресен турайтыбрак. – Барысы да син теләгәнчә булыр, бәхетегезгә, шушы көннәрдә генә яңа чигә алкасы үрнәге эшләгән идем, ул фәкать сездә генә булачак...

Ул өстәлгә эскизларын җәеп салды.

Алканың колакка тагу өлеше сырлап эшләнгән йомры кысадан гыйбарәт иде. Төптән чылбырлы өч үрмә төшә, аларның очына йомырка рәвешендәге зур асылташлар беркетелгән. Шуларның барысына да энҗедәй алтын бөртекләр сибелгән.

– Кыса эчендәге үрдәк сурәтенә игътибар итегез, – диде Йосыф, – алканың мәгънәви асылын нәкъ менә шушы үрдәк сурәте тәшкил итә дә инде.

– Безнең кошыбыз – аккош, – диде Бану. – Үрдәкне аккошка алыштырырга кирәк булачак.

Йосыф учы белән битен сыпыргалап торды да әйтте:

– Бикә, үрдәк – риваятьләрдә урын алган изге кош. Бик борынгы заманнарда дөнья очсыз-кырыйсыз дәрьядан гына торган бит. Дәрья өстендә фәкать бер ялгыз үрдәк кенә йөзеп йөргән. Бервакыт ул чумган да дәрья төбеннән бер бөртек балчык кабып алып чыккан. Һәм шул балчыктан җир хасил булган. Аккошларга килгәндә, сүз дә юк, матурлар. Аларны мәхәббәт билгесе дип тә саныйлар. Әмма, бикә, аккош усал һәм кансыз кош. Башка кош, әйтик, көндәшен куып кына җибәрә, ә аккош суга батырып үтерә.

– Бр-р-р, илаһи кадыйр, – дип, йөзен чытты Хөсникамал. – Миңа күбрәк үрдәк ошый төшә.

– Мин барыбер аккош яклы, – диде Бану, – Аккош аккош инде ул, тугрылыклылык үрнәге.

Йосыф Бану бикәгә – аккош сурәтле, Хөсникамалга үрдәк сурәтле алка ясады.

*Тарихи белешмә:*

*Заманында Уралның бер бик бай эшмәкәре Әби патшага затлы вә кыйммәтле бүләк бирергә ниятли. Бик озак сайлана бай абзый, бик озак эзләнә. Ахырда Болгарның нindидер могҗиза белән сакланып калган үрдәк сурәтле колак алкасына туктала. Тик, ни кызганыч, алка берәү генә. Патшабикәгә сыңар алка бүләк итеп булмый бит инде.*

*Бай үтенече белән данлыклы Урал осталары аңа нәкъ болгарларныкы шикелле итеп икенче нөсхәсен дә ясап бирәләр.*

*Әби патша бүләкне бик ошата.*

*Вакытлар үткәч, әлеге алкалар музейда урын ала. Шунда икенче алканың төп нөсхә булмавы ачыклана да. Урал зәркәнчеләре, ничек кенә тырышсалар да, күпсанлы алтын бөртекләрен болгар остасы кебек бер-берсенә нәфис итеп беркетә алмаганнар.*

*Ә менә оригиналны Йосыф оста эшләгәнме, башка бер зәркәнчеме – анысы билгесез.*

***

Идел Болгарстанының бик күп илләр, халыклар белән җанлы икътисади-сәяси киң сәүдә мөнәсәбәтләре урнаштыруы безгә мәгълүм инде.

Ошбу халыкара сәүдә багланышларына кагылышлы юлларның иң олысы – коры юл белән Урта Азиягә, Һиндстанга, Кытайга, Шәрык мәмләкәтләренә юнәлдерелгәне – Кызлар каласы (тиз арада сәүдәгәрләр «кальга» сүзен «кала» сүзенә алыштырдылар) аша үтә.

Сәүдә – табышлы гамәл. Ә табышның иярчене – җинаять. Җинаятьнең иярчене – хыянәт. Җиңел юл белән баерга омтылучы юлбасарлар җимгә җыелучы кошлар кебек шушы төшемле җиргә ябырылалар. Шуңа күрә сәүдәгәрләрнең иминлеген саклауны тәэмин итү дәүләти вазифага әверелде.

Ни кызганыч, һөҗүмнәр барыбер әле анда, әле монда кабынгалап тора. Шундый чөен чыгарырдай хурлыклы һөҗүм Кызлар каласы кальгасында да булып алды.

Балчык өемен үт тә инде, елганы да кич, ди, ә ничек чебен-черки дә очып керә алмас дип саналган таш кыядай тоташ биек койманы үтмәк кирәк? Әле бит балчык өеме янында да, елга буенда да, ныгытманың үз эчендә дә яугирләр сакта тора. Ни сәбәпле алар борын төпләрендә кырын эш белән кайнашкан юлбасарларны күрмәгән?

Башта шулай гөманлаганнар иде. Бактың исә, юлбасарлар кальга эченә Үзәк капкадан үтеп кергәннәр икән ләбаса! Тавыш-тынсыз гына әүвәл сакчыларны хәнҗәр очына утыртканнар. Шул кадәр бәдбәхетләрчә кыланганнар ки, берсен хәтта ядкарь итеп, капка аратасына ук асып куйганнар.

Иркенләп кергәннәр дә, йокларга яткан гарәп сәүдәгәрләрен талап, кыл бөртек малсыз калдырып, ипләп кенә чыгып тайганнар.

Тузынды да соң мәлик, сакбашны тере килеш үзе казыган чокырга күмдерде.

Соңыннан бу сәер хәлнең чыбык очы хыянәткә барып тоташуы ачыкланды. Ләкин тәгаен генә төбенә төшә алмадылар, чөнки хыянәтне

оештыручы сакбаш үзе булып чыкты. Ә аны кайнар эздән теге дөньяга озатканнар иде инде.

Мәликкә сәүдәгәрләрнең югалткан малын капларга туры килде.

Булыр инде бу дөньяның
Тетрәнеп алган чагы,
Дер селкенеп алган чагы,
Утларга салган чагы...

Берничә көннән ул Бану белән Хөсникамалны сараена чакыртты. Күңеле китек иде.

– Адәм хурына калдык, – диде.

Бану бикә аны юатырга теләп, нидер әйтмәк иде дә, мәлик алданрак җитеште.

– Ни әйтәсеңне беләм, бикә, – диде уфтангандай, – синең теге вакыттагы тәкъдимеңә игътибарым җитмәгән, хәер, әле соң түгел, «Кызлар каласы – Бүләр» арасындагы сәүдә юлы иминлеген саклауны хатын-кыз яугирләргә йөклим. Җаваплылыкны да икегезгә йөклим.

– Баш өсте, падишаһ, ышынычың өчен рәхмәт.

– Үзегезгә рәхмәт, хушыгыз, сүзем бетте.

– Падишаһ, минем сүзем бар иде, – дип, Хөсникамал уттай янып торган карасу-кызгылт керфекләрен җилпештереп, яшьләргә хас беркатлы кыюлык белән: – Мөмкинме?

Мәлик баядан бирле бер читтәрәк ниндидер ашыгыч йомышын йомышлау минутын җиткерә алмыйча кадак өстендә утыргандай утырган вәзиргә карап, гафу үтенгәндәй, җилкәсен сикертеп куйды да:

– Рөхсәт, яугирә, тыңлыйм, – диде.

Хөсникамал анасының кисәтүле ым кагуларын баш очыннан гына очыртып җибәрде.

– Падишаһ, син бер вазифаны ике кешегә йөклисең, – дип, сүзен сарай кагыйдәләренә туры килми торган тәнкыйди кимәлдә башлады. – Минемчә, бу башбаштаклыкка китерә.

– Падишаһ, кичер, зинһар, кызым балалыктан аерылып кына килә бит әле, – дип, Бану урыныннан сикереп торды. – Безгә китәргә рөхсәт бир.

Мәликнең күзләрендә исә очкын кабынган иде.

– Юк инде, бикә, яугирәне тыңлап бетерик, – диде кош тоткандай. – Бәлки тәкъдиме дә бардыр?

– Бар, – диде Хөсникамал канатланып китеп, – бар!

– Җә-җә, ягъни мәсәлән?

– Ягъни мәсәлән, Бану бикәнең мәшәкатьләре болай да башыннан ашкан, аның карамагында ике кальга, бистәләр, эше тавык чүпләп тә бетерерлек түгел. Яңа өстәлгән вазифага аның көче дә, вакыты да җитмәс дип уйлыйм...

– Кызым, җитте! – дип, Бану янә урыныннан кузгалды.

– Ә тәкъдим? – дип, мәлик шук кына учын-учка уыштыргалап алды. Яугирә бикәч аны чын мәгънәсендә әсир иткән иде.

– Ошбу җирлектәге сәүдә юлы иминлеген тәэмин итүне үземә генә тапшырсагыз, мин бик якын арада анда чын тәртип урнаштырачакмын, – дип чатнатты Хөсникамал. – Үкенергә туры килмәс.

– Нәкъ үзеңә охшаган кыз үстергәнсең, – диде Силки мәлик Бануга, – афәрин!

– Тәкъдимем хуплана алайса, падишаһ, – дип, бикәч сукыр черкидәй янә арага килеп кысылды.

– Хуплана, яугирә, хуплана.

***

Хәрәзем якларыннан килгән кәрванбаш Муса әкә үзе белән ләтчәләр алып йөри иде. Бу мәхлуклар шулкадәр акыллы өйрәтелгән иде ки, хуҗаларының ни-нәрсә теләвен ым кагуыннан төшенеп алып, ә дигәнче үтәп тә куялар.

Үзләренә карап туймаслык. Пәйгамбәр камчысыдай сыгылмалы озынча саргылт шома гәүдә, һөдһөд кошыныкына охшаш төймә күз. Урта бармак буе гына кыска аяклары да бик килешле. Ә йөрешләре, ут борчаларың бер якта торсын. Урта Азиянең танылган сәүдәгәрләр династиясе вәкиле Муса әкә озын һәм ялыктыргыч сәүдә юлларында шушы матур җәнлекләренең һөнәрләренә багып хозурлана, күңел ача. Якыннары, кулдашлары «әкә» дип мөрәҗәть итсә дә, әле аңа егермесе генә тулып килә. Каккан баганадай төз вә бүтәннәрдән бер башка калку озын гәүдәле, кыздырылган балыкка охшаш тоңык йөзле, чем кара күпермә куе кашлы, ыспай сакал-мыеклы егет кәмәше. Өстендәге яшькелт хөббәсе аяк йөзенә кадәр төшеп тора. Башына шакмаклы яулык ябып, аны кыршаулап куйган.

Шулай да тәүге күрешүдә күз үзеннән-үзе кәрванбашның битенә көчкә-көчкә генә сыеп торган, тугыз күркә кунарлык борынына төшә. «Танау» дигән кушаматы да шуңа ярашлы. Ә үзе:

– Мин борын-борыннан килүче саф канлы чын гарәп инсаны, – дип, борын чөя. – Без барыбыз да – борынбайлар.

Кызлар каласын, болгарларның кечелекле, ярдәмчел вә гадел халкын ошатты әкә. Алыш-биреш өчен дә шартлар менә дигән икән, табыш үзе кулга сыланам дип тора. Ләкин бу озын сәфәргә озатканда:

– Аң бул, Болгар ул – бик бай ил, әмма анда юлбасарлар һәм еланнар мыж килеп тора, – дип, колагына киртләде күпне күргән остазы. – Һәр адымыңны үлчәп атла.

Чүп өстенә чүмәлә, баксаң, сәүдә юлын яугирәләр саклый икән ләбаса! Кыз-хатын табигате белән үк куркак зат, куян җанлы, чыпчык йөрәк. Аларга бит эт тә өрми, акыллары да җил өргәнче җиде төрлегә әйләнә, ди.

Муса әкә, өстәмә сак ялларга кирәк булыр, дигән фикерне күңеленә беркетеп куйган иде инде. Алай да, бу ярым-йорты яугирәләрнең дә уяулыгын тикшереп карарга булды.

Нигә әле бер көлке тамаша ясап алмаска? Ошбу нияттә аңа, әлбәттә, ләтчәләре булышачак. Бу җәһәттән сәүдәгәр әкәнең тәҗрибәсе бар, күпләргә курчак туе ясады инде ул.

Тукталу урыны да уңай, сакчылар утары күршедә генә. Көне буе тыз-быз, әйтерең бармы, эшем кешеләре, имеш.

Кәрванбашның «тыз-быз» дигәне дөреслеккә туры килми иде, билгеле. Каравыл – хәрби тупланма, анда тәртип барысыннан да өстен. Ә кызлар төркеме бу яктан башкаларга үрнәк.

Муса әкә кача-поса гына яугирәләр бинасына якынлашканда, Зөбәрҗәт төркеме ялга туктаган иде.

Әкә куенындагы ләтчәләрен ипләп кенә кулына алып, ишек уемыннан эчкә шудырды.

– Валлаһе әгъләм!

Ләтчәләр үз вазифаларын бик яхшы белә иде, күрәсең, шундук ниндидер аңлаешсыз яшелле-зәңгәрле гырындык тавыш чыгара-чыгара, очар кошлар кебек кенә бүлмәне бетереп әйләнделәр-тулгандылар да, куркуларыннан күзләре әсәрләнгән яугирәләрнең иңнәренә кундылар. Берсе хәтта Зөбәрҗәтнең муенына ук килеп сарылды.

– Уф, үләм, – дип оран салды кыз. – Коткарыгыз!

Бу тамашаны тышкы якта посып кына күзәтеп торучы әкәнең көлсу йөзендә мут елмаю дулкыннары биешеп алды.

Мәрхәбә, ярдәмчеләрем!

Ул уенчак җәнлекләреннән бик риза иде.

Зөбәрҗәт өтәләнепме-өтәләнә, ләтчә исә аның саен муенына ныграк урала гына бара. Бу хәлне күреп, дусты Сәмига кулына кылычын алды.

– Хәнҗәр белән, хәнҗәр белән!

Яртылаш ачык ишек уемыннан әлеге манзараны күзәтеп торып, инде үзе куркуга төшкән кәрванбаш ашыгычлык белән тылсымлы әмерен яңгыратты.

– Валлаһе әгъләм!

Ләтчәләр хуҗасы катына ыргылдылар.

Кызлар бу йөгәнсез сәүдәгәрнең шәүләсен генә шәйләп калсалар да, барыбер таныдылар.

– Эт этлеген итмәсә, эче күгәрә, ди, кызлар, гөрәнкәсе үзеннән дә җиңелрәк икән бу мактанчык борынбайның, алай да тавыш куптармыйк, – диде Зөбәрҗәт. – Җаным сөйми шундый сансызларны.

Тамаша уйлаганча ук барып чыкмаса да, әкәҗан барыбер муенына ләтчә сарылган болгар кызының чәбәләнүеннән канәгатьлек хисләре кичерде. Ни гаҗәп, кыз хәтта төшенә дә күренеп китте сыман. Бәлки, шулай тоелгандыр гына. Һәрхәлдә, бу башындагы бихисап уйның кечкенә кыйпылчыгы иде, шундук онытылды да.

Йокысыннан ул ниндидер чарасыз тавыштан уянып китте. Таң беленеп кенә килә иде әле.

– Йокы бирмиләр, ни бар анда? – дип сорады ул җансакчысыннан.

– Юлбасарларны тотканнар, – диде тегесе, шулар белән мәш киләләр.

Муса тиз-тиз генә киенде дә тышка чыкты.

Кыйбла як офыкка инде алсу төс кунган, күк йөзе ачылып кына килә иде. Кошлар да уянган, ботактан-ботакка куна-куна, Ходайның бу бирмеш матур иртәсен сәламләп, чырык-чырык куанышалар.

Ул әлеге манзараны күздән кичерде дә тавыш килгән тарафка юнәлде. Анда аяк-куллары богауланган юлбасарларны тезеп, типкәли-типкәли каядыр куалыйлар иде.

Яугирәләр да шунда. Муса туры төркембаш Хөсникамал янына килеп:

– Әссәләмегаләйкүм, – дип сәлам бирде.

– Вәгаләйкүмәссәлам, әфәнде, – дип җавап кайтарды Хөсникамал, – әзерләнегез, тиздән кузгалабыз.

– Ә болар? – дип, Муса богаулыларга ым какты, – болар бар бит әле...

– Безнең вазифа юлбасарларны тоту, җәзаны башкалар бирә, әнә, Салкын ташка, җәза мәйданына алып китеп барулары, – диде Хөсникамал.

Муса, дөрес ишеттеме, дигәндәй, бермәлгә тынып калды. Аннан:

– Сез үзегез? – дип, икеләнүен белдерде.

Хөсникамал сәүдәгәрнең тел төбен шундук аңлап алды.

– Әйе, без үзебез, – диде көлемсерәп. – Падишаһыбызның әмере, ә әмер һичшиксез үтәлә.

Муса юлбасарлар, аларны тоту, һөҗүмнәрне кире кайтару турында төпченмәк иткән иде дә, бу уеннан кире кайтты, чөнки Хөсникамал төркембаш кыяфәтендә иде инде: төмсә чырай, сөзмә караш, кырыс килеш-килбәт...

Алай да үтенечен җиткерде:

– Миңа өстәмә сак кирәк булачак, – диде. – Күрәм, монда юллар хәвефле икән, аннан соң...

Төркембаш аны тыңлап бетермәде, бүлде.

– Муса әфәнде, борчылма, без сезне Бүләр-калага исән-имин озатып куярбыз, башыңнан бер бөртек чәчең дә коелмас, малыңа тузан бөртеге кадәр дә зыян килмәс.

– Юк, яугирә... мин...

– Кыз яугирәләргә үзегездән дә артыграк ышана аласыз, килештекме? – диде Хөсникамал инде чибәркәйләргә хас рәвештә күзләрен тәгәрәтеп кенә: – Әйткән сүз – аткан ук.

– Килештек, – диде бу караштан сихерләнгән егет.

***

Мусаның таулар өстендә шундый зур таң яктысын беренче күрүе иде. Әйтерсең лә, Сәмләил фәрештә башындагы энҗе якут таҗының бер бөртеге офыкка өзелеп төште.

Ул күңеленнән: «Сөбеханә Халикун-нур», – дип, җиденче күк тәсбихен кабатлады.

Бераздан күктән Сур быргысы моңына тартым искиткеч аһәңле ашкынулы сайрау авазы иңде. Әкә шуңа мөкиббән булды.

– Безнең тургаебыз, – диде аның янына килеп туктаган Хөсникамал, – кошкаебыз шулай җырлый-җырлый, безне сәфәргә озата.

Тургай, гүя яугирәнең сүзләрен ишетте, аяза барган күккә таба үрли-үрли, төртке чаклы гына булып калып, котып йолдызыдай бер урында тукталып калды. Аннан тирә-юньне илаһи моңга чумдырды.

– Бездә тургай дигән кош юк, – диде кәрванбаш, уфтангандай.

– Тургай бала чыгарганчы гына сайрый шул ул, – диде Хөсникамал, – анысы да иртәнге якта гына. – Аннан сүзен икенчегә борып, көн эссе булырга охшый, сак булыгыз, дип кисәтте.

– Без – чүл кешеләре, – диде Муса, борынын чөебрәк. – Никадәр эссе, шулкадәр яхшы.

Кәрван авыраяк дөяләр көенә салмак кына чакрым саный. Бу басынкы тынлык эчендә ара-тирә атлар пошкыруы, йөкчеләрнең бызырдык авазлары гына ишетелеп киткәли. Юл такыр, тирә-як күркәм. Җир өстенә, гүя биниһая зур келәм җәйгәннәр, дәһри дәрьядай ямь-яшел булып җәйрәп ята.

Тора-бара Хөсникамалның кисәтүе раска килде. Дала бөркүләнеп, ут кабардай булып кызды. Җирдән күтәрелгән кайнар һава иреннәрне киптерә, тамак төпләрен корыта башлады. Кояш та рәхимсезләнде, дөньяны күреккә салгандай көйдерепме-көйдерә. Әлсерәгән кәрван арып-талып, икенде намазы алдыннан гына урман аланына аяк басты. Шунда ялга туктадылар.

Сак өчен эссеме, яңгырмы-буранмы, җилме-гарасатмы, көнме-төнме – аерма юк. Ул һәрвакыт уяу. Бигрәк тә тукталыш вакытында. Юлбасарлар арган-талчыккан кәрванга нәкъ менә тукталыш вакытларында һөҗүм итәләр дә инде. Әле дә яугирәләр кәрванны боҗрага алдылар. Һәр төркемнең үз урыны. Зөбәрҗәтнеке урман авызына туры килде. Аны урнашып җитәр-җитмәс борын ук ниндидер шау-шулы тавыш сагайтты. Тиз генә шул якка элдертте.

Ә анда Муса әкә арба өстенә дрән баганасыдай менеп баскан да, кулларын буташтыра-буташтыра, җанатарларына күрсәтмәләрен бирә иде.

– Чукмар белән, чукмар белән...

– Аңгыра, артыңа кара...

Уф, тагын шул хәерсез борынбай! Күр инде еланнар белән көрәшә башлаган. Көт, тоттыра, ди, елан кавеме. Әнә ничек ыргак башларын күтәреп ысылдыйлар. Чукмарың бармы да юкмы, алай бик бимазаласаң, чагып алырга да күп сорамаслар.

Зөбәрҗәт атын туктатып, бу куышуның мәгънәсез дә, куркыныч та икәнен аңлатмак итте.

– Юкка йөгерешмәгез, еланнар көн кызуында шулай җылынырга җыелалар, – диде. – Көн инде сүрәнләнде, кумасаң да, ояларына таралыр вакытлары җиткән.

– Яугирә, минем җанатарларымда синең эшең юк, кысылма, – дип, еландай ысылдады кәрванбаш.

– Кысылам, минем вазифам шундый, – диде Зөбәрҗәт. – Еланнардан шөлләп, яу куптарган ир-егетне беренче күрүем...

Муса маңгаендагы тир бөртекләрен учы белән сыпырып төшерде дә чаялыгы бөтен килеш-килбәтенә чыккан яугирәгә текәлеп бакты.

Һәм... күзләре әлҗе-мәлҗе килеп, мәче бәбәге рәвешенә керде. Чөнки аңа йокылы-уяулы төшендә мизгел эчендә генә чалынып киткән болгар кызы карап тора иде. Баксаң, чибәркәйнең алтынсу-саргылт чәче, күперенке сусыл иреннәре, күк зәңгәрлегендәге өрфә күзләре, бер учка гына сыярдай йомры ияге күңелендә сурәт булып уелып калган икән.

Могҗиза дисәң дә могҗиза. Ул ни әйтергә белми, каккан баганадай тик катып калды.

– Еланнар таралышты инде, Муса әкә, бу кеше арбасыннан төшсәң дә була, – дип шукланды кыз.

– Синең исемең ничек? – дип белеште егет, ниһаять, аңга килеп.

– Вазифаи исемем Зөбәрҗәт, – диде кыз.

– Минем чын исемеңне беләсем килә.

– Ни хаҗәткә?

– Ни хаҗәткә дип, мин әле өйләнмәгән егет...

– О-о, син куркак кына түгел, хыялый да икәнсең, әкә, – дип көлде кыз. – Мондый очсыз сүзләр белән колагын тешләткән кәләшеңне мыскыл итәргә ярамый бит.

Сүз арты сүз чыгып, кәрванбаш белән яугирә күптәнге әшнәләрдәй бер-берсен бүлә-бүлә, көлешә-көлешә сөйләшеп киттеләр. Муса хәтта кичәдән бирле үзенә тынгы бирмәгән сәер вакыйгага да ачыклык кертәсе итте.

– Кичә ул алыптай гайрәтле юлбасарларны ничек тоттыгыз соң сез, бу һич тә яшь мөслимәләр кулыннан килә торган гамәл түгел ләбаса, шул һич башыма сыймый, – дип, әңгәмәдәшенә текәлде.

Зөбәрҗәт кәрванбашны күз иләге аша уздырып, кулына җәясен алды да:

– Әкә, әнә теге ялгыз кызгылт нарат ботагына кунаклаган кошны күрәсеңме? – дип сорады.

– Күрәм.

– Шул кош утырган ботак очында бер күркә асылынып тора.

– Әйе, тора.

– Ә хәзер ул күркә җиргә тәгәрәячәк.

Зөбәрҗәт җәягә ук саплаган иде инде, шундук очырды да.

– Һоп!

Күркә өзелеп җиргә тәгәрәде.

– Инде шул нарат агачының җирдән ике кылыч биеклектәге гөмбәсенә күз төшер.

– Төшердем.

– Һоп!

Хәнҗәр күз ачып йомганчы гөмбәнең нәкъ уртасына барып кадалды.

– Кылычны йөзгә-йөз килгәндә уйнатабыз, – диде яугирә кынысын сыйпаштыра-сыйпаштыра, без аларга якын килмәскә тырышабыз, бер-икесе дөмеккәч, үзләре аяк астына килеп ава.

– Гадәмеңә хәсәнат, – диде Муса уены-чыны белән. – Олы юлда сезгә очрарга язмасын.

– Кешесенә карап инде, – диде яугирә, – кечелек итсәң, олылык күрерсең, дип өйрәтә безне падишаһыбыз. Ә куеннарында таш йөрткән кара йөрәк бәндәләргә, хак, рәхим-шәфкать юк.

– Шулай да, мин синең белән олы юлда, кече юлда да һаман очрашып торыр идем, – диде Муса, кыздан күзен алмыйча. – Гел-гел...

– Очрат соң, – дип, чырык-чырык көлеп алды Зөбәрҗәт. – Җаны теләгән елан ите ашаган, ди. Хәер, елан синең кан дошманың булса кирәк...

Бу озын буйлы гарәп кәмәше аның үзенә дә ошый башлаган иде инде. Алай сансыз ук түгел икән, әнә, ничек матур итеп сөйләшә, гел-гел очрашып торыр идем, дигән була бит әле, борынбай...

Ир-егеткә гашыйк булу өчен җидегә кадәр санау да җитә, диләр. Муса өчен, күрәсең, бу шундый очрак иде. Кызны да эретте. Шушы чыбыркы сабыдай кыска гына вакыт эчендә алар арасында ниндидер эчкерсез сәрахәтән сәмави мөнәсәбәт урнашты. Алдан сөйләшеп-килешеп куйгандай инде, әнә, тезгеннәрен-тезгенгә урап, урман эченә кереп югалдылар.

Мусаның ата-анасы вафат иде инде. Алар урынына калган бертуган агасы Ясәви әфәнде аны ничек кенә башлы-күзле итәргә тырышмасын, энесе ул сайлаган кәләшләрнең берсен дә ошатмады. Шуннан соң агасы да, теләгәнеңне үзең тап дип, кулын селтәде. Һәм менә Нух каргасы да очып килеп җитә алмастай ерак Идел буеннан килеп тапты кәләшен. Зөбәрҗәтнең әти-әнисе белән танышып, кызларын хәләл җефетлеккә сорады.

– Кызыбыз риза булса, без каршы түгел, – диделәр.

Зөбәрҗәтнең исә шартлары бар иде.

– Мин – җаным-тәнем белән Болгар кызы, яугирә, – диде. – Шулай булып калачакмын да. Үзеңнең илеңдә дә яугирәләр төркеме оештыруыма хәер-фатиха бирсәң, тәкъдимеңне кабул итәм. Калганы барысы да үз карамагыңда калыр, турылыклы, ышанычлы җәмәгатең булырмын.

– Әл-Кадиринең кадере төшмәк әл-мисактан кадир, шәт, вәгъдәләшүебезне Ходай да хуп күрер.

Ярты елдан Муса агасы Ясәви әфәндене ияртеп, янә Болгарга килде.

Никах, туй – барысы да шәригатьчә узды.

***

Бану бикәнең инде хәтсездән тәхет катында булганы юк иде. Хак, Кала тау, Кызлар каласы биләмәләрендә тормыш мәшәкатьләре хәттин ашкан, чара өстенә чара, өлгер генә.

Алай дисәң, тормыш кайда да майланмаган арба тәгәрмәче шикелле шыгырдып бара инде ул. Бикә генә түгел, даирәнең башка әһелләре дә мәликне борчымаска тырыша, читтәрәк торуны мәгъкуль күрәләр. Чөнки сәбәбе җитди – көтмәгәндә, тәхет хуҗасының сәламәтлеге какшап китте. Бурадай булып юанайды, гәүдәсен авырлык белән генә йөртә башлады. Тышау җитмәс кыска муены мичкә рәвешендәге күкрәге эченә кереп батты. Аяк-кул бармаклары өреп кабарткандай каз куыгына охшап калды, чынаяк та тота алмый.

Шуңа күрә үзен сарайга дәшеп килгән чапкынның сүзләре бикәне куркуга салды.

– Әллә падишаһ...

– Падишаһ иртәнге якта сине сарайда көтә, – дип, тегесе аның гөманын өзде. – Соңлама!

Соңлыймы соң, иртүк сарай бусагасына барып баскан иде инде. Сүз кайтарып сөйләшмәскә, мәликне генә тыңларга, дип кисәттеләр үзен.

Силки мәлик аны күргәч елмаерга тырышып караган иде дә, бу омтылыш йөзен генә чалшайтты. Бану аягы астына барып ауды да яшен күрсәтмәс өчен камзул итәкләрен йөзенә каплады.

– Падишаһым...

Мәлик аның башын сыйпагандай итте.

– Бикә, м-и-и-нем го-ме-р са-нау-лы, ва-а-а-ри-сым олуг улым Ал-мы-ы-ш. А-ңа те-е-рәк бул...

Шуннан соң сулышы авырлашты, гыж-гыж килеп туктап калды.

– Ант итәм, падишаһым!

Шул көнне кичкә таба Силки мәликнең гомере өзелде.

*Тарихи белешмә:*

*Болгар дәүләт буларак, оешу, ныгу чорын гына кичерә иде әле. Болгар дигән гомуми атамада бердәм халык тагын ике йөз елдан соң, ягъни XII гасырда гына тәгаенләнәчәк.*

*Олпат галимебез Шиһабетдин Мәрҗани язып калдырганча, Болгар мәмләкәтендә булган һәр кабилә бер урынга, бер су буена урнашып, төрле исемнәр белән аталып йөртелгән. Мәсәлән, Чирмеш болгары, Нократ*

*болгары, Бәхре Хәзәр болгары, Түбәнге болгар, Тимтүче болгар. Бу күптөрле кабилә, нәсел һәм сыйныфларның кабилә, ыруг патшалары үрнәгендә үз хакимнәре булган. Билгеле инде, һәркайсы үзен генә хуҗа итеп санаган. Өстәвенә, монда күпләп фин-угор кабиләләре дә гомер сөргән. Мондый этник төрлелек, аңлашыла, каршылыклар да тудырган.*

Силки мәликнең вафаты әлеге каршылыкларны тагын да кискенләштереп җибәрде. Моңарчы да баш бирергә атлыкмаган суарлар тәмам йөгәннән ычкынды. Үз акчаларын сугалар, үз гаскәрләрен тоталар, үз илчеләрен тәгаенлиләр. Соңгы кыланмышлары яшь хакимне зур борчуга салды. Бакырбашлар яу белән килгәндә, Вираг бәк орышка сыңар яугир да җибәрмәде. Хәлбуки, мондый хәлнең булганы юк иде.

Тәхет иясе вазифасында бу – Алмышның тәүге орышы иде. Ул аның тулы җиңелүе белән тәмамланды, аздан гына әсир төшми калды. Аны орыш кырыннан аерып алып, тау итәгенә кысрыклаганда, бәхетенә, эзәрлекләүче бакырбашларның берничәсе аты-ние белән яр астына мәтәлде. Шулай гына котылып калды.

Билгеле, бу очраклык кына. Ә бит зарурилык очраклыклардан тәгаенләнә. Менә монысы кутыр өстенә чутыр инде. Димәк, үткән эшкә салават, яңача яшәргә кирәк.

Тик ничек?

Алмыш хәзерендә көне-төне шул хакта баш вата, очына гына чыга алмый, әйләнчек бәрәндәй һаман атасы идарә иткән чорга килеп төртелә.

Силки мәлик кояшка табына иде. Авыр вакытларда иртән иртүк Кала тауның кеше йөрми торган иң биек очына менеп баса да башын күккә чөеп, чыгып килгән кояшка гозерен җиткерә, догага ойый иде. Мөгаен, атасының абруе (ә ул абруйлы иде) шушы догаларга барып тоташадыр?

Ул исә, дуамал бәндә, асыл булышчысына кадер-хөрмәт күрсәтәсе урынга, үзлегеннән нидер кылмак булып азаплана.

Кала тау түбәсе хәсәнәи мәҗүсиләрнең догада ою урыны. Анда кышның кыш буе буран себерә, җәй көне тәмугтагы шикелле эссе була.

Алмыш та атын, җансакчыларын тау итәгендә калдырып, югарыга күтәрелде. Кояшның тау артыннан яңа чыгып килеше. Таң кызыллыгы әкрен-әкрен җәелә-тарала бара. Дала ягыннан зәңгәр елгадай җил дә агыла башлады. Дөнья әкияти тылсымлы манзарага охшап калды.

Әй, Кала тау, Кала тау,
Ата-бабам үскән җир!
Әй, Кала тау, Кала тау,
Ак болытлар туган җир!

Кояш бер карыш күтәрелүгә, Алмыш тезләнеп, догага оеды.

– И җиһанны яшәтүче олуг мәрхәмәт иясе, якты вә нурлы игелекле Кояш! Миңа, Болгар дәүләтенең хакиме Алмыш мәликкә, һидәятеңне ач, олы юлга чыгар, дәүләтебезнең иминлеген, бөтенлеген саклау мәнфәгатьләрендә миңа ни-нәрсә эшләргә, киңәш-табыш ит.

Аңа таулар артыннан кайтаваз булып, ниндидер тонык тавыш ишетелгәндәй булды.

– Яу ча-а-а-п... яу...

Ул әлеге тавышның янә кабатлануын көтеп, кат-кат догага оеды. Ләкин тавыш кабатланмады.

Бу аның күңелендә тәгаенләнеп килгән тынгысыз уйның гына аваз салуы иде, әлбәттә. Ничек кенә булмасын, Кала таудан ул йөрәгенә нәкъ шушы фикерне сеңдереп төште.

Җансакчылары ниндидер бер сәер адәмне уратып алганнар иде.

– Кем бу, ни кылып йөри? – дип сорады.

– Үзе җавап тотсын, безгә берни әйтмәде, – диде сакбаш. – Шикле адәм.

Чыннан да, бу таш-тау арасында әлеге ят кешенең өс-башы ук мантыйкка туры килми иде. Аяк йөзенә кадәр төшеп торучы, әвәлге төсен югалтса да, бернинди тапсыз чиста хөлләсен билбау белән бәйләп куйган, аркасында биштәр, башына калын итеп, соры чалма ураган, кулында шомарып беткән озын артыш таяк.

– Син кем, илең кайда, шөгылең ни? – дип сорады Алмыш кырыс кына.

– Мин Хәмид бине Мөнтан булам, мөсафир, олуг пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вәссәлам белән кабиләдәш, көрәешле, Хозер галәйһиссәламнең дәвамчысы. Ә яшәү урыным Аллаһы Тәгалә бар кылган бөтен җиһан. Миңа чикләр юк, бүген монда, иртәгә тегендә. Атыла юлым мәшрикъ һәм дә мәгърибкә табан.

– Ә шөгылең? – дип ашыктырды мәлик.

Мосафир сөзмәле очлы карашын батырып, кулындагы дисбе җебендәге хөрмә җимеше төшләрен бармаклары аша үткәрә-үткәрә, Алмышның соравын җаваплады.

– Ялан-кырларда йөрим, бураннарда-яңгырларда адашкан дәрвишләргә, ил гизүчеләргә юлдаш сыйфатында ярдәм күрсәтәм. Янә дә төрледән-төрле потларга табынучы адашкан мәҗүсиләрне хак юл – Аллаһы юлына кайтырга, иман китерергә булышам.

Раббыңны олыла!

Киемнәреңне пакь тот!

Һәм поттан качып кит!

– Минем Аллаһым – Кояш, – диде Алмыш, күктә балкыган якты җисемгә башын иеп. – Тереклекне Кояш яшәтә.

– Кояш, хөрмәтле таждар, Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә бар кылган дөньяның бер кисәге генә, – диде мосафир. – Кояшка табыну – юлда аунап яткан таяк кисәгенә табыну белән бер. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә бәндәләргә мөрәҗәгать итеп, Үзенең бердәнберлеген түбәндәгечә белдерә: «Ий, кешеләр! Сезнең Иләһегезнең тиңдәше юк – бер генә Иләһедер».

Хак, Аллаһының барлыгына һәм берлегенә иман китерү өчен шиксез ачык дәлилләр бар.

Мөсафир, тыңлыйсыңмы, дигәндәй, Алмышка күтәрелеп карады да, тегесенең күзләрендәге кызыксыну чаткыларын күреп, сүзен дәвам итте.

– Менә син әйткән кояшны гына алыйк. Дөрестән дә, кояш Аллаһы Тәгалә тарафыннан җирдәге тереклекне дәвам иттерү өчен яратылган җисем. Коръәни Кәримдә кояшка «Шәмсү» сүрәсе багышлана. Ул үз вакытында чыга, үз вакытында байый, күктә балкыган вакытында җиһанны яктырта, тереклекне яшәтү нурлары белән туендыра. Саный китсәң, күп аның күркәм сыйфатлары. Әмма ул җансыз, хәрәкәте Аллаһы көйләгән яссылыкта гына башкарыла...

Сакбаш, сүзең озынга китте, дип булса кирәк, мосафирны сукмактан читкәрәк этеп төшермәк иткән иде дә, мәлик аны күз карашы белән генә туктатты.

Моны Мөнтан сизде, димәк, әңгәмәсенең төп төенен сүтәргә вакыт.

– Таждар, миңа синең ни борчу белән Кала тауга килүең мәгълүм, – диде, – ошбу җәһәттән дә иң беренче Аллаһы Сөбханәкәгә таяну зарур. Ул кешеләргә: «Ий, мөэминнәр, әгәр сез Аллаһы дине – Исламга ярдәм бирсәгез, Аллаһ сезгә дошманыгыз өстенә ярдәм бирер», – дип, үзе юл ача.

Хак, Аллаһы Тәгаләгә ышану – нигъмәттер.

– Җә, хуш, – диде Алмыш, мосафирны күз элмәгенә алып. – Аңлашылганча, Аллаһы көч куллануны, яу чабуны хуплый, шулаймы?

– Яуларның мәсләгенә карап инде, – диде Мөнтан. – Ә уртак мәмләкәт булып яшәү өчен халыкларның, барыннан да элек, рухи яктан бербөтен булып оешуы шарт. Ислам дине исә әнә шундый бөек берләштерү көченә ия дә инде.

– Мосафир, – диде Алмыш җитди генә. – Бик мәгънәле сүзләр сөйлисең, аларны юл өстендә генә күңелгә сеңдерү бик авыр, әйдә, киттек минем белән, сарайда яшәрсең, үзеңне киңәшчем вазифасына куярмын.

– Олылавың өчен тәшәккүрдән гаҗизмен, таждар, – дип, түбәнчелек белән башын иде Мөнтан. – Мин, инде әйтүемчә, Хозыр галиһиссәламнең дәвамчысы, яшәвем дә табигать кочагында, утрак тормыш миңа ят.

– Кызганыч...

– Борчылма, таждар, синең янәшәңдә генә зур гыйлем иясе, ырудашым Хөсәен бине Ибраһим дамелла яши, – диде мосафир. – Мөхтәрәм Бану бикәнең рухи остазы.

Алмышның битенә бызылдап, черки килеп кунды. Аны куган арада мосафирдан җилләр искән иде инде.

Могҗиза арты могҗиза, дигән уй йөгереп үтте башыннан, моның бер хикмәте бар, әлбәттә, бар.

Алмыш мәлик беренче эш итеп, Бану бикәгә чапкын җибәрде.

Алмыш атасы Силки мәлик шикелле үк тулы гәүдәле, озын буйлы, купшак тәнле кеше иде. Йодрыклары түмәрдәй, аяк ботлары – бастырык. Беренче карашка, мендәренә генә чумып утыра торган ваемсыз инсани затка охшаган. Чынында исә, ул тынгы белмәс ифрат тере кеше иде.

Бану бикәне дә урыныннан торып, ишек катында каршы алды, беренче булып үзе сүз катты:

– Бикә, мөселманнар ничек сәламләшә? – дип белеште.

Бану җавап бирергә ашыкмады, аптырабрак калды, чөнки Болгарда мөселманнар шактыйга җыелса да, гореф-гадәтләренең моңарчы тәхет катына үтеп кергәне юк иде әле. Яшь мәликнең үзенә чын кызыксыну белән карап торуын күргәч кенә:

– Без «Әссәламегаләйкүм», дип сәлам бирәбез, «Вәгаләйкемәссәлам», дип җавап кайтарабыз, – диде.

– Ә мәгънәсе нидән гыйбарәт?

– Гыйбарәнең турыдан-туры тәрҗемәсе түбәндәгечә: «Сезгә тынычлык булсын!» Мәгънәсе исә мәшругәнә киң. Мөхәммәд пәйгамбәрдән сорыйлар: «Йә, Расулуллаһ! Исламда нәрсә иң хәерле?» Әйтә Расүлуллаһ: «Ризык биреп ашату һәм сәлам бирү, – дип, – аны тыңласаң да, тыңламасаң да».

– Күрәм, ислам бик игелекле дин икән, – дип, бәясен чыгарды Алмыш.

Утырышып, җимешләрдән авыз итеп, ширбәтләр эчеп, сусауны басканнан соң да, ислам дине белән кызыксынуын дәвам итте ул. Иң кирәкле соравын әңгәмә ахырына калдырган иде.

– Бикә, дөресен генә әйт әле, ислам динен тоту авырмы? Иң мөһиме, аның өстенлеген нидә күрәсең?

Бануның карашы җитдиләнде, иреннәре кысылды.

– Бик катлаулы сорау бирәсең, мәлик, – диде бераз уйланып торганнан соң. – Бу дин әһелләре вазифасы, ә, шәхсән, минем үземә килгәндә, әгәр иман китереп, Аллаһының берлегенә, Мөхәммәднең пәйгамбәрлегенә ихластан инанасың икән, авырлыгы юк. Ә өстенлеге шунда, шәригать инсанны илаһи бер тәртиптә тота. Шуннан чыгып, мин җиһанның киләчәге ислам динле дәүләтпәрвәр кулында, дип саныйм. Бу хакта мин сиңа Хөсәен бине Ибраһим дамелла белән әңгәмә корырга тәкъдим итәр идем. Зур гыйлем иясе, үкенмәссең.

Алмыш, гадәттәгечә, башын юлпычтай киң учларына салып, бүгенге хәлләрне күңел иләге аша үткәреп, уйланып утырды. Чөнки нәкъ менә бүген үзенә тынгы бирмәүче, йөрәгенә таш кебек утырган борчуларына дәва булырдай өметле тәкъдим-тәкбирләр ишетте. Болгар мәмләкәте шартларында, барча кабилә-ыруларны да берләштерүче уртак дингә килү, ихтимал, мөмкин дә түгелдер. Әмма шунысы хак, Ислам дине ошбу максатларда башкалардан өстен икән. Һәрхәлдә, уйланырга, өйрәнергә, киңәш-табыш итәргә урын бар. Һәм бу җәһәттән ул бөтен тырышлыгын куячак. Аккан-тамган су булган, калган-тоткан ил булган. Әйе, биле ныкның гына иле нык булыр, дигән бабаларыбыз да.

Алмаш әле генә йокыдан уянгандай, күзләрен угалап алды да:

– Бикә, әңгәмәбез минем өчен бик файдалы булды, рәхмәт, – диде. – Янә бер киңәшеңне тыңлыйсым килә.

– Баш өсте, падишаһ!

– Хөсәен бине Ибраһим дамелланы үз яныма сарайга алмакчымын, киңәш ит, бу ниятемә мөнәсәбәтең ничек?

– Бик хуш, падишаһ, хуплыйм.

***

Тарих тугыз йөз дә егерменче елның җәендә Алмыш мәлик әмере белән Болгар илчесе Габдулла ибне Башту Багдад хәлифәте башкаласына аяк басты. Аңа моңарчы да күп кенә мәмләкәтләрнең шәһәр-калаларында булырга туры килә иде. Тик аларның берсе дә Багдад белән тиңләшә алмый икән. Зурлыгы ягыннан да, төзеклеге, яшеллеге, матурлыгы ягыннан да Багдад чагыштыргысыз. Манаралары күккә ашкан алтын айлы мәчетләре, гүя галәм киңлекләренә омтыла, шәһәр менә-менә сәмруг кош кебек канатларын җәяр дә очып китәр сыман.

Алыш-биреш, сәүдә рәтләре – үзе бер мавыктыргыч дөнья. Ул әлегәчә үз иленең Биләр янындагы Ага Базардан да зуррак вә байрак базар булуы мөмкин түгел дип уйлый иде. Ә монда, сөбханалла, каланы тоташ базардан гына тора диярсең. Җаның ни тели, рәхим ит, тиешлесен түлә дә, букчаңа сал.

Патша сарае – бу инде бөтенләй башка чут. Чын мәгънәсендә алтын-көмештән, энҗе-якутлардан тукылган Багы Ирәм – җирдәге оҗмах оясы. Ул Мөхәммәд галәйһиссәламнең Мигъраҗ хатирәләренә охшатып, шул

үрнәктә корылган. Пәйгамбәребез исә Аллаһы Тәгалә катына аяк басуын түбәндәгечә тасвир итә: «Каршымда кояшка охшаган якты нурлы, яшел палас күреп, күзем камашты. Ир булды, өстенә басып, җитмеш мең пәрдә үттем. Рафраф, ягъни яшел палас Гареш[1] янында тукталды. Гарешне һәр нәрсәдән өстен күрдем. Гарештән бер тамчы тамып, телемә төште. Андый ләззәтле нәрсәне телләр татыганы юк иде...»

Бу гайре мәгъруф күренеш түгел, багдадлыларның тумыштан гарше әгъляларга җилкенгән күңел халәте иде. Ник дисәң, Багдад хәлифәтенә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлламнең агасы Габбас хәзрәт нигез салган. Әл-Мажур, әл-Мәһди, Һарун ар-Рәшид хәлифәләр чорында хәлифәт тагын да күркәмрәк үсешләргә ирешә. Хәзерендә дә шул ук мөхтәрәм Габбас хәлифәләреннән әл-Мөгътәдир биллаһ хакимлегендә гомер кичерә.

Биллаһ ир уртасы кеше икән. Сакал-мыегы гарәпләргә хас рәвештә кыска итеп кистерүле. Шуңа күрәме, читтән сакал-мыегы ябыштырып кына куелган кебек күренә. Гомумән, аның йөз-кыяфәте, ялтыравык ыспай киемнәре, хәтта бизәкле тәхете дә, рәссам тудырган сурәткә охшап тора иде.

Мәгълүм ки, гарәп хәлифәләре ашаган-эчкән вакытта мөнбәр бүлмәсендә җыр-бию тавышларының яңгырап торуы фарыз. Әле дә бүлмәгә шушы әкияти дөньяга әкияти матурлык өстәп, аккоштай канатларын кага-кага әкияти гүзәл җарияләр кереп тулды. Барысы да бериш, сыгылмалы буй-сыннары бериш, асылташлар белән бизәлгән нәфис баш киемнәре, ымсындыргыч гәүдәләренә сыланып торган киң итәкле озын күлмәкләре бериш. Шунда ук субра-моңчылар арфа кылларын тибрәтеп җибәрде, аларга ашкынулы думбра кагучылар кушылды. Җарияләр үтә күренмәле өрфә иңсә япмаларын җилфер-җилфер уйната-уйната, бүлмәне әйләнеп чыктылар да кулларындагы озын борынлы кувшиннарыннан бәллүр касәләргә күз яшедәй чиста шәраб тамызып, хәлифә каршына килеп тезелделәр.

Хәлифә һәр касәгә иреннәрен тигезеп куйды да:

– Кунакларымны, даирәмне сыйлагыз, – диде.

Җарияләрнең берсе Башту илче алдына да килеп, тез чүкте.

Якыннан ул әкияти булып тоелмады. Күренеп тора, рәссам сурәте. Мул итеп иннек сөрткәннәр, кашларын каралтып-сызып, кош канаты рәвешенә керткәннәр, күзләренә шулай ук бик мулдан сөрмә тартылган, буяу сыланган иреннәр...

Әмма ошбу «ваклыклар» дикъкать белән караганда гына беленә. Чөнки аларны йөздәге төтендәй юка сөтрә – бит пәрдәсе үз эченә томалый иде.

Афәрин, күзгә төтен дә җибәрә белә икән гарәпләр!

– Рәхмәт, – дип, ул җариянең учына бер алтын динар салды.

Ашау-эчү һәм сөйләшү-гәпләшү бер-берсенә үрелеп барды. Бераздан хаким карашы белән Баштуны эзләп тапты да:

– Җә, илче, сине нинди мәшәкатьләр йөртә? – диде. – Мәсләгеңне даирә алдында да шәрехлә.

Ул илчене кабул иткән иде инде. Аңарда бигрәк тә Багдад белән Болгарның Хәзәр каһанына каршы килешү төзү тәкъдиме зур кызыксыну уятты. Ошбу җәһәттән һәр ике дәүләтнең дә сәяси юнәлешләре тәңгәл килә иде.

[1] Гареш – тәхет.

Болгар өчен бу аеруча зарури. Ник дисәң, Болгар Хәзәр каһанлыгы бишегендә туган яшь дәүләт. Дөресрәге, кануни яктан караганда, ул аның фәкать бер өлкәсе генә булып санала. Алай гынамы, Силки мәликнең кызы көчләп, яһүд динле каһанга кияүгә бирелә, ә Алмыш илтәбәрнең улы каһан сараенда тоткын хәлендә яши. Һәм иң үкенечлесе: күрә торып, шушы гаделсезлекне эчеңә йоту.

Әлеге килешүне мәлик үзе, тулы мөстәкыйльлеккә ирешү юлында бик үтемле адым булыр, дип фаразлый иде. Хәлбуки, ике арадагы бәйләнеш инде сүнеп, пыскып бара, Болгар хәзер үз акчасын суга.

Багдад исә Хәзәрнең көчәюен теләми. Төбәкара йогынты мәсләгендә дә алар көндәш. Болгарның теләктәшлеге, һичшиксез, файдага гына булачак.

Башту – тәҗрибәле илче. Даирәне күз уңыннан үткәрде дә сүзен тәхет иясенә мөрәҗәгать итүдән башлады:

– Ислам дөньясының бөекләрдән-бөек тәкъваи башлыгы, җиңелү белмәс Габбасия хәлифәтенең гаделләрдән-гадел падишаһы, барча мөселманнарның тиңдәшсез дусты һәм ярдәмчесе хөрмәтле биллаһ Әбел-Фазыл Җәгъфәр бине әл-Мөгътәзыйд хәлифә хәзрәтләре Сезгә Аллаһының рәхмәте белән Болгар мәмләкәтенең кануни падишаһы Алмыш мәликнең эчкерсез сәлам вә котлауларын ирештерергә рөхсәт итегез.

Мөгътәдир хаким аның мәдхиясен ошатты булса кирәк:

– Болгар падишаһы Алмыш туганыма минем сәламнәремне дә ирештер, Ходай аңа озын гомерле тәхет насыйп итсен, – диде.

– Баш өсте, мөхтәрәм хәлифә, сезнең сәлам вә теләкләрегез падишаһыбызга яңа көч һәм дәрт өстәр, – дип, илче бүләк өлешенә күчте. Ым кагуга, хезмәтче егетләр Тугыр агачы алып керде. Аңа көмеш чылбырга уралган данлыклы ау кошлары-шоңкарлар кунаклаган иде.

Тугры юк шоңкармын,
Ту җебендә очармын.
Тугалы юк ялгызмын,
Күпне күзләй күчәрмен.
Канатны канга тигезмәм...

Баштуның теле телгә йокмый, шоңкарларга зиннәтле эчле чапан, сөттәй ак чалма кисеясе, өске җилкә япмасы, башлык, пута кебек күз явын алырдай матур кием-салымнар өстәлде. Алар барысы да алтын-көмеш, укалы җепләр белән тегелеп каймаланган, кыйммәтле асылташлар белән бизәлгән иде.

Ул төп игътибарны аеруча «Болгар олтан» исеме белән дөньяга танылган сәхтиян читеккә юнәлте.

Аягыңда читегең,
Болгар икән олтаны;
Сине сөйми, кемне сөйим,
Син бит егет-солтаны.

Бүләкләр тәхет хуҗасының күңеленә хуш килде. Аларны тапшырганда, ираннәре гел мелт-мелт итеп торды. Шул ук вакытта төрттереп куюны да кирәк санады, күрәсең.

– Җә, ничек, илче, җариядәремне ошаттыңмы? – дип, күзләрен уйнаклатты.

– Мәшһүр Багдад хәлифәсенең җарияләре җиһанда бер инде ул, – диде Башту. – Аңа тиңнәр була алмый.

– Юк, илче, минем гаремымның бер бик зур кимчелеге бар, ныклабрак уйлап кара әле.

Шаярта, дип куркуга төште Башту. Чөнки белә, хакимнәрнең шаяртуы ике башлы таяк кебек ул, еш кына баш тәгәрәү белән тәмамлана.

– Мин бернинди кимчелек тә күрмим, падишаһ...

– Колагыңа киртлә, – дип, бармагын янагандай итте хаким. – Минем гаремымның кимчелеге шунда: анда болгар чибәре юк.

– Булыр, падишаһ, сүз бирәм, – дип, җиңел сулап куйды Башту, – мәлигебез ошбу кимчелекне төзәтер.

– Инде озын сәяхәтеңнең максатын шәрехлә, – диде тәхет иясе.

– Падишаһыбызның максаты аның хатында тәфсилләнә, миңа аны шәрехләү вәкаләте бирелмәгән, – диде илче. – Мин бары җавап кына алып кайтырга бурычлымын.

– Бик хуш, синең өчен очрашу шушының белән тәмам, хат буенча минем шәрәфле җавабымны җиткерерләр, – дип, хәлифә баш бармагын тырпайтты.

Ул «Багдад – Болгар – Хәзәр» мәсьәләсендә карарын кабул иткән иде инде. Даирәсе белән фәкать мәликнең башка үтенечләре буенча гына киңәшүне кирәк тапкан иде. Шуңа күрә сүзне кыска тотты.

– Сәкалибә патшасы Алмыш бине Силки белекварь, белүегезчә, үзенең миңа язган хатында илнең барлык шәһәрләрендә һәм төрле якларда торып, ислам динен һәм шәригатен өйрәтерлек галимнәр, мәчет һәм мөнбәрләр ярдәмендә чит ил патшаларының явыз таләпләреннән сакланыр өчен шәһәренә кальга-крепость төзергә осталар җибәрүне сорый. Шулай ук Ислам динен дәүләт дине итеп игълан итү карарына килүен дә белдерә. Шушы уңайдан сезнең фикерләрегезне дә ишетәсем килә.

Беренче булып, арада хәлифәнең иң яшь ышанычлылар рәтендә йөрүче Баязит солтанның башы калыкты. Солтан вәзирлеккә дәгъва итә, шуңа күрә, һәр ярыкка чөй дигәндәй, урынлымы-урынсызмы, үзен күрсәтергә, әлеге вазифага аннан да лаеграк, аннан да акыллырак дәгъвачы юк икәнен хәлифәнең күңеленә сеңдерергә тырыша. Хаким үзе дә аңа хәерхаһ. Шунлыктан башкалар бу яшь тайның кыланмышына тешләрен кысып булса да, түзәргә мәҗбүр.

Әле дә дрән баганасыдай озын гәүдәсен бишкә бөгеп, тәхет иясенә салават җырларга тотынды.

– И-и мөхтәрәм падишаһыбыз, сез әнтә нурун фәүка нур җәнабе гали, бар җиһанда бердәнбер...

– Фикереңне әйт, – дип бүлде аны хаким. – Вакытыбыз тар.

– Баш өсте, мөхтәрәм падишаһыбыз...

Солтан берара ни әйтергә белмичәрәк торды да эре тешләре арасыннан үзенең дә һушын алган казалы җөмлә очырды.

– Мин... каршы... падишаһ...

Мөгътәдир биллаһ әллә ишетте, әллә ишетмәмешкә салынды, әллә бүтән берәр сәбәптән, кул ишарәсе белән генә дәгъвачыны урынына утыртты да:

– Җәгез, тагын кемгә сүз бирәбез? – дип, каршыдагыларга күз атты.

Ә даирә телен тешләде, берәүнең дә үз фикерен әйтергә кыюлыгы җитми. Ник дисәң, алар, хаким үзенең Болгар патшасы хатына мөнәсәбәтен Баязит солтан аша белдерде, дигән нәтиҗәгә килгәннәр иде. Димәк, ул да каршы...

– Җә?!

Шулай да, шомлы тынлыкны кемдер бозарга батырчылык итте.

– Мөмкинме? – дип, урыныннан торып басты.

– О-о, Сәһсән әр-Рәсиби! – дип, биллаһ та аны күтәреп алды. – Әйдүк-әйдүк.

– Түбәнчелек белән гафу үтенәм, мин, шәхсән, Баязит солтанның нинәрсәгә каршы икәнен төшенеп җитмәдем, – диде Сәһсән, шартлап торган тавышы белән бүлмәне яңгыратып. – Шуңа күрә, әгәр яраса, әлеге мәсьәләгә ачыклык кертергә кирәк, дип саныйм.

Ул хәлифәдән хуплау көтеп, тынып калды.

– Тыңлыйм, дәвам ит, – диде хәлифә.

– Болгар патшасының үтенечен канәгатьләндерәме-юкмы, дигән сорау, гомумән, урынсыз, – диде Сәһсән сүзләре белән таш яргандай, үзенә бер ярсу белән. – Бу безнең изге бурычыбыз. Чөнки бу пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлламнең васыяте!

Гәүдәләр турайды, башлар алга сузылды.

– Онытканнарның исенә төшерәм, белмәгәннәр белеп калыгыз, – дип дәвам итте солтан. – Пәйгамбәребез даирәсендә төрки телне белүчеләр дә күп булган. Шуларның берсе, Расүлуллаһның ихтыяры белән бер төрки халыкка хат белән мөрәҗәгать иткән. Кызганычка, әлеге хат нишләптер онытылган. Ә кайсы халыкка юнәтелгән икән соң ул? Бу заманда Гарәп, Шам илләрендә, Рум мәмләкәтләрендә төрки телдә сөйләшүче халык юк иде. Кытай да Каф тау артында. Хат, бәлкем, якындагы халыкка аталган булгандыр? Әйтик, Болгарга.

Хак, шулай. Ул инде исбатланды. Мәгълүм ки, Гарәп халкы ислам дине барлыкка килүгә, Болгар дәүләте белән эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштырган. Гарәпләр, мәсәлән, Болгарның бер елгасы тирәлегендә көмеш ятмасы табып, аны сәнагати дәрәҗәдә эшкәртүгә ирешәләр. Әлеге елга тора-бара гарәпчә «Нократ елгасы» дигән атама ала. Ә «нокрә» эретелгән көмеш дигән сүз. Бу төбәктәге халык «Нократ болгарлары» дип йөртелә башлый. Нократ исемендә вак көмеш акча да сугалар.

Аңлатмам кыскача менә шушы, – дип, башын иде Сәһсән. – Карар, мөхтәрәм падишаһ, сезнең ихтыярда.

Мөгътәдир биллаһның карары әзер иде инде, әлбәттә. Сәһсән әр-Рәсибигә туп-туры карап, әмерен ирештерде.

– Солтан, сине болгар патшасы Алмыш белеквар үтенечен тормышка ашыру буенча рәсми илчем итеп билгелим, төркемегез биш йөз инсанга исәпләнә. Белгечләрне сайлау хокукын да сиңа йөклим. Кятибең каләмкәш Әхмәд бине Фадлан булыр. Карарымны илчегә җиткер.

– Баш өсте, падишаһ.

– Тәмам!

***

921 ел, июнь ае, 11 нче көн.

Сарай мәйданы иртә таңнан гөж килеп тора, әйтерсең лә, Нәүруз бәйрәменә җыелганнар. Ашкына-ашкына дум-думбак кагалар, эреле-ваклы

быргы тавышлары яңгырый, пыр тузып, биеп тә китәләр, хәтта ара-тирә колакларны сузынкы моңлы җырлар да иркәләп алгалый. Күрәсең, ошбу «иркенлек» дин әһелләре белән алдан килештереп куелган иде. Шулай булмыйча, Багдад бүген Болгар җиренә илчеләр озата.

Табигать-Ана да бәйрәм хозурында. Ә күк әле генә яралган диярсең, чип-чиста, зәңгәрсу офык читенә эленгән үтәкүренмәле аксыл болыт челтәрләре дә бу пөхтәлеккә самими бизәк кенә өсти иде.

Яшел куаклар эчендә илаһи күләгәсе төшкән мөэмин-мөселманга бәхет иңдерүче риваяти һөмә кошларына охшаш сары түшле, йомгактай йомры әһле канатбикәчләр сайраша.

Мөгътәдир биллаһ хәзрәти киемнән иде. Өстендә бернинди бизәксез гадидән-гади киң итәкле тафта хөллә, башында шулай ук гадәти чалма. Ул фәкать иясенең шәрәфле дәрәҗәсенә ишарә сыйфатында зурлыгы белән генә аерылып тора, кисвәгә тукыма кызганмаганнар.

И-и, Алмыш падишаһның бүләк киемнәрен кияргә иде, Болгар муллалары да моңардан затлырак киенә, дип уйлап куйды илче Башту.

Хәлифәнең исә үз мәнфәгате, үз киштәсе. Соңгы вакытта кайбер үтә кадими тәкъваи әһелләр аның алтын-көмеш, кыйммәтле асылташлар белән мавыгуын дин кануннарыннан читләшүгә тиңләп, ризасызлык белдерә башлаганнар иде.

Болгар сәфәре, һич уйламаганда, шундыйларның авызын томаларга бик тә вакытлы мәслихәт гамәл булып чыкты. Шуңа күрә үзе катнашында шушындый тантаналы, шау-шулы озату оештырырга кирәк тапты да инде. Өс-башы да әлеге максатны күздә тотып сайланды. Бу Мәдинәтес-сәлам[2] Җәмигъ мәчете имам-хатыйбы, олуг илаһиун Әкрәметдин хәзрәт киңәше иде.

– Холәфаи рашидин тәкъваи затларның тәҗрибәсе бик кулай булыр, – диде.

Мөгътәдир, билгеле, Расүллулаһтан соң килгән дүрт хәлифә – Әбүбәкер, Гомәр, Госман, Гали хәзрәтләрнең – Хөләфаи рашидин атамасында йөртелүеннән хәбәрдәр иде, әлбәттә.

– Ошбу гасре сәгадәт дәверендә яшәгән мөхтәрәм хәлифә-сәхабәләр пәйгамбәребез үрнәгендә үзләрен бик тыйнак тотканнар, кием-салымнары да халыкныкыннан аерылып тормаган, – дип шәрехләде үзенең тәкъдимен имам-хатыйп.

Өйлә вакыты җиткәнен белдереп, азан тавышы яңгырады.

– Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр!

Халык бер сулышта намазга басты. Хәлифә намазлыгын «Болгар сәфәре» әһелләре илче Сәһсән әр-Рәсиби, кятиб Әхмәд бине Фазланнар белән бер рәткә җәйде.

– Әй, Аллаһы! Без Синнән бу сәфәребезгә изгелек, тәкъвалык һәм Син риза була торган гамәлләр итүеңне сорыйбыз. Әй, Аллаһы! Безнең бу сәфәребезне җиңеләйт һәм аның ераклыгын кыскарт. Әй, Аллаһы! без Сиңа сыенабыз!

Намаздан соң «Болгар сәфәре» юлга кузгалды.

*Тарихи белешмә:*

*Ярдәм мәсләгендә туган ошбу сәфәр Болгар җирендә моңарчы дөньяның бер кыйтгасында да күрелмәгән инкыйлабка тиң дәүләти вә җәмгыяви, тәкъваи вә мәдәни миссия рәвешендә тәгаенләнәчәк. Ислам динен рәсми дин буларак тану*

[2] Мәдинәтес-сәлам – Багдад шәһәренең икенче исеме.

*дәүләтчелек институтын югары сәяси мөнбәргә күтәрү белән беррәттән, икътисадны үзгәртеп коруга, фән, мәгърифәт, мәдәният һәм сәнгать үсешенә тәрәккый вә тәгали кимәлдә яңа сулыш өрергә киң мөмкинлекләр ачачак.*

*Шул рәвешчә, бу чор тарихка болгар һәм кардәш кабиләләрне берләштерүне, нигездә, төгәлләү, төньякта болгарларның үзәкләштерелгән яңа дәүләтенең – Идел Болгарстанының оешып җитү чоры булып теркәләчәк.*

*Алты гасырдан соң Идел буе төркиләренә «Болгар сәфәре»нә охшаш тагын бер тарихи вакыйганың эчендә кайнарга туры киләчәк әле.*

*Алтын Урданың унсигез ел тәхет тоткан Олуг Мөхәммәд ханны көндәшләре башкаладан куа. Хан Урдасын алып, кайчандыр үзе бөек кенәзлеккә фатиха биргән Василий II янына, Мәскәү тарафларына юл тота. Максаты – бөек кенәз ярдәмендә гаскәр туплау һәм дошманнарын тар-мар итеп, тәхетен кире кайтару.*

*Ләкин Василий инде игелекләрен оныткан, остазын ядрә коеп каршы ала. Көче дә бар, 41 мең гаскәриле армиясе һөҗүмгә әмер генә көтеп тора.*

*Олуг Мөхәммәд кул астында исә аналар, балалар, картлар-карчыклар... Нибары 3 мең кылыч тотучы.*

*Һәм могҗиза! Ходайның рәхмәте һәм ярдәме белән, җиһангир русларның әлеге кырык бер меңлек көтүен пыран-заран китереп ташлый. Яңа килеп туган вазгыять мәсләген дә үзгәртә. Ул Идел буенда Казан ханлыгына нигез салып, яңа дәүләтнең тәхетенә утыра...*

*Бабаларыбыз юл газабын гүр газабына тиңләгән. Мәсләге якты, гамәле изге, күңеле пакь мосафирга фәрештәләр канат җәяр, ди. Әлеге гыйбарә Багдад мәгърифәтчеләренә дә туры килә иде.*

Алар әлеге озын юлны, әкияттәгечә, ай барасын көн барып, кирәк чакта коштай канат кагып, бик кыенга дучар булганда, еландай шуышып, кырыкмаса кырык башмак туздырып, шактый атларын, дөяләрен югалтып, биниһая күп кала-салалар үтеп, сансыз елга-сулар кичеп, елга якын вакыттан соң, ниһаять, Болгар җиренә аяк бастылар.

Ошбу хикмәти йөрешне күз алдына китерү өчен «Болгар сәфәре»нең сәркатибе, күренекле галим Әхмәд ибне Фадланның рисаләсеннән бер кечкенә өзек китерү дә җитәр, мөгаен:

«Ул әйтте: без болар (башкортлар) иленнән кузгалып киттек һәм Җәремсан елгасын, аннан соң Уран елгасын, аннан соң Урам елгасын, аннан соң Байнаҗ елгасын, аннан соң Вәтыйгъ елгасын, аннан соң Бәнаснә, аннан соң Җаушир елгасын кичтек. Без телгә алган елгаларнең бер-берсеннән арасы – ике көн яки өч көн яки дүрт көн».

Бу бит бары йөз чакрым тирәсе ара!

***

922 ел, май ае, уникенче көн.

Кышкы озын йокыдан соң табигатьнең инде тәмам уянып, чәчәккә бөреләнгән илаһи матур чагы. Ялан-кырларны узган елгы кура калдыкларын ерып чыккан түбәтәйдәй купшы үлән патшалыгы үз кочагына алган. Яшел күлмәкләре бик килешле. Куакларда кошлар куанышa, зәңгәр күктә кояш елмая.

Кая карама, яз, яз, яз!

Шулвакыт искәрмәстән генә кыйбла ягыннан өрфә җил җанланып китте

дә үлән яфракларын, агач ябалдашларын, чатыр япмаларын иркәләп сыйпап узды. Шуннан соң ук тау читеннән кош оясы кадәрле генә бер болыт калкып чыкты. Киләкилешкә ул күзгә күренеп, ачы камырдый кабара-кабара, мизгел эчендә күкне биләп алып, чакма ташыдай сызып җибәрде: әүвәл яшен камчысы елкылдады, аннан шартлау тавышы яңгырады.

Шифалы, җылы, мәрхәмәтле лэйсән яңгыр башланды.

Болгарлар лэйсән яңгырын «Рәхмәт яңгыры» дип йөртә. Фаразларынча, лэйсән суы бака йотса – энҗегә, елан йотса, агуга әйләнә икән.

Яңгыр тамчылый башлауга, Алмыш мәлик атыннан җиргә сикереп төште дә үлән өстеннән тәгәрәп китте. Аңа даирәсе иярде.

Ләкин тамаша озакка сузылмады, күзәтүче угланның көр тавышы яңгырады:

– Киләләр!

Шушы хәбәрне генә көткәндәй, җилбикә болытны тау артына куып алып китте. Кояш янә елмаеп, җиргә нурларын сипте.

Сөбханалла!

Күп тә үтми, ашъяулык җәелгәндәй тигез үзәнлек очында «Болгар сәяхәте» теземе күренде. Иң алда – илче Сәһсән әр-Рәсиби. Бик күркәм бурлат атка атланган. Бурлат шушындый тамашалар өчен өйрәтелгән иде, күрәсең, биеп кенә килә.

Илче киң саргылт билбау белән уратып алынган көрәнсу җиләннән иде. Башында алсу өслекле чалма, аякларында бизәкле кызыл читек. Ни өчендер, илчегә хас булмаганча, биленә кылыч та аскан.

Аннан бер-ике адымга гына калышып, илчелекнең сәркатибе Әхмәд ибне Фадлан килә. Ул башкалардан аерылып тора иде. Киеме дә үзгә. Өстендә карасу бишмәт, кызыл күлмәк, башында яшел камаулы кызгылт башлык. Биле буш, кылыч та, хәнҗәр дә такмаган. Аның урынына бармакларында алтын-көмеш балдак-йөзекләр ялтырый.

Ибне Фадлан ерактан ук Алмыш мәликне күз уңына алды. Затлы дирбияләргә уралган Тимер-күк толпарын да, хакимнәргә генә тиң кыйммәтле кием-салымын да ошатты. Падишаһ шулай күрекле булырга тиеш инде ул.

Каләмкәш бит, күңеленә аның сурәтләмәсен дә беркетеп куйды. Мәлик киләсе буыннарга шушы сурәтләмә буенча барып ирешәчәк. Менә ул: «Алмыш – ярыйсы гына тулы гәүдәле, инде корсак та үстерә башлаган урта яшьләрдәге боеручан бер хакимдер».

– Әссәламегаләйкем вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһү, – дип сәламләде илче мәликне. – Ходай хәерле падишаһлык насыйп итсен.

– Вәгаләйкүмәссәлам, – дип җаваплады хаким, – бирахмәтикә йәә әрхәмәррахимин.

Кыска вакытлы бу очрашу Мораса елгасы янында урнашкан шул ук исемдәге авыл тирәсендә, табигатьнең гаҗәеп матур урынында, киң тугайда үтте.

– Сезнең өчен гөмбәзле чатырлар кордырдым, ашагыз-эчегез, әйбәтләп ял итегез, – диде Алмыш мәлик. – Аллаһы рәхмәте белән, җомга көнне хуҗам һәм туганым мөхтәрәм әл-Мөгътәдир биллаһ Әбел-Фазыл хәлифә хәзрәтләренең юлламасын кабул итү тантанасына җыелырбыз. Ике ил

арасындагы элемтәләребез турында да, сезнең алдагы гамәлләрегез турында да шунда фикер алышырбыз.

– Сөбханалла, мәлик, – диде илче Сәһсән әр-Рәсиби. – Без сезгә бик рәхмәтлебез.

Болгарның алдагы өч көне намазлык өстендә узды. Меңләгән мөэмин-мөселман Аллаһыдан киләсе изге җомганың аяз, җил-яңгырсыз кояшлы матур көн булып тууын үтенеп, догага оеды. Алмыш үзе дә күп вакытын мәчеттә уздырды.

Бу эчкерсез вә ихлас дога-теләкләр җылы шытым бирде. Көн тыныч вә дымык, гыйззәтле вә нәфис иде. Иртә таңнан олысы-кечесе тантана буласы урынга ашыкты. Бераздан үзәнлектә алма төшәр урын да калмады, халык мыж. Читтәгеләр ат өстендә, тау башы да чуп-чуар.

Тәртип саклау Хөсникамал яугирәләр өстендә. Күрәсең, мөслимәләргә ышаныч зуррак иде. Хак, кыз-хатынның сиземлеге ау төлкесе сиземлегенә тиң бит ул, кемнең ни уйлаганын, ниятен үз-үзен тотышыннан ук тоеп-белеп ала. Падишаһ һәм шәрәфле кунаклар килгәнче, әнә, берничә тынгысыз бәндәне озатып та өлгерделәр. Шым булды гавам.

Алмыш мәлик тантананы үзе ачты. Ул, ни сәбәпледер, бизәкле-чуклы киемнән иде. Мул гәүдәсенә юка-җиңел күлмәк-ыштан килешә икән үзе.

Сүзләре дә шушы бизәкле киемнәре кебек бизәкле һәм килешле иде.

– Рәхимле вә шәфкатьле Аллаһының исеме белән, – дип башлады ул нотыгын. – Хисапсыз мактау һәм мактaлу кодрәте Аллаһы Тәгалә хозурына булсын. Безне адәм итеп яратты, туры юлга күндерде. Мин иманга килүем, мөселман булуым белән чиксез горурланам. Күркәм йөзле, хак сүзле пәйгамбәребез Мөхәммәд саләллаһу галәйһи вә сәлламгә Аллаһы Тәгаләнең салават-сәламнәре булсын. Шушы изге юлдан барып, барча мөселманнарны Иман нурында коендыручы Габбасия хәлифәләреннән Әмирел-мөэминин әл-Мөгътәзыйд хәлифә хәзрәтләренә дә эчкерсез ихтирам вә сәламнәремне җиткерәм.

Ул озын һәм киң җиң эчендәге кесәсенә тутырган көмеш тәңкәләрне ерактан килгән кунаклар өстенә сипте.

– Әлхәмдүлиллаһ! Әлхәмдүлиллаһ!

Мәйдан уртасына илче Сәһсән әр-Рәсиби чыгып басты. Кулында байрак.

– Данлы Болгар дәүләтенең лаеклы падишаһы мөхтәрәм белеквар Силки ибне Алмыш хәзрәтләре! Мөселман дөньясының олуг башлыгы, Габбасия мәмләкәте хәлифәсе әл-Мөгътәдир сине үз канаты астына ала, – диде, тавышына тантаналы төсмер бирергә тырышып, – шул игелекле ниятенең билгесе итеп, Дәүләтебезнең ошбу байрагын кабул итеп ал.

Алмыш байрак алдында тезләнеп, аны битенә япты. Шунда ук бизәкле камзулларын салдырып, аңа Габбасия хәлифәтенең әһле йөзе саналган махсус кара чапан кидерделәр, башына чалма урадылар.

Ә аннан?

Сыпра сынлы ерау
Тора биреп тулгайдыр,
Тулгай биреп сырнайдыр,
Боты савырлы көрән ат,
Ботка тартып менәр ат.

Йосыф пәйгамбәрдәй мөкәммәл буй-сынлы ике гайде гази мәшһүр Гали имам Дөлдөле шикелле озын аяклы, җиңел гәүдәле җилдәй җитез толпар-атны ефәк тезгененнән тотып, мәйдан әйләнделәр дә мәлик каршына килеп туктадылар.

Кыйган камыш колаклы,
Тустыгандай тояклы,
Арт өркәчле дөядәй,
Арысландай күкрәкле,
Юлбарыстай сөйрәкле,
Чапкан чакта җил җитмәс,
Табаны ялпак Тарлан бүз.

– Аргамак Мөгътәдир биллаһның шәхси бүләге, – диде илче. – Үз утарыннан.

– Афәрин!

– Инде хөрмәтле болгарлар, – дип дәвам итте илче. – Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламнең ыру дәвамчысы әл-Мөгътәдир хәлифәнең хатындагы изге җөмләләрне тыңлап, әһвале рухия күңелләрегезне хушландырыгыз.

Хатны илчелекнең сәркатибе Әхмәд ибне Фадлан укыды. Тавышы көчле һәм аһәңле иде, тын да алмый тыңладылар.

– Аллаһудан башка иләһә-мәгбуд юк. Аллаһу әкбәр!

Дәррәү намазга бастылар.

Намаздан соң чалмалы Алмыш мәлик үзенең шәрәфле карарын җиткерде.

– Мөхтәрәм өммәтем, мин бүгеннән үз исемемнән ислам динен дәүләт дине дип игълан итәм, – диде. – Аллаһы рәхмәте белән Бөтенболгар җыены җыячакбыз һәм җыен минем бу карарымны хуплар, дип ышанам.

– Аллаһу әкбәр!

Үзән бертавыштан җаваплады.

– Аллаһу әкбәр!

Хаким сүзендә торды, нәкъ ике айдан соң Бөтенболгар җыенында ислам динен кабул итүне инде рәсми төстә бөтен халык исеменнән игълан итте.

*Тарихи белешмә:*

*Болгарлар Хәлифәттән үз илләренә ислам диненә өндәүчеләрне, мәчет һәм кальга төзелешендә ярдәм итәрлек кешеләр җибәрүне сорый. 922 елның уртасында Җаушир (мә) елгасы ярларында (хәзерге Чистай районының Яуширмә авылы янәшәседә. Бүген анда «Ханнар буасы» дип аталган урын бар) җирле аксөякләрнең – болгар кабиләләре башлыкларының Алмыш хан җитәкчелегендә корылтае була. Анда Ислам дине Идел буе Болгар дәүләтенең рәсми дәүләт дине дип янә бер тапкыр игълан ителә.*

*«Төсләр балкышы» китабыннан.*

Бүләкләр бирешү төгәлләнүгә, кунакларны һәм даирәне аш мәҗлесенә чакырдылар.

Мең кеше сыйдыручы бу утау-киез өй үзе бер сәнгать әсәре иде.

Чаңгырагы киртештән,
Увыгы бар көмештән,
Бусагасын бурлаткан,

Кирәгәсен сырлаткан
Утауга инде иләт –
Алтмыш терәкле ак утау.

Нәкъ уртада – алтыннан коелган, яфраклар белән бизәлгән зур күчмә тәхет. Аяклары көмештән, өске өлешендә күктә атышып уйнашкан йолдызлардай асылташлар җем-җем килә.

Җыелышучылар мәликне баш киемнәрен салып сәламләделәр.

Тәхет киң вә зур иде. Мәликнең җәмәгате дә шунда утырды. Уң якта – әмирләр, сул якта – кунаклар.

Алмыш кулын чәбәкләп алуга, алдына кәбаб-кыздырылган ит китереп куйдылар. Ул аннан өч калҗа кисеп алып авыз иткәч, чираттагысын Сәһсән әр-Рәсибигә сузды.

Шуннан соң гына башкалар ризыкка үрелде.

Гарәпләрдән аермалы буларак, Болгар табынында җыр-бию, күңел ачуларга урын бирелми. Хәлбуки, сөҗү дигән әче балны чатагы-чатагы белән китереп кенә торалар. Хәзерендә аның гайрәте тел куәсен генә арттыра.

Бер җаен китереп, Ибне Фадлан да үзен борчыган бер мәсьәләне кузгатмак итте.

– Падишаһ, – диде ул чираттаны касәне бушатканнан соң. – Кичә мин бер мәчеттә булган идем, хотбә догасында имам: «Аллаһеммә әслих әл-мәликә Белеквар мәликә Болгар», – дип тәкрарлады. Бу бит хата, дөреслеккә туры килми.

– Ничек туры килмәсен, – дип Алмыш сәркатипне күз туя күргәндәй тураебрак утырды да: – «Йа Ходა, мәликне, Болгар мәлиге Белекварны, изгелеккә юнәлдер», дигән хотбә ничек хата булсын ди? – диде.

– Әл-Мәлик – Аллаһы Тәгаләнең туксан тугыз исеменнән берсе, һәм бик дәрәҗәлесе, – диде Ибне Фадлан, – тимер, җиргә ышкылып, күгәрегеннән чистарган кебек без дә Аллаһының гүзәл исемнәрен кабатлап сафланабыз. Мәлик – фәкать бер Хода. Аннан башка затны «Мәлик» дип атау гөнаһка тиң гамәл.

Алмыш авыз эченнән генә иман китереп:

– Хотбәдә алайса мине ничек атарга соң? – дип сорады.

– Үз исемеңне һәм атаңның исемен телгә алу мәгъкуль санала.

– Мин рухи хуҗам әмирел-мөэминнең исемен алырга телим, – диде Алмыш. – чөнки атаем мөселман түгел иде. Бу мөмкинме?

– Мөмкин, – диде Ибне Фадлан. – Хәзрәт Җәгъфәр бине Габдулла, дип исем кушсын.

– Хотбәдә ничек телгә алырга тиешләр?

– Аллаһемә әслих габдәкә Җәгъфәр бине Габдулла әмире Болгари мәүла әмирел-мөэмин.

– Сиңа, мөэмин туганым, хаталарымны төзәткән өчен игелекле теләкләрем муаффәкъ булсын, – дип, кулларын күкрәгенә куйды белеквар, – бик рәхмәтлемен.

Табынга үзенә бер тантана һәм купшылык хозурында кылгандай саргылт озын чәч толымнарын кылтык кына калку күкрәкләренә салган чын болгар кызлары тәлинкәләрен уйната-уйната, тары боткасы китерделәр.

Болгар – тары иле. Шуңа күрә тары ризыгы һәрвакыт дастархан түрендә. Әлеге җәһәттән, ул, калышса да, иттән генә калышадыр, мөгаен. Кунакларга хөрмәт йөзеннән бүген тары боткасын бия сөтеннән кабартып пешергәннәр иде. Әчкелтемрәк исе генә ни тора. Шарты да бар: тәлинкәне ялап кую зарур.

– Каймак ачы, сөт төче, салма бирсәң камыр, шалкан бирсәң тамыр, тары боткасы бирсәң, җилегеңә май тулар, әйдә, боткабыздан авыз итегез, – дип, Белеквар бер кавым ботканы тамагына шудырды.

Ибне Фадланның күңеле исә башкада иде. Баядан бирле патшабикә белән янәшә утырган бер мөлаем ханымга күзе төшеп, каш астыннан гына шул сылукайны күзәтеп утыра. Моны тәхет хуҗасы да сизеп алган икән.

– Бану бикә дәүләтебезнең бик ихтирамлы, бик абруйлы һәм искиткеч эшлекле әгъзасы, – дип мәгълүмат бирүне кирәк тапты. – «Кала тау», «Кызлар каласы» кальга-бистәләрен төзеде, үзе менә дигән яугирә. Өч кызын да үз үрнәгендә тәрбияләп үстерде. Бүгенге тантаналы чарабызның иминлеген дә, мисал өчен, төпчеге Хөсникамал тупланбаш яугирәләре тәэмин итә.

– Күрәм, Болгарда хатын-кызлар, күкәй эчендәге сары кебек икән, абруйлылар, – диде Ибне Фадлан. – Хәтта махсус «Кызлар каласы» да бар икән. Мине Бану бикә белән якыннанрак таныштырсаң, бик рәхмәтле булыр идем.

– Мөмкин, бик мөмкин.

– Мөхтәрәм кунагыбыз Ибне Фадланның синең белән танышасы килә, – диде урыныннан торып баскан Бану бикәгә. – Берочтан корылмаларыңны күреп китәр.

– Башөсте, падишаһ, – диде бикә сәркатипне күз уңыннан үткәреп. – Кунакны кайчан көтәргә боерасың?

– Иртәгә билгелик, бүген ял итсеннәр инде, мәҗлес арыта ул.

Кунаклар мәҗлестән, мондагы йола буенча ашаудан калган кәрҗин тулы ризыкларын кулларына тотып кайтып киттеләр.

***

Бану бикә «Кызлар каласы» белән танышуны кунакка яшь яугирәләрнең хәрби осталыкларын күрсәтүдән башламак иткән иде дә, тегесе кулын гына селтәде.

– Бикә, сугыш-орыш хәлләренең үз кешеләре бар, ә мин сәяхәтче, галим, мине шәхсән халыкларның тормыш-көнкүреше, йолалары, гореф-гадәтләре, бер-берләренә, дәхи дә читләргә булган мөнәсәбәте күбрәк кызыксындыра, – диде, – әлеге сәфәрдән соң хәлифәбезгә шул хакта рисалә язып тапшырырга бурычлымын.

– Ихтыярың, – диде Бану. – Алайса, әйтегез, нидән башлыйбыз соң?

– Мөселман кешесенең иң изге урыны Аллаһ йорты, өйлә намазы да җитә, мәчеткә барыйк, аннан соң күз күрер.

Тәү салынган мәчет күршедә генә иде, шунда керделәр.

Пыяла тәрәзәле зур гына агач мәчет. Якты. Идәненең буеннан-буена яшел төстәге купшы келәм җәелгән. Кешеләр дә шактый күренә.

– Хатын-кызларның үз бүлмәләре бардыр инде, – диде Ибне Фадлан, – Ходай хәерле намаз насыйп итсен.

– Без мәчетне ир-ат, хатын-кызларныкына бүлмибез, – диде бикә.

Билгеле, бу ислам кагыйдәләрен бозу иде, шулай да, Ибне Фадлан телен тешләде. Ник дисәң, Болгарда аңа моннан да хәтәррәк сәер «бозулар»ның шаһиты булырга туры килгән иде инде.

Шулай беркөнне Багдадтан килгән тегүче белән ясигъ намазына азан әйтүләрен көтеп, гәпләшеп утырганнар иде. Ниһаять, азан яңгырады. Чыксалар, иртә намаз вакыты җиткән!

Мәәзиннән:

– Кайсы намаз азанын әйттең? – дип соравына тегесе:

– Иртә намаз азанын әйттем, – диде.

– Ә ясигъ намазы кайда?

– Аны ахшам белән бергә укыйбыз, – диде мәәзин.

Баксаң, җәен Болгарда төн бик кыска икән, кояш баерга өлгерми, инде таң беленә башлый. Үзләренчә шуңа җайлашулары, имеш.

Үзләренчә дигәннән, бер авылда ул агач ботагына асып куелган мәеткә тап булды. Хыянәтче токымыннан, күрәсең.

– Исләнеп беткән бит бу, нигә монда тотасыз? – дип белешкән иде, җавабы тагын да сәеррәк яңгырады:

– Хыянәтче түгел ул, бик мактаулы, бик тырыш гыйлем иясе тәкъваи инсан иде, – диде аны озатып йөрүче углан ниндидер үзенә бер горурлык белән. – Ә андый изге затларның хакы – Раббыбыз Аллаһы Тәгалә рухына корбан булу. Аны үз ризалыгы белән асып куйдык. Ул үзе өзелеп төшкәнче асылынып торачак.

*Тарихи белешмә:*

*Тарихчы галим Шиһабетдин Мәрҗани «Күпне белсәң – асарлар, юаш булсаң – басарлар» дигән әйтем шул йолага бәйле рәвештә туган булырга тиеш, дип саный.*

Шушы кыска гына вакыт эчендә дә Ибне Фадланга шактый гына сәер хәлләр белән күзгә-күз очрашырга туры килде. Үзләрен мөселман өммәтеннән дип санаган ир-атлар белән хатын-кызларның шәп-шәрә килеш бергәләшеп су керүләрен күреп тә чөгендердәй кызарган иде. Дин әһеленең исе дә китмәде, бездә гомер-бакый шулай инде дип кенә куйды.

– Бу соң зина кылуга туп-туры юл лабаса, – диде Ибне Фадлан.

– Андый хәлнең булганы юк, була да алмый, – диде мулла. – Бу үзеңне үлемгә дучар итү икәнен һәркем белә. Йолабыз шундый: андыйларның гәүдәсе тураклана һәм дә агач ботагына эленә. Козгыннарга – азык.

БелекВар ислам диненә йөз тотып, бик дөрес эшли, дип уйлап куйган иде Ибне Фадлан, ошбу кыргыйлыктан адәм баласын бары шәригать кенә йолып ала ала.

Кызлар мәктәбе – Гыйрфан җәзирәсе, Мәгърифәт утравы.

Бу Ибне Фадланның бәясе. Ошатты ул кызлар мәктәбен, бик ошатты. Җәй айларында дәресләр булмавы гына кызганыч. Гарәпләрдә, мисал өчен, мондый мәктәпләр юк. Гарәпләрдә кыз баланы әдәп-әхлакка, аш-

су осталыгына, кул эшләренә, дөнья көтү серләренә ана кеше өйрәтә, төшендерә. Үзе ничек, кызы да шул калыпта тәгаенләнә. Наданнан – надан, өлгердән – өлгер, ялкаудан – ялкау... Ә бу мәктәптә талибәләргә белем-күнекмәләрне мөгаллимәләр бирә икән.

Яшь буынны тормышка яраклы итеп үстерү җәмгыятьнең дә тотрыклылыгы дигән сүз. Бу бик яхшы. Шуның белән бергә, яңа иман китергән яшь мөслимәләргә диннең асылын, аның кануннарын, шәригатьчә яшәү нечкәлекләрен аңлату да бик мөһим. Гомумән, мәдрәсәләр күбрәк ачылса, дин тотудагы төрлелек алда телгә алынган сәер гореф-гадәтләр дә күзгә күренеп кимер иде.

Бану бикә дә килеште бу фикер белә. Ләкин әйтте:

– Мәдрәсәләр ачар өчен, хөрмәтле сәркәтип-илче, әзерлекле мөгаллимнәр кирәк, ә бездә алар юк дәрәҗәсендә. Мин үзем, шәхсән, кызлар мәктәбе өчен Багдад сәүдәгәре Муса әкәгә кияүгә чыккан Зөбәрҗәт яугирә булышлыгы белән генә ике мөгаллим китертә алдым. Бу җәһәттән дә без сезнең ярдәмгә бик мохтаҗбыз.

– Үтенечләрегез, һичшиксез, хәлифәбезгә җиткерелер.

Ибне Фадлан шактый күп кеше белән очрашып сөйләшергә өлгерде инде. Арада төрлесе бар. Аны исә кемсәнең җәмгыятьтә тоткан урыныннан битәр, фикер йөртү куәсе, күңелендәген эзлекле итеп җиткерә белү осталыгы, тел байлыгы кебек зыялылык сыйфатлары кызыксындыра. Ык-мык килүчедән кая ул рисалә өчен мәгълүмат туплау, башыңа авырту гына аласың. Ә аңа мәгълүмат кирәк, күп кирәк.

Бану бикә аларның барысыннан да өстен иде. Бу дөньяда ярты гасырга якын яшәү дәверендә шактый гыйлем тупларга өлгергән, күп нәрсәдән хәбәрдар. Шул исәптән, илаһиун вә илаһият диңгезләрендә дә ярыйсы гына йөзә. Һәрхәлдә, үзенең әйтүенә караганда, Хөсәен бине Ибраһим дамелладан бик теләп белем эстәгән.

Ул әңгәмәдәшен төрле яктан сынамак итеп, хәтта ерак дәвер бакчасына да таш атып карады.

– Хатын-кыз идарәчеләрдән Клеопатра язмышы сезне ни дәрәҗәдә кызыксындыра? – дип сорады.

Бикә ирен читләре белән генә елмайгандай итте дә:

– Хөрмәтле сәркатип-илче, мин бит яугирә, мине барыннан да элек сузылмалы шам кылыч, еракка очучы сәрпи ук ише орыш яраклары күбрәк кызыксындыра, – диде. – Шулай да, Клеопатраның Мисыр патшабикәсе булуы ничектер колагыма кереп калган. Ә менә сезнең мәгълүматны рәхәтләнеп тыңларга әзермен.

Сәркатип-илче хәл алгандай, күзләрен кыса төшеп, кулы белән һаваны ярып алды да:

– Мисырда Клеопатра исемле җиде патшабикә тәхеттә утыра, – диде, – дан алганы җиденчесе. Аның турында искиткеч чибәр, бик тә булдыклы, үз сүзен сүз итүче, чын гыйшык иясе, дип тәкрарлыйлар. Данлыклы Рим императоры Юлий Цезарьны да үзенә караткан ул.

Клеопатра кебек үз язмышын гына түгел, мәмләкәт язмышын хәл итәр дәрәҗәдәге хатын-кыз идарәче булу өчен үз-үзеңнән дә яхшы булу шарттыр, мөгаен. Менә сез, «Кала тау», «Кызлар каласы» шәһәрчекләрен төзегәнсез, авыр булдымы?

Бану озак уйланып тормады, гадәтенчә, көлемсерәп кенә:

– Беләсезме, Ходай кыз-хатын җәмәгатен шулай яраткан ки, аның калебендә бик күп затлар көн күрә: алиһә, җани мәгъшука, фәрештә, пәри, галимә, шәйтан, мөгаллимә, җитәкче... күп алар... Мәгънәсе исә бик гади, шуларның кайсысын уяталар, хатын-кыз шул сыйфатта була.

– О-о, сез әле фәлсәфәче дә икән, бикә!

– Коръәни Кәрим шулай өйрәтә. Мин ән-Ниса – хатын-кызлар сүрәсендәге аятьне һәрвакыт күңелемдә йөртәм. Анда әйтелә: «Сез үзегезнең малларыгыз белән дә, үзегез белән дә сыналырсыз, сезгә кадәр китапка ия булганнардан һәм мөшрик булучылардан күп рәнҗеткеч сүз ишетерсез. Әгәр сабыр булсагыз һәм тәкъва булсагыз, хакыйкатьтә, бу – эшләрдә ныклы булудан бит».

– Ир-ат, хакыйкатьтә, тискәре халык, аның үз утызы утыз. «Кызлар каласы»ндагы вазгыять, аларга, мөгаен, бик ошап бетмидер, – дип, сәркатип әңгәмәне җирле шартлар юнәлешенә борып җибәрде.

Бикә бу юлы, шуны да аңламыйсызмы әллә, дигәндәй, әңгәмәдәшенә күз атып алды. Шуннан соң гына:

– Без бит ир-атларны алыштырмыйбыз, фәкать алар белән бер хокукта уртак мәшәкатьләр дулкынында кулга-кул тотынышып яшибез, эшлибез, яу чабабыз, – диде.

Ошбу җөмлә Ибне Фадланның колак очыннан гына шуып узды, күңелен кузгатмады. Чөнки йөрәген шушы керфек каккан арада гына булып алган йөгерек караш өттереп алган иде, башы әйләнеп китте.

Дөрес, кылган чәчле бу ханыманың күкрәк түреннән чыккан үтә дә ягымлы, үтә дә моңлы тавышы башта ук күңеленә хуш килгән иде. Була торган хәл. Ә бу өттергеч караш исә бөтен калебенә үтеп кереп, ниндидер ашкынулы хисләр уятты. Хәтта эч серләрен бүлешү теләге дә уянып китте. Югыйсә ул йомакый бәндә, барысы да – яхшысы да, яманы да – үз эчендә, сыны катса да, сер бирергә ашыгучылардан түгел. Яшәү шигаре дә шуңа охшаш: аһ димә, дошманнар ух, димәсен.

Ул бикәнең язмышыннан хәбәрдар иде инде. Канаты каерылган ятимә ханым. Үзе дә шундый язмышта. Яратып өйләнгән хатыны баладан вафат булды. Бу югалтуны авыр кичерде, бик пар килгәннәр иде. Бераздан яңа тормыш та корып карады-каравын, тик уңыша алмадылар, аерылышырга туры килде.

Бану хатын-кызларга гына хас эчке сиземләү белән каршысында утырган илченең хәл-халәтен ул үзе тоемлаганчы ук абайлап алган иде инде. Ялгызак ир-егетнең генә кыяфәте шундый сагышлы була, назга сусаган ир-егет кенә кыз-хатынга туры карарга базмый, керфекләрен түбән салып кына сөйләшә, гыйшкы уянган ир-егет кенә дулкынлануын сүз калыбына салып, яшерергә тырыша...

Һәм илченең бу халәте үзенә дә ошый иде. Кайдадыр еракта, бик еракта томанланып яткан хисләре таш-тауны ерып, җир өстенә ургылган кайнар чишмәдәй искәрмәстән генә бөтен асылын биләп алды. Бу инде күптән онытылган, шул ук вакытта бик тә таныш искиткеч ләззәтле хис иде. Әгәр шундый ук хис кичерүче илче гамәли хәрәкәт дулкынына керсә, ахыры ни белән беткән булыр иде, анысы билгесез, әмма ир-егетнең кыюлыгы җитмәде, утлы тойгы кабынмыйча сүнде.

Ул арада бикә дә үз халәтенә кайтырга өлгергән иде инде.

– Хөрмәтле сәркатип-илче, Суарга бару турында сүз кузгаткан идегез, борчылмагыз, сезне озатып куярлар, – дип, урыныннан торып басты. Ишек катына җиткәч, башын бормыйча гына өстәде:

– Игътибарыгыз өчен рәхмәт, очрашу да, әңгәмәләрегез дә бик файдалы булды.

– Бикә...

– Хушыгыз!

Алар башка күрешмәделәр. Бану йокысыз төннән соң иртән иртүк Кыз күленә юл тотты. Шатлыклы чакларында да, кайгылы чакларында да, күңеле җилкенеп, үз-үзенә урын таба алмаганда, ул шушында килә, изге Айтулы кызга мөрәҗәгать итеп, юаныч таба, борчыган сорауларына җавап ала.

Әле дә көзгедәй ялтырап яткан күл өстендә урын җил шаярткан шадра дулкыннарга карап, эч серен чиште дә:

– Айтулы кыз, киңәшеңне бир, миңа нишләргә? – диде.

Кинәт кенә җил кузгалып алды, күл өстендә өермә купты. Һәм шул ярсу гарасат эченнән Айтулы кызның тавышы яңгырады:

– Хәтереңдәме, тәүге саф вә пакь мәхәббәт ләззәтен минем күлем буенда татып, шушы өермәдәй зилзиләле рәхәтлек кичергән идегез. Ярмәк углан минем эзем калган җирдән туфрак алып, сиңа да үптерде, үзе дә үпкән иде.

– Хәтеремдә, бик хәтеремдә...

– Хәзер каберенә барып, миңа сөйләгән сүзләрне аңа да сөйлә.

– Ул мине гафу итәрме?

– Ярмәк ише олуг җиһангир җәмәгатенең башка кеше куенына керүе хыянәттән бигрәк, җинаять булыр иде…

Билгеле, безгә инде мәгълүм, бу Бануның үз күңелендә, үзе күрергә теләгән риваяти фаразлаулар гына. Әмма ул аларга ышана. Ә үзең ышанган хакыйкать – иң хак хакыйкать.

***

Даирәнең үз арасында да Болгардагы бу үзгәрешләрне кабул итмәүчеләр, үз мәнфәгатьләрен алга сөрүчеләр бар икән.

Мәҗлестә Ибне Фадлан Исегел әмире белән дә аралашып алган иде. Тәхет тотуына ике-өч кенә ел икән әле. Яшь, чибәр, күрекле углан.

Ибне Фадлан аны бәйрәм белән котлады.

– Мин бик рәхмәтлемен, – диде әмир. – Без, барсил кабиләсе иярченнәре, мәшһүр барс-җанварга табынабыз. Һәм ата-бабаларыбыз рухына тугрылыклы булып калачакбыз да.

– Исегел Болгар дәүләте вилаяте түгелме соң? – дип, җилкәсен сикертеп куйды Ибне Фадлан.

– Әйе, – диде әмир касәсен жулпычтай киң учлары арасында әйләндергәли-әйләндергәли. – Киләчәктә дә бергә булачакбыз, аркадаш булып, бер-беребезгә терәк булып яшәячәкбез. Ә менә кайбер мөселман әмирлекләре, белүемчә, башка чыгу сәясәтен алга сөрә.

– Мәсәлән?

– Мәсәлән, Суар...

Әңгәмә шушы урында өзелде. Әйтерсең лә, әңгәмәне ишетеп-тыңлап торган, озын торыклы, какча гәүдәле Суар әмире Вираг бәк үзе яннарына килеп сәлам бирде.

Исегел әмир аларның икесен генә калдырып, китеп барды.

– Сезгә йомышым бар иде, – диде Вираг әмир. – Мөмкинме?

– Бик рәхәтләнеп, әмир.

– Болгар дәүләтендә ике җәмигъ мәчете булырга тиеш, дип саныйм, – диде әмир, – берсе – Биләрдә, икенчесе – Суарда. Безнең мәчетебез бар, тик аны җәмигъ мәчете таләпләренә туры китереп киңәйтү зарур. Шушы уңайдан мин сезне Суарга чакырам, барысын да үз күзләрегез белән күрерсез.

Исегел әмирнең суарлыларның башка чыгу омтылышы турындагы гайбәткә тартым сүзләре Ибне Фадлан күңелендә зур кызыксыну уяткан иде. Чакыруны бик теләп кабул итте.

– Бик хуш, тик бераз соңрак, – диде. – Чиратта – Кызлар каласы.

– Рәхмәт, өметләребез акланыр, дип ышанам.

Ибне Фадлан, әлбәттә, әүвәл мәгълүмат туплады.

Дөрестән дә, Исегел әмиренең сүзләрендә хаклык бар икән. Суарлыларның мөстәкыйльлеккә тартылуы берәүгә дә сер түгел, диделәр. Үз акчаларын сугу хәстәрен дә күрәләр, имеш. Бу инде башка чыгудан битәр, аерылып чыгу омтылышы дигән сүз.

Алай да ул, Суарда йөреп кайтканнан соң, Вираг әмирнең Болгар дәүләтендә ике җәмигъ мәчете булдыру турындагы тәкъдимен хуплавын белдерде. Кала бу ташламага лаек иде. Матди ярдәм күрсәтү мөмкинлеген дә таптылар. Шулай, Багдад өчен яңа мәчетләр төзү, ислам диненең колачын киңәйтү халыкларның үзара тынышу-тынышмауларыннан өстен иде.

*Тарихи белешмә:*

*Суар әмирлеге тартыша торгач, барыбер Болгардан аерылып чыга һәм утыз алты ел (940–976) мөстәкыйль дәүләт буларак яшәп ала. Габдулла ибне Микаил, Талиб ибне Әхмәд хакимнәр исеменнән Суар акчасы да сугыла. Әйтергә кирәк, әлеге акчалар киң таралыш таба, археологлар аларга ерак Дания җирләрендә дә тап булалар.*

***

Җәгъфәр падишаһ ямьле җәй көннәрендә үзенең гаиләсе һәм якыннары белән матур табигать кочагында, балыклы су буйларында ял итәргә ярата иде. Бу хозурда еш кына даирә дә катнаша. Даирә бергә җыела икән, димәк, бу инде – гомумдәүләти чара.

Июнь аеның соңгы атнасына билгеләнгән мәҗлес тә көн үзәгендәге бик зарури мәсьәләләрне күздә тотып ниятләнгән иде.

– Бисмилла иррахман ирахим, җәмәгать, Багдад илчелегенең Болгарда булып китүенә бер ел тулды, инде бу игелекле сәяхәтнең тәүге нәтиҗәләре турында фикер алышырга вакыт җитте, – дип башлады сүзен илтәбәр. – Шулай да, ошбу сөйләшүне башкалабызны яңача кору, бигрәк тә Җәмигъ мәчетен пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламнең туган көне, Мәүлид бәйрәменә өлгертү хәлләренең торышына багышласак, тагын да урынлырак булыр.

– Афәрин!

– Бик мәгъкуль, падишаһ!

– Бик хуш, алайса, иң элек Биләр бистәсенең баш кешесе Туйгуҗа бәкне тыңлап үтик, аннан...

– Падишаһ, гафу, падишаһ, – дип, Бану бикә урыныннан торып басты. – Миңа иравыл яугирәләрем янына китәргә рөхсәт итсәң иде, әллә нигә күңелем урынында түгел, чәршәмбе бакырбашларның тышаудан ычкына торган көне, Аллаһ, сакланганны гына саклармын, дигән, ул-бу була күрмәсен, димен...

– Яугирәләрдән тыш та сак ишле бүген, бикә, – диде Җәгъфәр. – Борчылырга урын юк.

Илтәбәр сүзе арасына, бака ботын кыстыргандай, башка берәү кереп тыгылган булса, үзенең кем икәнлеген күрсәтер иде, әлбәттә, тик мәмләкәтнең күз өстендә каш булып саналган олы абруй иясе Бану бикәне атасы Силки мәлик кебек үк үзе дә бик ихтирам итә иде. Шуңа күрә сак кәсәфәтендә чамасы чамага туры килеп бетмәсә дә, калын иреннәрен кыйшайтыбрак елмайгандай итте дә:

– Көне дә матур күренә, бар, бикә, җилләнеп кайт, – диде.

Бикәнең күңеле исә бүген, киресенчә, матурлыклардан ерак тора иде, киселгән ипи кебек җәрәхәтле иде аның күңеле.

Хәләле Ярмәк угланны югалткан кайгылы вакытлардагы кебек төне буе саташып-бастырылып чыкты. Башта Айтулы кыз белән төшләнде. Ләкин ул күрергә күнеккән «Айтулыга тиң булырмы, йирдә адәм баласы» тасвирламасына якын да килми иде. Чәче-башы тузган, йөзе чалшайган, тешләре ыржаюлы... Акай күзләрен уйнаткалап, коры сөяккә калган куллары белән аның муенына чытырмандай ябышты да:

– Әйдә, мин сине үз дөньяма алып китәм... китәм... китәм.., – дип янавын белде...

Ә аннан соң яшьлегендәге упкын төбенә мәтәлгән толпары пәйда булды.

– Алаяк, син исәнмени, Алаяк?!

Ә Алаякның күзләре тонган, тонугынамы, вәлфәҗер укый. Чабуы чабу түгел, көндәш кәҗә тәкәседәй арт санын сикертеп килде дә тибеп тә җибәрде.

– Гоп!

Шунда гына күзләре ачылды. Карап бакса, өстәл өстендәге сулы чүлмәкне башына аударган икән.

Бану юеш урын-җирен читкә этәреп куйды да тышка чыкты.

Таң сызылып килә иде инде. Гадәттә, таң пакьтән-пакь алсу челтәрләр япмасын нурландырып ярала иде. Бүген исә офык читенә томан, дисәң, томан түгел, болыт сәләмәсе, дисәң, болыт сәләмәсенә охшамаганниндидер карасу-саргылт ябышкак боламык сыланган иде.

Кояш шул ябышкак боламык кочагыннан котылырга тырыша. Тартыша торгач, ниһаять, урак сыртын күрсәтеп алды, бәгырь. Тора-бара тулышты да. Тик, ни гаҗәп, гүя кырлач кояшы, ике колаклы иде.

Якында гына яшелле-зәңгәрле килешсез тавышы белән күңелгә шом салып, торна кычкыра. Үзе бии, үзе кычкыра. Ә бу фаҗигале фал. Ник дисәң, чыңгырау торна таптаган урында үлән дә үсми.

Көн әнә шулай туарга теләмичә генә туды.

Бу хәлләр тикмәгә түгел дигән нәтиҗә чыгарды Бану, итәк-җиңнәрне җыебрак йөрү мәслихәт булыр.

Ул яугирәләре янына килеп җиткәндә, көн кичкә авышып килә иде инде. Һава аксыл-соры төскә кергән, аяз көннәргә ишарә, димәк, керкүңел бакырбашлар өчен бу бик уңай.

Шулай уйлады да аннан үзен-үзе битәрләп алды.

Дөнья бит бу! Аның тетрәнеп алган чаклары да, дер селкенеп алган чаклары да, утларга салган чаклары да була. Шуны белә торып, ни пычагыма җебеп төште соң әле ул? Үзенә дә, даирәгә дә тынгы бирми. Батмас борын күбеккә тотыну куян йөрәклеләр эше ләбаса.

Хатын-кызның сиземләү-тоемлау куәте туганда ук, калебенә салына. Ул ялгышса да, бик сирәк ялгыша, фаразы һәрвакыт дөрескә чыга. Бану бикәнең дә шөбһәләнү-үрсәләнүләре юкка булмаган икән. Колаклы кояш баш түбәсеннән үтеп, көн сүрелә төшкәч, тау ышыгындагы күзәтүче яугирәдән чапкын килеп, хәвефле хәбәр җиткерде.

– Яу килә!

Сораштыра торгач, шул беленде, бакырбашлар елга кичүендә икән инде. Барысы да ат өстендә, ди. Димәк, талау төркеме. Һәрвакыттагыча, ай күрә, кояш ала.

Хөсникамал сәргаскәр карамагындагы ярдәм тупланына чапкын җибәрде дә:

– Атларны тезгеннәргә! – дип, тәүге әмерен җиткерде.

Яугирәләр коралларын барлап, һөҗүмгә әзерләнгән арада, үзенә яратып карап торучы анасы ягына башын борып:

– Бикә, күрсәтмәләрең өчен рәхмәт, ә хәзер сиңа падишаһ янына кайтырга вакыт, ашык! – диде.

Бану атын саф ягына борып өлгергән иде инде.

– Орыштан качкан яугирә куркак яугирә ул, ә минем андый хурлыкка төшкәнем юк, – диде. – Кайнар йөрәк дигән кушаматыма да хыянәт итә алмыйм.

Бакырбашлар җитезрәк булып чыкты, яугирәләр әрәмә ышыгына килеп җитәргә өлгерә алмыйча калдылар, йөзгә-йөз бәрелеш ялан уртасында ук башланды.

Орыш орыш инде. Ул бөтенләй башка, үзгә халәт. Мизгел эчендә гаскәрне киреакмага эләккән йомычкадай пыран-заран китереп ташлый. Аның үз аһәңе, мәнфәгате дә бөтенләй башка. Йөрәк комга ыргытылган балыктай үз-үзенә урын таба алмый: ашкына, үрсәләнә, тыпырчына... Нәфсе, гомумән, арканнан ычкына, корбан арты корбан таләп итә башлый.

Бану бикә дә, яшь вакыттагы кебек үк балмаса да, шактый җитез селкенгәли. Шөкер, көче бар икән әле. Искәрмәстән генә, әнә, бер җирән сакалны ияреннән дә очырды.

Ә менә икенчесен?

Көбәсен ерып, җилкәсенә сөңге килеп кадалгач кына, ул икенчесенең саргылт тешләрен ырҗайтып көлүен абайлагандай булды. Бәлки тоелгандыр гына. Чөнки шундук аңын да җуйды. Аңа хәзер җирнең өсте дә бер, асты да бер иде шикелле. Керфек кагып, күз ачып йомганчы вазгыять әнә шулай төбе-тамыры белән үзгәрде.

– Аһ!

– Җаны эленеп кенә тора...

Ул әллә кызы Хөсникамалның шушы ачынып әйткән сүзләреннән, әллә җилкәсенең өзелеп төшәрдәй булып сызлавыннан, ничектер айнып киткәндәй итте.

– Тупланбаш, син ник яу кырын ташладың? – дип, хәлсез тавышы белән авырту-сызлаулары аша кызына ризасызлыгын белдерергә ашыкты.

– Чагдавыл гаскәрләр килеп җитте инде, бикә, бакырбашларга котылу юк, – диде Хөсникамал. – Менә синең генә хәл...

– Миңа ни булды? – дип бүлде аны Бану.

– Сөңге кададылар, каныңны көчкә туктаттык, – диде кыз. – Бик куркыткан идең... Аллага шөкер, уяндың...

– Мине кая алып барасыз?

– Падишаһ хозурына, аның табиблары янына.

Бану арыды, ахры, күзләре йомылды.

Яралы орышчыны ат өстендә икенче җайдак алдына утыртып, кочып бара. Авыр гамәл. Шуңа күрә еш-еш алышынырга туры килә.

Бану кызы чиратында янә аңына килде. Үз бәгырь җимешенең самими җылысын ана кеше тын өрүләреннән үк сиземли бит ул, гүя кызы җилкәсенең өзелеп сызлавын үзенә алды.

– Кызым, син үзең табиб, тәнемә сихәт керде, – дип, тагын да елыша төште. – Кызым...

– Анаем-бикә, яраң авыртадыр инде, – диде Хөсникамал. – Авыртадыр...

– Авырта, кызым, авырта, сулышым кысыла, һава җитми...

– Ыңгыраш соң, анаем, җиңеләеп китәрсең...

– Үз балаңның җылысыннан да җылырак, татлырак, сихәтлерәк җиңеллек юк ул дөньяда, кызым, синең үзеңә дә ул бәхетне татыр чак җитте...

Бану гырылдабрак өзек-өзек сулыш алды да тагын тынып калды.

Гамь-госсадан рахәт улдың дияр имди.

Хөсникамал тәэссеф-кайгыга төшеп, анасының кулын капшады. Кулы җылы иде, йөрәгеннән таш төште.

Бикә дә уянып киткән иде.

– Кызым, без кая барабыз? – дип белеште.

– Табиб янына, анаем-бикә...

– Кызым, минем гомерем кыл өстендә инде, атаең Ярмәк углан янына алып бар, – диде Бану, хәлсезләнгән тавышына йомылып. – Арысланым катына...

– Анаем!

Анасының күзләре йомык иде инде, куллары җылы, күзе йомык.

Хөсникамалның тәкате төкәнде. Тыңларгамы анасының сүзен, тыңламаскамы? Табиблар янына кайтса, бәлки, исән калыр?

Тыңласа, аны вакытыннан элек гүргә кертү булмасмы?

Ике юл чатында да ул тәгаен генә бер фикергә килмәгән иде әле.

Икеләнүләргә толпары Очкын нокта куйды, туп-туры Кала тау ягына борылды.

Хөсникамал аты ирегенә буйсынды.

Өзелер алдыннан сырхауга нindидер илаһи көч керә, ди бит. Хак икән.

Ярмәк углан кабере янына килеп җиткәч, Бану бикәнең дә күзләре ачылды, телен әйләндереп соңгы сүзен әйтә алды.

– Яр-мә-ә-гем, был-был-ыңны үз яны-ңа ал... лә-ә илә-ә-һә-ә ил-ләл-лә...һу...

Күп тә үтми, күктә пар аккош сурәтендә ике мәгъшук җан пәйда булды. Көмештәй ялтыравык ап-ак канатларын җилпештереп, каберлек өстеннән әйләнделәр-әйләнделәр дә галәм зәңгәрлегендә эреп, күздән югалдылар.

Миһербаным, әлфирак;
Дилбәр җаным әлфирак.

***Автордан:***

*Кала тау, Кызлар каласы кирмән-шәһәрчекләренең язмышы аянычлы да, гыйбрәтле дә. Аларның һәр икесе дә монголларның 1229 елгы һөҗүме вакытында җимерелеп, яндырылып, җир белән тигезләнә. Кызлар каласы инде мантый алмый. Ә менә вакытлар үтү белән, халыкта Хәтер каны уяна, изге ата-баба җиренә, Кала тауның җәрәхәтле урынына килеп төпләнә башлыйлар.*

*Бану бикәнең вафатыннан соң Кала тау Шәһре Бану исемен ала. Аннан соң халык теленә Шәрбән исеме белән кереп китә. Шушы исем белән ул безнең көннәргә кадәр килеп җитә.*

*1996 елда күренекле галим Әнвәр Хәйри туган төбәге Шәрбән авылының нигезләнүенә 1100 ел тулу мөнәсәбәте илә «Шәһре Бану – Шәрбән кыйссасы» дигән китап язып бастырган иде. Иганәче ярдәме белән Яр Чаллы шәһәрендә нәшер ителгән бу нибары 60 битлек йомшак тышлы китапчык үз чоры өчен бик кыю басма, үзгә бер яңалык буларак кабул ителде.*

*Минем ошбу әсәремнең чишмә башы да яңа карашлы тарихчының шушы бүләк китабына барып тоташа. Чирек гасыр күңелемдә йөрткәннән соң, ниһаять, анда сурәтләнгән вакыйгалар роман кысасында тәгаенләнде. Мең-мең рәхмәт Әнвәр дуска.*

*«Шәрбән авылының тарихы – халкыбызның тарихыннан аерылгысыз, ул аның үзәгендә. Авыл үзенең гыйбрәтле һәм данлыклы үткәне белән чиксез горурлана һәм киләчәгем матур булыр дип, хаклы рәвештә өметләнә ала...» – дип яза автор.*

*Әлеге роман аксубай-шәрбәнлеләрнең асыл якташлары гөман иткән күркәм өметләренә канат куйсын иде, дигән изге теләктә калам.*

*2021 елда Болгар дәүләтенең рәсми рәвештә Ислам динен кабул итүенә 1100 ел тулды. Әсәр тәрәккый пәрвәр халкыбыз тормышында бәһа биреп бетергесез бу әһәмиятле вакыйга белән дә якыннан аваздаш. Анда болгарларның күркәм омтылышына, Багдад илчелеге, аерым алганда, Ибне Фадлан эшчәнлегенә лаеклы урын бирелә.*

*Сөбеханә Халикун-нур!*



Флюра
Низамова

# ТАУ ЮЛЫННАН ТӨШЕП КИЛӘМЕН...

## Хәл белешү

Хәлләрегез ничек? Иминлекме?
Матур яши болар, диярлекме?
Бәйрәмнәрдә балкып, күңел ачып,
Аллы-гөлле күлмәк киярлекме?

Эшләрегез ничек, уңасызмы?
Басуларда иген урасызмы?
Сулар кипте, көчләр бетте диеп,
Әллә урмый гына торасызмы?

Үрчемегез ничек? Артасызмы?
Тупырдатып бала сөясезме?
Бала тавышына тулган авыл –
Иң бәхетле авыл, беләсезме?!

Тукай, Такташларны укыйсызмы?
Тыңлыйсызмы әле Илһам җырын?
«Папа, мама» диеп тормыйлармы
Бала-чага, тел ачылмас борын?..

Йолдызларга карап сокланамы
Сездә кеше җәйнең кичләрендә?
Азан тавышлары яңгырыймы
Һәр көн саен авыл өсләрендә?

Кояш кебек җылы, яктымы сез?
Тулган айдай серле, күркәмме сез?
Сәламлимен сезне туган телдә:
Татарларым, саумы-исәнмесез?!

Флюра НИЗАМОВА (1953) – *шагыйрә, журналист. Дамир Сиражиев исемендәге премия лауреаты. Башкортстанның Ярмәкәй районы Иске Шах авылында яши.*

## Беренче Май хатирәсе

Кызган тимер белән йолдыз уеп
Җәберләнгән азмы ялпь-яшь тән...
Кино карап, китаплардан укып
Без хәбәрдар шундый вәхшәттән.

Сәер булыр микән, чагыштырсам
Кеше тәне белән җир тәнен?
Бер хатирә бәлки сөйләп бирер
Охшашлыкның нидә икәнен.

Беренче Май – бездә тау бәйрәме,
Гадәт шундый: ул көн һәммәсе
Эркелешеп тауга менә иде,
Маевкага чыга, янәсе...

Ә түбәдә яңа чирәм үскән,
Шундый садә, шундый яшел ул,
Тиздән көрәклеләр менәчәген
Әле белми, әле яши ул!

Менә хәзер комсомоллар килер,
Яшь чирәмне кәс-кәс турарлар,
Җир тәненә йолдыз уярлар да
Зур бер учак ягып куярлар!

Ялкын кызыллыгы йөзгә төшәр,
Канга күчәр шушы кызыллык...
Без шул учак кызуында үстек,
Йолдыз яктысында кызындык!

Хәзер уйлыйм: җиргә йолдыз уеп
Йә, без нинди бәйрәм корганбыз?
Асылда бит тупас идеянең
Кыргый варислары булганбыз.

## Барлау

Түркләрем-төркиләрем,
Төрекләрем, татарларым!
Кара диңгез, Кырымнарым,
Ураллларым, Алтайларым!

Казакъ, кыргыз бавырларым,
Кумык, нугай бәгырьләрем –
Далаларны иңләп йөргән
Атлы-шанлы дәверләрем...

Башкортларым, чувашларым,
Хакас, саха, тываларым –
Бар да газиз кандашларым,
Җанга якын туганнарым!

Угызларым, хәзәрләрем –
Данлы тарих язарларым,
Ефәкләрем, парчаларым,
Хикмәт тулы базарларым...

Төрекмәнем, гагаузым,
Кырымтатар – бал авызым,
Йөземнәрдәй татлы телем,
Сездә минем җан азыгым!

Ширбәт, хәлвә, кара чәем, –
Кумык, балкар, карачаем,
Каракалпак, үзбәк, уйгыр –
Чүл кызуын эчкән җәем...

Алтай... Байкал.. Дәште Кыпчак...
Идел буе... Нугай йорты...
Төрки дөнья киңлегеннән
Калган бүген ярым-йорты...

Татар илен чатнаттылар,
Кым-кырычка кыйраттылар...
Ят кавемнәр җәтмәсенә
Эләктерепураттылар...

Бу дөньяда имгәк булма,
Бул икән бит һаман көчле!
Безнең тарих нинди шанлы!..
Бүгенгесе – үкенечле...

Артык зурдан кубарылып,
Әллә инде хәлдән тайдык?
Сак белән Сок аерылгандай
Аерылдык, ерагайдык.

Әллә туфан калыктымы?
Ят бер диңгез монда бары...
Шул диңгездән калкып тора
Ялгыз төрки утраулары...

Утрауларның бар төрлесе:
Бар көчсезе, бар хәллесе,
Төркиләргә әләм булган
Зур Төркия кадәрлесе...

Бар яшәреп сөенгәннәр,
Яңа күлмәк киенгәннәр,
Дәүләт дигән зур бүләккә
Әле генә тиенгәннәр...

Аларныкы сокландыра,
Көнләштерә, кызыктыра...
Алгысып, үз утравыннан
Татар, башкорт карап тора...

...Су биектән агып төшсә,
Йөзгә-меңгә парчалана,
Тик кушылып өр-яңадан,
Көчле ташкын була ала...

Араларны ничек кичик?
Ишкәкләрне ничек ишик?
Әллә әкияттәге кебек
Бу диңгезне бетереп эчик?!

Кардәшләрем, сезне сагынып,
Армый-талмый гел сөйләрем!
Аймыл булмыйк гасырларда,
Кавышыйк бер, төркиләрем!

## Пәйгамбәр

Мин дигәнчә генә бармый дөнья,
Күпме изге ният корсаң да,
Мин дигәнне чынга ашырырга
Акыл-тәүфыйк җитми инсанга.
Тау башыннан аска карап торам:
Анда – тормыш, көрәш, узышу,
Чабышалар зур-зур машиналар,
Җир байлыгын талап ташый алар,
Шул байлыкны эстәп ызгышу...
Мин дигәнчә булыр иде тормыш,
Уйлый белсә адәм борчылып,
Табигатьне буйсындырып түгел,
Табигатькә үзе буйсынып,
Бөҗәкне дә, үләнне дә сөеп,
Үз-үзеннән җирне зур күреп,
Бу дөньяны мин дигәнчә аңлап,
Игелекләр кырын үстереп!
Дәүләт дилбегәсен тоткан затлар
Мин дигәнчә әгәр уйласа,
Бар байлыкны колачларга теләп
Илләр илгә золым кылмаса,
Нәфесенә хуҗа булып кына
Яши алса икән көчлеләр! –
Алтын-көмеш белән уйный-уйный
Беркайчан да үлмәс төслеләр...
Мин дигәнчә булса.
Мин дигәнчә...
Мең терелеп, мең кат үләмен...
Вәхи кабул иткән пәйгамбәрдәй
Тау юлыннан төшеп киләмен...

## Пушкиннан бер тәрҗемә

***(...Свободы сеятель пустынный...)***

Ирек орлыгы чәчим дип,
Иртә таңнан кырга чыктым:
Гөнаһсыз, чиста кулымнан
Җиргә орлыклар ыргыттым.
Тик әрәмгә китте вакыт,
Изге уем, дәрт-дәрманым.
Ирек кирәкмени аңа,
Мал сыман үшән гавамга
Ирешмәс барып ораным!
Утлый бир, кымшанмас кавем.
Терлеккә соң ирек нигә?!
Хайван ул чалуга лаек
Йә йонын кыркып өюгә...
Нәселдән килгән мирасың –
Шөлдерле камыт вә камчың...

## Тау сыртында томан бар

Табигатьтән сынамыш, халык әйткән гөман бар:
Көн тиз генә аязмас, тау сыртында томан бар...

Куе томан эченнән кояш куя ялтырап,
Алда әле чалт аяз якты көн дә бар сымак...

Мин әле кая барам? Тукай әйткән җөмләме...
Без соң кая барабыз – томангамы, көнгәме?!

Бу вакыт кая илтә? Әллә төн, әллә таңга?
Әллә килеп җиттекме шомлы ахырзаманга?!

Ниләр булмас томанда, – бик чамалап барыгыз,
Сөрлекмәсен абынып, тәнегез вә җаныгыз!

Тау сыртында томан бар... Тауда гынамы томан?
Илкәемне тоташтан томан каплаган сыман...

## Асрамага

Бер тәҗрибә ясыйсым килә:
Кара карга асрыйсым килә!
Тутый-мазар түгел, нәкъ карга.
Кара булсын, булсын чем-кара.

Алпан-тилпән атлап йөрсә дә,
«Карр-карр!» диеп, йокым бүлсә дә,
Күзгә туры карар иде ул,
Һәр сүземне аңлар иде ул.

Чытлыкланып, бушка сүз катмас,
Көтмәгәндә китеп, соң кайтмас,
Хыянәтсез булыр. Чәпчемәс,
Караны – ак, юкны – хак димәс...

Ул зур, сәер кара кош булыр,
Күзе очкын, күңле хуш булыр.
Кенәридәй чибәр булмас та,
Ямьсез, ләкин тугры дус булыр...

Бу тәҗрибәм, хәер, уңмастыр,
Өйдә карга асрап булмастыр...
Таш фатирда, ничә карама,
Яшәү яшәүмени каргага?

Хөр дөньяга, иркен кырларга
Асрамага ал мине, Карга!...

## Коткаручы

Корылыктан көеп, сусап бетеп, кибеп,
Дым тансыклый үлән, чишмә эзли киек.

Күләгәле куак арасына качып,
Ышык эзли кошлар, томшыклары ачык...

Ләгән тулы суны бер кабардай булып,
Очып төште коңгыз. Кем соң алыр йолып?

Үз телендә, мескен, сөрән салып ята:
«Бу күл мине йота, коткарыгыз, батам!»

Аның ялваруын кем ишетсен-белсен,
Кем ташласын салам, кем ярдәмгә килсен?!

Мин ишетәм аны! Мин – күз-колак монда.
Үләнле-бөҗәкле үз ишегалдымда.

Иелеп ләгәнгә, коңгызга кул бирәм,
Утыртып учыма, кояшта киптерәм.

Бөҗәк мине күрми, күрми – ә тотына.
Мин бит – коткаручы, ул ышана миңа!

Хисаметдин
Исмәгыйлев

# ТАШ ТҮККӘН – СИХРИ БОҖРА

РОМАН*

Хуҗаларның йорты бер тыкрык кебек урында булып, елга ярында урнашкан. Тормышларын әллә ни җитеш дип әйтеп булмый, чөнки кичләрен керосин лампасын кабызырга да рәтләре юк. «Черек теш» кайбер чакларны совет хәрбиләреннән, әфьюнга алыштырып, солярка алып кайта торган булган. Хәзер ул да юк. Алачыкларында хан заманыннан калган примус белән керогаз дигән нәрсә яга. Бакча артыннан гына тау елгасы шаулап ага. Елга буенда тал һәм башка куак-агачлар үсә. Аларны да кышын ягарга дип кисеп бетереп баралар. Тау куенына сыенып утырган бу кышлакка су элек арык буйлап агып килгән. Тик берничә ел элек язгы ташу су күтәрә торган җайланманы җимереп ташлаган. Ә дамба-арыкны яраксыз хәлгә китереп ерган. Кышлакта ирләр юк. Барысын да яңадан торгызырга, яңадан сипләргә карт-корының кулыннан килми.

Шурави беркөнне ул урынны барып карап кайтты. Кышлактан әллә ни еракта түгел, авылның югары очында икән. Әсир коллыкта көн күргән йорт бик уңайлы урында урнашкан булып чыкты. Ни дисәң дә, су белән тәэмин итәр өчен дамбаны буарга һәм арыкның җимерелгән урынын торгызырга гына кирәк. Су күтәрә торган ватык тәгәрмәч буа янында ята. Ринат йорт эшләреннән бушаган арада атна-ун көн шул зур тәгәрмәчне сипләп маташты. Аның ниятен белгәч, авылдагы малай-шалай да кушылды. Тәгәрмәч әзер. Тик ничек аны торгызып, элекке урынына утыртырга? Шулай аптырап йөргәндә, кышлакның теге очында яшәгән бер сүсәреп беткән карт килеп, өчаяк ясап, шуның ярдәмендә күтәргәннәрен сөйләп аңлатты. Ул өчаякны каян аласың да аны ясар өчен җиде-сигез киртәне каян табасың?

Күмәкләгән – яу кайтарган, ди. Бу эшкә иң элек кызыксынып, шурави берүзе булдыра аламы, юкмы, дип көткән карт-коры да, яшь җилкенчәк тә, үзләре дә сизмәстән, аңа ярдәм итә башладылар. Каяндыр өчаяклар да табылды. Зур куласага кидерергә торба да булды. Шулай итеп, ай ярым дигәндә, авылга арык буйлап су да килде. Ринатны да төнгелеккә богаулап, сарык абзарына япмый башладылар. Ашавы да бераз әйбәтләнде. Кышлактагы халык, үз авызыннан өзеп булса да, бу уңган әсиргә ихтирам

* Журнал варианты.

*Ахыры. Башы узган санда.*

күрсәтергә тырышты. Ул инде бераз иркенлек алды. Хәзер кышлактан ераграк китеп йөрү мөмкинлеге дә туды. Дөрес, аңа «черек теш»нең 10-12 яшьләр чамасындагы улы күз-колак булып торырга тиеш. Шулай кушылган. Ә алар бу малай белән күптән дуслаштылар инде.

Шулай бер сәфәрендә Ринат тау астында тәгәрәп яткан «Урал» машинасын күреп калды. Ничек итсә итте, тау астына төшеп, шул машинаны карадылар. Машина янында бер мәет ята. Аны ташлар белән күмеп, җирләп куйдылар. Бу изгәләнеп беткән бер «Техпомощь» машинасы булып, будкасы эчендәге җиһазлары урынында иде. Таланып бетмәгән. Шунда ук бензин белән эшли торган ике цилиндрлы бер электр генераторы да ята. Кайбер урыннары ямьшәйгән булса да, эшләтерлек. Менә монысы – шәп нәрсә. Һәм шуравиның башында бер уй-ният туды. Безнең халыкта «ният – ярты эш» дигән әйтем бар. Бүген шушы тау астында аунап яткан машинадан барча ачкыч-чүкеч кебек кирәк-ярак җиһазларны алып кайттылар. Шурави малайдан бу турыда дәшми торырга ант иттерде. Шулай килештеләр, малай дәшмәскә вәгъдә бирде. Икенче көнне тау астыннан теге машинада булган электр генераторын күтәрделәр. Бәләкәй арбага салып алып та кайттылар. Кызыксынучы һәм күпне күреп, күпне белергә яратучыларның шикләрен арттырмас өчен арбага чыбык-чабык һәм үлән дә тутырдылар.

Кабызып карадылар, тик генератор эшләмәде. Никадәр тырышса да, ул эшләргә теләмәде. Инде юкка алып кайттык, ахры, дип уйлый башлаган Ринатның башына бер төнне бик тә даһи уй килде. Чөнки соңгы атналарда йокысын йокламый, көне-төне дигәндәй, шушы генератор турында уйлады. Уй болай иде: ярар, двигателе кабынмаса да, генераторны су ярдәмендә әйләндерергә була бит. Тик теге су күтәрә торган тәгәрмәчкә ничек генераторны көйләп куярга? Уйлана торгач, анысын да тапты. Су күтәрә торган тегермән куласасы кебек зур куласа кырына, бәләкәйрәк тәгәрмәч әмәлләп куярга кирәк. Тырыша торгач, анысын да эшләп куйды. Кышлак малайлары бик белдекле, кайда нәрсә ятканын белмәсәләр, буламыни? Бер яр астында үзләре тәгәрәтеп төшергән зур трактор көпчәген исләренә төшерделәр. Анысын да алып кайтып, су күтәртә торган куласа күчәренә беркетә алдылар. Бала-чаганың һәм әсирнең буш вакыты шушы эш белән үтте. Шулай итеп, беркөнне су ярдәмендә генератор әйләнеп, ток бирә башлады. Менә могҗиза, менә табигатьнең сере. Чын сихер инде бу... Кышлактагы карт-коры бу сихерле машинаны карарга җыелды. Кара син аны, бу кол хезмәтчедән дә башлы кеше юктыр якын-тирәдә. Шәһәрдәге гаҗәеп ут турында ишетеп кенә белгән картлар хәзер инде үзләренең кышлагында да шундый ут барлыкка килгәнен үз күзләре белән күрде.

Тик әле әйләнү тизлеге җитмәгәнлектән, генератор бик көчсез, берничә лампочканы гына кабызырлык иде. Малай-шалай дәртләнеп, яңадан эшкә тотынды. Тырыша торгач, яңа буа буып, икенче зур куласа эшләделәр. Хәзер инде барлык эш белән Ринат җитәкчелек итте. Генераторны авыл уртасына күчерделәр, чөнки төнлә урлап та китәргә мөмкиннәр икән. Шулай итеп кышка керүгә бу егерме-утыз йортлы кышлакта, зәгыйфь кенә булса да, электр уты яна башлады. Бу хәбәр тиз арада тирә-якка таралып, бу могҗизаны күрергә күрше кышлактан килүчеләр дә ешайды.

Менә беркөнне кышлакка рухларның бик зур булмаган отряды килеп

төште. Күрәсең, кышлакта электр уты аларны да гаҗәпләндерде. Һәм рухлар командиры авылны утлы иткән колны күрәсе килгәнен белдерде.

Ни өчен чакырганнарын аңламаган Ринатны командир урнашкан бай йортына алып бардылар. Егет тагын кырны минадан чистартырга алып китәрләр инде, дип уйлады. Рухлар командиры уң аягына чатан бер яшь кенә егет иде. Әле үзенә юньләп сакал-мыек та чыкмаган бер юеш танау. Тик тыштан гына шулай күренә. Ә чынлыкта сугыш барган илдә барчасы да гаять тиз өлгерә. Һәм бу командир утны-суны кичеп чыныккан тәҗрибәле сугышчы иде. Аның алдына китереп бастырдылар. Командир бик җитди кыяфәттә, чатанлый-чатанлый, тоткынны игътибар белән алдын-артын карап чыкты. Аннан урындыкка барып утырды да:

– Пуштунча каян беләсең? – дип сорады.

– Өйрәндем.

– Үзбәкчә дә беләсең, диләр, дөресме?

– Беләм.

– Аны кайдан өйрәндең? Үзбәк мәллә?

– Юк, мин үзбәк түгел. Безнең телләр охшаш.

Теге шулай сорау ала, ә Ринат хәтер сандыгын актарып, бу рухны кайда күрдем икән, дип баш вата. Маңгаендагы миңенә чаклы таныш.

– Әйе, кайчан плен төшкәнемне дә оныттым инде. Биш ел чамасы шикелле. Гарәпчәгә һәм намаз укырга шул-шул кышлактагы Лотфулла бабай өйрәтте.

Дошман командиры тагы урыныннан торып, бик чатанламаска тырыша-тырыша, йөренеп алды. Аннан инде бик тә мөһим мәсьәлә караган кебек:

– Бүгеннән үземнең приказым белән сине кышлак малайларын укытырга мөгаллим итеп тәгаенлим.

– Малайлар?..

– Әйе, малайлар автомат тотар алдыннан хәреф танып укырга-язарга өйрәнергә тиешләр...

Түрә шулай Ринатка эшне башлап җибәрергә кирәклеге турында нотык укыды. Ә шуравиның зиһене, казан кайнагандагы шикелле кайнап чыгу дәрәҗәсенә җитеп, кызганнан-кызды. Нотык сөйләүченең тавышы да колагына бикерактан чак-чак ишетелә.

– Кара әле, әсир, әллә син мин сөйләгәннәрне тыңламыйсың да инде?

– Хайр... Хайр... ул бик яхшы итеп тыңлыйм сезне Хайр... ул.. ло, – дип куйды.

Шурави шулай тотлыга-тотлыга, бу командирның исемен чак исенә төшерә алды. Ялгышмаса, теге чакны, яңа гына хезмәт итә башлаган елны, кышлак кырында аягы яраланган малайны шулай атыйлар иде шикелле... Ялгышырга да бик мөмкин, аягы чатан бәндәләр белән дөнья тулы. Ә менә маңгаендагы миңе нәкъ шул малайныкы кебек, сул ягында иде. Тагы да үз алдына кабатлап:

– Тыңлыйм, Хайрулло, тыңлыйм, – дип тынып калды.

Хәзер инде командирның гаҗәпләнер чагы җитте. Ул да тынып калды. Эчтән генә: «Кара син аны, җир астына яшерелгән минаны да үтә күрә дип сөйлиләр, күрәсең, дөрестер. Әллә чынлап та бу әсир күрәзәчеме икән? Минем исемне каян белә?» дип уйлады.

Әфган илендә, наданлык бик көчле булу аркасында, им-томга, сихергә

һәм башка шундый юк-бар хорафатларга халык бик ышана. Беразга командир зиһен-уиларын җыя алмый торды. Чөнки командир үзенең алдындагы чын әфганнарча киенгән, инде җилкәләрен дә бераз нығытырга өлгергән сакаллы шуравины танымады.

– Син барысын да каян беләсең? Әллә сихерчеме?

– Юк, мин сихерче дә, күрәзәче дә түгелмен. Миңа, әлхәмдүлилләһ, Аллаһы Тәгалә ярдәм итә. Аның ярдәме белән менә сезнең илегездә кол рәвешендә булса да исән-имин йөрим. Иншалла! – дип, Лотфулла карт сүзләрен кабатлап җавап бирде.

Түрә инде үзенең алдында чын мөселман басып торганын зиһене белән аңлады. Шуңа да нык аптырады. Һәм гаҗәпләнеп:

– Мине каян беләсең?

Ринат бу командирның теге чакта яраланган малай Хайрулло икәненә шиге калмыйча:

– Беләм, сарык-кәҗә көткәндә, совет солдатлары аягыңны яралаганнарын да беләм. Үзеңне шул вакыт чак атып китмәделәр. Анысын да беләм. Бабай өендә ничек дәваланып ятканыңны да, кемнәр дәвалаганын да беләм, – диде дә бер мизгелгә тынып калды. Өйнең түбәсенә тезелеп чыркылдашкан чыпчыкларга карап алды. Аннан, берсенә дә игътибар итмичә, текә таулар ягына борылып һәм шул тау башындагы ап-ак бозларга күз йөртеп, үз алдына сөйләнгән кебек дәвам итте: – Сугыш бетә. Ә менә мин һаман сезнең илдә кол хәлендә иза чигәм. Миңа дә өйгә кайтырга вакыт, – дип куйды.

Командир Ринатны танымады. Танырлык та түгел шул. Әмма ул сөйләгәннәрне һушы китеп тыңлап торды. Бу әсир аның барча тормышын сөйләп бирде түгелме соң? Рух нәрсә әйтергә дә белмәде. Бары тик:

– Шуннан? – дию белән генә чикләнде.

– Син ничә тапкыр үлемнән калдың? Сиңа дә өеңә кайтырга вакыт. Мине дә үзең белән ал. Коллыктан коткару изге мөселман эше һәм саваплы гамәл. Иншалла! Коръәндә дә шулай язылган.

Әйе, иртәгәсен Ринатны Хайрулло үзе белән алып китте. Ринат шатланып бетә алмады. Чөнки бу туган илгә таба, коллыктан котылу ягына ясалган тагы бер адым иде. Хайруллоның солдатлары Пакъстан чигенә китеп бара икән. Сөйләшүләреннән шуны белде. Анда корал төялгән кәрванны каршы алып һәм саклап кайтырга тиешләр, ди. Менә ничек килеп чыкты. Ул һаман үзенең язмышы, тәкъдир күрсәткән юлдан атлап, СССР чигеннән ераклаша гына түгелме? Нәрсә язган булса да, тик яхшыга гына була күрсен инде. «И Аллам! Үзеңнең рәхмәтеңнән ташлама», – дип, Ходайга ялварды.

Икенче көнне тигезлеккә чыгып, аларны көтеп торган машиналарга төялделәр. Төркемдә утыз биш баштанаяк коралланган сугышчы. Хайрулло әсирне үзеннән ерак җибәрмәде. Аның белән киңәшләшкән булды. Әллә чын күңелдән, әллә күз буяр өчен генә. Шушы корал артыннан барулары уңышлы буламы, әллә каршылыкларга очрарлармы дип сорашты. Тагы да кабатлап инде менә ничәнче тапкыр:

– Теге көнне сугыш туктый, дидең. Моны кайдан белдең? – дип сорап куйды.

– Күңелем шулай сизә. Озакламый сугыш бетәргә тиеш. Тик үзара ызгыш-талаш булачак әле. Ә безнең сәфәр – бик куркыныч сәфәр. Уяу булырга кирәк, – дип куйды.

Башта аңа корал бирмәделәр, ул үзе дә сорамады. Чөнки беләиде: ул-бу була калып, эш бәрелешкә китсә, кемнең кулында корал, шуны беренче үтерәчәкләр. Ринат үзенең гадилеге һәм Әфган илендәге сәяси хәлне, бигрәк тә сугыш хәлләрен белмәве аркасында Совет гаскәрләре, үзебезнекеләр, әлбәттә, кәрванга һөҗүм итәрләр дип көтте. Тик безнең гаскәрләр Пакъстан чигенә чаклы килеп җитә алмаганнар иде. Чик буе районнарында рухларның төрле хәрби төркемнәре хәрәкәт итә. Кайчакны бер төркем икенче төркем сугышчылары белән дә бәрелешеп алалар.

Менә чик вазифасын үтәгән бик зур булмаган елга янында теге яктан корал төяп килгән машиналарны бушатып, рухлар бу яктан килгән машиналарга төяделәр. Пакъстанлылар үзләренең йөге өчен акча алып кайтып китте. Хайрулло шушы урында ук куна калырга булды. Учак ягып тормый гына, коры паёклар белән кичке ашны ашадылар. Командир тирә-якка сак куеп чыкты. Елга ягыннан камау һәм тегенди-мондый дошман килере көтелмәгәнлектән, ул якка сак  куймады. Качарга иң уңай вакыт җитте түгелме?! Ринат таң алдыннан елга буйлап качарга ниятләде.

Төн караңгы. Күктә йолдызлар гына чекерәешеп, бер-беренә күз кысышалар. Командир дөрес уйлаган икән, төн уртасында кемнәрдер аларга һөҗүм оештырды, бәрелеш булып алды. Шушы алыштан файдаланып, Ринат елгага таба тәгәрәп китте. Торып йөгерергә курыкты. Чөнки йә боларның, йә һөҗүм итүчеләрнең пулялары тияргә мөмкин иде.

Кайда шуышып, кайда тәгәрәп дигәндәй, елгага барып төште. Тавыш чыгармаска тырышып, су аккан уңайга йөзеп китте. Су җылы иде. Менә бераздан атышу тавышлары да тынды. Ә ул елгадан агып бара. Иң курыкканы – бу көньяк елгаларында крокодил булмаса ярар иде, дип уйлады. Кесәсендәге Лотфулла бабай калдырган бәләкәй генә үткер хәнҗәрен капшап куйды. Ярый әле, Хайруллоның солдатлары аны тентемәде. Югыйсә бабай калдырган пычактан да, әз-мәз кара көнгә дип тоткан акчадан да колак кага иде. Агым уңаена озак йөзде. Ярга чыгып, эз калдырудан курыкты. Аннан елганың аргы ягына йөзеп чыкты. Елганың урта җирендә агымы бик тә көчле икән. Ярдан менүләре дә бик читен булды. Менеп җиттем дигәндә, әллә ничә тапкыр кире егылып төште. Бик озак этләнгәннән соң гына, чак ярдан күтәрелеп, тигез җиргә ауды. Озаклап ятарлык түгел. Төнге салкыннан калтырата башлады. Инде котылдым дигәндә, суык тидерүдән куркып, ашыга-ашыга, тагын алга атлады. Атлагач, алай ук салкынлык сизелми. Хәтта бераз җылынып китте. Киемнәр дә кипшенде. Кызулык белән юеш киемнәрен дә сыгып тормаган иде.

Менә таң да атты. Ул һаман елга буйлап салынган сукмактан алга атлады да атлады. Юньләп белми дә, әллә ул Әфган, әллә Пакъстан җиреннән атлап китеп бара. Алда билгесезлек. Ә шулай да азатлыкка ни җитә, нинди татлы кичерешләр. Хет торып йөгер, хет җиргә ятып тәгәрә. Сине беркем дә тыймый. Сине беркем дә күзәтеп тормый. Һавадагы һәм елга буендагы төрлечә сайрашкан иртәнге кошларның тавышы да икенче, ирекле булып ишетелә. Кичә Хайруллодан:

– Нигә елганың теге ягына чыгып туктамыйбыз? Су да кереп алыр идек. Ул якта әнә тал-агачлар да күбрәк. Учак ягып, чәй кайнатырга да булыр иде – диюенә, теге:

– Ярамый! Ул як Пакъстан җире, – дип аңлатты.

Әфганлыларга бик ышанырлык түгел. Ул бит – аларның колы. Ә колга барысын да сөйләмиләр. Ярар, Әфган җиреме, Пакъстан җиреме, кайсы булса да, ул – азат. Тик яңадан рухлар кулына гына эләкмәскә кирәк. Ә Пакъстан җире булып, чик сакчылары очраса, аларга ни дип аңлатыр? Аларның телен аңлармы да, алар аның сөйләгәненә ышанырлармы? Чик сакчыларын искә төшерү аны айнытып җибәрде. Сакланырга кирәк. Саклангaнны Аллаһ саклармын, дигән. Чик сакчыларына нәрсә сөйләр дә нәрсә дип аңлатыр? Тотып алып, кире Әфганстанга озатсалар?

Ул шундый шөбһәле уйлар белән таллар арасыннан салынган бормалы-бормалы сукмактан атлый бирде. Яр буйлап читтәрәк юл да бар икән. Ул да бу якка борылып, аңа таныш булмаган агачлар белән ышыкланган сукмакка килеп кушылды. Моңа качкын шатланды гына, чөнки юлдан бару җиңелрәк. Агач арасыннан баргач, аны бик күреп тә бетермәячәкләр. Арттан, йә булмаса, алдан килгән машина-мазарларның тавышын ишетеп алачак. Бу аңа тиз арада агачлар арасына кереп качарга мөмкинлек бирәчәк. Ул инде гадәтенчә, юлда килеп туачак хәлләргә алдан ук әзерләнеп, һаман атлый бирде. Менә юл, кинәт кенә борылыш ясап, елгадан бөтенләй читкә борылды. Борылмада ал да, арт та юньләп күренми. Тик тавыш-мазар ишетелмиме дип, ул колакларын ныграк торгызды. Тирә-якны тыңлап, артына тагы бер кат күз салып тикшерә-тикшерә атлавын белде.

Алга борылып караганда, соң иде инде. Ул килеп чыккан борылышта бер йөк төялгән арба кыйшаеп туктап калган. Җитмәсә, кырында аны бик тә игътибар белән күзәткән адәмне дә күреп алды. Ни эшләргә? Кире борылып, артка торып йөгерергәме? Алай итәр идең, кешедә, ирексездән, шик тудырачаксың. Юл читендәге таллар арасына кереп югалырга мөмкин. Тик алай да ярамый. Әфган кышлагындагы кебек, авыл кешеләре җыелып, шиклене эзли чыксалар? Якында гына кышлак та булырга мөмкин. Ул бит бу якларны белми. Ничә көн машинада килделәр. Чынлап та, теге рух әйткәнчә, бу Пакъстан җире булып чыкса? Һәм ул үзенең сизгерлегенә таянып, юлын дәвам иттерде.

Бабай үзенең кыйшайган арбасының әле бу, әле теге ягына чыгып карый. Ә үзе юлдан килүчене күзеннән ычкындырмый. Кораллы кеше дә түгел. Типсә тимер өзәрдәй ир дә түгел. Ап-ак сакаллы карт кына бер бабай. Ринат, нишләптер, олы кешеләргә, бигрәк тә карт бабайларга ышанып карый. Бәләкәйдән үк шулай булды. Бабайның арбасына нәрсәдер булган. Җайлап кына бабай янына килде. Өйрәнелгән гадәт буенча кулын күкрәгенә куеп, бераз иелә биреп, тавышсыз гына исәнләште. Бабай аңа күз кырые белән генә карап алды да чип-чиста пуштун телендә:

– Тәгәрмәч төште, куешырга ярдәм ит, улым. Рәхим итеп! – диде.

Ринат дәшми генә арбаны карап чыкты. Тәгәрмәчне ныгытып куйган олы шөреп-болты төшкән икән. Бабай шул болтны тотып аптырап басып тора. Егет җәһәт кенә арбаның тәгәрмәче төшкән ягындагы үрәчә астына керде дә арбаны иңе белән күтәрде. Шактый авыр иде. Бабай тәгәрмәчне кидереп, болтын борып ныгытты һәм егеткә зур рәхмәтләр әйтеп, үзе янына утырырга тәкъдим ясады. Егет арбадан урын алгач, кузгалып киттеләр. Карт тегесен-монысын сорашкан була. Ринат башы белән арткы, үзе килгән якка күрсәтеп:

– Елга башындагы кышлактан киләм. Эш эзләп китеп барам. Яшәргә мөмкинлек калмады, – дигән булып, гомуми сүзләр белән генә җаваплады. Алты ел әсирлектә булу аны күп нәрсәләргә өйрәтте. Бигрәк тә чит-ятка ачылып китеп, барысын да сөйләмәскә кирәклеген күптән аңлаган иде. Бабай бик сүзчән кеше булмыйча, үзенең сораулары белән шуравиның җанын кимермәде. Икесе дә үз уйларына бирелеп, арба тибрәткән уңайга селкенеп бардылар. Менә алда тигезлектә урнашкан әфган кышлакларыннан берние белән дә аерылмаган авыл күренде.

Әйе, еракта-еракта шул ук башлары бозга каткан таулар тезмәсе күренә. Елга ягындагы тигезлек өстендә басулар җәелеп ята. Әле күктә, әле елга ягындагы тал-куаклар арасыннан чыркылдашкан кошлар тавышы ишетелә. Кышлакка керер алдыннан бабай егеткә карамый гына:

– Хәзер кайсы якларга юл тотарга уйлыйсың? – дип сорап куйды.

– Әллә инде. Кайда әзрәк акча эшләргә була, шунда барырга исәп.

Бабай тагы сүзсез калды. Дилбегәсен тарткалап, атны ашыктырды. Бераз баргач, ничектер бөтенләй чит кешегә сөйләгән кебек.

– Хәзер эш табулары, ай-һай, авыр булачак. Булмаса, әзрәк миндә эшләп ал. Кием-салымың да таушалган. Яңартырбыз. Яхшырак кием кисәң, эшнең дә арурагын табарсың. Улларым белән таныштырырмын. Алар икесе дә Карачи каласында портта эшлиләр.

Арба хуҗасы шулай диде дә тагын тынып калды. Күрәсең, бу яшь кешегә уйларга мөмкинлек биреп, җавапны ашыктырмады. Ат һаман лырт-лырт йөгерүен белде. Ат йөгергән уңайга арба да ниндидер ритмга ияреп селкенде. Кызык иде. Ике тәгәрмәчле арбада Ринат элек кол хәлендә барган булса, хәзер беренче тапкыр иректә кеше булып тирбәлеп бара. Ә алар ягында арбалар озын һәм дүрт тәгәрмәчле. Атлар да эре гәүдәле. Монда атлар вак.

Менә кышлакка килеп керделәр. Әфгандагы кышлактан берни белән аерылмаса да, монда урамнар киң һәм туры, чөнки тигезлектә урнашкан. Әнә урамның теге кырындагы пуштун үзенең лавкасын ачып маташа. Тагы да ниндидер йорт эченнән тимер чүкегән тавыш ишетелеп, борынына ташкүмер төтене исе килеп бәрелде. Тыкрыктан бер төркем халыкны тәбәнәк кенә арбасына төяп, безнең «Беларус»ларга охшаган трактор үтеп китте. Шурави коралллы кешеләрне күрмәде. Шунысына игътибар итте: урамда электр баганалары тезелеп утыра. Кышлак электр белән тәэмин ителгән икән, дип уйлап алды. Күңеле бераз тынычлана төште. Әмма аны бу бабайның пуштун телендә сөйләшкәне генә бераз шикләндерде. Пакъстанда да пуштун кабиләләре яшәгәнен шурави белми иде әле.

Бабай ике урамны тоташтырган тыкрык кебек урамда яши икән. Аның кайтканын көтеп торганнар, ахры, капкага якынаюга, ул ачылып китте. Ике яшь кенә малай икән. Берсе, йөгәненнән тотып, атны алачык кырына ук алып килде. Йорт алдына эреле-ваклы тагы берничә бала килеп чыкты. Башта чым-чыкыр килеп йөгерешеп чыксалар да, арбада чит кеше утырганын күреп, шым булдылар. Бабай:

– Менә кайтып җиттек. Әйдә, өебезгә рәхим ит, – диде.

Ринат ни дип әйтергә белмәсә дә авыз эченнән:

– Рәхмәт... рәхмәт, – дип мыгырдап алды. Һәм арбага карап:

– Утыннарны бушатып куйсак, әйбәтрәк булмасмы?

– Малайларга эшләргә дә эш калсын. Ялкауга өйрәнеп үсмәсеннәр, – дип әйтеп тә бетермәде, теге ике малай арбадагы утыннарга килеп тә ябыштылар.

Кулларын чайкап, эчкә үттеләр. Өй эче матур гына җыештырылган. Икенче бүлмәдә, кыска гына аяклы өстәл өстенә мул гына ризыклар тезгәннәр. Ашарга утырдылар. Пуштуннарның гадәтен бераз белгәнгә, егет бабайның баягы тәкъдименә дәшмирәк торды. Тегесен-монысын сөйләшкәләп ашап алдылар. Ринат ничек кенә ач булса да, алдындагы ризыкларга егылып төшмәде. Тыелды. Аның күптән мондый тәмле итеп ашаганы юк иде. Рухларның ризыклары үзләренә дә чамалы. Ризыклары үзләре кулга төшергән Совет гаскәрләренең коры паёклары гына иде. Ни дисәң дә, мондагы ризыкка хатын-кыз кулы тигәнлеге күренеп тора. Менә чәй китерделәр. Шурави чәйне рәхәтләнеп эчә-эчә, шул ук вакытта йорт хуҗасына үзенең сүзен әйтергә вакыт җиткәнен чамалап алды. Бу кунакчыл бик гади генә йорттан йә чыгып китәргә кирәк булачак, йә хуҗа әйткән тәкъдимне кабул итәргә. Ә кая барсын ул? Хәтта кайсы тарафка юл тотарга икәнен дә белми. Кемнән һәм ничек сорыйсың? Мин шул-шул, әсирлектән качып туган илгә кайтып барган совет солдаты, дип әйтсенме? Ә тотып алып ябып куйсалар? Аннан да аламасы, рухлар кулына кире илтеп тапшырсалар? Анда инде качак әсирне «Әйдә, хуш киләсең, исән-имин кайтып җиттеңме?» – дип тормаслар. Шуларны уйлап алды да әллә ни әһәмият тә бирмәгән кебек:

– Бабай, мин сезнең бая әйткән тәкъдимегезгә риза. Тик түләү ягы ничегрәк булыр? Чынлап та өс-башны ныгытырга да кирәк шул, – дип куйды.

Бабай да касәдәге чәен эчкәләп:

– Сөйләшербез. Ашау ягына килгәндә, мин ашаганны ашарсың. Үзең күреп торасың, кышлакта эшнең иң кызган мәле. Эшче куллар җитешми. Риза булып, миңа ярдәмләшсәң, эш хакыннан канәгать булырсың.

Ринат барысын да алдан уйлап, тагын өстәп куйды:

– Шунысы бар. Мин кайчан китәргә телим, шунда сездән китәм. Һәм эшләгән өчен исәпләшү шул көндә үк булса гына калам. Акча иртәгә, берәр атнадан, йә булмаса берәр айдан соң, дип вәгъдә итү булса, мин кала алмыйм. Шуңа сез риза булсагыз, калганына мин риза, – дип, килештек дигәнне аңлатып, бабайга кулын сузды.

Хуҗага болай ачыктан-ачык сөйләшү ошый иде. Һәм ул да бик канәгать елмаеп, егетнең учына шапылдатып кулын салды да җылы гына кысып куйды. Шулай килештеләр.

Ринатның монда яши башлаганына да өч айдан артык вакыт үтеп китте. Ул үзенең Пакъстан илендә икәнлеге беренче көннәрдә үк ачыклануына шат иде. Ничек кенә булмасын, ул – ирекле! Ул тәүге көннәрдән үк бабайның оныклары белән дуслашып алды. Малайлар бик ачык күңелле һәм эшчән иде. Ринат аларның кайда ничек укулары белән кызыксынган булды. Тегесен-монысын сорашты. Уку әсбаплары арасыннан географик карта табып, бик шатланды. Малайлардан сорашып, үзләренең кайда яшәгәнлекләрен күрсәтергә кушты. Һәм үзенең Әфган чигеннән әллә ни ерак булмаган бер зур гына кышлакка килеп эләккәнен белде. Шуны аңлады: Әфганстан аша туган илгә кайту турында уйлый да алмый икән. Иран иленә чыгып та кайтырга булыр иде. Тик аны билгесезлек һәм картада

төшерелгән ком чүлләре аша үтәргә кирәк булачагы куркытты. Барыннан да бигрәк яңадан коллыкка эләгүдән шикләнде. Ә бу Пакъстан дигән илдә аңа әлегә беркемнең бер сүз дә әйткәне булмады. Шулай яшәп ята. Әфганда бөтен уй-кайгысы әсирлектән ничек котылырга булса, монда барча уй-зиһенен ничек туган илгә, Уралга кайтырга дигән хыял биләп алды.

Бабай әйбәт кеше булып чыкты. Һәм бу эшчән егетне чын-чынлап яратты. Авылда үскән егет бит, тегене эшлә, моны эшлә дип әйткәнне көтеп тормый. Беренче көннәрендә үк мондагы тормышның нечкәлекләренә тиз төшенде. Әсирлектә чакта башкарган эшләрнең дә ярдәме тиде. Менә беркөнне бабайның олы улы кайтып төште. Кечкенә бәйрәм ясап алдылар. Ринат аның белән якыннан танышты. Рахмангол исемле икән. Ул Карачи кала портының ниндидер бер бүлегендә йөк төяүчеләр бригадасының түрәсе иде. Яшьләр дуслашып китте. Мамык басуыннан мамык чыбыкларын бергәләп ташыдылар. Ринат инде үзенең таулар арасындагы кышлакта үткән «балачагы» белән кыскача гына таныштырып алды. Үзе җайлап-җайлап, Рахманголның портта нинди эшләр белән шөгыльләнүе турында белеште. Сәүдә корабларының кайсы илләргә сәяхәт кылуларын һәм нинди товарлар алып барганын, кире кайтканда, нәрсәләр алып кайтуларына чаклы ачыклады. Ул инде Рахманголдан уратып-уратып кына белеште. Чөнки турыдан-туры күп нәрсәләр сораша башласа, аңарда шик-мазар тудырудан курыкты. Эшнең авырмы, юкмы икәнен сорашты. Шунысы бик кулай булды: Рахмангол сүзчән һәм бик ачык егет иде.

Озакламый Рахмангол үзенең киләсе дүшәмбе көнне Карачи каласына китәсен әйтте. Шул вакытта Ринат та әллә ни әһәмият бирмәгән кебек үзенең дә шушы арада шул якка юлга чыгарга җыенганын белдерде. Бу хәбәрдән хуҗаның улы бераз аптырабрак калды. Һәм бик тә уфтанып:

– Әле басуда эшләр бетмәгән. Син дә, мин дә берьюлы кузгалсак, әтигә кыен булачак. Әллә әзрәк эшләр кимегәнен көтәсеңме?

Ринат барсын да алдан уйлаган иде, шуңа да бераз икеләнеп торган кебек дәшмирәк торды да:

– Бабайга бик зур рәхмәт! Тау арасында мин күреп үсмәгән эшләргә өйрәтеп, күп нәрсәләргә төшендерде. Баштанаяк киендерде. Әгәр дә мине үзең белән Карачи шәһәренә алып китсәң, мин әтиеңнән эшләгән өчен бер тиен дә сорамыйм. Ә ул шушы акчага икенче бер кешене эшкә яллый ала, – диде.

Хәзер инде Рахмангол тотлыгып калды. Чөнки Ринатка дүрт ай чамасы эшләгән өчен хәтсез генә акча тияргә тиеш иде. Ул бит бу бабайга бар көчен җәлләми намус белән эшләде. Күп очракта бабай кулына эш калмый да иде. Бу егет бик тә ымсындыргыч тәкъдим әйтте түгелме соң? Шулай булуына карамастан, бабайның улы дәшми калуны кулай күрде.

Елга буеннан камыш кисеп ташыйлар иде. Өйгә кайтып җиткәнче, Рахмангол да, Ринат та бу турыда яңадан сүз куертмадылар. Һәркем үз уйларына бирелеп барды. Шурави Урал таулары, урманнар арасында калган авылын, әти-әнисен уйлады. Әйе, котылып, Пакъстан иленә чыккач, әниләренә үзенең исәнлеген белдереп, хат язып сала ала иде. Тик әлеге шул курку дигән нәрсә һәркемнең баш очында авыр күсәк булып асылынып тора. Әтиләрен, әлбәттә, милициягә чакыртачаклар. Анда инде сорау алу башланачак. Улыгыз нишләп исән калган да, нишләп безгә

дошман капиталистик илгә чыккан? Шул кадәр вакыт эчендә нигә бер хәбәр дә бирмәгән? Мөгаен, рухларга сатылып, СССРга каршы сугышып йөргәндер әле? Йә булмаса, шпион-разведчиклар әзерли торган лагерьларда укып, безнең илгә каршы берәр нәрсә эшләргә җыенадыр? Һәм тегесе, һәм монысы. Ринат шул уйларга бирелеп, үзенең якыннары, киләчәге хакында уйлады. Ә инде Рахмангол Ринат турында фикер йөртте. Чынлап та бик эшчән, тырыш егет. Нинди генә эш башкарса да, көчен җәлләми һәм ихласлык белән башкара. Әтисе дә бу тау арасындагы кышлактан чыккан егетне мактап бетерә алмый. Рахмангол шунысына игътибар итте: тау арасында үскән булса да, укыган. Кайсы гына темага сөйләшсәләр дә, аң-белеме киң. Таулардагы кышлакларның күбесендә мәдрәсә дигән нәрсә бөтенләй юк. Булса да, дин дәресләреннән башканы укытмыйлар. Андый мәдрәсәләр мондагы тигезлектә урнашкан зур кышлакларда да юк дәрәҗәсендә. Ә бу үзен Ринатулла дип йөрткән егет бик белемле. Тик үзенең ичмаса бер документ-кәгазе булса икән. Өйгә кайтып җитәрәк, Рахмангол:

– Кара әле, Ринатулла, аңлавым буенча син миңа ияреп, Карачига китәргә чамалыйсың. Шулаймы?

– Әйе, ияртсәң, синең белән юлга чыгарга иде. Ә инде үзең эшләгән Карачи портында берәр эш тә табып бирсәң, мин сиңа бик тә рәхмәтле булыр идем.

Рахмангол тагы сүзсез калды. Әмма тиздән:

– Ринатулла, менә сиңа карап торам да уйлап куям. Синең бит кулыңда бер генә документ-кәгазең дә юк. Тәүдә документ булдырырга кирәк. Чөнки эшкә урнашканда, һичшиксез документ сорыйлар. Документсыз тәүге полиция тикшерү пунктында ук сине тотып алып, кире борачаклар. Монысы яхшы очракта. Зинданга ябып куюлары да бик мөмкин.

– Документлар кирәген үзем дә аңлыйм. Безнең өйдә янгын чыгып, барча кәгазьләр дә янып юкка чыкты. Анысын юнәтү турында әллә ни башка да килмәде. Башка килгәндә дә, ул документларны булдырганчы, әллә күпме акча кирәк. Ә аны кайдан аласың? Менә шулай яшәп йөргән булам.

– Ярар, сиңа документлар ясауны үз өстемә алам. Тик син бездә тагы берике ай эшләп тор. Ай ярымнан энекәш, ягъни миннән кече булган туганым кайта. Ул да Карачи портында эшли. Шуның белән килерсең. Аңа чаклы мин сиңа берәр кулай гына эш тә табып куярмын. Риза булсаң, иртәгәдән документ артыннан йөри башларбыз.

Шулай итеп төрле мәшәкать-мажаралар белән Ринатуллага үзенең кемлеге һәм кайда туганлыгы турында документ юнәтә алдылар.

Рахмангол китте. Һәм Ринатуллага кагылышлы барча булган кәгазьләрне әтисенә калдырды. Хәзер инде Ринатка бабайның икенче улы Үмәрулла кайтканын түземсезлек белән көтәргә генә калды.

Бабайның җир биләмәсе зур гына булып, бу кышлакта ул җитеш гаиләләр исәбенә керә иде. Аты, вак-төяк эшләр өчен ишәге һәм берничә сыеры булып, башка вак малларын тауларда яшәгән ниндидер туганнарына илткән икән. Чөнки монда җәйләр бик эссе. Шуңа да күп кенә малларын таулар арасындагы кышлакта яшәүче туганнарында тота. Менә хәзер шул малларга кышка печән әзерләргә килделәр. Кыш дип, әллә ни суыклар да булмый. Дөресрәге, кыш монда юк. Әмма тауларда җәй көне дә кар бүрекләре эреми.

Ә мондагы печән әзерләүнең «рәхәтлеген» Ринат үз җилкәсендә татыды.

Әйтәм, Рахмангол аны тагы ике айга калырга ныклап үгетләде. Юкка түгел икән. Чөнки бу – чынлап торып коллар эше. Бабайның шушы таулар арасында да җире бар икән. Шунда аның малларын көтәләр. Һәм шунда ук печәнен дә әзерлиләр. Печән чаба торган җиргә бару үзе бер газап. Таудагы кышлакка барып җитмәс борын, кыя ташлар арасыннан, печәнлек урнашкан тарлавыкка төшәргә кирәк. Ә анда тик җәяү генә төшәргә була. Менә шул тарлавык төбендә куна-төнә эшләп, хәтсез генә печән әзерләделәр. Печәнне чабуын чаптылар, ә менә аны ничек моннан кышлакка алып кайтырлар икән, бу турыда әлегә ул белми иде әле. Бала чактан ук чалгы, сәнәк тоткан кешегә печән әзерләү бер уен эш кебек кенә иде...

Мондагы табигатьнең матурлыгын исә сөйләп тә, язып та аңлатырлык түгел. Искиткеч хозурлык. Тагы да астарак һәм елгага якынрак урында зур гына урманы да бар. Еракта тау итәгендә кыргый тау кәҗә-тәкәләрнең эреле-ваклы көтүләре йөргәне дә күренеп киткәли. Һавада тау бөркетләренең, канатларын кагарга да иренеп, ялкау гына очканнары күренә. Алар кайчакны печәнчеләр өстеннән дә карап әйләнә-әйләнә очкалыйлар.

Печән кибеп, вак-вак чүмәләләргә өелде. Шуннан бабай ярдәмгә көтүен көтешкән бер туганын алып килде. Юкка гына булмаган икән. Эшнең иң кыены – әзерләнгән печәнне өч-дүрт чакрым ераклыктагы юлга чыгару башланды. Бабай баудан махсус үреп эшләнгән җайланмага бер-ике сәнәк печәнне салып, бәйләп куйды. Аннан егетләргә дә шундый ук йөкне әзерләде. Менә шуннан чамалап күз алдыгызга китерегез инде. Әзер йөкләрне һәркем үзенең җилкәсенә күтәреп, алга – тау башына, юлга таба кузгалып киттеләр. Тау-таш арасыннан юлга җиткәнче берничә тапкыр туктап, хәл дә алдылар. Ринат түзәр иде дә, бабайга авырга килә. Икенче юлында ул бабайдан үзенә күбрәк салырга сорады. Миңа бу йөкне күтәреп менү берни дә түгел, күтәрә алам, дисә дә, бабай аның йөген дә чама белән генә бәйләде дә соңыннан аңлатты. Бу тау арасындагы тарлавыкта кайчакны искәрмәстән генә бик көчле җил чыгып куя икән. Күтәргән печәнеңне вакытында җиргә ташлап өлгермәсәң, печәнең-ниең белән тау астына очырырга мөмкин, ди.

Беренче көнне шулай, җилкәгә печән күтәреп, алты тапкыр чыгара алдылар. Аннан ул печәнне атка төяп, кышлакка алып кайттылар. Ринатның чамалавы буенча ике «КамАЗ»га якын печәнне егерме көн ташыдылар. Ул үзенең туган якларындагы печән әзерләүләрне исенә төшерде. Андагы печән әзерләү бер бәйрәм генә булган икән. Әйе, монда адәмчә яшим дисәң, аттан да арурак эшләргә, дөя кебек чыдам булырга кирәк.

Мондагы халык йә бик ярлы, йә ару гына бай. Ярлылар белән дөнья тулы. Кышлакта бер ике-генә кеше ару хәлле яши. Уртача яшәгәннәр дә байтак кына күренә. Алар инде иртә таңнан караңгы төнгә чаклы ат кебек җигелеп эшли. Шунысы да бар: елның җәй дигән кызу вакытында басуда кинәнеп эшли алмыйсың, артык кызу. Төштән соң сәгать дүртләр тирәсендә генә халык басуга чыга. Көне буе басуда бил бөккәннәр дә бар. Тик алар нинди халыктыр, Ринат андыйларны аңлый алмады.

Бабайның шушы ук таулар арасындагы җирендә бәрәңге бакчасы да бар икән. Анысы тагы да астарак елга кырында ук. Кояш һәм җылы җитәрлек булгач, елына ике-өч уңыш алалар. Февраль башларында ук

бәрәңге утырталар. Бәрәңге өлгергәч, кишер, чөгендер һәм нут яки башка борчак кебек нәрсәләр чәчәләр икән. Әмма барысы да яңгырга бәйле. Дөрес чәчмәсәң, корылыкка кала, анда инде уңыш көтмә.

Менә вәгъдәләшкән вакытка бабайның икенче улы да кайтты. Шулай атна-ун көн кунак булып, байтак кына эшләрен эшләшкәч, Ринатны ияртеп, Карачига алып китте. Рахмангол аларны әзерләнеп көтеп торган. Шуңа да торырга урын, ашарга ризык эзләп җәфаланырга туры килмәде. Эшкә урнашканда гына, бераз тоткарлык булып алды. Төрле түрә-тикшерүчеләрнең кулларын майлап, кесәләрен калынайтып, Ринатны да эшкә урнаштыра алдылар.

Ринат туган иле Уралга, Башкортстанга кайтырга тагы бер зур адым ясадым дип уйлады. Шул уйлар белән канатланып, үзенә йөкләтелгән эшләрне тагы да тырышыбрак башкарды. Аннан да бигрәк инглиз телен өйрәнер өчен портның үзендә үк булган тел өйрәнү курсларына язылды. Эштән бушаган вакытларында портка килгән төрле корабль һәм лайнерларны күзәтергә тотынды. Исәбе буенча бу зур портка кайчан да булса бер СССРдан килгән кораблар да керергә тиеш иде. Тик нигәдер андый корабльләр бер дә күзенә чалынмады. Бер ял вакытында шәһәргә чыгып, карта сатып алды. Шул картага, үзенә генә билгеле тамгалар белән, корабларның портка нинди илләрдән килгәнен билгеләде.

Беркөнне аның географик картада нокта-сызыклар куйганын Рахмангол күреп:

– Син нәрсә, әллә берәр чит ил разведкасына эшлисеңме? Нигә алай билгеләп барасың? Әгәр дә бу хәлне порт сакчылары белеп калса, үзеңә төрмә янаганын белеп тор. Ташла, берәрсе юри дә хәбәр итәргә мөмкин.

– Юк. Мин бернинди чит ил разведкасына да эшләмим. Англиягә укырга барасым килә. Шуңа да ул якка юл тоткан корабларны билгеләгән идем.

– Шуны алдан ук искәртәм. Әгәр дә матрослар белән килешмичә, корабка яшеренеп кереп утырып китсәң, сине кайда табып алсалар, шунда диңгезгә ташларга мөмкиннәр. Бу бигрәк тә Азия илләреннән бара торган судноларга кагыла. Европадан килгән корабларга утырырга тырыш.

– Син барысын да беләсең. Ярдәм ит миңа. Үземнең соңгы өч айда эшләгән эш хакын сиңа калдырам. Миңа Польшага, Норвегиягә, йә булмаса, Дания белән Бельгия илләренә бара торган суднолар кулай булыр иде. Бу илләр бай һәм мин анда укырга керер өчен әзрәк акча да эшли алыр идем.

Гадәтенчә, Рахмангол берни дә дәшмәде. Тик серле елмаеп:

– Синең ниятләр зурдан. Башкарып чыга алырсыңмы икән? – диде.

– Ният – эшнең яртысы. Синең ярдәмеңә ышанам.

Башкача бу турыда сөйләшмәделәр. Чөнки бүлмәгә Ринат белән бергә эшләп, бер бүлмәдә яшәгән ир кайтып керде.

Ринат әле соңыннан куркып та йөрде. Юкка бу Рахманголга барча сер-планнарны ачып салды. Ярый да бит порт куркынычсызлыгы сагында торган хезмәткәрләргә җиткермәсә. Рахмангол андый кеше түгел иде. Һәм ул беркөнне:

– Нәрсә, Ринатулла, ниятләрең үзгәрмәдеме? – дип сорады.

Тәүдә Ринатның башына сүзнең нәрсә турында барганы барып җитми торды. Һәм Рахмангол кабатлап:

– Укырга барасы планнарың турында әйтәм, – диде.

– Ә син ул турыда икән. Юк, минем ниятләр шул көенчә. Тик менә барысын да ничек башкарырга?

– Яхшы. Алайса бик яхшы.

Ринатулла портта йөк төяү терминалында эшли. Нинди генә эшләр башкарырга туры килмәде аңа. Ул вагоннар бушату, дисеңме, шул ук вагоннарга башка чит илләрдән килгән чимал-товарларны төяү, дисеңме? Барысы да булды. Алар эшләгән терминалдан күпчелек очракта чәй, дөге һәм авыл хуҗалыгы үстергән башка нәрсәләрне озаталар. Сменасы туры килгәндә, инглизчә өйрәнү курсларына йөргән булды, тик алай йөреп уку бик авыр. Аны ташлады. Рахмангол да куркытып куйды: «Карачи шәһәрендә иркенләп йөри алмыйсың. Чак кына шикләнделәрме, бетте. Тотып алып китәргә мөмкиннәр. Йә полиция, йә булмаса хәрбиләр. Аннан бит әле порт тирәсендә махсус куркынычсызлыкны тәэмин итүче хезмәткәрләр дә бар. Алар кулына эләксәң, бөтенләй исән калырмын, димә. Яшәгән ятагыңда тыныч кына яшәп, эшләп йөр. Берәр җае чыкканын көтәрбез. Минем башка бер уй килде дә ул, ничек башкарып чыгарбыз? Менә шунысы бар».

Алар шулай сөйләшеп, Ринатулланы Европага озату турында төрле планнар кордылар. Һәм беркөнне Рахмангол дусты кырына килеп:

– Шушы көннәрдә Норвегиядән килгән корабны төйи башларга тиешбез. Йөк – чәй һәм дөге. Тагын да төрле җимеш һәм йөзем. Судно әллә ни зур түгел. Мондагы егетләр белән сөйләштем. Корабка чәй тутырылган тартмалар төйи башлагач, сине шул тартмаларның берәрсенә урнаштырып булса гына инде. Уйлап кара.

– Миңа уйлап торасы юк. Мин риза.

– Анысы шулайдыр да ул. Тик шунысы бар: судно Норвегия дигән илгә чама белән айга якын барачак. Ким дигәндә, егерме көн үтәчәк. Шушы вакыт эчендә ашарга-эчәргә дә хәстәрләргә кирәк булачак.

– Мин ул егерме көнне ач кайтырга да риза...

Шулай диде дә Ринат тотлыгып калды. Чөнки артыгын ычкындырды. Аңа кайтырга дип түгел, барырга дип сөйләргә кирәк иде. Һәм ул хатасын төзәтергә була: – Норвегия иленә барырга була, ач та торырга ризамын. Сусыз кыен булачак. Су хәстәрләргә кирәк, – дип куйды.

– Суга, егермешәр литрлы ике канистр хәстәрләдем хәстәрләвен. Үзеңне һәм ул ике канистрны ничек судногакертү турында уйларга кирәк. Әгәр сизеп калсалар, үзеңә төрмә, ә бригадагызда эшләгән барыгызны да эштән куачаклар. Аларны да әле зинданга илтеп тыкмасалар... Контейнер эченә кереп утырсаң һичкем сизмәс иде. Тик ул контейнердан чыгу ягын да карарга кирәк булачак бит. Шунысы да бар: Норвегия портында ул контейнерны әллә судноны бушаткан көнендә үк алалар, әллә ун көннән соң. Ә кайчан ачалар? Менә шунысын да уйларга кирәк.

Алар шулай озак баш ватты. Мамык төргәк-тюгына кереп утырыргамы? Әллә чәй тутырылган кап-әрҗәгә яшеренергәме? Озаклап, планнар корырга вакыт бик аз иде. Ринатулланы сәүдә судносының трюмына төяләсе зур гына чәй тартмасына яшерделәр. Шул ук тартма кырындагы икенче тартмага су һәм азрак азык-төлек тә урнаштырдылар. Кирәк була калса дип, үткер генә хәнҗәр дә алды. Портта эшләүче халык бик бердәм булса да, бу

эшләрне яшерен эшләделәр. Ринатның булачак сәяхәте турында барлыгы ике кеше генә белде. Рахмангол төрле киңәшләр бирде.

Диңгезгә чыгып, биш-алты сәгать үтмичә торып тартмадан чыкмаска кушты. Һәм хәнҗәрне кулына тоттырып:

– Тартмадан чыкканда, кыенлык туса, тартманы тишеп чыгарсың, – диде.

Шулай килештеләр. Шунысы да бар бит әле: Ринат утырган тартма кая эләгә? Аста калса, үлемең шунда икәнен көт тә тор. Һәм, алдан сөйләшенгәнчә, трюмга төялгән башка чәй тартмалары өеменең иң өстенә урнаштырдылар.

Мең бәла-мажаралар белән Норвегиянең тәгаенләнгән портына килеп җиткәндә, егерме биш көн вакыт үтте. Юлда Ринат әллә ни ашарга тырышмады. Кипкән йөзем һәм хөрмә җимешеннән генә авыз иткәләде. Ач торуга килгәндә, ул инде Әфган коллыгында ач торырга өйрәнеп беткән иде. Анда бит кай вакытларны атна-ун көн ашарга бирмичә интектергән чаклары булды. Шуңа да ач торуның нәрсә икәнен белә. Ашамагач, эчәсе дә килми. Башка хаҗәтләр белән дә интегәсе аз.

Ринатның бәхетеннән, Норвегия портында йөкләрне бушатканда, кран белән өстә яткан, яртылаш ачылып, чәе коелган тартманы читкә алып куйдылар. Чөнки ватылган тартма аста калса, бөтенләй изелеп, өстәге тартмалар ишелеп төшәргә мөмкин. Иртәгә комиссия белән карап, тиешле документ тутырырга тиешләр.

Караңгы төшкәнен чамалап, Ринат яшеренгән тартмасыннан чыкты. Уңайсыз, кәкрәеп ятудан һушы алынып, чак аягына басты. Портта салкынча, җиләс. Җитмәсә, яңгыр сибәләргә чамалый. Ринат портта төнлә дә эш кайнап торганлыгын белә. Тирә-юньне прожектор-фонарьлар яктыртып тора. Аларның яктысына эләкмәскә нихәтле генә тырышмасын, бу мөмкин түгел. Бар җирдә дә эш кайный. Бушаткан йөкләрне әле бер урынга өяләр, әле икенче урынга күчерәләр. Ринат аптырагач, йөк машиналары киткән якка атлады. Порттан чыгу урыны шул якта булырга тиеш дип чамалады. Ләкин бу ят киемгә киенгән һәм күп көннәр ашамаудан бөтенләй хәлсезләнеп, чак атлап барган кешене бая ук күреп калганнар иде. Өч кеше ике беләгеннән килеп тоткач, ул дертләп куйды. Ләкин качып китәргә, йә булмаса каршылык күрсәтергә аның хәле дә, теләге дә юк иде.

Беләктән келәшчә кебек эләктергәннәрнең берсе таныш түгел телдә нәрсәдер сорады. Тик ул бу телне бөтенләй аңламаганга мәктәптә немесчә укыганлыктан:

– Найн, – дигән булды.

Карачи базарында европача киенергә тырышып, ару гына чалбар белән свитер дә алган иде дә бит. Чит-ят икәне әллә кайдан күренеп тора, барыбер эләктерделәр. Тегеләрнең берсе немес телендә берьюлы әллә нәрсәләр сорап ташлады. Болар әйткәннәрнең берсен дә аңламаганга ул тагы:

– Но, но, – диде.

Хәзер инде инглизчә нәрсәдер сораша башладылар. Тик ул тагы бернәрсә дә аңламады. Аптырагач ул, мин Россиягә кайтып барам дип, урысча әйтергә мәҗбүр булды. Хәзер үзен эләктергән адәмнәр берни дә аңламадылар. Шулай да Ринат үзен полиция бүлегенә алып барачакларын аңлады. Ярый әле, ул полиция бүлеге бик ерак булмыйча, тиз барып җиттеләр. Тагы да бераз атласалар, аның хәле бетеп егылырга мөмкин иде.

Менә йөк бушату һәм төяү терминалыннан читтәрәк торган ике катлы бинага алып керделәр. Өстәл артында чиста итеп кырынган олы гына яшьтәге зәңгәр күк төсендәге күлмәк кигән полиция хезмәткәре утыра. Ул бу өчәүдән аягында чак басып торган Ринат турында сорашып, сөйләшеп алды да аңардан паспортын сорады. Ринат паспорт сүзеннән үзеннән нәрсә сораганнарын аңлады. Аның кесәсендә Пакъстан паспорты гына иде.

Аягында чак басып торганын күреп, аңа урындык тәкъдим иттеләр. Сөйләшә торгач, аның русча белгәнен аңлап, тылмач алып килделәр. Ринат үзенең Әфган әсирлегеннән качып кайтып барганын аңлата алды. Тагы каядыр шалтыратып, әллә кемнәр белән сөйләшеп алдылар. Нindидер кенәгәгә исем-фамилиясен кабат-кабат сорап язып куйдылар. Шуннан бу хәлсез әфган тоткынына кофе белән печенье һәм ысланган дуңгыз ите кыстырылган бутерброд китерделәр. Диванда ял итеп алырга тәкъдим иттеләр.

Күп көннәр чәй әрҗәсендә бөкләнеп-бөгәрләнеп яткан кешегә йомшак диванга сузылып-киерелеп яту бик рәхәт иде. Тик аны йокы алмады. Тылмач сөйләгәннәрне тагы бер тапкыр хәтерендә барлап ятты. Ул тәрҗемәчедән үзен ни эшләтәчәкләрен сораган иде, тегесе кулбашларын сикертеп: «Иртәгә органнар барысын да ачыклар. Кире Пакъстанга җибәрергә дә мөмкиннәр, йә булмаса, бүтән берәр нәрсә тәкъдим итәрләр. Ә иң яхшысы: Ослодагы Совет илчелегенә тапшырырлар», – дигән булды. Их, шулай гына була күрсен иде. Пакъстанга кире җибәрергә уйласалар, һич анда бармаячак. Көчләп, корабка утыртсалар, төнлә суга сикерәчәк. Юк, кире ул якка аңа юл ябык. Үлсә дә, туган ягы Башкортстанга – Уралга кайтып үләчәк. Ул бит әти-әнисенә исән-сау кайтырга вәгъдә бирде. Менә ничәмә еллар үткәч, инде шушы якты хыяллары тормышка аша дигәндә, яңадан үлем бозрасына эләгәсе килми. Ул шул үлем боҗрасына эләкмәс өчен барысын да эшләячәк. Кулдан килгәнен дә, килмәгәнен дә. Шулай уйланып ята торгач, ул йоклап китте.

Иртән полиция бүлегендә смена алышынганда уянды. Уянганын сизеп, аңа бәдрәф бүлмәсен күрсәттеләр. Иркенләп һәм рәхәтләнеп юынып алды. Их, мунча кереп чыгарга иде дә бит, каян табасың андый туган яктагы кебек каен утыны ягылган мунчаларны. Идәнгә бераз су чәчрәгән иде, кәгазь тастымал белән аны корытып маташканда, ишек ачылып китте. Аның идәнне корытып йөргәнен күреп, кабинетта утырганнар бер-берсенә карашып куйдылар да, үзара нәрсәдер әйтешеп, көлешеп алдылар. Тагы кофе белән ризык тәкъдим иттеләр. Ринатның кәефе күтәрелеп китте. Ул һаман үзенең Норвегия иленә килеп җиткәненә ышанмый иде. Әйтерсең лә, болар барысы да төш кенә.

Бераздан телефон шалтырады, өстәл янында утырган полиция хезмәткәре Ринатка карый-карый, нәрсәдер сөйләшеп алды. Күп тә үтмәде, аның артыннан икенче бер яшь кенә полиция хезмәткәре килеп җитте. Менә аны машина белән каядыр алып киттеләр. Юлда машина тәрәзәсеннән карап һәм полиция бүлегендәге диварда эленеп торган картадан укып, үзенең Норвегиянең башкаласы Ослога килеп эләккәнен аңлады. Сәүдә судносының кая барасын Рахмангол дөрес әйткән икән. Менә шулай элекке Совет солдатын, Әфганстандагы шурави, аннан рухлар тоткыны һәм җиргә күмелгән үлем миналарын үтә күрүче гаҗәеп әсир һәм элекке кол-качкынны

Норвегиянең полиция машинасында билгесезлеккә алып китеп баралар. Их, белсә икән ул үзенең газиз башкайлары ниләр күрәсен? Тик кеше дигән Аллаһ колы үзенең маңгаена язылган тәкъдир-күрәчәген әлегә чаклы укырга өйрәнә алмаган шул. Мөгаен, шулай яхшырактыр да әле. Анысын инде шул Аллаһ дигән Илаһи-барча Галәмне юктан бар кылган Зат кына белә торгандыр.

Ринатны фотосурәтләргә төшереп, махсус кәгазьгә бармак эзләрен бастырып алдылар. Ниндидер корреспондентлар да килеп сораштырган булды. Нәрсәләрдер яздылар. Тәрҗемәчеләре бик шәптән түгел иде. Мигрантлар хокукын яклап, аларның мәнфәгатьләрен кайгыртучы оешмадан килгән берәү аны мунчага алып, барып эчке киемнәрен алыштырды. Аннан баштанаяк киендерделәр. Чөнки Пакъстаннан киеп килгән киемнәре җәйге эсседә генә кия торган иде. Ә монда шактый салкынча һәм дымлы.

Полициядә аның кем икәнлеген тәмам ныклап ачыклагач, мигрантлар һәм качаклар белән шөгыльләнә торган бер оешма карамагына тапшырдылар. Кунып һәм бер ашханәгә кереп ашап йөрер өчен бу ябык егетнең кулына талон да тоттырдылар. Ринатны иң нык гаҗәпләндергәне: бу илдә тәртип һәм чисталык иде. Кешеләр дә Карачидагы кебек каядыр ашыкмыйлар. Үзләренең бәһаләрен белеп кенә йөриләр. Ә инде теләнче һәм хәерчеләргә килгәндә, алар монда бөтенләй күренми.

Беркөнне Ринатны иртән үк психологка чакырдылар. Бер яшь кенә хатын икән. Пуштун телендә сөйләшә. Хатын аңардан төрле-төрле тест-сорауларга җавап бирдерде. Шулай җайлап кына сөйләшә торгач, хатын аның нинди милләттән булуын сораша башлады. Әлбәттә, егет үзенең милләтен әйтте. Тик хатын андый милләт турында белми иде шикелле. Шкафтан бер китап алып, шуннан караштырып утырды. Тагы нинди телләрдә иркен сөйләшә алганын ачыкларга тырышып:

– Тагы нинди телләрдә сөйләшеп, аңлаша аласың? – диде.

– Татарча һәм русча.

– Русчаны кайдан беләсең?

– Безгә мәктәптә рус телен дә өйрәттеләр.

Шуннан бу хатын каядыр шалтыратып, берәү белән сөйләшеп алды. Күп тә үтми, бүлмәгә олырак яшьтәге икенче бер хатын килеп керде һәм бүлмәдәгеләр белән норвег телендә исәнләште.

Бүлмәдәгеләр дә, урыннарыннан торып, һәркем үзенчә җавап бирде. Шуннан бу яңа кергән хатын Ринатны үзе белән алып, икенче катка менде. Иң элек егеткә утырырга кушып, йомшак диваннан урын күрсәтте. Үзе тиз генә кофе әзерләп, егеткә тәкъдим итте. Һәм моңарчы Ринат белән русча гына сөйләшкән хатын, аны сискәндереп, юк, сискәндереп кенә түгел, бөтенләй гаҗәпләндереп, татарча:

– Йә, сөйлә, туганым, нинди язмышлар бу якка китереп ташлады? – диде.

Ринат, ни әйтергә дә белми аптырап, тотлыгып калды. Чөнки армиягә алынганнан бирле, ничәмә еллардан соң, туган телен беренче ишетүе иде. Тамагына төер килеп утырды, керфегенә аның ихтыярыннан башка яшь эленде. Ул тешләрен кысты һәм туктаусыз юк төкереген йота башлады. Аптырагач, тамагын кыргалап алды. Нәкъ шул мизгелдә егетнең бәхетеннән телефон шалтырады. Хатын телефоннан кем беләндер тиз-тиз сөйләшеп алды. Шушы вакыт Ринатка үзен кулга алып тынычланырга җитә калды.

Алдындагы чынаяктан берничә йотым кофе эчте. Хатынга сиздермәскә тырышып, яшен сыпырып төшерде. Тик хатын бик сизгер иде шул, егетнең хәлен сизмәмешкә салышып утырса да, барысын да күреп, сизеп торды.

Телефоннан сөйләшү бетте, хатын диван кырындагы кәнәфигә килеп утырды да баягыдан да тынычрак һәм ягымлы тавыш белән:

– Сөйлә туганым, сөйлә. Мин Фәридә исемле булам. Монда икебездән башка беркем дә юк. Кыенсынма, – диде.

Әйе, менә ничәмә еллар үзенең кем, нинди кеше икәнлеген ул кемнәрдән генә яшермәде. Үзе турында бик сөйлисе килеп, эч серләрен үзенә ярдәм иткән Рахмангол белән дә уртаклашырга курыкты. Әйе, Ринатка үз башыннан үткәргән коточкыч вакыйгаларны кемгәдер сөйләп, эчен бушатырга кирәк иде. Һәм ул йөрәге белән сизде: шушы урта яшьтәге, бераз гына татарча белгән апага сөйләргә кирәген аңлады. Тагы алдындагы кофены бер эчеп, тамагын кыргалап алды да җай гына сөйләп китте.

– Әйе, мин Урал тавы итәгендә урнашкан Таш Түккән авылында тудым. Армиягә да шуннан алдылар...

Ринат никадәр кыска һәм йомшартып сөйләргә тырышса да, сөйләгәне ару озын һәм кызганыч иде. Мондый хәлләрне үз башыннан үткәрмәгән кеше берничек тә һавадан алып сөйли алмас.

– Шушылай чәй сала торган тартмада яшеренеп, Норвегия иленә килеп җитә алдым. Менә барча башымнан үткәннәр, – дип егет үзенең тормыш юлын сөйләп бирде. Әйтерсең лә бик авыр йөктән котылган кебек тирән итеп тын алганнан соң, җиңел сулап куйды.

Вакыт та ару гына үткән икән. Егет башын күтәреп караганда, теге апа тәрәздән тышны күзәтә иде. Менә ул Ринатка борылып карады, аның күзләреннән дә яшь ага иде. Хатын дәшми генә килеп, егетнең башыннан сыпырып, аркасыннан яратып алды да:

– Туганым, Аллаһ ярдәм итеп, алдагы көннәреңдә бәхет бирсен үзеңә! Әти-әниеңне исән-сау кайтып күрергә язсын. Монда чагыңда үзем ярдәм итәрмен. Тынычлан, берүк тынычлана күр, – дип, егетне юатты.

Бу армиягә озатканда, аркасыннан сыпырып, үз әнисе тынычландыргандай тоелды. Тешләрен кысып, ничек кенә еламаска тырышса да, барып чыкмады. Егет түзмәде, тавышсыз гына елап җибәрде. Әйе, аның әсирлектә үткән коллык тормышы артта калды. Шул тормышның артта, еракта калганына менә әле генә ышанып, күңеле йомшарып китте. Ул бит әлеге мизгелгә чаклы үзенең тоткынлыктан котылуына күңеле белән ышанмый иде. Хәзер ул әсирлектән качкан качак түгел, ә Норвегия илендә мигрант иде.

Бераздан егет тынычланды. Яшьләрен учы белән сөртеп төшерде. Моны күргән ханым аңа кесәсеннән кулъяулык чыгарып биреп:

– Үзеңә үк ал, туганым. Бер истәлек булыр. Вакыт соң инде. Әйдә, шушында урам чатында гына бер бәләкәй ресторан-кафе бар. Шунда кереп капкалап алыйк.

Ринат, ризалыгын белдереп, башын гына какты. Һәм менә алар өстәл артында кичке аш ашап утыралар. Ринат тәмам тынычланды. Ул инде бу татарча сөйләшергә тырышкан апага үзе дә сораулар бирергә батырчылык итте.

– Ә сез татарча кайдан беләсез?

– Минем әтием – Уфа татары. Аны фин сугышына алалар. Ул шунда

кар өстендә ятып, аяк-кулларын туңдыра. Аны фин солдатлары табып алып, тылга – госпитальгә озаталар. Әнием – Финляндиядә туып үскән татар кызы. Госпитальдә шәфкать туташы булып эшли. Әни әтине коткара. Икесе дә – татарлар. Әти терелеп чыга һәм әнигә өйләнә. Менә шуннан беләм татарчаны. Мин Хельсинки университетында көнчыгыш телләр факультетында укыдым.

Апа бераз тынып торды да сәгатенә карап алды.

– Ярар, туганым, бүген бик соң инде. Калганын иртәгә сөйләшеп бетерербез. Хәзер мигрантлар үзәгендәге ятакка кайтып ял ит.

Хатын кафедагы телефоннан такси чакырды. Юл уңаенда Ринатны озатып куйды.

Икенче көнне егетне яңадан теге апа чакыртып алды. Тагы озак кына дөнья хәлләре, Ринатның гаиләсе, туган авылы турында сорашып, сөйләшеп утырдылар.

Шуннан Фәридә ханым:

– Туганым, онытып торам, безгә сәгать уникеләргә шул-шул урамда урнашкан Совет илчелегенә барырга кирәк. Синең исемнән кабул ителүгә язылдым. Шунсыз туган илеңә – Башкортстанга кайтулары бик кыен булачак. Илчелектә үз гражданнарына ярдәм итәргә тиешләр. Бу – Халыкара конвенциядә, кеше хокукларын яклау параграфында язылган кагыйдә.

Алар илчелеккә барып җиткәндә, кабул итү башланмаган иде әле. Фәридә Ринатка ничегрәк сөйләшергә, үзен ничегрәк тотарга кирәклеген бераз гына өйрәткән булды. Чөнки егет үзен бик ышанычлы тоймый иде. Кыюрак булырга кушып:

– Үзеңнең әсирлектә булуыңны, качып, Пакъстан иле аша Норвегиягә килүеңне кыскача гына сөйлә. Озакка сузма. Анда эш белән бик мәшгуль кешеләр утыра. Шуңа да үзеңә кирәген генә сөйлә, кыюрак бул, – диде.

Менә Ринатның чираты җитте. Аны илчелекнең эмигрантлар һәм Ринат кебек туган илләренә кайтучылар белән эшләүче яшь кенә ир кабул итте.

Нинди мөрәҗәгать белән килгәнен сорады. Ринат кыскача үзенең хәлен сөйләп, туган иленә кайтырга теләвен әйтте. Бик чиста итеп кырынган, кояш күрмәгәндәй гаҗәеп ап-ак битле бу бәндә төксе генә:

– Нинди документ-кәгазьләрең бар? – дип сорап, кызларныкы кебек шома һәм озын бармаклы кулын сузды.

Ринат Пакъстан паспортын һәм Норвегиядә бирелгән мигрантлар бүлегендә вакытлыча яшәргә рөхсәт кәгазен күрсәтте. Ринат русча бик үк чиста сөйләшми иде, шуңа да бу бәндә аның кәгазьләрен бераз караштыргач:

– Кайда тудың, кайсы шәһәрдә яшәдең?

– Башкириядә тудым. Шунда яшәдем. Мин – авыл егете.

– Андый өлкәне белмим. Нәрсә мине алдап басып торасың?!

Хезмәткәр җайлап кына кыза башлады. Сүзләре берәм-берәм мылтыктан аткан кебек һәр әйткәне өстәлгә йодрык белән суккандай яңгырый. Бу бәндә Мәскәүдәге бер зур гына түрәнең килделе-киттеле укыган һәм бик иркәләп кенә үстергән бердәнбер улы иде. Наданлыгы чиктән ашкан бер бәндә. Төрле дус һәм акча ярдәмендә әтисе шушы урынга урнаштырган. Шуңа да ул Башкортстанның кайда икәнен дә белми иде. Идел елгасының аръягында яшәгәннәр аның өчен барысы да – кыргый халык.

Эшнең болайга борылганына бераз югалып калган Ринат:

– Мин – Уфадан, татармын, – дип әйтергә мәҗбүр булды.

Кулына алган кәгазь-документларны Ринат алдына тупас кына ташлап:

– Сатлыкҗаннарга бездә урын юк! Әнә анда сине Пакъстан гражданины дип күрсәткәннәр. Шунда кайтып кит. Пошёл отсюда, предатель! Ишь син аны, туган иленә кайтасы килгән, сатлыкҗан татар. Сиңа төрмә белән Колыма чак таман!

Ринат барыбер түзмәде, чыгып киткәндә, хезмәттә чакта рус егетләреннән ишеткән иң начар сүгенү сүзе дип исәпләнгәнләрен әйтеп, ишекне каты гына ябып чыгып китте.

Күпме якты өмет-хыяллар белән илчелекнең капкасын ачып кергән иде бит. Менә хәзер барысы да тузан булып, җилгә очты. Аңа шулкадәр үкенечле иде. Ирексездән, күзеннән яшьләре атылып чыкты. Туган илгә, туган авылга, әти-әниләр янына кайтып булмас микәнни, дип уйлап алды. Ринат кара янып, илчелек капкасыннан килеп чыккач, Фәридә ханым барысын да аңлады. Әниләрчә:

– Һич паникага бирелмә! Бүген булмаса, иртәгә, монда булмаса, икенче урында булыр. Иң мөһиме – син исән-сау Норвегия иленә килеп җиттең. Ә бит күпләрегез, әсирлектән котылу түгел, һаман шунда кол хәлендә яшәп яталар. Аннан да бигрәк күпме совет солдаты Әфганстанда ятып калды. Ә син исән. Таза, сау-сәламәтсең. Һәм яшьсең. Тормышың алда әле, – диде.

Эмигрантлар һәм күченүчеләр эше белән шөгыльләнүче оешмага кайтып җиткәч, Фәридә ханым Ринатны тагын үзе эшләгән бүлмәгә чакырды. Тиз генә кофе өлгертеп, печенье, тәм-томнәр белән егет алдына куйды. Үзе дә егет каршысына утырып, ерактан гына сүз башлады.

– Ярар, туганым, барысын да төзәтеп була торган хәл. Син Европаның иң бай, алдынгы һәм иркле илендә икәнеңне белергә тиешсең. Алдыңда шундый юллар, шундый юнәлеш-тармаклар тора. Монда Әфганстан да, Пакъстан да түгел. Бу, туганым, Европа, Норвегия! Телисең портта эшлә, теләсәң, нефть промыселендә акча каер. Диңгездә балыкчылык тармагында эшләсәң дә, буш калмассың. Менә мин ирем белән Финляндиядән килеп эшләп йөрим. Ярар, хәзергә сине СССР кабул итмәде. Соңрак кабул итәр. Шунысы да бар бит әле, илеңә кайткач хөкем итеп, Себергә дә сөрергә мөмкиннәр. Шуны да уйла. Илчелектә нәрсә әйттеләр? Күреп торам, сине кочак җәеп каршы алмадылар.

Ринат бераз тынычланган иде. Ул инде бу киң күңелле апаны тыңламады да диярлек. Ханым үзенең соравын тагын кабатлады:

– Илчелегегездә нәрсә дип әйттеләр?

Шунда гына Ринат апаның соравын ишетеп:

– Мине кабул иткән ниндидер бер ишәк, безгә сатлыкҗан татар кирәкми, – дип әйтте.

– Ярар, аның өчен янып көймә. Киләсе атналарга посол үзе кабул итәргә тиеш, диделәр. Ниндидер эш белән Мәскәүгә чакырганнар икән. Әле кайтасы күперләр янып бетмәгән.

– Юк! Мин анда башкача бармыйм. Монда чаклы кайтып җиткәч, туган илемә ничек тә кайтып җитәрмен әле. Җәяүләп булса да кайтачакмын.

– Болай үҗәт булуың мактауга лаек. Бу илдә әзрәк эшләп, акча җыеп

кайтсаң, тагы да яхшырак булыр иде. Кайда эшче куллар җитмәгәнен бая сөйләдем. Тик моның өчен норвег һәм инглиз телен өйрәнергә кирәк булачак. Телне өйрәнү өчен бушлай курслар бар. Тырышсаң, алты ай эчендә ипи-тозлык өйрәнергә була. Эшкә урнашырга үзем ярдәм итәрмен. Бер-ике ел эшләсәң, кайткач яшәп китәргә менә дигән мая булачак.

– Булмый, мин әти белән әнигә баеп кайтырмын дип түгел, ә исән-имин кайтырмын дип вәгъдә бирдем. Шулай булгач, миңа ничек тә тизрәк Башкортстанга, туган илемә кайтырга кирәк. Сез миңа нык ярдәм иттегез. Монысы өчен бик зур рәхмәт! Тагы да бу илдән ничегрәк СССРга кайтып була? Ярдәм итсәгез, бик яхшы булыр иде.

– Итәм, туганым, ярдәм итәм. Без – мөселманнар, бигрәк тә татарлар, бер-беребезгә ярдәмләшергә тиешбез. Кыен чакта гына түгел, һәр көнне, һәр сәгатьтә. Ә бүгенгә шәһәр белән таныш. Экскурсия автобусларына утырырга мөмкин. Тик анда инглиз телендә сөйлиләр инде. Барыбер карап, күреп чык. Бик матур ил. Астагы катта кассада паспорт һәм вакытлыча яшәргә рөхсәт кәгазеңне күрсәтеп, акча һәм туристларга хезмәт күрсәтә торган автобуска билет алырсың. Ул автобус сәгать саен урам аша гына булган тукталышка туктап китә. Иртәгәгә кадәр сау булып тор!

Ринат Норвегиянең башкаласы Осло белән танышырга сәяхәт автобусына утырып китте. Аңа бүгенге хәлләрне анализлап, киләчәккә ниндидер планнар корырга кирәк иде. Портка, йә булмаса, порт тирәсенәрәк эшкә урнашырга кирәк булыр. Монда чаклы килеп җитә алганны, диңгез аша торган туган илгә кайту әллә ни кыен булмас. Мөгаен, Фәридә апасы әйткәнчә, юллык булса да, акча эшләр. Тик ул дигәнчә генә бармый шул дөнья...

Осло шәһәре әллә ни зур түгел. Шуңа да мигрантлар үзәгенә җәяүләп кайтырга булды. Кайтышлый әллә ничә урында гына сакаллы ирләрнең бер-берсен кочаклап, үбешеп торганнарын күреп, хәйран калды. Хезмәттә чакта ишеткәләп калган иде шундый ирләр турында. Ышанмады. Ә монда көпә-көндез урам чатында шундыйлар басып тора. Кешеләре дә әллә нинди караңгы чырай-кыяфәтлеләр. Хатын-кызлары да ул кадәр нәфис, назлы күренмиләр. Әйтерсең лә, кулы эш белмәгән балта остасы әле генә юнып ясаган да урамга чыгарып җибәргән. Юк, бу илдә бер минут та калырга ярамый. Тизрәк ычкынырга кирәк моннан. Шундый җәмгыять була, димени? Әфганстанда да, Пакъстанда да мондый ирләрне таш белән бәргәләп үтерерләр иде дә, ишәк койрыгына бәйләп, чүлгә чыгарып очырырлар иде.

Әйе, Норвегия – бай һәм җитеш тормышта яшәүче ил. Әмма Аллаһ сакласын мондый җәмгыятьтә яшәүдән. Чираттагы очрашуда Фәридә ханымнан туры китереп сорады да әле.

– Болар нинди ирләр? – диде.

– Аптырама, туганым. Бу бит – көнбатыш. Монда демократия бик көчле үскән. Кем-кемгә ошый, кем-кемне ярата – беркемнең дә монда эше юк.

– Әйе, һуш китмәле хәлләр. Юк, Фәридә апа, мин мондый илдә кала алмыйм. Мөмкин булса, тизрәк миңа моннан ычкынырга кирәк. Берәр җаен табыйк инде.

– Туганым, ашыкма! Һәр нәрсәнең үз вакыты. Озакламый миңа ял бирәләр. Финляндиягә кайтып киләсем бар. Шунда бергә кузгалырбыз.

Аннары Финляндиядән Россиягә чыгу өчен бернинди каршылык булмаячак. Кайбер нәрсәләрне тиз генә эшләп тә, башкарып та булмый. Һәм барысын да сиңа ачып та сала алмыйм. Үзең аңла. Әлегә шул вакытлы эшеңне башкарып тор. Эш алай кыен түгелдер бит?

– Юк, мин эшнең авырлыгыннан куркып тора торган кеше түгел. Вакытлыча булса да эшкә урнаштырдыгыз. Рәхмәт! Әти-әниемне шул кадәр сагындым. Сөйләп кенә аңлатырлык түгел. Башкача көтәргә тәкатем калмады.

Шушы сөйләшүдән соң менә берничә ай үтеп тә китте. Ә көннәр сузылды да сузылды. Инде Ринат Фәридә ханымга да шикләнеп карый башлады. Күңелендә: «Мине юри алдап, төрле вәгъдәләр белән юмалап йөрми микән? Инде бу вакыт эчендә Финляндиягә җәяүләп тә барып җитеп булыр иде. Мөгаен, апаның ялган вәгъдәләренә ышанып тормаска кирәктер. Киләсе айга качам», дип, төрле планнар да кора башлады.

Атна азагында Фәридә ханым егетне чакыртып алды да:

– Дүшәмбе көннән минем ялым башлана. Якшәмбе кич белән юлга кузгалабыз, – дип шатландырды.

Бу шатлыктан Ринат ике тәүлек йокламады дияргә була. Якшәмбе көнне кибетләрдә юл кирәк-яраклары һәм егеткә матур гына копюшонлы куртка да алдылар. Билгеле, барысына да Фәридә түләде.

Фәридә ханым Хельсинкига чаклы паромга ике билет алган булып чыкты. Шушы паром белән әллә ни маҗараларсыз гына Финляндия башкаласына килеп җиттеләр. Ә инде шул атнаның җомга көнендә Ринат Финляндиядәге Совет илчелегенә кабул ителүгә керә алды. Монда Фәридә ханымның бергә укыган курсташлары ярдәм итте. Шуларның булышлыгы белән менә кабул итү бүлмәсендә үзен чакырганнарын көтеп утыра.

Илченең беренче ярдәмчесе үзе кабул итте. Олы гына яшьтәге бер абзый. Ринат белән бик ипле генә сөйләште. Төрле-төрле сораулар бирде. Кырында утырган ярдәмче кыз барысын да яза барды. Кабул итү әллә ни озак булмаган кебек тоелса да, сәгать ярым вакыт үтеп тә киткән икән. Ринатка исеме белән бик тә рәсми генә:

– Хөрмәтлем! Кайбер мәгълүматларны ачыклаганчы һәм Мәскәүдән җавап килгәнче, бераз көтәргә туры килер. Монда кадәр кайтып җитә алгач, ике көнгә генә түзәрсез инде. Дүшәмбе көнгә шул-шул вакытка килерсез. Кайда туктадыгыз? Ашарга-эчәргә һәм кунакханәгә түләр өчен финанс якларыгыз ничек? – диде.

– Норвегиядән монда чаклы паромга билетны бер апа алып бирде. Әле алар йортында туктадым. Акча ягы юк инде, – дигәч, илче ярдәмчесе кемгәдер шалтыратып, егеткә финанс ярдәме күрсәтергә кушты.

Шулай итеп, Совет илчелегеннән әзрәк ярдәм дә алып, урамга чыкты. Фәридә ханым урамда такси белән көтеп тора иде. Аларга киттеләр.

Әгәр дә илчелектә, «бар, кайта тор, сине чик аша бер тоткарлыксыз үткәрәчәкләр», дисәләр, ул кайтыр якка торып йөгергән дә булыр иде.

Дүшәмбе көнне илчелектә аның кулына төрле белешмә кәгазьләр тоттырып, хәерле юл теләделәр. Ринатны нык аптыратканы эшнең болай тиз башкарылып чыгуы иде. Саубуллашканда, Фәридә ханым Ринатны кочаклап:

– Ринат, СССРда әлеге вакытта тәртип бетте. Көне-төне илегез таралыр

чиккә килеп җитте дип сөйлиләр. Бик авыр була башласа, кире кил. Үземә шалтыратырсың. Менә адресым һәм телефон номерым язылган визиткам. Тизрәк инглиз теле өйрәнергә тырыш!

Ринат шул көнне үк Хельсинки – Мәскәү поездына утырып кайтып китте. Әйе, поезд тәгәрмәчләренең һәр әйләнеше аны туган иленә, Башкортстанга, Уралга якынайта. Күршеләренең барысы да диярлек вагон тәрәзәсеннән табигатьне күзәтеп баралар. Кайберләре чәй эчәргә әзерләнә башлады. Өстәл өстенә төрле-төрле ризыкларны тезеп, ашарга утырдылар. Ирләрнең берсе Ринатны табынга чакырды. Ул бик итагатьле генә итеп тәкъдимне кире какты. Ашау кайгысымы соң анда?! Бар уе белән ул күптән балачагы үткән Түгәрәк тау итәгендә, авылдашлары янында иде. Инде менә ничәнче тапкыр, ничек итеп авылга кайтуын, ничек итеп капкадан керәчәген күз алдына китерде.

Моннан сигез ел элек хезмәткә киткән көненнән башлап, әлегәчә үткән тормышын күз алдына китереп ятты. Ничек түзде икән ул кимсетү, хурлыкларга? Ничек итеп, ул миналар белән бергә шартлап, һаваларга очмады да, кырында күпме иптәшләре аның күз алдында шул миналар астында һәлак булганда, ул исән калды икән? Әле дә уйлап аптырый...

Шулай туры килде. Авылларына кичләтеп кенә кайтып керде. Юлда күпме генә игътибар белән караштырып кайтса да, танышларын да, авылдашларын да очратмады. Менә ул үз капкалары алдында басып тора. Капка кыйшайган. Йорт алдына үлән үскән. Хәтта йортка кергән сукмак та юкка чыккан. Ринатның йөрәге кысылып куйды. Нәрсә уйларга да белмәде. Капканы ачып, бил тиңентен үскән әремнәрне таптый-таптый, йортка үтте. Тирә-якка борынны кытыклап, әрем исе таралды. Әфганстанда миналанган басуларны да әрем баскан иде. Анда, шушындый ис таралган тау башында, туган якта үскән әремнәрне сагына торган иде. Туган авылын, тауларны юксынып исенә төшерә иде. Хәзер шушы әрем исе аңа ирексездән Әфганстандагы миналар яшерелгән үлем тулы басуларны исенә төшерде. Ишектә йозак... Ул, хәлсезләнеп, бусагага килеп утырды. Нәрсә уйларга да белмәде. Берәр яры күчеп киттеләр микән әллә дип уйлады. Яңадан торып, абзар, мунча яннарын карап килде. Юк, берсе дә юк иде. Бәрәңге бакчаларында да чүп үсеп утыра. Бусагага килеп утырды. Шуннан, бер карарга килеп, келәт алдында лом табып, йозакны каерып ташлады. Өй эче тәмам караңгы, күңелен шомландырып, нindидер салкынлык һәм ят күгәрек исе килеп бәрелде. Күзе бераз караңгыга ияләшкәч, өй эчен күздән кичерде. Алгы яктагы караватта мендәр-юрганнар өелешеп тора. Сәке өстендәге палас та, ул хезмәткә киткәндә җәелеп калган көе иде. Ринат, өс киемнәрен дә салмыйча, баш очына бер бәләкәй генә мендәр кисәге ташлап, сәкегә сузылып ятты да тавышсыз гына елап җибәрде. Әйе, туган йорты аны шушылай шыксыз бушлык белән каршы алыр дип башына да китермәгән иде ул. Үзенең кайтуын гел бәйрәм төсле күз алдына китерә торган иде. Елагач, ничектер күңеленә бераз җиңелрәк булып китте. Тынычлана төште. Шулай караңгы түшәмгә карап ята торгач, ничек йоклап киткәнен дә сизми калды. Һәм ни гаҗәп, төшендә әнисен күрде. Әни кеше улын күргәч, и, шатланды. Ул да елап җибәрде. Килеп, улын кочаклап алды да аркасыннан сөеп:

– Улым, без кайта алмыйбыз инде. Күрше Заһит бабаң килүгә самавырны яңартып, чәй әзерләп тор. Су алып кайтып, идәннәрне сөртеп ал. Базда җиләк кайнатмасы бар. Син кайтуга дип әзерләп куйган идем. Берсендә син яраткан каен җиләге. Анысы бәләкәй банкада. Хәзер үк суга бар. Ялкауланып ятма! Заһит бабаңны тыңла!

Ринат әнисенең шул сүзләренә дерт итеп уянды. Һәм аптыраш та калды. Нинди төш күрде соң ул? Чынлап та әнисе уята икән дип белде бит. Тизрәк торып, чишмәгә төшеп китте. Билдән чишенеп юынып алды. Су салкын һәм шифалы иде. Сизелерлек хәл кереп, кәефе күтәрелде. Су алып кайтып, самавыр куеп җибәрде. Өстәл өстенә, тәрәзә төпләренә кунган тузаннарны сөртеп алды. Идәнне дә сөртеп чыгарган булды. Инде нәрсә эшләргә дип туктап калды да, самавыр кайнаганчы дип, мичкә ягып җибәрде. Исәбе, өй эчендәге салкынлыкны һәм күгәрек исен бетерү иде.

Егетне иң аптыратканы шул булды, базга төшеп, әнисе әйткән вареньены алып чыкты. Тик кайнатма күптән күгәреп беткән, ашарга яраксыз хәлдә иде. Шул кайнатманы караштырып торганда, ишектән Кыекбаш Заһит бабасы килеп керде. Һәм кырә-керешли үк банкадагы вареньега карап торган, бөтенләй үзгәргән Ринатны күреп, шелтәле тавыш белән:

– Син, шилма малай, кайда югалып йөрдең? Теге кара кәгазең килгәч, сине Әфганда һәлак булды дип сөйләделәр. Берәүләре рухлар ягына чыккан икән дип тә гайбәт таратып йөрде. Вәт афәрин, исән-имин кайтып җиткәнсең! Молодец! Тик, парень, түзәсең инде. Мин сиңа дөресен әйтергә тиешмен. Барыбер кем дә булса моны әйтәчәк бит. Менә шул, синең «хәбәрсез югалды» дигән кәгазең килгәч, әниең түзмәде, йөрәк чире белән бер ел җәфаланды да мәрхүм булды. Синең кайгыдан һәм әниең кайгысыннан әтиең дә озак тормады. Менә шулай, парень, эшләр. Түз, улым, түз!

Кыекбаш килеп, Ринатның кулбашына кулын салды. Ринат әтиләре белән нәрсәдер булганын сизенгән иде инде. Кичә үк чамалады: өйләреннән ниндидер җан өшеткеч суык бәреп тора. Аның күңелсез уйларын бүлдереп, Заһит бабасы куеныннан бер ярты чыгарып, өстәлгә утыртты да:

– Ярар, улым, син бирешмә. Тормыш бу, тормыш. Теге кем әйтмешли, инәңне ормыш. Үлгән артыннан үлеп булмый. Шуңа да син яшәргә тиеш. Тырмашып булса да, яшәргә тырыш! Бу минем сиңа әмерем. Приказ! Белдем мин синең кайтасыңны. Шуңа да тегеләрдән яшереп саклыдым моны. Ышанмасаң, менә чыккан елын һәм аен кара! Стәрлетамакта син хезмәткә киткән айны һәм көнне, икенче сминәдә чыгарылган аракы бу.

Заһит шулай сөйләнеп, Ринатны авыр уйларыннан арындырырга тырышты. Ә егет бүген бик тә чын итеп төшендә күргән әнисен уйлады. Әнисе әйткәннәр ничек чынга ашты. Аптырарлык хәл. Әфганда чакта да шулай әнисе төшенә кереп тә, төшенә кермичә, өнендә дә әллә ничә тапкыр «анда басма, алай эшләмә», дип дәшеп, искәртеп торды түгелме соң? Баштарак, кайдандыр якында гына әнисенең тавышын ишетеп, контузия галәмәте дип шикләнеп тә йөрде. Шулай булуга карамастан, тавыш кушканча эшләргә тырышты. Бигрәк тә әфган басуларын минадан тазарта башлаган көннәрдә. Аннан инде үзе дә ул миналарны җир астыннан ук үтәли күрергә өйрәнде.

Заһит карт, егетнең тыңламый утырганын чамалап:

– Син, туганым, мин сөйләгәннәрне тыңламый да утырасың түгелме соң? – дип, егетнең кулбашыннан сыпырып алды. Шунда гына ул уянып киткәндәй:

– Тыңлыйм, Заһит бабай, тыңлыйм.

– Тыңласаң, менә шул. Хәзер син үзеңнең дөя түгел икәнлегеңне бар дөньяга исбатларга тиешсең. Монда, парень, үзең күреп торасың, барысы да үзгәрде. Урамда перестройка! Шуңа күрә, бернигә карамыйча, яңа баштан документ-кәгазьләреңне булдырырга кирәк. Кеше булыр өчен иң элек кәгазь кирәк. Тегеләрчә әйтсәк, без бумажки – ты букашка. Документсыз сине бу илдә санламыйлар, балам. Юк, санламыйлар. Кара әле, кулыңа тоткач, эчеп куй! Җиңелрәк булыр. Югыйсә сөмсерең коелып утыра.

Заһит карт Ринатны кыстарга тотынды. Тик егетнең мондый нәрсәне күптән, бик күптән эчкәне юк иде. Паромда кайтканда, Фәридә ханым бик кыйммәтле шәраб белән сыйлады. Ә соңгы тапкыр Уфадагы чакыру пунктында егетләр белән матур гына төшереп алганын хәтерли. Поездда барганда да, егетләр җыелышып эчкәндә, аларга кушылмады. Шуннан бирле аракының нәрсә икәнен оныткан иде. Тегендә чакта аракы дигән нәрсәне бөтенләй күрмәде. Юк иде ул анда. Карт кыстагач, егет авыр уйларыннан арынырга теләп, әзрәк тотып куйды. Заһит карт өстәлгә бер кисәк ипи, суган һәм казылык кисәге чыгарып салды.

– Кабып куй.

Егет дәшми генә капкан булды. Мондый нәрсәне байтактан авызына алмаганга һәм күптән юньләп ашамаганга, тиз исерде.

– Булды, картлач! Мин исердем, – диде дә сәкегә ауды.

Аның берүзе генә каласы килде. Моны аңлап, Заһит карт та, өстәлдәге шешәне кесәсенә салып, өенә юнәлде.

Ринатның исән-имин йөреп, Әфган сугышыннан кайтуы, авылга яшен тизлегендә таралды. Әле тегесе, әле монысы кереп, хәл белде. Туган тиешлеләре дә, тиеш түгелләре дә. Бер-ике дус егет шешә күтәреп кергән булды. Әле дә Заһит бабасы бар, кайберләрен выжлатып куып чыгарды. Ул чак тоткынлыктан котылып кайткан егетнең шешәгә бирелеп китүен теләми иде. Аның киңәше белән район үзәгенә дә барып кайтты. Барча документларны яңадан булдырырга кирәк иде. Бер уңайдан хәрби комиссариатка да кереп чыкты. Анда да әллә ни елмаеп каршы алмадылар. Икенче атнага килеп китегез, ачыкларбыз, дигән булдылар. Паспорт өстәлендә:

– Военкоматтан кәгазь булмыйча, паспорт бирә алмыйбыз. Шул-шул белешмәләр белән шундый-шундый кәгазьләрегез булсын, – дип чыгардылар.

Егет үзенең беркемгә дә кирәк түгеллеген аңлады. Әле тегендә, әле монда эшкә урнашырга чамалады. Юк. Документсыз беркайда да эшкә алырга теләмәделәр. Эшкә алган җирдә акчасын түләмәделәр. Бер колхозга барып, эшкә урнашкан булды, тик анда да түләмәделәр. Акча сорап, председательгә кергәч, тегесе:

– Акча юк, туган. Әнә силосын алып кайт. Фуражын да аласыңдыр әле? Җитмәсә, бер-ике центнер яздырып ал. Мин имзамны куярмын. Бозау алсаң да була. Үстереп сатарсың. Үстерергә иренсәң, бозау килеш сат.

Юк инде, колхоздан эшләгән өчен силос-фураж урлап, сатып йөреп

булмас. Шулай, Заһит карт әйтмешли, эт сугарып йөреп, кыш та җитте. Кайбер оешмаларда «Әфганстан сугышына сезне без җибәрмәдек», диючеләр дә булды. Документлар һаман да әзер түгел. Уфага, республика хәрби комиссариатына да барган иде. «Шул-шул көнгә, сәгать тугызга килеп җит. Соңга калма! Военком хәрби кеше, соңга калып йөргәннәрне яратмый. Югыйсә ул озакламый ялга китә. Тагы ике айсыз эшендә булмый. Аннары Мәскәүгә квалификациясен күтәрергә, укырга барачак. Тәк што, алты ай анда булачак. Өлгерергә тырыш!» – дип кайтардылар.

Ринат якшәмбе көн үк юлга кузгалырга булды. Уфага барып кайтырлык кына акча да юнәтте. Авылдашлары әйтүенчә, шул-шул сәгатьтә, автобус килергә тиеш. Тукталышта озак тормый. Шуңа да алдан чыгуың хәерле, диделәр.

Иртән чамалап иртәрәк чыккан булды. Караса, автобус тукталышта тора икән. Йа Хода! Ринат, үзен-үзе белештерми, торып йөгерде. Тукталышка чыгарга бер тар гына сукмак. Җитмәсә, кем хатыны булгандыр, сукмакны тутырып, судан кайтып килә. Егет хатынга килеп җитәрәк:

– Юл бир! Юлдан кит! Автобуска соңга калам, – дип кычкыра-кычкыра йөгерде.

Тик теге бер тискәре хатын иде.

– Трамвай түгелсең, урап та үтәрсең әле! Иш син аны, берәү автобуска ашыга икән. Ә мин судан кайтып киләм. Мин дә ашыгам.

Ринат, бу хатынны урап үтмәкче булып, сукмактан читкә сикерде. Теге хатын егетнең ниятен аңлап, юри каршысына чыга бирде. Карашы автобуска төбәлгән булса да, Ринат каршысына чыгып баскан хатынның ниятен чамалады. Тагы читләтеп үтәргә тырышты. Тегесе аның саен үҗәтләнеп, юлына аркылы басты. Егет каударланып, су тулы чиләккә килеп бәрелде. Өстенә су түгелде. Кая монда автобуска ашыгу, бөтен өсте лычма су булды. Моны күреп, хатын шаркылдап көлеп җибәрде. Зур итеп ачылган авызы һәм мыскыллап, усал ялтыраган күзләре күренде. Шул мизгелдә шурави үзенең алдында Әфгандагы черек тешле, судан кайтып килгән һәм тез астына көянтәсе белән суккан рухны күрде. Тау барсы ирбис кебек сикереп, хатынга килеп ябышты. Һәм суы түгелми, карга төшеп баткан икенче чиләккә аның башын тыкты. Куркудан һәм кинәт тын алудан хатынның үпкәсенә су тулды. Бер-ике минут үтмәгәндер, хатын инде тынсыз һәм җансыз гәүдәсе белән башын чиләккә тирәнрәк батырды. Ринат үзен-үзе белештерми автобуска торып чапты. Тик барып җитә алмады, автобус төтеннәрен болгап, егеттән мәрхәмәтсез көлә-көлә, фырфылдап кузгалып китте.

Иртәнге суыкта сулы киемнәр боз булып катты. Ринат шул бозлы киемнәрен шатор-шотыр кыштырдатып, кире өенә кайтырга борылды. Сукмакта тынсыз-җансыз яткан хатынның гәүдәсен аягы белән читкәрәк этәреп куйды. Әйтерсең лә, юл өстендә ятма, читкәрәк китеп ят, кешегә сукмактан йөрергә башкача комачаулама...

Әллә ни тикшереп тә тормадылар. Суд булды. Һәм егетне унике елга ябып та куйдылар. Тышта 1992 ел иде. Ни генә димәсеннәр, төрмә – төрмә инде. Бигрәк тә мәрхәмәтсез рәвештә кеше гомерен кисүчеләргә.

Төрмәнең сыек шулпасын чөмереп, икенче елына аяк басканда, шулай беркөнне аны күрешү бүлмәсенә чакырдылар. Барча тикшерүләрне һәм

төрмәнең бүтән йола-чараларын үтеп, тиешле бүлмәгә барып кергәндә, анда аны көтеп, ике ир заты утыра иде. Урындык тәкъдим иттеләр. Ринат ни уйларга да белмәде. Ул бу шоп-шома итеп кырынган һәм бик тә пөхтә итеп киенгән кешеләрне белми иде. Тегеләр сүзне ерактан башлап, тегесен-монысын һәм хәлен сорашкан булдылар. Төрмәдә утыру шартлары белән кызыксындылар. Чөнки бу вакытта иректә яшәгәннәрнең дә хәлләре әллә ни мактанырлык түгел иде. Төрмәдәгеләр өчен шартлар бигрәк тә читен. Ирләр алмаш-тилмәш Әфганстанда ничек әсирлектә булуы турында сорашкан булдылар. Ринат инде төрмә институты белән яхшы таныш булганга, әллә ни тартынып һәм кыенсынып тормыйча:

– Егетләр! Әйдәгез, кара капчыктагы кара песинең койрыгыннан тартып булашмагыз. Әйтсәгез, турыдан әйтегез дә куегыз! Сезгә ни кирәк?

Бу икәү башта бер-берсенә карашып алды. Күренеп тора, егетнең соравыннан бераз гына югалып калдылар. Шуннан олырагы:

– Син, браток, бик ашыктырма. Һәр нәрсәнең үз җае, – диде.

Егет, нәрсәдер сизенеп, дорфа гына:

– Мин сезне белмим, – диде. – Шулай булгач, мин сезгә брат та, сват та түгелмен. Туганлык турында әйтеп тә тормыйм. Сез кемнәр буласыз? Менә мин, шул-шул статья белән төрмәдә утыручы фәлән-фәләнов булам, – диде дә теге икәүгә карап тора башлады.

Болар тагын үзара карашып алдылар да олырагы, тамагын кырып, Ринатка карамыйча гына, әйтеп куйды:

– Мин фәләнов фамилияле, военкомат кешесе булам. Ә бу егет фәлән-фәләнов, хокук саклау органнарының шул-шул бүлек җитәкчесе. Кыскасы, төрмә туйдырмадымы?

– Туйдырса соң? Нәрсә әйтергә телисез? Турысын әйтегез!

– Безнең сине кызыксындырырлык бик тә кирәкле һәм файдалы тәкъдимебез бар.

– Ну!

– Олыларны бүлдерми генә тыңла! Син яшь бит әле. Барча тормышың алда. Әллә ничаклы гомереңне шушы таш капчыкта үткәрергә җыенмыйсыңдыр бит. Шулай булгач, безне игътибар белән генә тыңла! Без контрактниклардан полк төзибез. Син – Әфганстанда сугышып кайткан тәҗрибәле солдат. Һәм сиңа тау шартларында сугышу алымнары бик таныш. Менә шул полкта инструктор булып, контрактникларны һәм яшь солдатларны тау шартларында сугышырга өйрәтеп укытырга кеше кирәк.

– Мин төрмәдә утырам бит...

– Анысы өчен кайгырма. Без килешү кәгазьләре алып килдек. Безнең тәкъдимгә риза булсаң, килешүгә имзаларыңны куясың да, эш бетте. Һәм безнең белән китәсең.

Ринат бу тәкъдимнән бераз гына югалып калды. Башы зыңлап китте. Бераз уйланып торганнан соң болай диде:

– Ярар, шулай да булсын, ди. Тик минем бер документым да юк. Әфганнан кайтканнан бирле паспорт та ала алмадым. Аннан бит әле шунысы да бар. Мин яшьләрне өйрәткәннән соң кире төрмәгә кайтырга тиеш буламмы? Әллә минем хәрби хезмәтем төрмәдә утыру исәбенә керәме?

– Менә шушы килешүгә имзаңны куйган минуттан башлап, син – ирекле! Һәм безнең карамакка күчеп, хәрби хезмәтең башлана. Төрмә турында онытырга туры киләчәк. Хезмәттә үзеңне ипле тотсаң, төрмәгә кире кайтмыйсың. Аңлашыламы?

– Әйе!

– Алайса башладык. Михайлович, чыгар кәгазьләрне!

Шулай итеп, Ринатның тормышында тагын кискен борылыш булды. Чечняда беренче сугыш башланды.

Аны разведка ротасына алдылар. Чөнки тау шартларында ул үзен иркен хис итте. Шунысы гаҗәп: аларның разведротасы шурави булганда, һич засадага эләкмәде. Ә чеченнар куйган миналарны, хет көндез, хет төнлә булсын, әллә кайдан сизде. Әфганстанда миналы ялан-юлларны тазартканда алган контузияләреннән һәм әллә ничә үлемнән калганнан соң, аның шундый гаҗәеп сәләте ачылган иде. Һәм бу сәләте Чечен сугышында яңадан уянды.

Чеченнар әфган рухлары гына түгел, авыл-салаларын, тарлавыктагы юл-кичүләрне нык саклыйлар. Ә Ринат кебек элеккеге шуравиларга вәгъдә ителгән акчаны башта түләгән булдылар да соңыннан туктаттылар. Имеш, икътисади хәл бик авыр. Әмма хезмәтегез беткәч, барысын берьюлы түлибез дип, алдап тота башладылар. Ярый әле Ринатның гаиләсе юк. Кайберәүләрнең өч-дүрт баласы бар. Шаулап йөреп, ризасызлык белдерүчеләр бик тиз башка урынга күчерелде, йә булмаса, яшерен һәм хәвефле хәрби «заданиедән» кайта алмады. Хәбәрсез югалдылар. Солдат югалган икән, аңа акча түлисе юк. Ринатның үзен-үзе саклау инстинкты сугыш хәлендә тагын көчәйде. Әсирлектә алган тәҗрибәсе дә шуны искәртеп торды. Исән каласың килсә – уйларыңны яшер! Артыгын сөйләмә! Рус әйтмешли: «Язык мой – враг мой». «Сүзең көмеш булса да, дәшми калуың – алтын», – ди татар. Икенчерәк әйтсәк, «Сүзең алтын булса да, дәшми торуың – ул синең гомерең». Менә шулай!

Сугыш бит ул – утлы мичтә коймак пешерү түгел, ә көн саен үлем белән күзгә-күз очрашып, исән калу өчен көрәш. Чеченнар белән сугышның кызган чагы. Солдатлар җитешми. Шунлыктан, разведротага да блокпостларда атналар буе сакта кизү торырга туры килде. Менә инде Ринатка да күрше рота солдатлары белән каравылда торырга әмер булды. Әмерне исә үтәргә кирәк!

Ринат кебек төрмәдән китерелгәннәрдән тора аларның отряды. Берничә егет бик тә хәвефле, хәвефле генә түгел, ә күрәләтә үлемгә алып бара торган боерыкларны, үтәүдән баш тарткан иде, аларны шунда ук кире төрмәгә озатабыз дип, аерып, сак астында алып киттеләр. Вәгъдә ителгән акча юк та юк. Ләкин яртылаш гипноз сөременә бирелгән солдатлар үҗәтләнеп, алларында кем торганына карамыйча, теләсә кемне үтерергә сәләтлеләр иде.

Блокпостта сакта торганда, Ринат шуны белде. Үткән атнада снайперлар, монда сакта торганнарның барысының да ирлек әгъзаларына атып, зарарлаган булып чыкты. Шуңа да каравылга басар алдыннан командир аларны ныклап кисәтте:

– Зур һәм калын бетон блоклардан төзелгән блокпосттан бик чыгып йөрмәскә. Чыккан хәлдә дә бер урында гына басып тормаска. Йөгерә-атлый йөрергә! – диде.

Ринат уйга калды. Аларның каравыл сменасында андый хәлдән Аллаһ саклады. Хәтта боевикларның һөҗүме дә булмады. Каравылдан соң, буш вакытында кыр госпиталенә барып, таныш егет белән сөйләшкән булды.

Тегесен сорашты, монысын белеште, дигәндәй, сөйләшеп утырдылар. Ринат бик әһәмият бирмәгәндәй генә сорап куйды:

– Ә нишләп боевиклар гел егетләрнең бот араларына гына аталар?

– Һе. Сез дә берәр чечен кызын көчләп карагыз! Бот арагызга гына атып калмаслар. Бер снайпер кызны әсирлеккә алып, күмәкләп көчләгәннәр дә, командирлардан куркып, кире җибәргәннәр. Менә шуннан башланды инде. Аннан ниндидер бер гаепсез унбиш яшьлек кыз баланы көчләгәннәр. Нәтиҗәсе шул, барсын да комиссовать иттеләр. Тәк што, сак бул. Ул блокпост сихерле!

Бу хәбәрдән соң Ринат нигә бу блок постка гел аның кебек төрмә мәктәбен үткәннәрне генә җибәргәннәрен аңлады. Постка каравылга бармый булдыра алмыйсың. Шулай да туры китереп, бер чечен картыннан сорады:

– Бабай, әйт әле, егетләрегез нигә гел безнең блокпостка гына һөҗүм ясыйлар?

Бабай бераз уйланып торгач:

– Балам, бердән сезнең постта һәм сезнең частьта күбесе акчага алданып, кеше гомерен кыярга килгәннәр. Юньле кеше акчага алданып, кеше үтерми. Алар бит карт-корыны да, балаларны да жәлләмиләр.

– Ә срочник, гади хезмәткә чакырылганнар ни белән яхшы? Алар бездән яхшыракмыни?

– Әйе, алар яхшырак! Алар сезнең кебек ерткыч түгел, кешене жәлли беләләр. Һәм алар ирексезләп китерелгәннәр. Подневольныйлар. Менә шулай, улым. Син дә акча эшләргә килгәннәргә охшагансың. Булдыра алсаң, кайтып кит, улым! Безнең егетләр иң элек синең кебекләрне юк итәләр. Хуш!

Бабай белән сөйләшү егетне уйга салды. Әйе, ике көннән аларны тагын әлеге шул каргалган блокпостка каравылга куячаклар. Юк, болай башы өзек кигәвен кебек яшәүне туктатырга. Икенче частька күчерсеннәр. Рапорт язарга кирәк.

Аптырарсың шушы боевикларга, бу юлы кизү торганда, шылт иткән тавышлары да чыкмады. Ә менә гипнозланганнар авыл ягыннан азан тавышы ишетсәләр, чыгырларыннан чыгып исәрләнә башлыйлар. Азан тавышы ишетелсә, кая кереп качарга урын тапмыйлар. Башларын мендәр астына тыгып яталар. Булдыра алсалар, башларын тәвә кошы кебек комга тыгарлар иде. Бу инде гипнозның турыдан-туры тәэсире. Менә шундыйлар белән хезмәт итә Ринат. Ә аңа азан тавышы гел бала чагын исенә төшерә. Әфганда әсирлектә чакта да азан тавышы аңа гел җирдәге рух-җаһилләрдән башка күкләрдә Аллаһ дигән үлемсез зат та барлыгын искәртеп торды...

Сакта торуның вакыты үтте, алмаш килмәде. Аның урынына тагы бер атна сакта торырга дигән боерык булды. Менә шушында башланды да инде. Сакта торганда эчәргә катгый тыелса да, сержант кайдандыр самогон алып китертте. Кичкә ару гына төшереп алган егетләрнең каны кызды. Ринат күңел ачуга катнашмады. Кирәк тә түгел иде аңа. Ул эчүгә бик әвәс түгел. Йокларга ятты. Күрәсең, ул йоклагач, чечен авылына чыгып киткәннәр. Алар шау-гөр килеп кайтып кергәндә уянып китте. Тавышка эре калибрлы

пулемёт урнашкан амбразуралы якка чыкты. Чыкты да телсез калды. Чөнки күзләре бәйләнгән ниндидер чечен кызын өстерәп алып керделәр. Бахыр кыз өзгәләнә, тартыша һәм тешләшергә чамалый. Кайда ул тешләшү, кычкыра да алмый. Авызына пычрак чүпрәк тыкканнар. Үзен бик «текә» дип исәпләп йөргән һәм төрмәдә ундүрт елының сигез елын утырырга өлгергән Бармалей кушаматлы ристан:

– Алар безнең егетләрнең ирлекләрен, ә без аларның кызлыкларын алабыз, – дип кычкырды.

Бу якка килеп чыккан Ринатны күреп:

– Әйдә, татарин, башла! Без малайлар белән сөйләштек, бу кызны сиңа бирәбез. Син безнең командада булганда боевиклар һөҗүме дә булганы юк. Югалту гына түгел, яраланучы да булмый. Күптән синең турыда «сихерләнгән» дигән гайбәт йөри. Менә хәзер тикшереп карарбыз. Иртәгә сиңа да атарлармы, юкмы? Атсалар, вот прикол була. Нәселсез калган татарин, диячәкләр.

Ринат ачу белән теш арасыннан төкереп:

– Минем бу пычрак эшкә катнашасым килми. Шайтаныма олагыгыз! – диде.

Ринат кире урынына кереп ятарга чамалаган иде, тыштан тегеләрнең икенче берсе кыздырылган шашлык тезелгән шампурларны өстәлгә кертеп салды. Блокпост эченә кызган ит исе таралды. Бармалей бер ит тезелгән шампурны алып, авызына тутыра-тутыра:

– Син генә чиста калырга телисеңме? Барып чыкмас. Әйдә башла! – диде.

Ринат үзенең күңел тоемы белән бу вәхшилекнең юньлелек белән бетмәсен тиз чамалады. Һәм көтелмәгән һәр нәрсәгә әзер булырга дигән эчке искәртүе белән җәя кереше кебек ныклы киеренке халәткә күчте. Әфганнан калган гадәт. Һәм ул ясалма басынкылык белән:

– Бик тә көтелмәгән тәкъдим. Тукта, карыйм әле, кемне алып кайттыгыз? Берәр убырлыны алып кайтсагыз, бушка да кирәкми, – диде.

Һәм ул идәндә утырган, чәчләре тузгып, битен каплаган кызны тартып торгызды да чәчләрен сыпырып, битен ачты. Аннан кызның күзе бәйләнгән чүпрәкне чиште. Һуш китмәле хәл. Чечен авылының бу башында ялгыз яшәгән карчыкның оныгы иде бу. Карт әнисе белән икәү генә торалар. Кыз әбисен карый. Сылу көн дә иртән бердәнбер кәҗәләрен бәрәннәре белән тау битенә чыгарып бәйли. Аннан зур кувшин савытын күтәреп, тау астындагы чишмәгә суга бара. Үткән дежурда, алдан чамалап, кыз чишмәгә төшеп киткәч, егет тә суга барды. Кыз аны күргәч куркып калды. Солдатның аңа зыян-зәурәт эшләмәсен аңлап, елмаеп җибәрде. Кырыннан үткәндә дә әле, егетнең якты карашын күреп елмая-елмая, вак кына адымнар белән атлап, тау башына менеп китте. Һәм сукмактан яр өстенә менеп җитәрәк артына борылып, егетнең күзен чагылдырырлык итеп, елмаеп куйды. Бик матур һәм ымсындыргыч күренеш иде. Менә шушы чечен кызы егеткә еракта-еракта Әфганстан таулары артында калган Зөһрәгә бик тә охшаган иде. Ринат исенә төшкән хисләрдән исереп, кызны күзе белән йотардай булып озатып калды. Шулай шул, монда кызлар суга көянтә белән йөрмиләр. Җиз калайдан эшләнгән тар һәм озын муенлы кувшин белән су ташыйлар. Иртәгә ул тагын шул кызны гына күрер өчен чишмәгә суга барачак иде.

Менә бит бу вәхшиләр нәрсә эшләгәннәр. Ә кыз нәфрәт тулы яшьле күзләре белән солдатларны өтә.

Ринатның бераз югалып калганын күреп өлгергән Бармалей иптәшләренә карап, усал елмая-елмая:

– Юкка күзендәге чүпрәкне алдың. Хәзер барыбызны да танып калачак. Бигрәк тә сине. Танымаган булса, исән калыр иде. Ә хәзер бу чибәрне үтерергә туры киләчәк. Әгәр дә карышсаң, үзеңнән Машкамы, Дашкамы ясыйбыз. Прәме шушы кыз алдында. Аннан соң гына десертка чибәркәйне тәмләп караячакбыз. Шулаймы, егетләр?

Усал көлештеләр. Ринат бер нәрсәгә дә әһәмият бирмәгән кебек Бармалей кулындагы шампурдан бер калҗа ит алып капты да чәйни-чәйни, куркуыннан хәлсезләнеп, кабат идәнгә тезләнгән кызны карап чыккан булды. Һәм:

– Прәме сезнең алдамы?

– Ә ничек теләр идең? Иш сине, үзең генә ләззәтләнергә тиешме?! Әлбәттә, безнең алда! Без карап торачакбыз!

– Ну, егетләр, без андыйга өйрәнмәгәнбез. Әмма шулай да булдырып карыйм.

Ринат өстендәге гимнастёркасын һәм майкасын салып ташлады. Аңа карап, әзмәвер Бармалей да, гимнастёркасын салып ыргытты. Ә инде Ринатның билгә кадәр чишенүенең сәбәбе: күрелмәгән каршылык килеп чыга калса, аны тотуы кыен булачак. Чөнки шәрә тәнле кешене тотуы авыр. Һәм шулвакыт Ринатның зиһененә бик тә даһи уй килеп төште. Ул Бармалей кулындагы ит калҗалары тезелгән шампурдан бер майлы калҗа алып тәненә майларын сөртә башлады. Кызык күреп, егетләр көлешә башлады.

– Син нәрсә? Ринат? Бу нинди ритуал? Мангулча берәр нәрсәме әллә?

– Юк. Ару көрәшчеләр хәлиткеч көрәш алдыннан көндәшен җиңәр өчен шулай тәннәренә май сөрткәннәр, – диде дә итле май кисәген кулыннан «ялгыш» төшереп җибәрде.

Борылды да Бармалей кулындагы шампурны алып, кулына тотты. Тагы авызына бер кисәк ит капты. Аннан кулындагы шампурын әзер тотып, әзмәвергә борылды да:

– Син – бугор, бу кырагайны күтәрешергә ярдәм ит инде. Мин чишендереп карыйм. Эчтән дә шулай матур микән? Карышса, шушы штык-нож белән чишендерәбез, – дип, кырындагы солдатның штык-пычагын алып, үзенең чалбар каешына кыстырды.

Барысы да әзер. Бармалейның, үзен төрмә жаргонындагы «бугор» дигәннән күңеле булып, кәефе күтәрелде. Син нәрсә, аны бит «авторитет-бугор» дип атадылар. Бүгеннән башкаларга да үзен шулай атарга кушачак. Бернинди дә Бармалей түгел, ә Бугор! Һәм шул сүзләр белән Ринат әзмәвернең уяулыгына төтен җибәреп, көл сипте. Теге җаһил кызның артында басып тора иде. Ул шатланып, кызны идәннән тартып торгызды да артыннан кочаклап, муен-җилкәләреннән үбә-үбә, шакшы куллары белән кызның күкрәкләрен изеп уа башлады. Кыз башын артка ташлап, тегенең битенә бәрергә тырышты. Ә Ринат, кулларындагы шампурны ычкындырмыйча, кызга якын ук килде. Бу чибәрнең итәген күтәреп карарга чамалаган кебек кыланып иелә бирде дә кызны кочаклап торган

Бармалейның сул як кабыргасы астыннан очлы шампурны тегенең йөрәгенә кадәр тыгып җибәрде. Киредән шампурны суырып алды да яңадан йөрәгенә эләгерлек итеп, тагы бер-икене кадап алды. Бармалей ых та итәргә өлгермәде, авыртудан кызны тагы да ныграк кочаклап, блок посттагы барча җиһазлар кебек чечен авылыннан талап алынган иске диванга ауды. Ул арада Ринат шампурны Бармалей тәненнән суырып алырга өлгергән иде. Ул берни булмагандай:

– Кара син аны, бугор үзе бу кыр кәҗәсенәберенче өлгермәкче. Карагыз, карагыз ничек тырыша, – дип көлде.

Тик аның көлүе усал ыржаю төсле яңгырады. Бармалей кочагыннан ычкынырга чәбәләнгән кызга кызыгып карап торучылар Бармалей тәненнән саркыган канны да, күкрәге астындагы тишекне дә шәйләмәделәр. Барысы да берни дә аңламыйча, бер-берсен бүлдерә-бүлдерә үлем белән тартышкан Бармалейны дәртләндерә башладылар.

Тавышка тышта сакта торган Бармалейның иң якын ярдәмчесе, терәге һәм аның белән бер зонада утырган корешы «Девятка» килеп керде. «Девятка» дигән «кликуха»ны юкка кушмадылар аңа. Урлашкан өчен сул кулының чәнчә бармагын камерадашлары кисеп ташлаган иде. Станокта ялгыш үзем кистем дип йөрде. Менә шул килеп керде дә, ишек яңагына сөялеп, дустының өстендә яткан чечен кызын алып ташларга чамалавын күреп, көлеп җибәрде. Ул да дустының үрсәләнүен аңламыйча:

– Әйдә, әйдә, – дип дәртләндерергә тотынды.

Ринат, үзенең бу планы ачылып, чечен кызы Бармалей кочагыннан шуып төшсә, үзенең дә исән калмасын белә иде. Эчке тавыш-сиземләве шулай дип аны искәртә. Һәм ул тыштан кергәннең кырына килеп:

– Әйдә, дустыңа булыш, – дип, чалбар каешына кыстырылган штыкны кулына алды һәм тегенең бавырына тыгып, эчен актарды.

Теге авыртуга түзә алмый кәкрәеп төште. Ринат Бармалей корешын бер кулы белән кочаклап, икенче кулы белән тегенең автоматын тартып алды. Һәм тегеңә:

– Нәрсә булды? Нәрсә булды? Түз, түз! Без хәзер, – дип, тиз генә аның билендәге патронташлы каешын ычкындырып, үзенең биленә буды. Девятка авыртудан үкереп җибәрде. Бу шулай ук бик тиз башкарылды. Бугорның чечен кызы белән «көрәшкәнен» карап, селәгәйләрен агызган егетләр һични шәйләмәде. Берсе хәтта тибенгән кызның аякларыннан тотарга чамалады. Ә кызның тузгып төшкән озын чәчләре Бармалейның йөзенә кунарга өлгергән үлем шәүләсен башкаларга күрергә комачаулады. Ринат теге куштанга:

– Түз, түз! – диде. – Хәзер синең чират! Әйдә икәүләп булашыгыз. Дустың берүзе генә булдыра алмый. Слабак, бөтенләй җебеп төште. Кызлар тотканы юк, ахры.

Ринат шулай сөйләнә-сөйләнә, Девятканы кочаклап алып килеп, Бармалей кырына диванга салды. Ул арада Бармалей селкенеп, аяклары белән тыпырчынды да тынып калды. Ә иптәше авыртудан кычкыра да алмыйча ыңгыраша башлады. Чечен кызы, ниһаять, Бармалей кочагыннан ычкынып, янындагы куштан өстенә тәгәрәп төште. Кыз бәйләнгән кулын ычкындыра алды. Торып басты. Теге җаһилләр ятып калды. Берсе бөтенләй тынсыз

һәм җансыз. Икенчесе авыртудан корсагын тотып, йөзе белән капланып яткан. Бугорның корсагында кан саркыган тишекне күреп, сержантның йөзе агарынып китте. Ул бу эшне чечен кызы эшләде дип уйлады. Кызны, яман сүгенеп, сугып екты. Ринат килеп туган хәлне кулыннан ычкындырмаска теләп, кулындагы автоматтан идәнгә ут сиптерде.

– Тукта! Югыйсә сине дә тишкәлим, – дип, тегенең аяк очына атып җибәрде.

Барысы да көтелмәгән хәлдән катып калды. Ринат яман ысылдап:

– Тик кенә утырабыз! Кем тычкан кебек чыелдый, монда утырганнарның берсе дә исән калмаячак. Барыгыз да Бармалей янына диванга тезелеп утырыгыз. Шым! Һәм җәһәтрәк!

Барысы да диванга өелеште. Ә Ринат ишек янындагы өемдә торган автоматлар янына барып басты. Ату тавышына тыштагы ике часовой-сакчы, тыннары бетеп, килеп керде. Ул башта кергәненә автомат прикладына белән сугып, һушын алды. Икенчесе әле дары исе иснәргә дә өлгермәгән яшь солдат иде. Ул, бахыр, бу хәлне күреп, шыр җибәрде. Ринат аның кулыннан автоматын тартып алды һәм яшь солдатка:

– Монда тартып китер! – дип, кызга күрсәтте.

Теге бахыр кызны җитәкләргә чамалаган иде, чибәркәй кыргый тау барсы җитезлегендә өстәлдә яткан штыкны алып, почмакка сикерде һәм:

– Кем килә, үтерәм! – дип ысылдады.

Кыз хәлләрнең кая авышканын аңлап өлгермәгән иде. Ә Ринат, теге явызларның берәрсе кызга ышыкланып, үзенә һөҗүм итүләреннән курыкты. Чөнки кызга атарга кулы күтәрелмәс иде. Шушы мизгелдә һушы алынып, аяк астында яткан солдат, аңына килеп, сүгенә-сүгенә тора башлады. Тик лепкәсенә тагы ару гына эләккәч, яңадан идәнгә сузылды. Ринат кызның беркемне дә якын китермәсен аңлады һәм ачуы кабарып:

– Тилермә! Кил минем янга! Әллә чынлап та үзеңне шушы сволота-явызлар көчләгәнен көтәсеңме? – дип, тешләрен шыгырдата-шыгырдата, яман акаеп, кызга ысылдады.

Ниһаять, теге аңлады шикелле, курка-курка, диванда утырганнардан күзен алмыйча, егеткә якынайды. Ринат җиңел сулап куйды. Хәзер кызга ышыкланып, үзенә һөҗүм булмасына инанды. Һәм барысына да карап, инде бөтенләй тыныч кына:

– Менә шулай, егетләр. Бүгеннән башлап, кызлар көчләвегездән туктасагыз гына, исән-имин өегезгә кайта аласыз. Моны миңа бер чечен карты әйтте. Монысы – бер. Икенчесе, бу икәү эчкән килеш үзара сугышып киттеләр. Һәм бер-берсен чәнчеп үтерделәр. Ә мине суга барган җирдән чеченнар урлап алып киткәнен үзегез күрдегез. Һәм берничек тә ярдәм итә алмадыгыз. Аңлашыламы? Аңлашылмаса, барыгызны да стенага тегеп куярга туры киләчәк. Хет берәрегез мине сатса, барыгызга да, нимес әйтмешли, капут. Чөнки миндә барыгызның да адреслары бар, менә монда, – дип, ул башына төртеп күрсәтте дә дәвам итеп: – Син шул-шул өлкәдән, шул-шул районндагы авылдан. Син дә әллә кайдан түгелсең. Шул-шул җирдән, әтиең-әниең белән генә торасың. Ә син шул-шул зонадан килдең, адресың шул. Хәтта почта индексың да шундый номерлы. Ышанмасаң, конвертларыңны кара! Мин өйгә хат яздым. Барыгызның да адресы минем

абзыйда бар. Аңа әйтеп куйдым: «Миңа берәр хәл булса, шул бәндәләрдән үзебезчә үч алырсың», – дидем. Тәк што, минем белән берәр хәл булса, йә ялгыш кына сатсагыз да, сезне нәрсә көткәнен өегезгә исән-сау кайткач белерсез!

Ринат шулай итеп, барысының да диярлек адресларын атап чыкты. Һәм яшь солдатка амбразурада торган эре калибрлы пулемётларның детальләрен алырга кушты. Алай иткәндә, пулемёт яраксызга әйләнә. Һәм барысының да автоматларын алып, рация белән телефонны сөйләшә алмаслык хәлгә китерде. Кырыйда бу хәлне карап торган кызга карап:

– Автоматтан ата беләсеңме? – дип сорады.

Тегесе, ниһаять, барысын аңлап алды:

– Әйе, – дип баш какты.

– Алайса, селкенә башласалар, һич шикләнмичә, барысын да атып үтерергә мөмкинсең. Ә без бөтен коралны юк итәбез, – диде.

Иң элек лимонкалар салынган тартманы көч-хәл белән күтәреп алып чыгып, якындагы яр астына очырдылар. Гранатомётларны һәм башка коралларны да шулай иттеләр. Азактан Ринат үлем көтеп утырганнарга:

– Каравыл бетәргә тагы өч тәүлек вакыт бар. Шуңа кадәр энәсеннән җебенә чаклы репетиция ясап, кем нәрсә сөйләргә тиешлеген кабатлап өйрәнеп куегыз! Син, сержант, төрмә мәктәбен үткән кеше. Өйрәтерсең! Тик кенә утырабыз. Гудбай! Әфганча мәгаләйкүм сәлам!

Ринат кыз белән яшь солдатны ияртеп, тышка чыкты. Тимер ишекнең биген эләктереп, авылга, караңгылыкка таба киттеләр. Бераз баргач, Ринат яшь солдатка:

– Ярар, туган, сиңа исән-имин хезмәтеңне тутырып, өеңә кайтырга язсын. Тегеләр янына хәлең беткән кебек тының бетеп кайтып кер. Качтым, диярсең. Ярдан аска сикердем, диярсең. Һәм телеңне тыярга өйрән. Бар, сыпыр моннан! Чынлап та аска сикергән урыныңны чамалап куй. Кулың-битең сыдырылган булсын!

Ринат белән кыз юлдан алга, чечен сугышының билгесез кочагына таба атлап киттеләр. Төн караңгы иде. Кыз бер-ике абынып та алды шикелле. Егет кызны җитәкләп алмакчы иде, тегесе дертләп, кулын тартып алды. Шурави шунда гына кызның кулындагы штыкны шәйләде. Үз алдына көлеп җибәрде дә, безнең кызлар шулай дошманына каршы тора алыр иде микән, дип уйлап куйды. Ул шулай уйлап та бетермәде, кыз тагы абына язып, үзе егетне култыклап алды. Һәм ишетелер-ишетелмәс:

– Рәхмәт сезгә! Мине коткарганыгыз өчен рәхмәт! Исемегез?

– Ринат. Мин – Ринат.

– Кызык исем, бездә андый исем юк.

– Сезнең исем?

– Адича минем исемем.

– Безнеңчә Хәдичә инде. Минем киңәшем шул, сиңа бу авылдан тизрәк качарга кирәк. Барысы да ачылса, сине эзләп табачаклар. Нәрсә булырын кем белә? Менә мин болардан киттем-китүен. Ә кая барырга? Үзем дә белмим. Үзебезнекеләргә дә кайта алмыйм. Каһәр суккан бу сугыш кайчан бетәр? Әлегә очы-кырые күренми.

– Мин картәнигә кайтып күреним инде. Аның коты очып торадыр.

Мине бит кәҗә саварга чыкканда тотып алдылар. Абзар алдында саклап торганнар.

Ринат кызның биленә кулын салып барырга чамалаган иде, барып чыкмады. Кыз кинәт читкә тартылды. Әмма кулын егетнең беләгеннән ычкындырмады. Ринат, Хәдичәнең билендәге штыкны чамалап алды. Һәм аптырап:

– Нәрсәгә ул штык сиңа? Ташла!

– Юк. Син мине коткаруын-коткардың. Ә үзең исәрләнеп, миңа бәйләнә башласаң?

Ринат дәшмәде. Шулай авылга килеп керделәр. Хәдичәләрнең йорты авыл очында ук. Ул егетне йорт уртасында калдырып, өйгә кереп китте. Хәдичә нигә һаман чыкмый дип борчыла да башлаган иде, ишектән бәләкәй генә төенчек тоткан кыз күренде. Ул бөтенләй икенче киемнән иде.

– Әйдә, мин сине сезнекеләр дә, безнекеләр дә булмаган таулар арасындагы бәләкәй генә авылга озатып куям. Анда картәнинең сеңлесе яши. Берәр җае чыкканчы һәм сугышлар бераз тынганчы, шунда яшәп торырсың.

Егет, ни булса шул була дип, кызга ышанып, артыннан иярде. Кораллы кешенең һәрчак шик тудырганын белә иде. Андыйны үзебезнекеләр дә, чеченнар да мушкага алырга мөмкин, шулай да автоматын ташламады. Әфган сугышыннан ук таныш хәл, тауларда ни булмас. Анда күзең – ук, колагың локатор булырга тиеш. Төне буе тар гына сукмак белән әле аска төштеләр, әле кәҗә сукмагы кебек кенә урыннардан өскә күтәрелделәр. Таулар арасында төннәрен бигрәк тә караңгы. Шуңа да егет кая барганын да чамаламады. Менә аста тау елгасының шарлап аккан тавышы ишетелде. Еракта этләр өрә кебек. Хәдичә туктап, ял итеп алырга тәкъдим итте.

Ташлар арасында бер җайлы гына урынга туктадылар. Тик төннәрен суык булганга озак утыра алмадылар. Хәдичә калтырый ук башлады. Ринат блокпостны ташлап киткәндә, кемнеңдер бушлатын эләктергән иде. Бушлатын салып, кыз иңенә япкан булды. Үзенә дә суык иде. Кыз моны сизеп, бушлатның яртысын егет өстенә япты. Болай җылырак булып китте. Икесе бер бушлат эчендә бер-берсен җылытып утырдылар. Егеткә дә, кызга да рәхәт иде. Менә шулай, тәннәре тәнгә тиеп, ниндидер ләззәт-рәхәтлек хисендә йөзделәр. Егет, батыраеп китеп, кызның муенына сак кына иреннәрен тидереп алды. Кыз карышмады. Егеткә ныграк кына елыша бирде һәм калтыранган тавышы белән әкрен генә:

– Нигә мине – дошман чечен кызын коткарырга булдың? – дип сорап куйды.

Ринат бераз сүзсез торды да:

– Дөресен әйтергәме?

– Әйе.

– Бердән, чеченнар миңа дошман түгел икәнен күптән аңладым. Ә икенчедән...

Ринат тагын сүзсез калды. Һәм кыз аның беләгеннән кысып тота бирде.

– Икенчедән, нәрсә?

– Икенчедән, шул: чишмәгә суга йөрмәскә иде. Аннан да бигрәк теге көнне, чишмә кырында очраганнан соң, яр башына менеп җиткәч, артыңа борылып карамаска иде. Менә шул көнне син минем йөрәгемне үзең белән алып киттең. Менә ничек килеп чыкты.

Кыз берни дә дәшмәде, егеткә тагын да елышыбрак утырды. Бу егет белән аңа рәхәт иде. Башыннан үткән бүгенге коточкыч хәлләр Хәдичәнең күзләрен ачты, дисәң дә була. Ул якты дөньяга, гомумән, тормышка икенче төрле карый башлады. Ничә сәгать элек кенә аның гомере кыл өстендә иде бит. Әлбәттә, күмәкләп көчләгәннән соң аны үтереп, упкынга ташларлар иде. Ярый әле, шушы Ринат дигән солдат коткарып калды. Кызның үзенең дә ошатып йөргән егете бар иде. Елдан артты, аңардан хәбәр-хәтер юк та юк. Ә бу егет ару гына күренә. Башкалар кебек әрсезләнеп, итәк астына үрелми. Кыз, шуларны уйлап, егетне тагы да ныграк кысып кочаклады. Чит милләттән булса да, үзе дә мөселман егете, аңа чиксез якын булып тоелды. Теге вәхшиләрдән коткаручы егет – аның яклаучысы, әлеге минутта аны үз җылысы белән җылытып утыра.

Ринат әллә ни уйлап тормыйча, кызның битен үзенә борып, иреннәреннән үбеп алды. Кыз карышмады. Җавап итеп, кайнар иреннәре белән үзе дә егетне үбә башлады. Әйе, сугыштагы кискен хәлләр вакыйгалар агышын тизләтә генә. Һәм әле генә булып үткән куркыныч вакыйгалар аркасында тәндә чиксез күп тупланган адреналин чыгарга юл эзли иде.

Шулай таң аттырдылар. Кеше-кара күренгәнче дип, Хәдичәнең апаларына караңгылы-яктылыдан барып керделәр. Хәдичә үзенең туганнарына нәрсә сөйләгәндер, егет аңламады, чөнки сөйләшү чечен телендә барды. Менә шулай итеп, егетнең хәле үзгәреп, ул хәзер качкын-дезертир булып, шушы кечкенә генә чечен авылында көн күреп ята.

Өч көннән, көтмәгәндә, таудан авылга боевиклар килеп төште. Күрәсең, күршеләрнең берәрсе әйткәндер инде. Хәдичәнең туганнарына солдатны күрсәтергә куштылар. Хәлне аңлагач, Ринат үзе үк тегеләр алдына чыгып басты. Китте сорау алу. Кем, кайдан? Нигә качтың? Ринат та әллә ни боргаланып тормыйча, бар булганын кыскача сөйләп бирде. Кеше үтердем. Унике елны чәпәделәр. Берничә ел утыргач, сугышка чакырдылар. Төрмәдә утыру туйдырды. Ризалаштым инде. Шунда боевикларның командиры:

– Ә бит дезертир-куркакларны беркайда да яратмыйлар. Сатлыкҗаннарны аталар, – диде.

– Мин сатлыкҗан да, дезертир-куркак та түгел! Кем өчен сугышканымны да белмим.

– Син безгә каршы сугышкансың.

– Юк, сугышмадым. Хәтта бер солдатыгызга да атмадым. Сезнең якка бер пуля да очырмадым.

– Ә нишләп монда безгә каршы сугышка килдең соң?

– Әйтәм бит, төрмәдә утыру туйдырды. Шуңа килдем.

Бу бик тә иркен һәм дорфарак сөйләшкән солдат командирны туйдырды шикелле, әллә сынап карарга булдымы?

– Стенага терибез! – дип, янындагы сакчысына тагын кемнедер чакырырга кушты. Үзе бу качкынны астан гына күзәтә башлады. Ә егетнең уйлары Хәдичә турында иде. Иртәгә аның кырына килергә вәгъдә биргән иде. Ата-нитә калсалар, күреп булмас микәнни, дип уйлап куйды. Егетне күзәтүеннән туктамыйча, боевик кесә телефоныннан каядыр шалтыратырга тотынды. Һәм шул мизгелдә Ринатның зиһененә келт итеп: «Ә ул киләсе сукмакны да миналап куйган булсалар? Кыз, һичшиксез, һәлак булачак».

Ничек башта ук башына килмәгән? Ә болары кайдан килеп төштеләр? Нигә миналарга эләкмәделәр? Болай булгач, бу авылга килер өчен тагы берәр яшерен юл бардыр?

Хуҗа хатын чыгып, егет ягына карап, боевикка нәрсәдер кызып-кызып сөйләп бирде. Күрәсең, сүз Хәдичә турында да барды. Боевик, егеткә карап:

– Әй, куркак, якынрак кил! Сине, бер чечен кызын коткарып калды, дип сөйлиләр, шул дөресме?

– Мин куркак түгел! Әйе, булды андый хәл. Дүртенче блокпостта.

– Ә ул кыздан сорасак...

– Ул килә алмый. Авылга төшә торган юл-сукмаклар барысы да миналанган.

Боевикның күзләре ялтырап китте. Һәм кызыксынып:

– Кайдан беләсең?

– Беләм инде. Хәдичә киләсе сукмакны минадан тазартырга кирәк. Әле сез үзегез ничек минага эләкмәдегез?

Шул вакыт авылның теге очында мина шартлаган тавыш ишетелде. Бу Ринатка таныш тавыш иде. Шуңа да ул:

– Башланды. Авыл халкын искәртергә кирәк, беркая да бармасыннар!

Боевик егеткә усал карап:

– Менә син безгә миналардан юлны тазартып бирәчәксең. Сезнекеләр куйды бит миналарны.

– Тазартам. Тик иң элек шул яктагы сукмакны тазартырга кирәк булачак. Югыйсә аннан киләсе кеше минага эләгергә мөмкин.

Шулай килештеләр. Миналарны эзләр алдыннан егет әфгандагыча, үзенә генә билгеле ниндидер бер киеренке халәткә керде. Хәдичә киләсе сукмактан дүрт мина алды. Җир ташлы иде. Шуңа да тәҗрибәле кеше күзенә яңа гына урнаштырылган миналар урыны күренеп үк тора. Бер «растяжка» да куйган булганнар. Сукмак чистарды. Соңыннан инде авылның теге башындагы зур юлны урнаштырылган миналардан тазартып чыкты.

Боевиклар Ринатның осталыгына һушлары китеп карап торды. Ә ул юлдан бер-ике адым атлый да, нәрсәдер тыңлаган кебек, як-ягына, алдына карап туктап тора. Шуннан миналарның кайда яшерелгәнен чыбык куеп билгеләп чыга. Аннан инде – ыргаклы авыр тимер белән тегеләрне җирдән актарып алалар. Иң аламасы: зарарсызландырып булмый торган миналар. Андый минаны берничек тә алып булмый. Казып ала башласаң, җиргә бәргән туп шикелле, өскә берәр метр чамасы сикереп шартлый. Һич котылырмын, димә. Ринат әпен-төпен куелган «растяжкалар»ын да алып ташлады. Бер сыер минага эләккән икән, шартлау тавышы шуңардан булган.

Ринат, йоклый алмыйча, озак кына уйланып ятты. Барысы да яңадан кабатлана. Әйтерсең лә, аның язмышы бер сукмак-эзгә төшеп алган да яңадан шул сукмактан бара да бара. Әфганда да басуларны минадан тазартты, монда тагы шул ук хәл кабатлана. Болардан күптән качып киткән булыр иде, Хәдичәсен күрәсе бар. Ризалашса, аны ияртеп, баш тарткан берәр якка чыгып ычкынырга кирәк булыр. Икенче көнне Хәдичә килде. Ул инде үзләренең авылындагы булган хәлне сөйләде. Солдатлар һәр өйгә кереп, боевикларны эзләп йөргәннәр икән. Ярый әле, егет ул авылда калмады. Һичшиксез табачаклар иде. Ринат шуны чамалады: мондагы боевиклар бик активлык

күрсәтмичә, нәрсәдер көтеп яталар. Шул ук көнне Хәдичәнең картәнисен дә монда күчереп алып килделәр. Хәдичәнең әти-әниләре Грозный шәһәрендә торып калган. Алардан бер хәбәр-хәтер дә юк. Ярый әле, әбинең бу авылдагы сеңлесе болай хәлле генә тора. Ашау ягына бик интекмиләр. Хәдичә белән Ринат яшеренеп кенә, ир белән хатын кебек яши башладылар. Апасы сизде сизүен, тик алай-болай тавыш күтәрмәде. Менә шулай мыштым гына яшиләр.

Юл, бакча, басудагы миналарны тазарткач, авылдагылар да, читтән килгән боевиклар да Ринатны ихтирам итә башлады. Шулай да кайберләре аңа булган шик-шөбһәләрен яшерми, чөнки Ринат аларга кушылмады. Үзләре белән нindidер авылга барып,солдатларны юк итеп кайтырга чакырдылар, кискен баш тартты, бармады. Менә беркөнне бу бәләкәй генә авылга тагы хәтсез генә боевиклар килеп төште. Барысы да сакаллылар. Кайберләре тамак төбе белән каты итеп сөйләшә. Ринат тиз чамалады: араларында пуштун телендә сөйләшкәннәре дә бар. Гарәпчә сүзләр дә яңгырап китә.

Кайчакны Ринат үзен яңадан Әфганда кебек тоя башлады. Шул ук текә-текә кыя ташлы, түбәләре ак карга төренгән таулар. Аска карасаң да, башың әйләнеп китәрдәй шул ук упкыннар. Аерма шунда: Әфганда халык бик тә ярлы һәм надан. Ә мондагылар акны карадан аерып, укый-яза беләләр. Ярлы һәм байлар арасындагы аерма да аз. Әмма бик бай йортлар да күренә. Бу йортлар, әйтерсең лә, бер зур крепость. Ихаталары гына да икешәр метрдан биегрәк һәм бик нык итеп салынган.

Ринатны иртән иртүк яңа килгән отрядның башлыгына, Әмир атлы боевик янына алып киттеләр. Бу бәндә йорт уртасында үскән алмагач, груша күләгәсенә урнаштырылган өстәл янында утыра иде. Егетне аның каршына китереп бастырдылар. Боевикларның бу отряды хәтсез зур гына булып, Ринатка таныш чеченнар күренмәде. Күрәсең, алары икенче урынга күчкән. Бүтән төркемнәр аңа буйсынганга, аны командир дип түгел, Әмир дип йөртәләр. Шуңа да ул үзен башка командирларга караганда күпкә һавалы тота. Һәм бу командирның ярдәмчесе бик җитди генә:

– Иртәгә без шул-шул район үзәгенә барырга җыенабыз. Син шул елга аркылы салынган күперне төнлә минадан тазартырга тиеш. Сиңа ярдәмгә килгән егетләр әзерләнеп көтеп торалар. Үзеңә корал сайла! – диде.

Ринат вакыйганың мондый борылыш алуына аптырашта калды. Күрәсең, аның оста минёр икәнен моңа да җиткергәннәр, дип уйлады. Ул теге көнне чечен командирына: «Үзебезнекеләргә каршы корал күтәрмим», – дигән иде бит инде. Бүген дә боларга шул сүзләрне кабатларга мәҗбүр булды.

– Мин аларга каршы бармыйм.

– Нигә?

– Беренчедән, сугыштан туйдым. Икенчедән, анда якташлар һәм татар-башкорт егетләре күп. Аларга корал күтәреп ата алмыйм.

– Барыбер барырга туры киләчәк, – дип, бу кыза башлады: – Сине мәҗбүр итәчәкбез! Нәрсә, монда курортка ялга килдең мәллә? Тыныч кына сугыш беткәнне көтеп ятарга уйлыйсыңмы? Барасыңмы, юкмы?

Ринат дәшмәде. Чечен, егетнең дәшми торуына ачуы кабарып, аннан да бигрәк башкалар алдында үзен күрсәтергә теләп, урыныннан торып, егет алдына килеп басты. Кизәнеп, яңагына сукмакчы булды. Ләкин тидерә алмады. Әфганда мондый сугуларны үзендә күп татыган шурави барысына

да әзер булып янтаеп калды. Гадәттәгечә, куркыныч янагандагыча, җәя кереше кебек киерелде. Бу минутта аңардан әллә нәрсәләр дә көтәргә була. Тик егетнең мондый сәләтен боевиклар әлегә белми иде. Кысыр кизәнүеннән, аннан да бигрәк бу хәлне күзәтеп торган чеченнарның елмаюын шәйләп, тегенең ачуы кабарды. Тагы кизәнде. Бу юлы да аның йодрыгы һаваны гына кыйнады. Ринат эчке сиземләве белән аның нинди хәрәкәт ясарга тиешлеген алдан ук чамалап торды. Юк, тагын булдыра алмады. Өстәл янында утырганнарның икенчесе:

– Синнән булмады! Әйдә әле син, – дип, таза гына икенче чечен боевигына ымлады.

Монда шундый шөгыль гадәткә кергән. Әсир төшкән солдатларны кем тизрәк сугып ега?! Әсирне кыйнаудан ләззәт табып, күңел ачалар һәм кул сугышы алымнарына өйрәнәләр иде. Ринатка каршы чыгасы боевик, билендәге кораллары эленеп торган каешын салып, кырындагы иптәшенә тоттырды. Барча халык кызык карарга теләп, түгәрәк ясап басты. Ринат та үзенең нинди хәлгә тарыганын чамалап һәм бераз ситуацияне йомшартырга теләп, өстәл янында утыручыдан:

– Ә миңа сугарга буламы? – дип сорады.

Командир дәртләндереп:

– Әлбәттә, әлбәттә. Булдыра алсаң, хет өстенә менеп атлан. Менә бит телең ачыла башлады, – дип куйды.

Ул үзенең боевикларының сугышчан сәләтләренә ышана иде. Хәтта чеченнарның кайберләре, кем җиңәчәк дип, үзара бәхәсләшә дә башлады. Ә Ринат эчтән генә: «Мөгаен, болар белән барырга туры килер. Барып чыкса, Әфган коллыгыннан качкандагы кебек болардан да елга аша качармын», – дип уйлап куйды.

Яңа боевик түгәрәккә чыга-чыгышлый ук Ринатның тез астына тибеп егарга уйлады. Барып чыкмады. Кулларын бутап, егетнең уяулыгын читкә юнәлтте, касыгына тибәргә чамалады. Тик мондый алымны алдан ук сизеп торган Ринат, тегенең аягыннан эләктереп, үзенә тартты. Боевик тигезлеген саклый алмыйча гөрселдәп, җиргә ауды. Ә дигәнче аягына торып басты да яңадан Ринатка таба килә башлады. Тик өстәл янында утыручы аны туктатып, кырында торган икенче берәүгә күрсәтте.

Монысы алдан ук, ыргый-сикерә, йодрыгын уйнатып килә башлады. Тирә-яктагылар Ринатка каршы түгәрәккә чыккан егетне дәртләндереп, кычкыра, сызгыра башладылар:

– Әйдә, әйдә, кыюрак!

– Күрсәт үзеңнең осталыгыңны!

Тавышка өй эченнән чатанлап, тагы бер сакалтай чыгып, бусаганың күтәрмә баганасына сөялде. Күрәсең, бу алыш аңа да кызык булып китте, титаклый-титаклый, бусагадан төшеп, өстәл янында утырган командир каршына килеп басты. Тегесе, тиз генә торып, аңа урын бирде. Ринатның күз алдында бала башы кадәр йодрык уйнаса да, ул барысын да күреп өлгерде. Чатан сакалтайның болар арасында зур һәм ихтирамга лаеклы зур командир икәнен чамалады. Һәм Әмир дигәннәре шушы микәнни, дип уйлап куйды. Күрәсең, Ринат башта Әмир дип уйлаган бандит бу чатанның ярдәмчесе генә булган. Чатан түрә өстәл янына килеп утыргач, барысы да тынып калды.

Шул тынлыкта Ринат ап-ачык итеп, тегеләрнең пуштунча сөйләшкәннәрен ишетте. Һәм теге чатанга тагын да ныграк игътибар итте. Барча уй-зиһене шул сакалтайга күчте. Кайда күрде соң әле бу чатанны? Кайда күрде?

Ринатның үзенә бик игътибар да итмичә, каядыр артка караганын чамалап, чечен да, ирексездән, карашын шул якка күчерде. Ринатка шул җитә калды. Яшен тизлегендә тегене, аяк чалып, бәреп екты. Барысы да «аһ» итеп тынып калды. Мондый кыюлыкны көтмәгәннәр иде. Чатан да таң калды. Ә боевик песи җитезлеге белән яңадан аягына басты һәм Ринатның яңагына кундырырга теләп кизәнде. Тагы шул ук хәл, аның йодрыгы һаваны гына ярып үтте. Чечен никадәр тырышса да, егетнең битенә тидерә алмады. Ринат та җитезлектә бу чеченнан калышырлык түгел иде. Барчасы кычкырып-кычкырып, тегене дәртләндерделәр. Тик Чатан чип-чиста пуштун телендә:

– Ашыкмый тор! Сораш әле, кайсы частьтан качкан? Кем булып хезмәт иткән? Минёрлык һөнәренә кайда укыган?

Моны ишеткән чечен сугышудан туктап, өстәл ягына карады. Тегесе соравын яңадан пуштун телендә кабатлады. Чатан чеченча да, русча да белми иде. Ачуын һаман баса алмаган боевик, күзләрен алартып, бернәрсә дә аңламыйча, командирына карады. Күрәсең, сакалтай тылмачтыр. Ул сорауны русчага әйләндереп, Ринатка җиткергәнче, егетнең бу пуштун кешесенә җавабы әзер иде. Тик ул җавап бирергә ашыкмады. Чөнки башында бүтән сорау һәм тагы әллә нинди хатирәләр ташып чыгар чиккә җитеп кайный башлады. Чатанның тавышын кайда ишетте соң? Үзен кайда күрде соң ул? Тылмач, аның дәшми Чатанга карап торуын күрде дә, җәһәт кенә өстәл яныннан торып, егет каршысына килде. Чеченга нәрсәдер әйткәч, тегесе тузанланган чалбарын кага-кага, иптәшләре кырына барып басты. Ә тылмач Ринатның артыннан тупас этәреп:

– Якынрак барып җавап бир! – диде.

Ринат һаман дәшмәде. Шунда тылмач билендәге хәнҗәрен алып, аның ияк астына китереп терәде. Егет таныды: мондый бизәкле хәнҗәрләрне тик әфган рухлары гына тагып йөри.

– Нәрсә, үләсең килә мәллә? Сорауга җавап бир! – дип, пычакны егетнең бугазына тагы да катырак тери бирде. Нык авыртудан зиһенендә кинәт кенә әфгандагы Хайрулло образы чагылып китте. Һәм ул үзе дә сизмәстән, чип-чиста пуштун телендә:

– Командир-Әмиргә әйт! Бүген мине үтерсә, иртәгә Хайрулло да үлә! – диде.

Рус солдатының авызыннан пуштун телендәге сүзләрне ишетеп:

– Нинди Хайрулло? Кемне әйтәсең? – дип, тылмач бөтенләй котыра ук башлады һәм аңына пуштунча сүзләр барып җиткәч, бер секундка югалып калды, аннары чатанга борылды.

Ринат шушы мизгелдә тылмач кулындагы хәнҗәрне тартып алды да абзар ишегенә таба ыргытты. Хәнҗәр, барысын да шаккатырып, зыр түгәрәк әйләнеп, ишеккә барып кадалды. Моны Ринат үзе дә көтмәгән иде һәм ул тагын ап-ачык итеп:

– Әйт командирыңа! Бүген мине үтерсәгез, иртәгә үзе дә һәлак булачак! – диде.

Тылмач бөтенләй аптырашта калды, аннары сорап куйды:

– Нинди командир? Кемне әйтәсең?

Бөтен йорт алды тынып калды. Әфганстаннан килгән командир бу сүзләрне ишетеп, колакларын торгызды. Аның чын исеме – Хайрулло иде. Тик монда килер алдыннан, боевикларны әзерли торган лагерьда исемен Хаттабка алыштырды. Шуңа да аны Хайрулло дип түгел, ә Хаттаб дип йөртәләр. Монда чечен боевиклары арасында үзен Әмир дип таныштырды.

Ринат берничә адым алга атлады да карашын Чатанга төбәде. Аның үткер карашыннан өстәл янында утыручының зиһене икегә бүленде. «Кем бу? Пуштунча кайдан белә? Нинди провокация булырга мөмкин?» «Кара син аны, минем исемемне дә белә түгелме соң?» Чатанның да ачуы кабара башлады. Ринат дәшмәде һәм карашы белән Әмирне борауларга тотынды.

Гадәттә, барысы да аның күзенә карарга куркып торалар. Ә бу кереп китәрдәй булып текәлгән. Чатан ачуыннан кайнап, аннан да бигрәк егетнең күз карашына түзә алмыйча, урыныннан ук торып басты. Ул инде бу тамашаны читтән генә карап торучыларга үзенең усаллыгын күрсәтеп, бәһасен күтәреп, абруен арттырырга теләде. Инструктор Хаттаб-Әмир шулай үзенең иярченнәрен һәм кул астындагы сугышчыларны куркытып алырга өйрәнгән. Куркалар, димәк, хөрмәт итәләр, дип уйлый иде. Тылмачы булдыра алмаганны үзе башкарырга теләде. Күзен чекерәйтеп карарга батырчылык иткән солдатны гадәтенчә сугып егып, җиргә тезләндерергә дип титаклый-титаклый, Ринатка таба килә башлады.

Ринат капыл үзенә таба килүчене ныклап танып алды. Аны суярга килгән сакалтай урынында нинди генә бандитны күрсә дә, бу кадәр аптырамас иде. Әллә кайчангы хатирәләр, әле кичә генә булган кебек, яшен утыдай чытырдап-ялтырап, миен ярып, күз алдына килеп басты. Шунлыктан да ул күз карашын ала алмый иде. Бандит, үзенә һаман карап торган «кяфер»нең алдына ажгырып килеп басты. Билендәге пистолетына ябышты. Тик ни гаҗәп, кобураның капкачын ача алмый торды. Ринатның зиһене капыл яктырып киткәндәй булды. Алдындагы бандитның сакалы аша сул як яңагындагы миңе дә шәйләнә түгелме?!. Бәй, бу... бу бит теге, кем соң? Бу бит... бу... Хәзер ул берәр сүз дәшмәсә, аны шушы минутта атып үтерергә мөмкин бит. Ринат чак исенә төшереп тотлыга-тотлыга:

– Хай... хай... рулло! Син мине бүген үтерсәң, иртәгә үзең дә үләсең. Тәкъдир дәфтәрендә шулай язылган, – диде.

Хәзер боевик гаҗәпләнеп калды. Тукта... Алдында күзен чекерәйтеп басып торган адәм аңа пуштун телендә нәрсәдер әйтте түгелме соң?! Тик «кяфер» әйткән сүзләр аның аңына барып җитмәгән иде әле. Шуңа да теш арасыннан гына:

– Нәрсә? – дип сорарга мәҗбүр булды.

Ринат, инде бу сакалтайның чынлап та Хайрулло икәненә шиге калмыйча, аның югалып калганыннан файдаланып, пышылдап кына тап-таза пуштун телендә:

– Ашыкма! Мине бүген үтерсәң, иртәгә, Хайрулло, син үзең дә үләргә мөмкинсең. Тәкъдир дәфтәренә шулай язылган, – диде.

Егетнең бу сүзләреннән, тегенең кобурага тотынган кулы салынып төшеп калтырый ук башлады. Сакалтай, тагын да ныграк титаклый-титаклый, үз урынына барып утырды. Бөтенләй тынып калды. Хәзер барча хәрәкәте сүлпәнәеп, хәтта усал ялтырап, ут чәчкән карашы да сүнеп тонықланды.

Тагы Ринатка күз сирпеп алды. Бер мизгел карашып алгач, ниһаять, командир, күкрәгеннән чыккан әллә нинди тонык тавыш белән:

– Син кем? Кайдан? Якынрак кил! – диде.

Ринат теге чеченнарга сөйләгәнне кабатлап сөйләп бирде.

– Пуштун телен кайдан beләсең?

– Өйрәндем.

– Хайрулло кем ул? Син үлсәң нишләп ул да үләргә тиеш?

Ринат тирән итеп тын алды да, бер мизгел дәшми торгач, һавага карап, яңа гына сайрый башлаган, күзгә дә күренмәгән тургайны эзләде. Юк, тургай күренмәде. Хайрулло да аңа ияреп, күккә карады. Ул да берни шәйләмәде. Шуннан Ринат сүзне әллә кайдан башлап:

– Хайрулло – көтүче малай. Ул ике тапкыр үлә язды. Мин дә үлә яздым. Безнең тәкъдир-язмышлар бергә үрелеп, бер яфракка язылган. Әгәр дә минем тәкъдирем язылган яфрак өзелсә, Хайрулло да үлә. Менә шул!

Бу сүзләрдән бөтенләй телсез калган Хайрулло-Хаттаб киеренкелектәнката башлаган яңакларын көчкә кузгатып, тамак төбе белән:

– Кем әйтте моны? – дип сорады.

– Миңа фәрештәләр әйтә.

Монысын инде егет бераз арттырды. Нишлисең бит, яшисең килсә, боргаланырга туры килә. Аннан да бигрәк исән каласың килсә, эч серләреңне бүтәнгә сөйләмә, дигән канунны белә иде. Шуңа да Хайруллога үзенең кем икәнлеген ачып салмады. Инде әзрәк айнып уйлый алырлык хәлгә килгән командир төпченеп:

– Нигә монда килдең? Нигә безгә – мөселманнарга каршы сугыштың?

– Чеченнарга каршы сугышмадым. Бер генә чеченның да канын коймадым. Беренчедән, төрмәдә утырудан туйдым, шуңа монда килдем. Икенчедән, сугышка бармаганнарның гомерен саклап калу өчен килдем.

– Гомерләрен ничек саклыйсың?

– Миналанган басу-сукмакларны тазартып, күпләрнең гомерен кем саклап калды? Мин түгелмени?

Хайрулло дәшмәде, чөнки алдында бик тә сәер, могҗизага сәләтле, барысын да үтәли күреп белә торган гаҗәеп кеше басып торганына инанды. Үзенең отрядындагыларга башкача бу кешене бимазаламаска кушты.

Хәдичә беркөнне аны үз янына яткырмады. Кискен каршы килеп:

– Никах укытканнан соң гына, – диде.

– Ярар. Тик кайчан? Һәм кем укый?

– Мөгаен, киләсе җомга көнне булыр. Апа белән картәнидән йоласына туры китереп сорарга кирәк булачак. Мулла белән алар үзләре сөйләшерләр.

Әмма вакыйгалар катлауланып китте. Аларның отрядын күрше районга җибәрделәр. Анда федералларның зур көчләре тупланырга тиеш икән. Шуларны алга үткәрмәскә дигән боерык алынды. Тау сукмаклары аша барырга туры килгәнгә, танклар, һаман үз сәгатьләрен көтеп, яшерелгән урында кала бирделәр. Ә инде әсир төшкән солдатларны таулар арасына озаттылар. Берничә солдатны шул көнне үк аттылар. Аларга: «Кеше каны коеп, акча эшләп йөрмәгез!» – диделәр. Шулай итеп, Ринатның Хәдичә белән буласы никахы билгесез вакытка чаклы кичектерелде.

Мондагы сугышның нинди буласын да белмәссең. Фронт юк. Кайда

федераллар, кайда чечен боевиклары – аңларлык түгел. Бүген бу авыл, бу биләмә Самара десантниклары кулында булса, иртәгә киресенчә – монда чечен сугышчылары хуҗа булып йөри.

Беркөнне Ринатлар яшеренеп яткан авылга өч федерал солдатны алып килделәр. Барысы да яңа гына әсирлеккә эләккән яшь кенә егетләр. Ринатка сакларга кушып, тегеләрне таш келәткә ябып куйдылар. Бу отрядта күпчелеге гарәпләр булып, чеченнар бик аз иде. Гарәпләр усаллыкта беркемнән дә калышмыйлар. Иртәгә бу яшь кенә егетләрне атарга да күп сорап тормаслар. Йә булмаса, коллыкка сатачаклар. Боевиклар киткәч, Ринат әсирләр белән сөйләшеп тә алды. Төрлесе төрле яктан икән. Икесен милиционер булып эшләгән җирләреннән монда командировкага җибәргәннәр. Юньләп, дары да иснәргә өлгермәгәннәр.

Ринат төннәр буе уйланып ятып, бу сугышның нindидер югары постларда утырганнар кесәсенә байлык тутырып, гади халыкка кан һәм күз яше генә китергәнен аңлады. Тик бу сихерле бөҗрадан ычкынып чыгып кына китә алмый. Шуңа да ныклы бер карарга килеп, кич җиткәч, келәт ишеген ачты да әсирләргә качарга кушты. Кайсылайрак барып, нинди юлдан федераль гаскәрләр кулындагы күрше авылга чыгарга була икәнен өйрәтте. Тегеләр рәхмәт әйтә-әйтә, ул өйрәткән якка ашыгып торып йөгерделәр. Ринат үзе дә алар белән китәр иде, әлеге шул Хәдичәдән кош телендәй генә хат алды. Анда: «Мин исән. Аягым яраланды. Шул-шул авылдагы бер апаларда ятам», диелгән иде.

Тоткыннар китте. Ринат та нindидер җиңеллек кичереп, иркен сулап куйды. Иртәнгә боевиклар авылга кайтты. Ә тоткыннар юк. Ринатны «Син федералларга сатылдың. Нигә әсирләрне ныклап сакламадың? Без алар өчен ару гына акча эшли ала идек. Хәзер үзеңне сатуга куябыз», – дип, бик каты кыйнап, үзен шул ук келәткә кул-аякларын бәйләп ябып куйдылар. Икенче көнне күзләрен бәйләп, таулар арасындагы башка авылга күчерделәр. Ринат, Хайрулло-Хаттаб очрар әле дип көтсә дә, барып чыкмады. Аны шушы авыл кешесенең зиндан ролен үтәгән сусыз кое төбенә китереп салдылар. Ул боевикларга:

– Мин Хаттаб кешесе булам. Чыгарыгыз мине, – дип ялынса да, барып чыкмады.

Болары икенче төркемдәгеләр иде. Алар:

– Хаттаб килгәч, үзенә әйтерсең. Шуңарчы ят шушында! – диделәр.

Бу зинданга тагы ике әсирне китереп яптылар. Ашау ягы бик чамалы. Тагы берәр атна шушы ризыкта гына тотсалар, качу турында уйларлык та булмый. Ачлыктан хәлсезләнеп, атларлык рәте дә калмаска мөмкин. Ә Хаттаб кайчан килә әле? Сугыш бит. Ике як та нык котырына. Килмәскә дә бик мөмкин. Ринат яңа килгән әсирләр ярдәмендә, зиндан эчендәге барча ташны капшап чыкты. Бәләкәй генә таш кисәге белән шакып тыңлап та карады. Өстәге ташлар арасында бер буш урын барлыгын шәйләп, шул ташларны билгеләп куйды. Шул ташны кубарып, казып, качарга план кордылар. Әмма котылу көтмәгәндә килеп чыкты. Аларга көн дә кич су белән кабартманы бер үсмер бау белән бәйләп кенә төшерә иде. Малай, баз авызын ачып, су төшерә башлады. Ашарга төшергән бау кулыннан шуып, базга төшеп китмәсен өчен бауның икенче очын кулына нык

кына ураган. Моны Ринат шәйләп алды. Күп уйлап тормый, үрелеп, шул бауны нык кына аска тартты. Һәм малай базга килеп төшкәнен үзе дә сизми калды. Башы белән кадала иде, Ринат кочагын җәеп тотып алды. Кычкырмасын өчен авызын каплады. Мондый вакытта бик тиз уйлап эшләргә кирәк. Башка әсирләр дә эшне чамалап алды. Малайның авызына чүпрәк тыктылар. Әсирләр, берсе өстенә берсе басып, Ринатны өскә чыгара алдылар. Бау белән тартып, икенче әсирне дә өскә чыгардылар. Әсирләрнең күзләрен бәйләп алып килгәнгә аларга бу йорт таныш түгел. Йорт алдында ишекләре ачык бер «УАЗ» машинасы тора. Хуҗалары күренми. Ринат, кыргый җитезлек белән машина янына килеп, эченә күз салды. Арткы утыргычында магазиннары белән әзер калашка күренде. Машинаның ачкычы да урынында. Иң мөһиме – тавыш-гауга куптармаска. Чөнки тавышка башкалар ярдәмгә килеп җитәргә мөмкин. «УАЗ»ның арттагы буш урынында әрҗәдә әзер лимонкалар да ята. Берничәсен алып, кесәсенә тыкты, иптәшенә дә сузды.

Өй эченнән әкрен генә сөйләшкән тавышлар да ишетелә. Ринат икенче әсиргә үзенә иярергә кушты. Һәм, беркемне дә чыгармаска кушып, аны ишектә сакта калдырды. Ишекне ачык калдырып, үзе сак кына эчкә үтте. Эчтәге кунак бүлмәсендә өч ир, дөньяларын онытып сөйләшә-сөйләшә, идәнгә урнаштырылган тәбәнәк кенә өстәл янында тәмләп ашап утыралар. Ринат кerә-керешли үк тыныч кына тавыш белән:

– Рәхим итеп, тавышланмаска тырышыгыз! Куллар өстәл өстендә! Югыйсә, барыгызга да каюк! – дип, калашкага һәм кулындагы лимонкага ымлады. Ялт-йолт бүлмә эчен күзе белән ялмап алды. Ишек төбендәге чөйдә тагы ике автомат эленеп тора. Ринат әкрен генә сызгырып куйды. Ишектән икенче әсир килеп керде. Аңа күзе белән генә автоматларга күрсәтте. Теге тиз үк аңлап, ике автоматны да алып, затворларын тартып, ике кулына тотты. Ринат эчтән генә тегене мактап куйды.

Табындагыларның берсе кузгала биреп:

– Сезгә нәрсә кирәк? Бу спектакльдән башка да сөйләшеп булыр иде, – диюгә, Ринат:

– Мин әйттем бит, шым гына утырабыз. Һәм русча сөйләшәбез. Исән каласыгыз килсә, мин әйткәннәрне генә тыңлыйсыз! Кем йорт хуҗасы? Кем командир?

Олы яшьтәге ир:

– Мин – йорт хуҗасы, – диде дә янында утырган сакалтайга ялт итеп карап алды. – Мин – шулай ук командир, – дигән булды. Шуравинымы соң алдап була. Ул барысын да аңлады һәм сүзен дәвам итте:

– Менә шулай, егетләр, без үлемнән куркасы кешеләр түгел. Тагын бер кат кабатлыйм, исән каласыгыз килсә, каршылык күрсәтмибез һәм шым гына утырабыз.

Ачудан кан тамырларын биетеп, уртларын чәйнәгән ирләрнең иң таза һәм көчле күренгәненә тешләрен кысып, ысылдый-ысылдый:

– Урыныңнан тормый гына мүкәләп, болайрак кил! – диде.

Теге әллә аңлап бетермәде, әллә бүтән исәбе бар иде. Торып басарга чамалады. Җитмәсә, кулын биленә таба шудырып куйды. Шурави, песи ничек тычкан өстенә сикерсә, шундый җитезлек белән тегенең өстенә

сикереп, башына автомат түтәсе белән тондырды. Сакалтай авып төште. Ринат тагы да усалрак итеп:

– Мин әйттем бит, кискен хәрәкәт ясамаска!

Идәнгә җәелеп төшкән чеченның уң кул сыртына автомат түтәсе эләкте. Хәтта шытырдап сөякләре сынганы да ишетелде. Монысы әзер. Бу башкача кулына корал тота алмаслык хәлгә килде. Тентеп, тегенең билендәге пистолетын алып, үзенең биленә кыстырды. Шулай ук хәнҗәре дә бар икән, анысын да алды. Аның чалбар каешын чишеп, кулларын артка каерып бәйләп куйды. Әле генә үзе бәйләп ташлаганы урынына, өстәл янына чүгәләде дә тыныч кына:

– Тагын кайсыгызда корал бар? – дип сорады.

Икенче яшь сакалтай сизелер-сизелмәс селкенеп куйды. Ринат аның да муен тамырына автомат түтәсе белән тондырды. Теге авып төште. Аны да чалбарының каешы белән бәйләп ташладылар. Җитмәсә, Ринат тегеләрнең чалбардагы барча төймә-сәдәфләрен кисеп ташлады. Йорт хуҗасына уйларга ирек бирмичә психологик басым ясар өчен шулай эшләде.

– Йә, абзый кеше, йорт-җирең исән-имин торсын, улың исән калсын дисәң, безне федераллар торган җиргә чаклы озатып куярга туры киләчәк. Ризамы?

Хуҗа, киеренкелектән тамагына килеп утырган төерне йотарга тырышып, көчкә:

– Р...Р... Риза, – диде.

Шурави ишекне саклаган иптәшенә: «Баздагыларга чыгарга ярдәм ит. Кара аны, малайны саклагыз! Кача күрмәсен. Тавышы чыкмасын!» – диде.

Малайны саклагыз дигәндә, хуҗаның дертләп куюын чамалап:

– Улыгызмы?

– Әйе, – дип, башын кагып куйды.

– Ә пистолетыңны өстәлгә куярга кирәк!

– Әйе, әйе, – дип, ашыга-ашыга билендәге пистолетын өстәлгә куярга әзерлеген күрсәтте.

Картлач ялгыш чак кына шикле хәрәкәт ясаса да, тегеләр кебек идәнгә авасын сизә иде. Шуңа да чалбар каешына кыстырылган коралын күрсәтеп, свитерын гына күтәрде. Ринат үрелеп, аның да коралын алды. Ул арада зиндан эчендәге тоткын да килеп керде.

– Йортта тагын кемнәр бар?

– Киленем белән кызым һәм хатыным белән әнием.

– Алар кайда?

– Әнине юындыралар, ашарга пешерәләр.

Ринат башкача сүз боткасы пешереп тормады, вакыты ул түгел. Тиз генә идәндә яткан сакалтайларны «УАЗ» машинасына чыгарып салдылар. Ышанычлырак булсын өчен тагын икесен бергә бәйләп куйдылар. Малай белән картлачны да машинага утыртып, юлга кузгалдылар. Картлач алгы утыргычта юл өйрәтеп барырга тиеш иде. Ринат кушуы буенча юлда очраган чечен постларына кулын күтәреп, бабай сәлам биргәләде. Картлач барысын да ул кушканча үтәде. Югыйсә бу үзен-үзе аямаган бәндә ике дә уйлап тормый, үзе белән барысын да шартлатырга мөмкин. Берәр сәгатьтән тигезлеккә килеп чыктылар. Шуны гына көткән кебек кояш та таулар артына кереп яшеренде.

Ринат нәрсәдер исенә төшереп:

– Бу бандитлар нигә килгәннәр иде? – дип сорап куйды.

Картлач нидер уйланып бара иде. Берара дәшми утырды. Шуннан уянып киткән кебек:

– Синең артыңнан килгәннәр иде. Хаттаб җибәргән, – дип куйды.

Әйе, кайчакны вакыйгалар үз җаена гына акмый шул. Шул вакыйгалар эчендә кайнаган кеше үзе дә хәлләрне кинәттән генә икенче якка борып җибәрергә сәләтле. Кем белә, әллә безнең язмышларны фәрештәләр шулай үзгәртәме? Әллә, шайтан-иблисләр туп уйнагандагы кебек безнең тәкъдир йомгагы белән шулай усал тибешеп уйныйлармы? Һич аңламассың!.. Ринат шундый уйларга бирелеп барды. Алда ниндидер зур гына елга. Елганың теге як ярында бик зур авылныңмы, әллә район үзәгенеңме, кичке утлары күренде. Юл борылышында ныгытылган блокпост та тора икән. Ринат шлагбаум кырына чыгып баскан кешеләрнең үзебезнең солдатлар икәнен шәйләп алды.

Ниһаять, азатлык! Ринатның иптәшләре шулкадәр шатланды. Тик ул гына шатланырга да, кайгырырга да белмәде. Үзләрен уратып алган солдатларга:

– Менә сезгә күчтәнәч, – дип, машинада ятканнарга күрсәтте.

Һәм чечен йортындагы табыннан алган бер коштабак ит белән бәрәңгене тегеләрнең берсенә тоттырды. Машинадагы сакалтайларны бушаткач, чечен картына:

– Машина йөртә белсәң, машинаңны алып сыпырт моннан! Йөртә белмәсәң, җәяүләп кайтырга туры килә. Ычкын тизрәк! Телеңне тый! Сүз сагызы чәйнәп йөрмә! – диде.

Карт – элеккеге шофёр, машина йөртә белә иде. Машинага утырып, тизрәк шылу ягын карады. Бераз киткәч, туктап, Ринатны чакырды:

– Әй, яхшы кеше! Бер минутка мөмкинме?

Егет аның кырына гадәте буенча автоматын әзер тотып барды. Белеп булмый картның башында нинди уй икәнен. Карт кабина ишеген ачып:

– Монысы малаемның сиңа бүләге. Улым, бир хәнҗәреңне! Ашыгып, коралсызландырырга оныткансың. Ал, ал, яхшы кеше. Ал!

Чечен карты Ринатка улының бик тә зәвык белән бизәлгән хәнҗәрен бүләк итеп калдырды. Шулай котылып, үзебезнекеләр ягына кайттылар. Ринат мондый эшләрдә шомарып беткәнлектән, юлда үзе белән зинданда утырганнарга кем, нәрсә һәм ничек сөйләргә өйрәтеп куйган иде. Әсирләр тик шуны гына кабатлады. Ринат үзе, дүртенче постта сакта торганда, суга барган җирдә минага шартлап, контузия алдым, башкасын хәтерләмим, дигән легенданы кабатлады. Аның сүзләрен тикшереп, төбенә тоз коярлык түгел иде. Чөнки дүртенче блокпосттагылардан берәү дә исән калмаган булып чыкты. Госпитальгә озаттылар, анда бер унбиш көнләп тоткач, кулына төрле белешмә-кәгазьләр тоттырып, комиссовать иттеләр. Чечен сугышында булган вакыты менә шулай тәмамланды.

Әфганстаннан сугышка килгән Хаттабның якын ярдәмчесе Исмаилне тере килеш федераль гаскәрләргә алып кайтканы өчен мактаган булдылар. Икенче боевик та инструктор булып чыкты. Егетләрнең өчесен дә медальгә лаеклылар исемлегенә язган булдылар. Әзрәк акча да эләкте...

Госпитальдә алган белешмәләр һәм военкомат ярдәмендә паспорт һәм башка документлар ала алды. Ринатның язмыш йомгагы тыныч тормыш

юлыннан үз җаена сүтелеп, әкрен генә тәгәри башлады. Өйләнеп җибәрде. Гадәттәгечә, акча җитмәү авыр йөк булып, яшь гаиләнең тормыш арбасына менеп утырды. Себергә чыгып китте. Кайткан чакларында Уфадагы элеккеге Әфганда сугышкан һәм Чечен сугышында катнашканнар оешмасында кайбер яугирләр белән дә дуслашып алды. Берничәсе белән ел саен кемдә дә булса җыелышып, үзләренең сугышта исән калуларын бәйрәм итеп, үлгәннәрне искә алып, табын корырга вәгъдәләштеләр. Ринат үзе дә ике-өч тапкыр, җәй көне иптәшләренең өйләренә барып, шул искә алу мәҗлесләрендә катнашты. Чират буенча быел аларда, Таш Түккәндә утырырга тиешләр иде...

Өйдә яшь хатын әзерләнеп, кунакларны көтә. Ә Ринат юлда тоткарланды. Эшеннән аларны алырга киләсе вертушка вакытында килмәде. Әле менә Уфага чак килеп төште. Юлда чакта да әллә ничә тапкыр хатыны да, дуслары да шалтыратып, хәлен белделәр. Җитмәсә, бер шугы явыз шаярып:

– Ярар, кайтып тормасаң да була инде, безгә монда синең яшь хатының белән болай да күңелле, – дип шалтыратып алды.

Юлда арып, алҗып кайтып килгән Ринатның кәефе юк иде. Инде болары тупас шаяртып, нәрсә дип шалтыраткан булалар бит? Әйе, соңлап булса да, кайтып җитте ул бу мәҗлескә. Табын мул гына әзерләнгән. Күрәсең, кунаклар да күчтәнәчләр белән килгән. Менә шашлык кыздырырга йортка чыктылар. Кызып алган кунакларның берсе Ринатның күңелен күтәрергә теләпме, әллә башка ният беләнме:

– Кайтып җитмәсәң, без, күмәкләшеп, яшь кәләш белән мунчага барырга ук әзерләнгән идек, – дип, хатынның биленә кулын салды.

Хатыны кунакның кулын биленнән алып ташламакчы булып, тегенең кулына сукты. Менә кунак, хатынның кулыннан тотып алды да, икенче кулы белән биленнән кочаклап, артына басты һәм биегәндәге кебек хәрәкәтләр ясый башлады. Хатын ычкынып китмәкче булып тартылды. Тик кунак аны нык тоткан иде. Шул вакыт Ринатка әллә нәрсә булды. Дүртенче блокпосттагы Бармалей күз алдына килеп басты. Ул да бит аның Хәдичәсен шулай артыннан килеп тотып, Ринатка мәсхәрәләргә кушкан иде. Әле дә шул ук хәл кабатлана түгелме соң?! Ринат пантера тизлеге белән учактан итләр тезелгән шампурны алып, тегенең корсагына батырды. Бу тамашаны авыз ерып карап торган икенче кунак Ринатны кочаклап алып тынычландырырга уйлаган иде, аның бугазына ямады. Болай сугуны көтмәгән кунак, чалгы белән чабып ташлаган үлән шикелле, баскан урынында гөрселдәп, җиргә ауды. Кунак кочагыннан ычкынырга өлгергән хатын нәрсә булганын да аңлый алмады. Әле генә хатынын кочаклаган кунак чайкала-чайкала, Ринатның каршына килеп басты:

– Син нәрсә, братан? Шаярганны да аңламыйсың?!

Ринат ул сүзләрне ишетмәде дә. Тегеңә тагын бер кадарга әзерләнде. Моны күреп, яшь хатын, ике арага кереп, ирен туктатмакчы булды. Тик соң иде инде, шампур хатынга килеп кадалды. Хатын:

– Исәр! Нигә алай эшлисең? Алар шаяртмакчы гына бит, – дип, ирен кочаклап, авыртуга түзә алмыйча, аның алдына тезләнде.

Тагы берничә кунак, бу күренештән һушлары алынып, тизрәк өйгә кереп шылдылар. Югыйсә аларга да эләгә иде. Түзеп торгысыз авыртудан бөгәрләнеп яткан хатынын күреп, шурави айнып киткән кебек булды. Бераз

гына хатынына һәм җирдә хәрәкәтсез яткан дусларына карап торды. Һәм, барысын да аңлады!.. Кулындагы шампурны читкә атып бәрде. Зиһене ачылып: «Бар да тагын яңадан кабатлана», дигән уй сызылып үтте. Шуны аңлап, бакча артыннан гына башланган урманга таба җай гына басып, көчкә атлап китте. Башында тик бер уй: «Бу гел кабатланган явыз һәм аяусыз сихерле боҗрадан ничек котылырга? Кара язмышының туктаусыз бер сукмактан әйләнүен ничек туктатырга?» Адашкан кеше дә бит әйләнә дә шул бер урынга килеп чыга. Бар аларның урманында андый урын. Печән чабарга барганда, шул тау янынннан үткән юлда ничек кенә ялгышмаска тырышсаң да, шушы шайтан тавын бер өч тапкыр урамыйча җибәрми. Җенле, сихерле урын.

Юк, язмышның бер боҗра кебек әйләнүен ничек тә туктатырга кирәк! Икенче юл, икенче сукмакка ничек басарга? Бу серле шайтан тавы янындагы юлда буталган кебек, бертуктаусыз урап йөрү булырга тиеш түгел бит инде! Югыйсә кешеләргә тагы да әллә нинди коточкыч бәла-кайгылар алып килүең бар. Беркемгә дә үзеңнең гаепсез икәнеңне исбатлый алмыйсың. Барысына да шушы каһәр суккан сугыш-контузия гаепле. Кемнәр, нинди комсызлар уйлап чыгара соң аны?!

Их, шул Әфган сугышы булмаса! Ничә тапкыр үлемнән калып, ничә тапкыр контузия алды бит. Шурави шуларны уйлый-уйлый, алдында куера барган томанга урала башлады. Үзе атлый, үзе куе томанга урала...

Нәкъ шушы минутта мәңге тотылмас дип исәпләнгән Хайрулло-Хаттаб та каты яраланып, әҗәл белән якалаша иде. Әле аңын югалта, әле исенә килеп, бертуктаусыз саташа башлады. Шул мизгелдә аның күз алдына теге үзен Ринатулло дип атаган әсир бар булмышы белән килеп басты.

«Мин үлсәм, син дә үләсең», – дигән сүзләре, әле генә әйтелгән кебек колагында туктаусыз яңгырап кабатлана башлады. Һәм ул, үзенең көтү көткән чагында яраланып егылгач, солдатларның берсе маңгаена калашкасын төбәп атарга җыенганда, аны коткарып калган шурави – Ринатулланы исенә төшереп, аны таныды. Әйе, ул Ринатулла иде. Алар белән Пакъстан чигенә корал сатып алырга барганда, бергә бардылар. Менә кем булган икән ул! Шурави барысын да белгән. Әллә булмаса, ул да җәрәхәтләнеп, үлем белән тарткалашамы? Мөгаен, шулайдыр...

Хайрулло-Хаттаб үзен-үзе белештерми:

– Шурави, үлмә! – дип акырып җибәрде. Авыр тын ала-ала: – Син үлсәң, миңа да якты дөнья белән саубуллашырга туры киләчәк бит. Үлмә! Әйдә бергә яшик! Бергә булыйк! – дип, үзенең пуштун телендә кычкырырга тотынды. – Ринатулло, үлмә! Мин дә өйгә кайтырга булдым. Үлмә!..

Янындагылары Хаттабның нәрсә кычкырганын аңламадылар. Алар сораулы карашларын тылмачка төбәде. Ул инде җилкәсен генә сикертеп куйды да:

– Сезнең белән саубуллаша, – диде.

Хаттаб тагы саташуга күчеп:

– Мин башка сугышмаска ант итәм! Шурави, үлмә! Үл..м..мә! Бүтән сугышмыйк. Шурави! Шура...ав..ии!..

Ә Ринат бу вакытта алдында куера барган ябышкак томан эченә бөтенләй кереп киткән иде инде...



*Гөлзилә Фәхретдинова (Гафурова) 1996 елда Балтач районы Алан авылында дөньяга килә. Туган авылында тугыз сыйныф укыгач, әүвәл Г.Тукай исемендәге Арча педагогика көллиятендә белем ала, аннан читтән торып КФУның татар филологиясе факультетын тәмамлый. Бүгенге көндә Арчаның Апаз авылы мәктәбендә эшли.*

*Гөлзилә балачактан шигырьләр яза, төрле әдәби бәйгеләрдә катнаша, шигырьләре республика матбагаларында басыла. Ул «Казан утлары» редакциясе өчен дә үз кеше. Аның шигырьләре «Ак җилкән» сәхифәсендә дөнья күргән иде. Әүзган ел азагында ул яшь иҗатчыларның «Иделем акчарлагы» әдәби бәйгесендә поэзия юнәлешендә I урынны яулауга ирешә. Әлеге җиңүе хөрмәтеннән яшь талант иясенә уңышлар, яңа үрләр теләп, яңа шигъри тәлгәшләре белән сезне дә таныштырабыз.*

Гөлзилә
Фәхретдинова

# АЯЗ ИДЕ ЮКСА КИЧӘ...

## Бу урамда

Йөзәрләгән, меңәрләгән йөзләр үтә.
Бу урамда син тынычлык табам, димә.
Кем ашыга, кабалана. Ә бер бәндә
Янчыгы күк буш күңелен селкеп килә.

Йөзәрләгән, меңәрләгән күзләр сынап,
Өмет өзгән кыяфәтен иләп уза.
Рәвешенә, йөрешенә бәя биреп,
Һавалана, күрмәгән күк үзе нужа...

Бу урамның тынган чагын күрим, димә!
Миллионлаган эзләр уза бу юллардан.
Өмет итмә бер җылы да, күзең төбәп,
Йон бияләй кигән суык күңелләрдән.

Бу дөньядан өмет итмә син тынычлык!
Син – мескенне аңлар җаннар күптән сулган.
Бу урамнар түшәлгәннәр кардан түгел,
Гамьсез күңел, битарафлык анда тулган.

## Аҗагандай гомер

Билгесезлек иңде. Карашларда
Мең сорау вә вөждан газабы.
Ватан чикләрендә яшь бөркетләр...
Ничек тәмамланыр азагы?!

Яшь бөркетләр утлы ядрәләрне
Күкрәкләрен терәп йоталар.
Ил күгендә кояш бер балкырмы?!
Куелырмы моңа ноктаалар...

Яшь бөркетләр! Сез янәшә чакта
Тыныч, имин ата таңыбыз!
Күңелләрдә ургый язгы ташкын –
Аҗаган күк гомер языгыз...

## Өмет эзлим

Күрә торып җанның бер кисәген
Янган утка салып буламыни?!
Нишлим икән? Каян көчләр алыйм?
Чәчәк кенә аткач суламмыни?

Нинди чара табыйм? Көннәремне
Синнән башка килми күрәсем дә...
Бу дөньяда ниләр майтарыла?
Белми идем... Килми беләсем дә...

Синең сулыш тигез булсынга мин
Әзер үзем көлгә әйләнергә!
Нишлим, әйтче, сине йолыр хакка
Кайсы кылга барып бәйләнергә?

Чоңгыллардан очып барган сыман
Үрелердәй салам – өмет эзлим!
Өмет эзлим... Синле язмышымнан,
Синле киләчәктән өмет өзмим.

Күрә торып бәгырь кисәгеңне
Салып буламыни упкыннарга?
И, җүләр мин, кайда язылган ул
Ирек өмет итү тоткыннарга?!

## Бу бураннар

Бу бураннар урамдамы?
Күңелдәме исә җилләр?
Бу йөрәкне юатырга
Көйлим икән нинди көйләр?!

Бураннарга йөгереп чыгып,
Карлар булып очар булам.
Мин әйтерсең бүген сәрхуш,
Бөтерелә бөтен дөньям.

Бу бураннар йөрәктәме –
Туздыра бар күңелемне?
Юл өстеннән очкан кардай
Көчсез тоям мин үземне.

Бар дөньямны җимерердәй
Бу бураннар кайдан исә?
Төнемне дә сагыш басты,
Аяз иде юкса кичә...

## Горурлык

Шулкадәр буталды дөньябыз.
Мин сине аңламыйм, син – мине...
Яратып әйтәсе сүзләрем
Әрнүдән түгелә шикелле.

Шулкадәр буталды бу тормыш.
Мин күкләр иләндә, син – җирдә.
Бер алтын урталык табалмый,
Яшәгән булабыз без бергә.

Сиңа да кирәктер аңлашу.
Миңа да бик тансык тынычлык.
Бәхеткә бер адым – сафсата!
Тынычлык китерә тырышлык.

Син миңа бер адым атласаң,
Ризамын мең адым килергә.
Горурлык иярли кешене:
Кая ул башларны иярга!

Шулкадәр тугланды дөньябыз.
Син – горур, мин – синнән көчлерәк.
Юкса бит бәхетле булырга –
Бер адым(!) атларга көч кирәк...

## Көнләшү

Мәгърур сының үкенеч шәүләседәй
Теләр-теләмәстән йөри янда.
Сүзләрең дә никтер назлы түгел,
Күңелләрең, белмим, әллә кайда.

Синең күзләр мине түгел, гүя
Әллә нинди асыл затлар тели.
Ялыктырды бугай бар булмышым,
Иркәләнә алмыйм алар кеби.

Үзең янда. Итәк күргән саен
Борылып карауларың җанга тия.
Түз, йөрәгем, сабыр... «Бу мәлгуньнән
Котылулар бармы икән» димә?!

Мин тотмыйм да, җибәрмим дә куып,
Яшьләремә чумам таңнарымда...
Синнән ышык, җылы өмет итәм,
Тиң сөеклең булып яннарыңда.

## Калдырма!

Калдырма! Бу кырыс дөньяда
Ялгызым калдырма... Үтенәм...
Йөрәктә шөбһәле шомлану,
Әйтерсең учымда ут үрәм...

Калдырма! Ялгызлык утлары
Өткәнче телгәләр җанымны...
Хакың юк җилләрдән сөйдереп,
Толлыкка ташларга ярыңны!..

Калдырма! Шушы сүз тын бирми,
Муенга чорналган бау сыман.
Җай гына тормышка шом үтте,
Алдымда – билгесез ак томан...

Бу җилләр, томаннар бар да ят,
Бар да чит һәм шыксыз... Бел, аңла!
Күңелем бакчасы шау чәчәк
Бары син янәшә булганда!

## Парә-парә

Тормышымның парә-парә килгән мәле,
Бу дөньядан өмет өзеп йөргән чагым.
Кулларыма йөгән тотып, таш сукмакка
Чарасыздан килеп чүккән мәлем тагын...

Күңелемнең парә-парә килгән чагы,
Бәргәләнә читлектәге сандугачтай.
Очар булам чиксезлеккә, иркенлеккә,
Очар булам хыял күгем – зур кояшка.

Бар дөньямның парә-парә килгән мәле.
Миңа кулын сузар затлар бу җирдә юк.
Канатлары каерылган кош шикелле
Кыялардан очып төшкән мин – янар ут.

Бар җанымның парә-парә килгән мәле.
Ике дөнья арасыннан очып барам.
Үз хәлемне беләм бары үзем генә,
Ялгышлардан гына берүк сакла, Аллам!



Рифә
Рахман

# ГАДИ ВАКЛАНМА

ПОВЕСТЬ

Зирәк чирәмлектә көннәр буе бәбкә саклый. Язын шулай эшлим, анда барам, монда, рәхәтләнеп балык тотам, дип көткән иде, ул уйлаганча булмады.

– Инде син зур, быел бәбкә – синеке, – дип, күкәйдән соңгы каты томшык борын төртеп, аягына ныклап басуга, кәгазь тартмага бөтен бәбкәне тутырдылар да аны да ияртеп, инеш буена алып төшеп киттеләр. Бабасы шунда тал чыбыкларыннан оя үргән икән. Су куйгач, ул җирен карагач, бу җирен, бәбкәләрнең барысын читән эченә җибәрде. Малайга тилгән, козгын куркытырга дип ясаган пумаланы тоттырды:

– Кояшы нинди бит, җылысы! Бәбкәсен, чирәмен колакларыннан тартып үстерә торган! Алып кача торганнары да булмаса! Яннарында гына утыр, яме!

Кая китсен инде ул?! Нурзидәне алмашка төшермәсәләр. Ул хәзер чишмәгә суга киткәндер.

– Колак миндә генә, бабай! – диде Зирәк, үзен шулардан тартып үстергәнгә салынып.

– Шуңа синең белән сөйләшәм дә.

Зариф карт бераз утырып, хәл алды да кайтырга күтәрелде:

– Ашарларына алып төшәм. Әбиең инде ясап куйгандыр.

Зирәк май башыннан – чирәмлектә. Сәгатьләр буе читәнлеккә карап утырасы килми аның – ул уенны уйнап карый, монысын, язган-укыган була, көннәре үтми дә үтми.

Бу кышта биш тулды Зирәккә. Хәреф таныгач, бәбкә сакларга төшкәндә, китабын бер дә калдырмый. Зариф бабасы алу-кушу, тапкырлау-бүлүгә кадәр өйрәтте аңа. Өйрәтмәгән дә булыр иде, апасы белән бергәләп, көзен мәктәпкә барасы килде малайның, ә ул аңа, үзенең зурлыгы белән мактангандай:

– Сине алмыйлар анда, яшең кечкенә, әле хәреф тә танымыйсың! – диде.

– Мәктәптә барыбер өйрәтәләр бит аны! – диде малай. Алай да Зирәккә апасының мыскыллавы җитә калды. Зариф картның бер алдына төште, бер артына, ахырда үзенә хәреф танытырга ризалыгын алды. Ул чагында чынында дүрт кенә иде әле аңа. Шомарыйм дип, көн дә укый торгач, биш яше тулганны сизми дә калды.

Нурзидә апасына – җиде. Ул да күптән укый, яза.

– Буең кечкенә, башың зур,– дип мактый кызны бабасы. Зирәккә эш кушасы булганда:

– Син инде зур,– дисә дә, араларында юк-бар бәхәс чыкса:

– Синнән олы апаң бар, аңа юл куй,– дип, гел Нурзидә ягына баса.

Зирәкнең дә апасы кебек буласы, бабасыннан мактатасы, мәктәптән күп итеп бишлеләр алып кайтасы килә. Мактау аңа болай да тия тиюен. Кәҗәләрне инеш буена куса да. Чебиләргә әрекмән җыеп кайтса да. Әбисенә чүп утарга булышса да. Алай да Нурзидә апасын күбрәк мактыйлар шикелле. Аркасыннан сөйгәндә, хәзер гел, Зирәкнең йөрәгенә кадагандай:

– Бигрәк тиз дәү кыз булдың, кызым, быел беренчегә барасың бит, – диләр.

– Мин дә зур, мин дә барам, – ди малай, үртәлеп.

Бабасы каршы төшми, ярар, дип тә әйтми.

Яз ахырында киләсе елга мәктәпкә алынасы балаларның исемлеген туплап йөрделәр. Ни көтте шул көнне Зирәк. Бабасын:

– Ападан барыбер калмыйм! – дип йөдәтә-йөдәтә көтте.

Бабасы түзмәде:

– Сәлимә апаң ризалыгын бирсә, теләгең үтмәсә, барырсың, – дип ычкындырды.

Зирәк бу сүзләрнең үзен тынычландырыр өчен генә әйтелгәнен тойса да, эченнән өметен өзмәде.

Сәлимә апасы алар урамының мәктәп башында тора. Зирәк аны көн дә күрә. Көтү шул баштан кайта. Ул, ян урамга кереп китмәсен дип, аермага сыер каршыларга бара. Сәлимә апасы да гел шунда була. Аның матурлыгына исең китәрлек! Чәчләрен чорнаган укалы косынкасы йөзенә шундый ятып тора!

Малайлары булса да, көтүне үзе каршылый Сәлимә апасы. Аларның сыерлары сөзгәк. Бервакыт Зирәк өстенә дә килде. Чүт качып котылды. Сәлимә апасын гына тыңлый ул. Аны күрүгә юашланып, яхшыланып кала. Сәлимә апасы матур шул... Ничек тыңламыйсың?! Җитмәсә, укытучы да.

Бәбкә сакларга төшәр дә мәктәпкә язылмый калыр дип, ни курыккан иде ул, юкка булган икән. Кичке якта чыбыклары таркалып тузып барган себерке белән ишегалдыннан тавык тизәкләрен җыештыргалап йөргәндә, кулына кызыл папка тотып, Сәлимә апасы килеп керде. Зирәк себеркесен лапас капкасына сөяде дә, киемнәрен сыпыргалап-каккалап, аның каршысына китте:

– Исәнмесез, апа!

– Исәнме, үскәнем. Бабаңмы, әбиеңме өйдәме?

– Өйдә. Хәзер чакырам, – дип, Зирәк кәлүшләрен сала гына башлаган иде, ишектән бабасы үзе килеп чыкты. Әллә инде бер генә таныклык тоткан? Апасыныкы гына алайса...

– Бабай, мин дә барам бит! Сәлимә апага әйт, яме! – диде аны тизрәк буш кулыннан килеп эләктергән Зирәк.

Карт берни ишетмәгәндәй кыланды – яшь чибәр укытучыга өр-яңа килеш сакланган яшел кәгазьне сузды:

– Ай тиз үсә икән балалар. Яңа гына туган кебек Нурзидәбез. Инде менә Сезнең кулга да килеп керер чагы җиткән.

– Бабай, мине дә әйтергә онытма! – диде Зирәк, бабасы гәүдәсенә төрткәләп, тавышын ул ишетерлек кенә чыгарырга тырышып. – Энесе дә бар әле, диген.

Укытучы малайның кыбырсыганын сизгән, бабасына әйткәннәрен дә ишеткән иде. Баскыч төбендәге урындыкка утырып, амбар кенәгәсенә таныклыктагы язуларны күчереп торган җиреннән Зирәккә күтәрелеп карады да:

– И апаем, анда олы балаларны гына алалар шул, әле синең яшең җитмәгән, – диде.

– Аның караве укый да да, яза да беләм, әле үземнән күпкә зуррак малайларга хәреф тә өйрәтәм мин! – дип, авыз турсайтты Зирәк.

Укытучы дәшмәде.

– Апа мәктәпкә киткәч, өйдә нишләп утырам инде? Рафис та мәктәпкә керә быел, Хәмит тә... Исемнәрен дә яза белмиләр. Мин Горькийның үзе турындагы китабын укып чыктым, име, бабай?!

– Әйе, улым.

– Татарча...

Зариф карт көлде. Малай аның нигә көлгәнен белә, укытучыга сөйләр дип, бик курка иде. Бабасы акыллы аның – сөйләмәде.

Узган ел, русчасы шуның кадәр генә булса да, күрше рус авылына кыяр сатарга йөрде Зирәк. Сатарга аны базар үзе өйрәтте. Беренче көнне, кәрҗинен аяк алдына куеп:

– Агурис, агурис, каму нужен агурис? – дип кычкырырга тотынган гына иде, бер марҗа килде дә:

– Горький? Хороший? – дип сорады.

– Гурький инде, учин-учин гурький, харуший, – дип ярды да салды малай, Горький китабы кебек яхшымы, дип сорый, ахрысы, дип уйлап.

Марҗа борынын җыерды да китеп барды. Тагын берсе килде, тагын шулай дип сорады. Монысы Зирәкнең җавабына түзмәде, рәхәтләнеп көлде. Алай да малайны кызганды булса кирәк, бер кыярны кисеп ашап карады да барысын берьюлы алды.

– Ай-яй, яхшы мактыйсың, – диде аның янәшәсендә сөт сатарга урын алган күрше апасы.– Кыярыңны бик әче дип әйтәсең бит, үскәнем. Не горький, вкусный, свеженький, диген.

Кайткач, Зирәк бабасына шул хәлне сөйләп биргән иде, ул да кычкырып көлде:

– Яшь кызлар кебек матур, татлы, дип макта син аларга кыярыңны, улым. Мине укытачак Сәлимә апа кебек, диген.

Зирәкне котыртырга аңа бир. Үзе гел шулай сөйләште... Тик менә, Зирәкне дә алыгыз әле, дип сорарга бер дә ашыкмый!

Малай ялгышкан булып чыкты. Апасы турында язганнан соң, бабасы, йомшак кына итеп, укытучыга тагын сүз катты:

– Мәктәпнең ишеге кемгә дә ачыктыр бит, Сәлимә? Бик сорый Зирәккәем. Укырга теләге зур малайның. Үзеңне дә бик ошаткач, аны синең класска тапшырырга уйлаган идек тә...

– Белмим шул,– дип, авыр сулады укытучы. Шулай да матур сүзгә эрегәнлеге күренеп тора иде. – Укыганлыгына ышанам. Тагын да алдырып китәсенә дә. Исеме дә акыллы икәнлеген сөйләп тора. Яше җитмәгән балаларны көн буе парта артында утырту бик авыр бит, Зариф абый.

– Сәгатьләр буе китап укыганны тыңлату кыен булмас, кызым. Зирәкне,

сүземне аяк астына салмыйча, исемлеккә кертеп кара әле. Өстәмә исемлеккәме. Директор белән киңәшеп...

Шулай диде дә Зариф карт әллә нишләп китте. Директор хөкем ителгән җиреннән әле әйләнеп кайтмаган, Сәлимә аның урынына калган, эшкә үз янәшәсенә яңа мәктәп тәмамлаган бер кызны алган, дүрт сыйныфны икәүләп укытып яталар иде. Карт кешенең башыннан мәңге онытылмаслык кебек нәрсәләр дә чыксын әле!

– Минеке – хата, кызым. Үзең директор бит, кеше аша хәл итәсе түгел, дип әйтәсе урынга...

Сәлимә дәшмәде. Ул чыгып киткәнче дип, бабасы өйгә инде Зирәк таныклыгы артыннан кереп китте.

Малай үзен укытачак яшь кызның киемнәрен, туфлиләрен, бөтен-бөтен җирен ныклап күзәтергә кереште. Бәйләнерлек, ошатмаслык җирен тапмады. Үзе дә, укытучының күңелен күрер өчен:

– Бигрәк Сезнең класска барасы килгән иде шул, – дигән булды.

Сәлимә апасының чыннан да шәп укытучы дигән даны бик нык таралган, ата-аналар арасында кызга хөрмәт зур, Зирәк тә моны ишетеп тора иде. Исеме беренчеләр арасына да язылгач, малай аны бигрәк тә яратып калды. Җил капканы үзе ачып чыгарды, артыннан үзе япты:

– Сау бул, апа!

Нурзидә белән Зирәк, әби-баба кулында бик тәрбиядә үссәләр дә, читкә киткән әти-әниләрен сагыналар иде. Малай, нахакка утыртылган Баһаветдин абыйсын гына түгел, тормышын берүзе алып барган Сәлимә апасын да кызганды. Бабасы әйткәнчә, директор абыйлары төрмәдән исән чыга алмаса, аның да, балаларының да ятим калачакларына шик юк. Үз аягында кайта күрсен инде, кеше ятимнәре кемгә кирәк, ди әбисе дә.

Зариф карт ике мәдрәсә тәмамлаган хаҗи иде. Авылда аннан да белемле кеше юк. Байлар хезмәтендә дә булган, колхозныкында да, рус язуын да яхшы белә, гарәпнекен дә. Авызында дин сүзе дә, дөньяныкы да күп булыр. Уразасын калдырмас, җае чыкканда, салгалап та кайткалар. Мәмдүнәсе бер дә яратмый аның шул гадәтен, әмма:

– Үзең укытучы буласы кеше бит син, Зарифулла, үзең, шушы яшел суларны капмасаң, – дип, бер чебенләп ала да басыла.

Көтүдән кичә дә салып кайткан иде ул. Быжгылдый башлаган карчыгына:

– Син минем ничәдәлекне уйлыйсыңмы, Мәмдүнә, юкмы, аны капмасам да, капсам да... Укытучы була алмыйм инде мин. Яшь чыккан. Балалар янып торган кешене, матурларны ярата. Сәлимә апалары кебек күрер күзгә чибәрләрне ныграк тыңлый торган була. Миндәй ап-ак сакаллы карт өйдәге оныкларын тәрбияли алса да, бик җиткән, – диде дә мич артындагы сәкегә кереп ятты.

– Чибәрен чибәр дә...

Мәмдүнә карчык теленә килгәнне әйтеп бетермәде. Зариф картның шул арада гырлап йокыга да киткәнлеген ишеткән иде инде.

* * *

Хәбибә әбинең Сәлимәсе, чыннан да, кашыкка салып йотарлык апаларыннан да чибәррәк булып җитеште. Авылда бар егетнең күзе төшкән кыз. Текәләнеп, борын чөймәсә, әллә кемнәргә барасы. Һәм сәгате җиткәч,

бара да – тормышның иң авыр вакытында, бөтен авыл, инде ни күрербез дип, дер калтырап яшәгәндә, утыз җиденең көзендә район судьясына кияүгә чыга.

Тик монысы әле соңрак...

Иң башта Нигъмәтулла әзмәвер акылын югалтырдай гашыйк була Сәлимәгә. Башкалардан да килеп торганны, һәрберсе кире борылганны ишетсә дә, яучы арты яучы җибәртә. Кызның кылын үзе дә әле тегеләй, әле болай тартып карый, һич уңай җавап ала алмый.

Соңгы димче, Сәлимәнең ачы җавабыннан өметсезлеккә бирелеп, ишек тоткасына ябышкач әйтә куя:

– Сабантуй батырын да кире каккач, кем кирәк микән аңа тагын (?!), ди инде Нигъмәтулла үзе дә. Башкалар да димләгән дип ишеттек, Сәлимә. Кыз баланың, сораганны кире каккан саен, бәхете кими бара. Күзе төшкән егетләрнең берсе дә сиңа яраррлык түгелмени соң?

– Яратмыйча гына чыгасы килми.

– Кайсы төшен яратмаслык Нигыйның?! Йөзгә чибәр, гәүдәсе төз...

– Мыегын ошатмыйм.

– Башта ук шулай дип әйтәсең калган. Анысын кырып атар, – ди дә яучы кире өстәл янына килеп утыра. – Эш шуннан гына торса.

Сәлимә мыек турында сүз урынына сүз булсын дип кенә әйткән була анысы, әмма инде Хәбибә карчыкның да, гәүдәсе бигрәк матур бит, гәүдәсе, дип кыставына түземлеге бетә, ризалаша. Эченнән, үзен бәхетле буласына ышандырырга теләгәндәй, өе дә яхшы, килере-тамары да бар, бер дигән яшәп китәрләр әле, дип фаразлый.

Кызның ахыр исәптә уңай җавабына сөенеп чыгып барган димче карчыкка алай да:

– Укытучыга тиң кеше түгел инде дә... Ярар, яшәп карыйк... Мин ризалашты дип, артык масаеп китмәсен,– дип әйтеп кала.

Ике генә ел мәктәп юлын таптаган, колхоз артилендә йон теткән Нигъмәтулла җиде класс тәмамлаган, шул сентябрьдән укытучы булып эшләргә хыялланган Сәлимәне өенә алып кайтып утырта да, атна узды дигәндә, әти-әнисе белән калдырып, Казанга укырга китеп бара. Көзен ындырдан аласы ашлыкны авырлык белән исәпләгән Нигъмәтулланы хатынның үзенә тиң санамавы сәбәп булганмы, башкасымы – кистереп әйтүе кыен. Колхозга агроном кирәк булгач, Сәлимәләргә ялварып килгән рәис, аннан да матур кеше юк, ул барсын, аны ике куллап алырлар, янында бала-чагаң юк, иреңне курсларга җибәреп кайтар әле, ди. Бу сүзләр яшь киленгә ошый, рәиснең аңа баш иеп килүе дәрәҗәсен тагын да үстереп җибәргәндәй итә, ярар, ичмаса балаларымның атасы укыган кеше булыр, дигәнен сизми дә кала.

Ни галәмәт, Нигъмәтулла китә дә бераздан башын кыңгыр салып әйләнеп тә кайта. Үзе тагын да матурланып, әллә инде яшәребрәк тә киткән, киемнәре үзгәргән. Тәмам шәһәрскигә әйләнгән.

– Сыерны сатыйк, Сәлимә, – ди ул капкадан керә-керешкә, бауга кер элеп йөргән хатынына күршеләр дә ишетерлек кычкырып.

Тегесенең кулындагы кере җиргә үк төшеп китә.

– Сәлам бирү, хәл сорау юк. Беренче сүзең шушымы? Кил әйдә. Күреш башта!

– Сыерны сатыйк, Сәлимә! – ди Нигъмәтулла, тагын да ныграк итеп.– Акчаның безгә иң кирәк чагы.

– Авылда сыерсыз яшәрсеңме? Ни дигән сүз бу? Уйлап сөйләш.

Нигъмәтулла, башын иеп, аның янына килә, керләрен үзе элеп бетерә дә инде хатыны да чак ишетерлек итеп пышылдый:

– Үгезне булса да алайса... Әле аннан суярлык мал ясаганчы...

– Әйтеп бетер инде тизрәк.

– Укуы бик авыр. Син аны аңламыйсың, хатын.

– Шуның кадәр матур була торыпмы? – дип таң кала иренә бөтен җирдә матурлык юл ярыр дип уйлаган Сәлимә.

– Казанда матурлыкка карамыйлар. Мин укырга барган җирдә бигрәк тә. Укуы бик авыр. Ике класс кына бетергән кешегә бигрәк тә.

– Бүтәннәр ничек укый соң?

– Укыган булып маташалар инде. Шулкадәр авыр. Белсәң икән син. Анда гади вакланмалар кирә. Синең, минем генә баш җитәрлек түгел. Белмәгәч, сөйләшү җиңел ул...

– Мин – быел математика укыта башлаган кеше. Кушу-алуны гына маңкасы агып торган, хәреф танымаган балаларга да өйрәтәм әнә. Егермедән узган башың белән!

– Укытып була ул, укып булмый. Белүе авыр. Ичмаса гади вакланма кермәсә дә, түзәр идем әле...

– Түзәргә тырыш. Әле башы гына бит.

– Әйтәм ич, гади вакланма кермәсә! Сыер кадәр сыерны сатам, дип кайтаммыни?!

Әзмәвер Нигъмәтулланың шулкадәр зарына түзмичә:

– Ташлыйсың гына мәллә? Алай ук авыр да булгач... Укыган кеше белән торырмын дигән хыял бетә инде алайса... – дип еламсырый ук башлый Сәлимә дә.

Шәһәр матурлыгына күңеле ята башлаган Нигъмәтулланың коты оча:

– Булмаганны! Сыер калып торыр. Үгезне сатып булса...

– Саттык ди... Аннан...

– Агроном булам бит. Билгеләрне акчага куйдырып кына алам да.

Көзге базарларның кызган чагы була. Үгезне ял эчендә саталар.

Шулай итеп, малдан кергәнне кесәсенә тыгып, Нигъмәтулла укырга китә. Бер өлешен, хатыны әйткәнчә, җылы ыштанының эченә тегелгән кесәсендә калдырып, бер өлешен түш кесәсенә сала, беразын, билге турында сөйләшү өчен кергәндә, директорга биреп калдыра. Әле калдырганчы, үзенекенә аракы алып кереп, каяндыр тозлаган кыяр табып, бераз утырып та алалар.

Директор кулына эләккән акча атнага гына җитә. Теге шуннан соң һәр көн иртән, математика дәресе башлануга, ишеккә килә дә, сәбәп тапкан булып, Нигъмәтулланы чакырып ала икән. Инде кесәсендә калган акчага алырга кушып, кибеткә аракыга йөгертә. Үгез акчасы диплом ясар көнгә бетеп тә куя. Директор айнымаслык эчкечелеккә чыга да эштән куыла.

Кесәсендәге үгез алып биргән диплом хисеннән кызып-тирләп, акчасыз бер көн дә яшәп булмаган башкаланы ташлап, укып бетергән шимбәдә үк Нигъмәтулла авылга – сөекле Сәлимәсе янына кайта. Кайтышына, белеп

торганнар диярсең – мунча ягылган, табын корылган. Ишетеп, ул арада туган-тумача җыела.

– Иптәш Насыйбуллин, диплом алып чыктыгызмы? – ди, кеше алдында хөрмәт белән һәм үзенә инде тиңлегенә ишарәләп, Сәлимә.

– Чыктым. Артымнан ук директор да чыкты.

Кич белән Сәлимә кочагына кереп ятканда гына, эшнең ни икәнлеген сөйли Нигъмәтулла:

– Үгез директорны тәмам эчкечегә әйләндерде.

– Гади вакланма. Нәрсәсенә аптырыйсың аның?! – дип кенә җавап бирә хатыны.

– Бер үгез тугыз айга җитте, дисең инде алайса, – ди ахыр чутта шуңа башы җиткән, гади вакланманың ни икәнлеген аңлый башлаган Нигъмәтулла.

Сәлимәгә алай да матур ир белән озак яшәү бәхете эләкми. Агроном булгач, Нигъмәтуллага – хатыннарның, хатыннарга Нигъмәтулланың күзе төшә башлый.

– Ирдәүкә Рәйсәнең кайсы җиренә кызыккансыңдыр? – ди аптырап колхоз рәисе бервакыт нәрәдтән соң тиз генә үзе яныннан чыгып китмәгән Нигъмәтуллага. – Хатының – гүзәлләрнең гүзәле. Яшь. Булган. Җитмәсә, укытучы. Җитмәсә, яхшы укытучы.

– Анысы шулай. Рәйсә дә аннан ким түгел. Атта матур йөри. Бик килешле утыра. Артыннан карап калсам, шул дәртемне кузгата. Атының арт санын камчысы белән дә кыздырып алса... Йөрәкне яргандай итә инде.

Колхоз эшенә чыккалаган Сабира карчык улы белән Рәйсәне берничә тапкыр бергә күрә дә, килененә әйтмичә генә, Нигъмәтулланы гаиләсеннән тартып алырга йөргән хатынның өенә талашырга бара.

– Сәлимәсенең барлыгын беләсең, укыган кеше икәнлеген беләсең, тиң түгеллеген беләсең... Башкалары беткән шикелле, – дип, сүзен әйтә генә башлый, Рәйсә ике бөеренә таянып, каршына килеп баса:

– Поздно инде, поздно!

Карчык җавап табарга өлгерми кала, чолан ишеген бәреп ябып кереп тә китә.

Сабира әби өлгесе ачык тәрәзәдән баш тыгып кычкыра:

– Тузган булыр менә, син үзең тузган! Атка ышкынган нәмәрсә!

Рәйсә сүзгә кесәгә керә торганнардан түгел:

– Карале моны! Ширмәнкә башы белән ни сөйли! Поздно, дим бит, поздно!

– Тузган? Бирермен мин сиңа тузганыңны! Саф кыз әле безнең Сәлимә! Бер дә тузмаган! – ди аның саен Сабира, Сәлимәнең бу вакытка өч баласы булганын да оныткандай.

Әйткәннәреннән күңеле булып, урам буйлатып кайтып барганда, карчыкның каршысына колхоз рәисе очрый да хәл белешергә уйлый:

– Гаиләгез турында авылда төрле сүзләр йөри.

– Йөри инде йөри... – ди рәисне юньләп тыңлап та тормаган Сабира. – Йөри. Бабасы йөргән, атасы йөрде, Нигъмәтулла кемгә охшап йөрмәсен?!

– Соң менә сиңа охшап йөрмәсә дә булыр иде дә бит, Сабирәттәй, – ди шаярткан булып рәис. Аннан телен тешли. Карчыкның да яшь чагы булган бит. Үзе бу авылда – килгән кеше генә. Бөтен нәрсәне ишетеп тә бетермәве бар...

Рәис, инде сүзне җитдигә борырга тырыша:

– Нигъмәтулла белән соңгы арада көн дә бу турыда ныклап сөйләшәм. Анысы тагын нәрсәдер, гади вакланма гына җитте башка, шул дәрәҗәне күтәрде, дипломлы да, сөяркәле дә итте, ди дә тора. Хатын-кызның укыган кешегә исе китә инде аның, нишлисең.

– Син җибәрмәгән булсаң укырга, яшәр идек әле тыныч кына...

– Алай димәле, Сабирәттәй. Улың шуның белән кеше булды.

– Кеше булса, чибәр Сәлимәсен онытып, ятлар янына йөрерме?

– Шулай инде. Килененең үзе ни ди? Аңа балалар алдында да читендер. Ата-аналар каршысында да. Синең белән арасы ничек соң? Нигъмәтулла да шулай гүләйт иткәч... дим инде кайчак үзем дә. Нинди ялынып өйләнеп...

– Килен нинди булсын?! Бик әйбәт. Андый яраткан киленне тагын кайдан табар идем әле: ике көннең берендә дарады* ди дә тора. Яратмаса, шулкадәр мактар идемени?!

Рәис эндәшми. Ваклаган икән инде бу гаиләне Ирдәүкә, ди эченнән. Нигъмәтулланың көн дә кабатлый торган гади вакланмасы әнә шул булмагае. Әнисенең талашып кайтуы хәлләрен ишеткән Нигъмәтулла икенче көнне Рәйсә йортына күченә, Сәлимә, балаларын алып, атасы йортына кайтып китә.

* * *

Бер-бер артлы туган сабыйларым бар дип тормады, Сәлимә утыз сигезнең җәендә икенче мәртәбә кияүгә чыкты. Һаман да башлангычта укыткан вакыты иде. Атта йөрүләре дә дәртен уятудан туктаган, аягыннан – күнитек, башыннан кепка төшмәгән Рәйсәдән инде күңеле кайткан Нигъмәтулланың эченә бу хәл утлар йөгертте һәм үсеп килгән балалары янына әйләнеп кайту уена ут төртте. Хәер, йортыннан чыгып китсә, муенныннан өстерәп, кире алып кайтачак иде аны кулы каты, күңеле анысыннан да катырак Рәйсә.

...Мингазиз карт, кызы да авылда кеше рәтендә йөргәч, артык байлыклары да булмагач, сәвиткә тел-теш тә тидермәгәч, һич кенә дә үзен кулга алырлар да төрмәгә илтеп ябарлар дип уйламый иде. Авыл буенча йөргән чират аңа да килеп җиткән. Кыр эшләре вакытында нииндидер тикшерү белән килгән район судьясы ул көтүдә вакытта карчыгы Хәбибәгә үзе янына чакырган язу калдырып киткән.

– Уен-муен эш түгел, шаяртуга алмасын, сәбәп табып, килми калмасын, сер итеп кенә әйтәм, картың кулга алынырга тиешле кешеләр исемлегендә, – дигән.

Хәбибәнең коты очты. Кызы Сәлимә мәктәптән кайтканчы елап шешенеп бетте. Аннан, шул хәбәрне җиткерергә кушып, аны атасы янына йөгертте. Картны судка ял көненә чакырулары сәер тоелса да, ярады: рәистән сорап торасы булмады, көтүдә кызы Сәлимә генә алмаштырды. Ул эшнең нәрсәдә икәнлеген шунда ук төшенде, әмма вакытыннан алда бу хакта әти-әнисенә сөйләми торырга булды.

Көтүне үләннәренең сусыллыгы юкка чыккан, ямьсез куе төсләргә буялган, анда-санда курага әйләнгән сабаклар тырпаеп утырган болынга җибәргәч, җиргә көртәсен җәеп ятты да Сәлимә уйга батты. Үзенә бер дә мондый язмыш юрамаган иде ул яшьлегендә. Мәктәптә менә дигән укыды. Эшкә кулы килешле иде. Авыл кызлары арасында үзенә тиң чибәрләр

* дарада – зараза

бар дип уйламады да уйламады. Укытучыларның халыкта кадере дә зур булгач, җитмәсә, балаларның да яраткан апасына әверелгәч, эшләгәненә уч тутырып акчасын алгач, ире Нигъмәтулла шадра битле, аягы чабатадан башканы күрмәгән, ярым җимерек йортта яшәгән ниндидер Рәйсәгә, артыннан караганда, атта баруы дәрт кузгата дип кенә күченеп китәр дип башына китерерлек идемени?! Инде ияләнгәч, балалары да булгач...

Дөрес, каенанасының ошатмаган яклары бар иде. Түзде. Бик ачуы чыкканда, үзалдына гына әйткәндәй, дарады, дип куя иде дә басыла иде. Балалар янында авызына тупас сүз бөтенләй килмәгән, әнкәсенең дә бер алдына, бер артына төшкән Сәлимә үзенең бу эшенә аптырый да аптырый, шул ук вакытта әле дә ярый Хәбибә карчык аны яхшы сүзгә ала дип, эченнән көлеп тә йөри иде.

Судьяның җәен авылга беренче килүе түгел иде. Иң элек Сәлимә аны кичке уенлыкта очратты. Балаларын йокларга яткыргач, минем кайсы ягым кешедән ким дип, су буена яшьләр янына төшкән иде ул. Ай яктысында башкалардан аерылып торган, шәп киенгән егет аның күзенә шунда ук чалынды. Ул да күреп алган: парлы бию башлануга, туп-туры аңа таба килде дә чакырып, кулын сузды. Хатын ялындырмады, чыкты. Танышып, сөйләшеп киттеләр.

Уенлыкларның кызган, кичләрнең җылы, рәхәт чагы иде. Ике дә, өч тә, күбрәк тә очратты район судьясын Сәлимә. Соңгысында егет, су буйлары буйлап әйләнеп килик әле, дип дәште дә, сүз арасында сүз чыгарган булып, хатынга өйләнергә теләвен белдерде. Сәлимәнең күңелендә гаиләле булу уе юк иде. Бер тапкыр яратмыйча чыгып янган иде инде ул. Икенче тапкыр сөймичә-сөелмичә чыкмыйм, ялгыз яшәсәм яшим дип, үз-үзенә сүзне бик нык биргән кебек иде. Дөрес, өч балалы хатынны, бик матур һәм яшь күренсә дә, сорап килүче дә табылмады. Әллә укыган кеше итеп тиңсенмәделәр, әллә Нигъмәтулла күңелендә һаман да ул булганны белгән авыл егетләре-ирләре аңа өйләнүне дөрес санамады.

– Бер тапкыр чыгып карадым бит инде, – диде Сәлимә. – Яңадан кабатлыйсым килми...

– Чыктым да кердем, дисең инде алайса, – дип көлгән булды Баһаветдин абыйсы. – Кара крәстиянгә чыгу судьяга чыгу белән бер булмас.

– Әйдә, кеше янына барыйк әле, – диде Сәлимә, бу турыда сүз озынайтудан файда юклыгын аңлатырга теләгәндәй.

Инде менә шул Баһаветдин Кашафович тагын авылга килгән, имеш тә... Әтисен үзе янына чакырткан. Хатын күңеленә әллә кайдан авыр уйлар, фаразлар өерелеп керде, бөтен дөньясын чиксез моңсулык биләп алды. Мингазиз картта гына түгел монда эш, дип уйлады ул, ярсып аккан мул суларга ташлар ата-ата. Шушы ярларда сөйләшенгән сүзләрне әтисе алдында кабат кузгатмакчы мәллә Баһаветдин, үз сүзенә барып?

Хөкемгә тартыласы кешеләр арасында әтисе исеме булганга һич кенә дә ышанырга теләми иде Сәлимә. Күңеле белән дә, акылы белән дә башкачарак тоя-чамалый иде. Аның сәбәпләрен Мингазиз карт та таба алмады. Тормышлары мулданрак булса да, кеше көнләштерерлек үк яшәмиләр шикелле. Башкалардан ким эшләмиләр. Сәвиткә тел-теш тидермиләр, анысы да аларны каныгып тинтерәтми... Инде менә сәвиткә дошманнар исемлегендә, имеш.

Чынлыкта да Баһау судьяның Мингазиз картны чакыртуы тотып алып ябып куярга дип түгел – ул хәтта исемлектә дә юк иде. Сәлимәгә бер күрүдә гашыйк булган ир башкача эшли алмады: кызның кияүгә чыгарга ризалыгын алу өчен, әтисен төрмәгә утырту, сөргенә сөрү белән куркытырга, төпчегеңне бирсәң, йолып калам, дип әйтергә уйлады. Мингазиз карт бүлмәсенә килеп кергәннән соң артык каты кыланмады. Алдына чәй китертте һәм ул капкалап утырган арада тыныч кына болай диде:

– Алдагы килүемдә үк кызыгызга күзем төште. Туп-турыдан әйтәм: әгәр миңа кияүгә чыкса, мин сине утыртмыйм, сөрмим, исемлектән төшереп калдырам йә суд вакытында аклыйм. Кайткач, бергәләп уйлагыз, авылыгызга шушы арада тагын килеп чыгасым бар, шунда җавабын бирерсез.

Мингазиз карт өнсез калды. Авызындагы чәен йотасы урынга, тәлинкәсенә кире чыгарды. Бераз утыргач, бөтен чәйне бер кабым итеп йотты да, чынаякны төбе белән әйләндергәч, саубуллашмый-нитми, ишеккә таба юнәлде. Башта борылып:

– Юк! – дип кистереп әйтергә дә уйлаган иде. Ялгышмагаем дип курыкты. Киткәннәрнең сирәге генә кире әйләнеп кайтканлыгын белә иде.

Ахыр чиктә Баһау судья тәкъдименә ризалашмый булдыра алмады Мингазиз. Карчыгы Хәбибә белән кызларын көчләп булса да, гаилә корырга күндерделәр. И елады Сәлимә, и елады, аннан әтисенең, балаларыңны карап торып, укырга җибәрермен, акчамны кызганмам, болай кем булырсың, халык дошманы кызы дип, мәктәбеңнән чыгарып ташласалар, дигәнен дә ишеткәч:

– Шулар хакына гына инде... – дип пышылдады. – Синең исәнлегең хакына да...

Сәлимә, кияүгә чыгып, читтән торып укып йөргәндә, Баһаветдиннең үзен эштән чыгардылар. Алай да бетереп үк ташламадылар, Сәлимә урынына башлангыч мәктәпкә директор итеп билгеләделәр. Монысы ярады. Баһаветдиннең үзен дә көн дә юлга чыгып китүләр арыткан иде. Авылда йорт салып, балалары белән бергәләп матур гына яшәп киттеләр.

Тормышы Малтабарда аерым көйләнгәч, Баһаветдин Зариф картларга кунакка йөрергә күнекте. Бабасы йортында затлы кияүнең урыны – гел түрдән, сүзе гел бәһале булу ошый иде аңа. Мунчаны да анда ягарга тырышты, шимбә кичләрен дә Сәлимәсе белән күбрәк әби-бабай янында уздырдылар. Табын янында сөйләшеп, сүзләре бетми иде. Зариф картның күңелен яман исемлеккә эләгү мәсьәләсе гел борчып торса да, шул хактагысын бервакытта да кузгатмады.

Бабай кешегә кияү ошый, кызын бәхетле яши дип саный иде. Алай да Баһауның бер мәгънәсезлегенә күнегә алмады. Умарта тоткач, Зарифларның өстәлендә һәрвакыт бал тора иде. Атнадан атнага мунчага дип килгән Баһау, яхшы каен себеркесе белән чабынып, тирләп-пешеп чыккач, шуны каерып-каерып алып, мәтрүшкәле чәй эчәргә күнекте. Чәйне бер йотканчы, балны ике дә каба, өч тә. Ахыр чиктә Мингазиз карт түзмәде: киявенең калагын сорап алды да балны кечкенә генә алып, кире үзенә тоттырды:

– Кабып кара әле, кияү, нәрсә тәме килә?

Баһаветдин рәхәтләнеп көлде: балдан нәрсә тәме килсен инде?!

– Бал тәме, бабай, бал.

– Барыбер бал тәме килгәч, ник соң аны шулай күп-күп алып кабасың? Кеше шикелле генә аша!

Баһаветдин шул көннән бабай мунчасына йөрүдән туктады, үзенә умарта алып җибәрде дә шул эшкә өйрәнергә кереште. Алай да аңа умартачы булу язмаган икән...

* * *

Көннәрнең берендә Малтабарга ГПУ сержанты килеп йөри башлаган да Сәлимәсенең яшь егеткә күзе төшкән булып чыкты. Сәбәп табып, анда да очрашканнар болар, монда да дигәндәй, Сәлимә районга барганда да, юллары кисешкән... Егет, ай саен өенә уч тутырып акча алып кайткан хатынга кызыкканмы, әллә үзенеке итәсе килгәнгә генәме, җае чыккан саен, аерыл да аерыл, миңа чык, ди икән.

– Ничек чыгыйм? Авыл халкын көлдереп. Укытучы башым белән ир ташлап? Балаларыма ояты ни торыр?

Егеткә гашыйклыктан нишләргә белмәгән Сәлимә үз-үзенә, күңелем басылганчы сөйләшкәләп йөрим дә, берзаман очрашудан туктармын, дип сүзләр бирә икән. Түзмәгән, моны иптәш хатынына сөйләгән. Анысы инде бөтен авылга чәчкән. Сүз Баһаветдинга да барып ирешкән. Ул менә нигәдер белгәнен бер дә сиздермәгән. Бер кабыныр да басылыр әле, дигәндер инде. Үтә чибәр хатыннарга хас нәрсә дип уйлады микән әллә?

Сөйләшкәләп йөрим дә онытырмын дигән Сәлимә яшь егеткә торган саен ныграк якынайган. Аны кем дә күреп-тыңлап тормаган инде, алай да шул хакта сүз йөрде.

– Мин бит – ир хатыны! – дигән бервакыт еларга җитешеп Сәлимә үзенә тагын яратуы турында сөйләгән Раухатка. – Үзем дә сине яратам. Ни Нигый белән сөеп-сөелеп тормадым, ни Баһау. Берсенә чыгарга, гәүдәсе матур, дип күндерделәр, икенчесенә, әтиеңне утыртмасын өчен дип... Гап-гади вакланма. Бик авырга саный иде аны Нигъмәтулла. Агрономлыкка укырга баргач, көчкә генә аңлый алды. Анда да үгез акчасын бетергәч кенә... Гап-гади вакланма, дисәм дә, тормышым авырдан узды. Укучылар миңа: «Апа, Сез нинди акыллы», – диләр. Үземнекеләр, и әни, уңган да инде син, дип ярата. Район җитәкчелеге дә мактап бетерә алмый. Бик бәхетле булырга тиештер бит инде мин алайса?..

– Туктале, еламале, – дип тынычландырмакчы була Раухат. Ул һаман сулкылдый-сулкылдый сөйли имеш:

– Өлкәннәр миңа киңәш сорап килә. Үз көнемне исә кеше киңәше белән, якыннарым үтенгәнне тыңлап корган икән мин.

Үкенгән кебек шулай дисә дә, тагын ялгышты Сәлимә. Ярату сукырлыгында ялгышты.

– Баһаветдин әтиеңне утыртырга уйлаган бит, әйдә без аның үзен утыртабыз да икәү рәхәтләнеп яшибез! – дигән Раухат сүзләренә ышанып ялгышты.

Сержант егет инде болай да Сәлимәнең әтиләрендә ашап йөри һәм балны Баһаветдиннән дә зуррак алып, күбрәк кабарга гадәтләнгән иде. Мине яратмаса, бергә яшәргә планнар кормаса, алай эшләми бит инде ул дип уйлады Сәлимә. Кичен мәктәптә чыра яктысында дәфтәрләр тикшереп утырган чагы иде. Аны күрергә дип килеп кергән Раухаттан:

– Ә ничек утыртасың соң син аны? – дип сорады.

– Иптәш Сталинны күрсәм, шунда ук атып үтерер идем, дип әйткәнен миңа язып бирерсең дә...

– Алай әйткәне юк бит аның! Җитмәсә, атарга коралы да юк.

– Бар, димим. Шулай язарсың, дим. Бик кирәксә, коралы да табылыр.

Ай узды, атна... Бу сөйләшү һич кенә дә күңеленнән китмәде Сәлимәнең. Картаеп барган иреннән бик тә суынган, тәненең яшь тәнгә тартылган чагы иде. Балаларымны үзенеке кебек үстерә, дип тә тормады, аларны ятим итәсен дә уйламады, зәңгәр кара белән язган шикаятен сержантына мәктәптә бергә булган тәүге кичендә үк тоттырып җибәрде. Сәлимәне җиңгән, әмма өч балалы хатынга өйләнү уе башында һич булмаган егет шул көннән авылдан юкка чыкты. Аның айлык утырту планы Баһаветдин кулга алынганнан соң тулган, ул югарырак эшкә күчерелгән иде.

Сталинны атачак мылтыкны Зариф карт өеннән дә эзләделәр, Баһауныкыннан да – таба алмадылар, әмма да ләкин, хатыны сүзенә нигезләп, ирне ун елга, «яңадан каралуга хокуксыз» тамгасын да сугып утыртып та куйдылар. Мылтыгын яшергән, сәвит системасында эшләгәнлектән, балалар укытканлыктан, үтә дә куркыныч кеше, диелгән иде суд беркетмәсендә.

Үз вакытында Сәлимәнең күңелен җәрәхәтләгән эше, каты чыгарылган карарның файдасы тияр дип уйламаган иде Баһаветдин, әмма дә ләкин шуның аркасында сугышка бармыйча, ун елын тутырып, төрмәдән исән-имин гаиләсенә кайтты.

Хатынын, йортына туп-туры кайтса да, кичермәгән, үпкәсен тирәнгә яшереп, чын-чынлап үзенекенә әйләнгән балаларын аякка бастырып бетерер, белем бирер өчен генә бергә яшәмәкчедер, дип уйлаган иде аның хакында авылдашлары. Кемнәрдер бу фикер белән килешмәде: кая барсын, торыр урыны юк лабаса, бетәшкән-бетерешкән, хатыннарны кызыктырырлык рәте калмаган, диештеләр.

Төс ташлаган, картайган, бөкрәйгән иде шул Баһаветдин. Искергән фуфайкадан. Таушалган ботинкадан. Сөял баскан куллары калтырап тора, аякка аксаган кыяфәттә иде ул. Сәлимәгә аны шушы сыйфатта күрү авыр, әлеге хәлләргә үзе гаепле булуын аңлау тагын да авыррак иде.

Баһаветдинне кабул итеп, кочагына кабат кертсә дә, күңеле белән аңа элекке кадәр дә якыная алмады, әмма хөрмәт күрсәтергә, карарга тырышты, ике арадагы суыклыкны читләр күзеннән яшерә килде Сәлимә. Әкренләп иренә төс кертте, гәүдәсенә ит кундырды. Һич сүзгә килми яшәсәләр дә, үткәндәге хаталары күңеленнән китми, үкендертә иде аны. Ялгыз калган вакытларында, хисләренә урын биреп, үзен битәрләргә тотынса да, соңрак барыбер:

– Әтине утырту белән куркытмаган булса, бу хәлләргә барып җитәр идекмени, гаепнең башы – анда! – дип басылырга гадәтләнде ул.

Баһаветдин дә эченнән шулайрак уйлый иде бугай. Кешеләрнең төрмә хәлләре, гаепсезгә утыруы турында сүз кузгатуларын өнәми иде ул. Тегендә-монда кемдер аңа шул хакта нәрсәдер әйтә башласа, әңгәмәне тизрәк башкага күчерә, бигрәк тә Сәлимәгә тел-теш тидертмәскә тырыша иде.

* * *

Зирәккә Сәлимә апасында беренче баруында озак уку язмаган икән. Дусларына ияреп, чүпрәк букча күтәреп, дәрт белән мәктәпкә йөри башласа да, атна-ун көн узгач, укытучы бабасын чакырткан да малайны укырга йөртмәвен үтенгән.

Зариф картның онытын укудан тыю көченнән килмәгәч, укытучы малай белән үзе сөйләште. Иртән мәктәпкә барырга чыккан баланы көтеп торды да:

– Бер өч елдан тагын үземә керерсең, син бик кечкенә әле, Зирәк, мәктәптә балалар күп, барыгызны да бергә укыту авыр, – дигән булды.

Сәлимәнең булыр-булмас кайбер эшләрен башкалар кебек артык гаепкә алмаса да, сәбәбен табарга, акларга тырышса да, Зариф карт укытучының оныгына карата кылган бу гамәлен яратмады. Борын салындырып, урамнан кире әйләнеп кергән Зирәктән:

– Улым, нигә дип мәктәпкә китмәдең?– дип сорады.

– Сәлимә апа, гөжжисең, ди бит. Башкаларны да, гөжжәмәгез, дип орыша. Күп кеше гөжжәгәч, башка каба, укыту авыр, ди...

– Гөжләгән балаларны да тыңлата алганга укытучы бит инде ул! – диде бабасы ачу беләнрәк. – Ярар, Баһаветдин абыең кайткач, анда гына укырсың.

Мәктәпкә йөрүенә каршы килсә дә, бабасы артыннан, туры китереп, әллә никадәр китап җибәргән Сәлимә апасы. Шул нәрсә барысында да укытучыга булган үпкәне оныттырды. Алай эшләмәсә дә, бер онытыр иде ул аны! Шундый матур укытучыга үпкәләп буламыни?!

– Хәзергә шуларны укый торсын, – дигән Сәлимә апасы. Янына чип-чиста дәфтәр, карандаш куйган. Чормаларында директор абыйсыннан калган дөнья китап, ди, аларның. Французча, инглизчәләре дә бар, имеш. Их, бөтен телләрдә дә укысаң икән ул, дип кызыга бабасы. Гарәпчәсе, фарсычасы да яхшы үзенең, тик:

– Буш вакытында янымда сүз көрәштереп утырганчы, шуларны караштыргала, – дип төрттергән карчыгына:

– Мин аларын мәдрәсәдә вакытта ятлап ук бетергән, дөнья танытканны, тормышка өйрәткәнне караштырасы килә, – дип каршы төшә.

Зирәккә барыбер Сәлимә апасында укырга язган булып чыкты. Элеккедән дә ныграк ярата башлады ул аны. Бөтен малайлардан да артыграк яратты бугай. Аннан да яхшырак укытучы дөньяда башка юктыр кебек иде Зирәккә. Сәлимә апасы турында кеше сөйләгәннәргә дә исе китмәде. Яхшы укыткач, матурның матуры булгач, үзен сыйныфтан аерып алып мактагач, аңа шул җиткән иде.

Башлангычны тәмамлагач, әниләре янына китеп, урта мәктәпне бетерде, аннан институтка керде Зирәк. Сәлимә апасының сурәте күңеленнән юыла да башлаган иде инде. Көтмәгәндә, авылдан аның фаҗигале үлеме турында хәбәр килеп ирешә. Гомерендә авызына аракы кабып карамаган Сәлимәнең ире Баһаудан икенче кат аерылгач, эчкечелеккә чыкканы, аракы белән бутап, серкә кислотасы эчүдән вафатлыгы турындагы хәбәр егетнең күңелен тетрәтеп җибәрде. Туктале кайтыйм, бабам каберен, беренче укытучым каберен күреп, баш иеп килим үзләренә, дип уйлады, исән чакларында әйтергә өлгермәгән җылы сүзләремне әйтим.

Зирәкнең беренче укытучысы, тормышка өйрәтүчесе чынлыкта бабасы

иде, алай да Сәлимә апасын да шундый ук якын, кадерле, кирәкле кешесе санады ул, анда үзеннән читтә яшәгән әнисе җылысын эзләде.

Зирәк зираттан кайтышлый мәктәпкә тукталырга булды. Анда Сәлимә апасының кызы Наилә укытканны беләиде. Янына килеп, ничек хәл сорашмыйсың?..

Сөйләшә, узгандагыларны искә ала торгач, сүзләре әллә кайларга таба сузылды.

– Әти акланды бит безнең. Әни, авылга килеп йөргән сержант мәҗбүриләп, куркытып, шикаять яздыртты, дип, тиешле урыннарга язып биргән, – диде Наилә инде саубуллашырга да кузгалырга уйлый башлаган Зирәккә.

– Алай икән...

– Әтигә зур итеп компенсация түләделәр, Серафимовка бистәсеннән фатир бирделәр. Беләсең: анда нефтяниклар яши. Әти, бездән китеп, шунда барып урнашканда, «село» иде әле ул. Анда «Объединение пуха и пера» дип аталган оешма бар икән. Куртка тегәләр, мендәр ясыйлар, имеш. Шунда электрик булып урнашкан. Гаилә корган. Без аны әнине гафу иткәндер дип уйлаган идек. Соңгы гомерләрен матур, тыныч яшәделәр бит... Үпкәсе бик тирәндә булгандыр инде. Безнең хакка түзгәндер. Барыбызга белем биргәч, башлы-күзле иткәч, шаккатырып, кем дә уйламаганда китте дә барды...

Зирәк боларга икенче кат гаҗәпләнде. Тормышы эзгә утыргач, Баһау абыйсы, бар нәрсәсен ташлап, каядыр күчәр дип, башына да китерми иде ул да.

– Без бит үзебез дә бала чакта чып-чынын белмәгән инде, – дип, сүзен дәвам итте Наилә. – Әти читләр сүзе белән утырды һәм гаепледер дә дип саный идек. Дөресен белгәч, абыйлар әнине кичерә алмады. Мин менә гафу иттем. Ул күргән, әти күргән авырлыкларның башы әнинең яратмаган кешегә чыгуыннан башланган бит, бабайны коткару хакына чыгудан башланган!

– Абыйларыңа да аңлатып карарга иде шуны.

– Без бит әнине дөньяның иң гүзәл кешесенә санадык, әти аның әләге белән ун ел төрмәдә утырган, диде Таип та, Халикъ та.

– Ә әтиегез? Ул аларга нәрсәдер аңлатып маташкандыр бит инде?

– Әти янәшәдә чакта болай әйтү түгел, уйларга да курка иде абыйлар. Бик тә ярата иде бит ул әнине. Минем белән һаман да бәхетсездер, дип китеп барган икән. Безгә менә әни картлык көнендә булса да, бәхетен тапкан кебек иде... Бик тә сабырланган, уйчанланган, барысын да акыл белән хәл итә торган әнигә әйләнгән иде ул. Әти менә... Әни үзен бик хөрмәтләгән, ир иткән чагында китте дә барды...

Эш белән Серафимовкага килеп чыккач, Баһаветдин абзасын да очратты Зирәк. Урам буйлап таякка таянып килгән картны күргәч, кем соң әле, дип башта аптырабрак калган иде. Аннан таныды: директор абыйсы лабаса! Яраткан Сәлимә апасының ире! Электрик булып озак йөрмәгән, эшен ташлап, дин юлыннан киткән, бистәнең халык таныган мулласы икән.

– Сәлимә апа вафат инде, – дигәненә картның күзләренә яшь тулды.

– Ишеттем. Ташлавым аркасында булуы үкенечле. Яхшыга дип кылган эшләрем гомер буе начарга гына алып килде. Аптыраган.

– Бер уңмаган – гел уңмаган, дигәннәре әллә шушы микән, Борһан абый? Язмышы шундыйдыр инде кешенең.

Баһау мулла, Зирәк сүзләрен игътибарга да алмагандай, үзенекен дәвам итте:

– И-и, яратып та өйләнгән идем Сәлимә апагызга! Аны гына яраттыра алмадым. Миннән дә иртәрәк китәр дип кем уйлаган?! Син менә, энем, аны гаеплисеңдер...

– Ни өчен? Һич юк!

– Башкалар кебек, Баһаветдин абзыйның башына җитте, бәхетсез итте – ун ел төрмәдә черетте, дип уйлыйсыңдыр, ә бит мин аны тагын да бәхетсезрәк иттем. Яратуым хакына, кызны үземнеке итим дип, әтисен сөргенгә сөрү, төрмәгә утырту белән куркыттым.

– Минем шуңа ышанасы да килмәгән иде...

– Ары таба күргәннәрем – шуның җәзасы гына. Балаларны урнаштыргач китеп баруым да шуңа. Боларны исенә төшергән күз көеге булып янында яшисем килмәде. Ә бит бәхеткә бик лаек иде ул, бик лаек!

– Әйе, лаек. Бәләкәй вакытымда үзем дә аңа гашыйк идем, Борһан абый, әллә нинди зур егетләрчә гашыйклык белән гашыйк.

– Мин менә һаман да шулай... Без барыбыз да эшләгән начар гамәлләребезнең җәзасын алдык, беркемне ярата алмаган Сәлимәне үзенә карата алган бердәнбер егет – Раухат кына – юк. Алай дисәң... Без бит аның тормышын бөтенләй белмибез.

– Әйе.

– Укытучы апаңның әти-әнисен догадан калдырмый идем, инде менә Сәлимәм дә – догамда.

Шулай диде дә Баһаветдин абзый каядыр ашыккандай кузгалды. Сәгатемә карадым. Намаз вакыты җитеп килә икән.

Бераз аптырабрак тордым да кабат карт артыннан киттем:

– Баһау абый, тагын нәрсәдер әйтәсең килгән кебек калды...

– Әйтмәм дә, дигән идем инде читләргә-ятларга. Сиңа күңелемдәгесен ачыйм. Аллаһка ныграк якынайган саен, дога күбрәк укыла. Бөтен сөенгәнем шул. Сәлимәнең дә, үземнең дә гөнаһларын юып бетереп китәсе килә...

– Үзеңне дөньяның иң начар адәме санагандай, алай димәгез әле.


– Мин бит – ничә ел башкаларны хөкем итеп утырган кеше. Араларында хакка җәза алганы да булгандыр, нахагы ул елларда күбрәктер. Аларның барысыныкы каршысында мин утырган ун ел нәрсә ул! Үземне менә нәрсә бәхетсез иткән минем!

– Алай димәгез әле, Баһау абый!

– Сәлимә апаңны гаепләргә ашыкма, яме, энем. Ул бик яхшы укытучы иде. Балаларын, укучыларын ярата иде. Мине генә мин аны яраткан кебек яратып китә алмады...

– Әйтәм бит, үзем дә чын күңелдән гашыйк булган идем мин аңа!

– Нигъмәтулласының гади вакланма дигәнен гел искә төшерә иде Сәлимә апаң. Без аның price бербөтен гомерен әллә ничә кисәккә бүлгәнбез, шуның берсендә дә бәхетле итә генә алмаганбыз. Бер дә гап-гади генә вакланма түгел икән бу тормыш...



Маһир Габилоглу – язучы, публицист, журналист, тәрҗемәче. Азәрбайҗанның Язучылар берлеге, Журналистлар берлеге әгъзасы.

Маһир Габилоглу 1966 елда Баку шәһәрендә туган, 1990 елда Баку дәүләт университетының филология факультетын тәмамлаган. Төрле елларда Азәрбайҗан Язучылар берлегенең «Dədə Qorqud» энциклопедиясендә әдәби хезмәткәр, Az-TVнең «Хәбәрләр» редакциясендә мөхәррир, «Space» каналының «Һәр көн» мәгълүмат программасында мөхәррир, баш мөхәррир урынбасары, «Халык гәзите» газетасында мәгълүмат бүлеге мөдире вазифаларында эшләгән.

Хәзерге вакытта ирекле иҗат белән шөгыльләнә. Халык шагыйре Габилнең 7 томлык «Әсәрләр» җыентыгының төзүчесе һәм мөхәррире. Президентның персональ пенсиясе иясе.

Маһир Габилоглу

# ӘРМӘН-АРМЕН – ШУШАНИК МӘХӘББӘТЕ

хикәя

Бу – Яңа Баку. Кайчандыр аны «Кара шәһәр» дип йөрткәннәр. Күчерелмә мәгънәсе шундыйрак микән, завод торбаларыннан өскә күтәрелгән кара төтен сәбәпчедерме – монысын тәгаен генә белмим дә. Без аны беркайчан да азәрбайҗанча атамадык: ул һәрчак «Чёрный город» булды. Әти-әнием «НЗС» дип аталган бистәдәге иске фатирны тапшырып, Шаумян исемендәге хастаханәгә каршы биш катлы йортка күченде. Интернациональ ишегалды барлыкка килде. Районыбыз – әрмәннеке – Шаумян, урамы да – Шаумян, җитмәсә, монда Шаумян бюсты тора, хәтта метросы да Шаумян исемендә иде.

Безнең тирәдә, нигездә, әрмәннәр һәм руслар яшәде. Һәрберсенең үз сөйләше, диалекты, үз мөгамәләсе.

Минем исемем – Әхмәт. Әрмәннәр – «Эхмеджан», руслар «Ахмедик» дип йөртә. Без дә аларга үз телләрендә эндәшергә тырышабыз. Әрмәннәргә – «җан», русларга «ик» ны өстибез.

«Җан» иҗеген ишетүгә, без, әңгәмәдәшнең әрмән икәнен чамалыйбыз, әмма бер нәрсәне аңлый алмыйбыз: «җан» азәрбайҗан сүзе ласа, аны ничек әрмәннәр үзләренеке итте икән соң? Безгә яраклашыр өчен мәллә?

Халык арасында кара чәчле, кара күзле кешене күрсәләр, шунда ук кызыксыну башлана: «Хаес, туркес? – Әрмәнме, төркиме?» Сәер тоела, әлбәттә. Кемнәр алар төркиләр? Азәрбайҗанда төркиләр дә яши микәнни? Бу бит Совет Азәрбайҗаны. Үзебез исә азәрбайҗанлылар.

Алар азәрбайҗан җырларын тыңлыйлар. Зәйнәб Ханларова һәм

Мамедбаһирә Баһирзадәне... Ә кайчак «Ул Әрмәнстаныбызның халык артисты» дип куялар да җыр башлыйлар:

«Бертуганнар булдык, Айастан, Азәрбайҗан».

Ишегалдыбыздагы һөнәрчеләрнең барысы да әрмәннәр иде. Һәммәсе алтын куллы. Азәрбайҗаннар фатирларына ремонтны бары тик алардан гына ясатты. Чиратны бер-ике ай алдан алып куясы иде. Ә руслар газ, нефть өлкәсендә яки башка кара эшләрдә эшләде.

Бер итекче әрмән бар иде. Мин аның иң нечкә кылларына кагылу юлын белеп алдым: ул – Анастас Микоянны ихтирам итүчеләрдән. Кибетләрдә җүнле аяк киеме юк чак, шуңа тузганын һаман төзәттереп торырга кирәк иде, хәер, кимендә җиде-сигез ел киелгән нәрсә инде. Мин Микоянның азәрбайҗан коммунистларының беренче җитәкчесе Шаумянның көрәштәше икәнен ишеткән идем. Хрущёв вакытында СССР Югары Советы Президиумы рәисе итеп тә сайланган хәтта.

Әлбәттә, Микоян күргән кешем түгел, шулай да аяк киемемне яхшылап төзәтсен өчен, итекчегә кушылып, аны мактарга мәҗбүрмен. Ул чакта азәрбайҗанның «Файдасы булса, әрмәнне дә бертуган абыең санарсың», дигән мәкален күз алдымда тотыбрак яши идем. Берчакны шулай, итекче өенә килеп кердем дә Анастас Микоянны мактап, сандугачтай сайрый башладым. Карапет агай: «Син миңа бик ошап торасың әле, егет! Менә, туфлиләреңне бер дигән итеп төзәттем, бүләгем булсын, Эхмеджан», – дигәнче тегене тәмам күкләргә чөйдем.

Рус яки әрмән үлеп китсә, безнең ишегалды эшсезләре өчен ул көн бәйрәмгә әверелде. Күзләрдән ялган яшьләрне сөртештердек, чөнки беләбез: дөньядан кичкәннәрне искә алу мәҗлесендә табынга исерткечләр дә куелачак. Аларда андый вакытта чәкештерми генә эчәләр. Безнең йолкышлар исә, кайчак онытылып китеп, чәркәләр чыңы астында «Рубик өчен!» кебегрәк сүзләр дә ычкындыралар.

Ерак түгел генә Ибиш агай дигән кеше яши иде. Әрмәнчә әрвахларны искә алу мәҗлесендә ул аягына да басып тора алмаслык хәлгә килә. Хатыны: «Оят бел! Мамед үлгәч, кырыгына да көчкә бардың. Хәзер нәрсә? Рубик күзен йомарга өлгергәнче, син аның ишек төбенә килеп утыргансың. Хәмер исен сизденме, ә?» – дип такмаклый.

Безнең ишегалды малайлары рус секторында белем алды, кызлар да шулай. Берсе – Армен агай кызы Шушаник азәрбайҗанча укыды. Бер сыйныфта идек. Мәктәпкә бергә бардык, бергә кайттык. Бик чибәр иде ул: кара күзле, озын толымлы. Кыскасы, һәркемне сихерләрлек. Аңа хәтта исеме белән эндәшүе дә рәхәт иде. Шушаник... Әйтерсең лә күзалдында Шуша җанланып китә. Миңа Шушаник «Шуша»дан, Карабахтагы шәһәр исеменнән алынгандыр сыман тоела. Шушы сүзне ягымлырак итәр өчен генә «ик» кушымчасы өстәгәннәрдер. Үз итеп эндәшкәндә, миңа да «Ахмадик» диләр бит.

Безнең нәсел тамырлары Шушага тоташа. Тик минем Карабахта бер тапкыр да булганым юк. Аның кайсы якта икәнен дә белмим, чөнки әтием дә, әнием дә Бакуда туган. Өйдә алар нәселебез турында сөйләшмәделәр дә кебек. Ә Шушаниклар гаиләсе Бакуга Карабахтан күченгән. Кызның әбисе белән бабасы Гадрутта яшәгән. Җәй саен кайтып йөргәннәр.

Ул йотлыга-йотлыга, ул якның матурлыгы – таулары, чишмә-елгалары турында сөйләде. Мин дә әрмән кызының Карабах хикәятләрен игътибар

белән тыңладым. Чын-чынлап Карабах турында дәресләр бирде. Күңелемнән бу яклар турында уйламаска тырыштым, чөнки минем тормышым монда – «Кара шәһәр»дә иде. Завод торбаларыннан ургылып чыккан куе төтен, бензин һәм нефть ташый торган локомотивлар сигналы, трамвайлар тавышы, Бульвар, Баку җиле белән күтәрелгән тузан – болар барысы да минеке! Шушаникның Карабах хикәятләренә караганда, күңелемә алар күпкә якынрак, үзрәк. Шулай да кызны тыңлаудан баш тартмадым.

Әрмән малайлары минем белән дуслашырга тырышты. Әрмәнчә дә беләм, рус телендә дә бик яхшы сөйләшәм. Алар да русча белә. Вата-җимерә булса да, минем белән азәрбайҗанча да сукаларга тырышалар. Ул чакта хаталарын әйтеп, аяусыз көлә торган идем. Шул хәлләрдән соң әрмән балалары тел белүдә үземнән дә уздырып җибәрде. Ахырдан гына төшендем: минем белән дуслашулары да тел өйрәнү өчен булган икән. Боларны уйлар дәрәҗәдә түгел идем шул. Шушаник белән дә дуслыгыбыз һаман ныгый барды. Армен ага да урамда да, мәктәптә дә кызына күз-колак булуымны сорады. Шуңа мәктәпкә бергә барабыз, бергә кайтабыз да. Аның Арсен исемле энесе исә безгә кырын карап үтә, этисеннән курыкканга гына дәшми чыдый иде.

Минем эти-әниләр дә дуслыгыбызга каршы килмәде. Дөресрәге, игътибар итмәскә тырыштылар. Күршеләр бит инде без.

Шушаник бик гыйлемле кыз иде. 1980 нче еллар – торгынлык чорында да ул киң күзаллавы белән аерылып торды. Кайчак мине һич җавабын табалмаслык сораулар белән күмә:

– Эхмеджан, Азәрбайҗанда совет властена кем нигез салды икән?

– Белмим шул.

– Шаумян, Степан Шаумян. Күрәсеңме, безнең район да аның исемен йөртә ласа. Азәрбайҗанда Шаумян дигән тагын бер район бар әле. Ә Таулы Карабах автономияле өлкәсенең башкаласы ничек атала?

– Белмим.

– Степанакертны ничек белмисең инде? Шаумян исемендәге. Ә Карабахның ничә районы бар?

– Белмим.

– Ай-яй. Шушаны ата инде хет. Мин Гадрут, Мардакерт, Степанакерт, Мартунины өстәрмен. Ә азәрбайҗанның беренче халык язучысы кем икәнне беләсеңме соң?

– Белмим.

– Александр Ширванзадә, әрмән милләтеннән. Өйдә «Хаос» исемле китабы бар. Укырга биреп торырмын. Дөрес, ул әрмәннәргә каты бәрелә. Ярар, анысы мөһим түгел. Барыбер безнең горурлыгыбыз ул. Ә «үзгәртеп кору»ның икътисади архитекторы кем? Әрмән, Ахмеджан, әрмән. Академик Аганбекаян. Рим империясен җимерелүдән, Спартак баш күтәрүләреннән шулай ук әрмән саклап калган. Ә гарәп халифәтен Бабәктән минем ата-бабалар саклаган. Бабәкне беләсеңме соң син?

– Әйе. Киносын караган идем.

– Хөррәмитләр хәрәкәтен ник шулай атаганнар? «Ирекле мәхәббәт» нәрсә ул?

– Белмим.

– Белмәвең яхшырак та. Башың яшь әле. Ә католикс әрмән кем?

– Белмим.

– Вазген, Эхмеджан. Яхшы, алайса сезнең рухи әйдәп баручыгыз кем – Шәйхел-исламмы?

– Беренче тапкыр ишетәм.

– Син мәчеткә йөрмисеңмени?

– Юк.

– Ә мин йөрим. Әни мине һәр атнада башта әрмән чиркәвенә, аннан Тезе Пир мәчетенә, аннан соң русларның православие чиркәвенә илтә. Шәм куябыз, дога кылабыз.

– Әрмән чиркәвен аңлыйм инде, ә православ христиан чиркәве нигә инде сиңа?

– Эхмеджан, гыйбадәтханәләр төрле, ә Аллаһы Тәгалә берәү генә.

– Йа Раббым, берни аңламыйм, башымны тәмам бутап бетердең ласа...

Ул мине сораулары белән чиксез ялыктырды. Һәм гел «әрмән, хай» дип кабатлап торды. Белмим, боларны кайлардан табып укыгандыр? Миңа, мәсәлән, эти-әниләрнең дә сөйләгәне юк, мәктәптә дә укытмыйлар. «Хай» дигән сүз дә бары тик «Гитлер» сүзе белән генә тәңгәллек тудыра. Ә хәзер сугыш турында кино караганда елмаеп куям. «Хай Гитлер» дигәнне ишетсәм, мөгаен Гитлер да әрмән булгандыр, дип уйлап алам. Ярый әле немец телен укыдык, һәм мин «хай» дип кабул ителсә дә, аның «хайль» икәнен беләм.

Без инде мәктәпне тәмамладык. Чыгарылыш кичәсе җитте. Бергәләп, таң каршыларга диңгез буендагы Бульварга киттек. Башкаларга сиздермичә генә Шушаник белән Киров исемендәге Тау ягы паркына мендек. Ул янә миңа сораулар яудырды:

– Синең «Асли һәм Кәрим» эпосын укыганың бармы?

– Юк.

– Нариман Наримановның «Баһадур һәм Сона»сын?

– Укымадым.

– Ә Гусейн Җәвиднең «Шәех Санан»ын?

– Әй, җитте инде, сорауларың белән ачуымны китермәсәнә. Укымадым – бетте-китте! Миңа аларның кирәге дә юк. Барыбер атам кебек нефтьче булачакмын. Техник юнәлештәге сораулар тап, әйдә, җавап бирермен.

– Их, Эхмеджан, мин бит синнән  Аветик Исаакян турында сорамыйм. Бөтен сорауларым азәрбайҗан әдәбиятына, тарихына кагылышлы. Яхшы, син азәрбайҗан егетенең әрмән кызын ярата алуына ышанасыңмы?

Мин Шушаникның кара күзләренә төбәлдем. Алар очкынланып яна иде. Шуннан соң гына бу сорауларның ни өчен бирелгәнен аңлап алдым. Беренчедән, аның үзен зур мәдәниятле халык вәкиле итеп күрсәтәсе килгән. Икенчедән, төрки егетләр һәм әрмән кызлары – Баһадур – Сона, Асли белән Кәрим язмышын үзебезгә ялгарга тырышкан.

– Ышанам.

Шушаник шуны гына көткәндәй, иреннәре белән минем иреннәргә кагылып алды. Унҗиде яшемдә беренче мәртәбә кызлар ирененең тәмен татыдым. Әллә ничек башым әйләнеп китте. Үз-үземне көчкә тыеп тордым. Шушаник кочагыма сыенган көе суырып үпте. Мин көтелмәгән хәлдән һәм хисләр агышы куәтеннән каушап төштем. Азәрбайҗан егете белән әрмән кызы арасында мәхәббәт булу мөмкинлеге каядыр таралып юкка

чыкты. Үземне упкынга тартканын белгән көенчә мәхәббәт чолганышында калдым. Ул чакта кинәт китереп бәргән хисләрдән батасымны да яки калкып, өскә чыгасымны да аңламаганмын. Ялкынлы мәхәббәттән Шушаникның күзләренә яшь тулды. Кочагымда мер-мер килде. Минем дә хисләремне йөгәнләр көчем бетте: тулысынча аның дөньясына йотылдым. Элек мондый дәрт, сөю, көчле теләк турында китаплардан да ояла-ояла гына укый идем. Хәтта «Мең дә бер кичә»дәге мәхәббәт хикәятләрендәге канунлашкан бетемнәрне ятлаганым да булды. Хәзер бу әкияттә төп катнашучы – үзем: «Солтанның корылган пушкасы атты. Ядрәсе кызның «крепостен» ватты. Ул тагын бер кат атты... тагын... Арыгач йоклап китте. Әкият кенә тиз сөйләнә. Тугыз айдан соң солтанның улы туды». Мин «Мең дә бер кичә» әкияте кочагында идем. Солтан була алмам, әлбәттә. Икебезнең дә урта мәктәпне тәмамлаган чагыбыз. Шул арада чыгарылыш кичәсе гөнаһына батканбыз. Тау буе паркында без чикне үтеп чыктык. Әмма соң иде инде. Дөресен әйткәндә, бу хәлгә сөендем дә: чөнки Шушаникны ярата идем. Хәзер инде монысын ул үзе дә белә. Тик әти-әнигә ничек әйтәсе?

– Шушаник, яктырып бара, әйдә, киттек.

– Кая?

– Өйгә.

– Юк, әйдә хәзер үк комсомол-төзелеш отрядына языйык. БАМга китик. Байкал-Амур магистрале төзелешенә кушылырбыз. Фатир алырбыз, гаилә корырбыз, комсомол туе уздырырбыз.

– Әйдә, өйгә кайтыйк, Шушаник. Аттестат алыйк, институтка керик. Алдагы тормышны аннары уйларбыз.

– Их, кемгә сөйләп торам соң?! Сез – азәрбайҗаннар, бөтенегез бертөрле. Өлгергәнлек аттестаты алыйк – балигъ булыйк, институтка керик – гыйлемлегә әверелик, шуннан армия – ир-егетлеккә юл, партиясе – карьера, шәхси үсеш өчен мөһим, имеш. Аннан соң кайтырбыз да эшкә урнашырбыз. Апабызның йә абыебызның кызына өйләнербез, бала тудырырбыз, аннан икенчене... тагын берне... Аларны үстерербез, өйләндерербез, кияүгә бирербез... Кем өчендер яшәрбез дә үләрбез. Дөрес сөйлимме, Эхмеджан?

– Белмим. Әйдә, яктырганчы өйгә кайтып өлгерик. Үзебезне тәртипкә китерик, өйдәгеләр сизенә күрмәсен.

– Сизенсеннәр. Бүген һичнигә алыштыргысыз бәхетне татыдым! Эхмеджанны яратам мин!

– Әкрен. Ишетмәсеннәр... Өйдә сиздерә күрмә тагын. Бөтен эшне бозарсың. Ярармы?

– Ярар, Эхмеджан, ярар. Синеңчә булсын. Син дә бит ир кешегә әверелдең... Мин дә...

***

Без аттестат алдык. Шушаник документларын – Халык хуҗалыгы, ә мин Нефть химиясе институтына бирдем. Икебез дә имтиханнарны яхшы тапшырып укырга кердек. Көн дә шулай ук бергә китәбез, бергә кайтабыз. Кайчак мин аны, кайчак ул мине дәрескә соңга калдыра. Икебез дә югары стипендия алып укыйбыз, шуңа сирәк булса да, Бакуның «Нәргиз», «Фирүзә» исемле танылган кафеларына керештерәбез. Ә чыгарылыш кичәсендәге серебезне

икебез генә беләбез. Икәүләп, институт беткәнне көтәбез. Әти-әниләр һава суларга чыкканда, йә туйга киткәндә, «дәресләрне бергә карыйбыз».

Бәхеткә тоташкан көннәребез шулай үтә торды. Мин көн саен дәресләрдән соң, Сәүдә урамы буйлап, Халык хуҗалыгы институтына юл алам. Шушаник урамда көтеп тора. Бергәләп йә китапханәгә керәбез, йә шәһәр буйлап йөрибез. Иртән дә шулай. Башта аны озатып куям, аннары дәресемә йөгерәм.

Еллар үтте. Без дүртенче курска килеп җиттек. Гадәттәгечә, янә Шушаник артыннан киттем. Коммунистлык урамында халык җыелган. Кемдер: «Отставка», кемдер: «Карабах» дип кычкыра. «Коммунистлар партиясенә оят булсын!» – диләр. «Әрмән, Карабахтан кулыңны ал!» дигән лозунглар күтәргән кешеләр, кычкыра-кычкыра, Ленин мәйданына юнәлде.

Институтка килеп җиткәч, гадәттәге урында Шушаникның юклыгын күрдем. Уку йортына үттем. Дәресләр тәртибе язылган тактадан соңгы дәреснең кайчан беткәнен карап алдым һәм аудиториягә уздым. Шушаник тәрәзәдән Коммунистлык урамы ягына карап өнсез калган иде. Үзе калтырана:

– Эхмеджан, син килдеңме? Мин куркам. Бик куркам, – диде ул.

– Нәрсәдән куркасың? Куркырлык ни эшләдең әле?

– Бүген шулкадәр күңелем күтәренке иде, әйтерсең лә бөтен дөнья учыма сыйган. Инде шом биләп алды. Сине югалтудан куркам...

– Мин янәшәңдә генә. Беркая да китәргә җыенмыйм. Ник соң мине каршыларга урамга чыкмадың?

– Курыкканга. Халык төркеме «Забастовка» дип кычкыра башлагач, бөтен егетләр урамга атылды. Миңа шундый ямьсез итеп карадылар...

– Яхшылап аңлат, йә, ни булды?!

– Белмим.

Гүя урыннарыбызны алмаштык. Хәзер Шушаникны мин сораулар белән күмдем. Ул исә һаман: «Белмим», – дип кабатлады. Әмма белгәнен бик яхшы чамалыйм. Чөнки «Әрмәннәр, Карабахтан кулыгызны алыгыз!» дип язылган күктә эленеп торган чакырудан аның күзләренә чыккан куркуны күрәм.

Без өйгә кайттык. Юл буена Шушаникның каушавы кимемәде. Югыйсә беркем дә күз чите белән дә карамады. Нигәдер ул үзен һаман гаепле кешедәй тотты. Ишегадына үттек. Әнисе балконнан урамга төбәлеп тора иде. Безне күрүгә тышкы ишеккәчә йөгереп төште. Гомер буена күрешмәгән кешеләрдәй кызын кочаклап алып, күкрәгенә кысты, битләреннән үпте. Аннан, миңа табан борылып:

– Эхмеджан, безнең бер гаебебез дә юк, Аллаһы Тәгалә үзе шаһит, безнең эш түгел бу... – диде.

– Ни турында әйтүегез?

Өйгә дә кереп тормыйча, мин янә Ленин мәйданына юнәлдем. Анда митинг бара иде. Әрмәннәрнең Топханинск урманнарын кисүе халык күтәрелешенә сәбәпче булган икән. Аптырап калдым. Кайда соң ул Топхана? Белмим. Сөйләшүләренә караганда, Карабахта кебек. Ә ни өчен митинг Бакуда үтә? Ике-өч агач өчен меңәрләгән халык җыела микәнни? Җыелганнар икән, бу эшкә чик куярга кирәктер. Болар кычкыруны гына белә. Берсе трибунадан торып җитәкчелек иткәндәй, халыкка әле «Утырыгыз!» әле «Басыгыз!» дип боера. Аннан: «Кем утырмый – шул әрмән», – ди. Берсе соңарыбрак чүгәләгән иде, шуның өчен аны типкәләп алдылар. Йа Хода, ни көтә безне алда?

Соңрак чыгыш ясаучыларның телендә «Тау буе Карабах автоном өлкәсе» дигән җөмлә чагылып китте. Шуннан соң академик Аганбекянның «Фигаро» дигән француз газетасына биргән әңгәмәсе хакында сөйли башладылар. Трибунага интеллигенция вәкилләре, тарихчылар күтәрелде. Митингта әрмән кызы Шушаник биргән кебегрәк сораулар ишетелмәде, күбесе аңлатмаларга кайтып калды. Аннан, әрмәннәр тарихи ватаннарыннан азәрбайҗаннарны куалар икән, дип сөйләштеләр. Кайберәүләрне үтергәннәр, кайберәүләрне тере килеш торба тишегенә тыгып, ике башын томалап куйганнар, ди. Бер хатын-кызның аркасына самовар беркетеп, шунда су кайнатканнар, ди. Йөкле хатыннарның корсагын ярып җибәргәннәр, тумаган да балаларны кылычтан үткәргәннәр, ди. Әрмән хачын аларның күкрәгендә яндырганнар. Карабах әрмәннәре Милли Карабах автоном өлкәсен Азәрбайҗаннан чыгарып, Әрмәнстанга кушуны сорыйлар, ди. Референдум да үткәргәннәр, шушы максатны яклап тавыш та биргәннәр, ди. Йа Аллам, дөрес ишетәмме мин? Әмма дөрес иде. Шуңа Шушаник та, әнисе дә шөбһәгә төшкәннәр. Димәк, алар бу хакта хәбәрдар булганнардыр?

Мин өйгә кайттым. Шушаниклар ишеген шакыдым. Ишекне ул куркып кына ачты.

– Нигә өнең алынды? – дип сорадым.

– Өйдә әнием белән икәү генә. Әти белән энем Гадрутка киттеләр. Куркудан ипигә дә чыга алмый торабыз, – дип җавап бирде.

– Сезгә кем сүз әйтсен?.. Нәрсәдән куркасыз?

– Әрмән булуыбыздан.

– Алайса, ипине үзем алып кертермен.

Әти өйгә соң гына кайтты. Ул шәһәрдәге хәлләрдән хәбәрдар иде. Без табын янына утырдык, шулчак ишек шакыдылар. Шушаник икән. Фатирга үтеп тормыйча гына ул минем колагыма берничә җөмлә пышылдады. Шатлыктан очып китә яздым. Әти-әнинең сөенечем сәбәбен белергә теләүләрен аңлап, берни дә яшермәскә булдым:

– Әти, әни, тиздән сез әби белән бабай булачаксыз, – дидем.

– Кайчан өйләнергә өлгердең соң әле? – диде әти.

– Күптән әйтәсем килеп йөрим. Мин... Шушаник белән... күптән бергә инде...

Әти белән әни өнсез калды. Мин куандым. Татлы хыялларга чумдым. Кыз туса да ярый, Шушаник кебек чибәр, акыллы, гыйлемле булыр дип уйладым. Әмма әти белән әни урындыкка ябышып калгандай, ни әйтергә белми катып, кашларын җыерып утыра бирделәр.

– Хәзер нишлисе инде, улым?

– Ничек «нишлисе»... Яучы җибәрәсе. Бүләкләр җыегыз. Туйга әзерләнегез. Үзебезнең гореф-гадәтләр белән...

– Бәлки бәрәннәрен дә чакырасыдыр? – диде әни, төрттереп. – Әрмән кызын алам дисең, шәһәрдә ни хәлләр барганны күрмисеңмени син? Кеше көлдермәкче буласыңмы? Туган-тумача ни дияр?

– Ничек аңларга сине, әни, кичә «Шушаник, балам минем» дидең, бүген «әрмән кызы»на әйләндеме? Ул сезнең күз алдында үсте бит. Без балачактан бергә. Ул – мине, мин аны яратам. Хәзер балабыз туачак. Иртәгә без Шушаник белән ЗАГС ка барачакбыз. Теләмәгәч, туйны ясамасагыз да була.

– Улым, Әрмәнстанда, Карабахта әрмәннәрнең ни кыланганын күрмисеңме, шушындый чакта син өйгә әрмән килен алып кайтмакчысыңмы?

– Әйе! Киленегез булыр ул. Безнең фамилияне йөртер. Кирәк булса, безнең дингә күчәр, милләтен алыштырыр.

Шулчак тынлык урнашты. Әти ашаудан туктады. Балконга чыгып, тәмәке тартып керде. Үз янына чакырып алды, каршысына утыртып:

– Улым, буласы булган инде монда. Синең намусың балага ятимлектә үсәргә юл куймас. Әмма бер тарихны яхшылап тыңла әле, – диде. – Берзаман бер әрмән мөселман буласым килә, ди икән. Мулла янына барган. Мулла барлык йолаларны аңлаткан. Әрмән аларны һичкарусыз башкарып чыккан. Ни кушса – шуны эшләгән. Тантаналы рәвештә сөннәткә дә утырган. Соңгы йоланы башкару вакыты җиткән. Мулла мәчет ишегалдына кабер казыткан. Янәшәсенә табут куйган. Моны ак кәфенгә төргән. Табутка яткыргач: «Әй, Вазген, синең мөселманча исемең ничек була?» – дип сораган. «Мамед», дип җавап биргән тегесе. Шуннан дүрт ир-ат Вазгенны табуты белән күтәреп, өч мәртәбә кабергә төшереп кире алганнар. Һәрберсендә мулла: «Вазген китте, Мамед килде. Вазген китте, Мамед килде. Вазген китте, Мамед килде», дип кабатлаган. Шуннан мулла Вазгенны табуттан чыгарган да: «Син, Вазген, бүгенге көннән Мамедка – мөселманга әверелдең, хәзер инде безнең дин кушканча яшә», – дигән.

Берзаман Мамедның шашлык ашыйсы килә башлаган. Әрмәннәр аны дуңгыз итеннән генә ясый. Ислам дине исә бу гамәлне тыя. Мамед белә, әлбәттә. Шуңа ислам гореф-гадәтләренә туры китереп, башын кыйблага каратып, сарык суйган. Шашлык пешереп ашаган. Нигәдер бер дә тәмен тапмаган. Ун көннән тагын шашлык әзерләгән, тик янә дуңгыз итеннән алган ләззәтне тоймаган. Теләге бик көчле булган, ул бу хәлдән чыгу юлын эзли башлаган. Ниһаять, тапкан, ишегалдына кабергә охшаган чокыр казыган. Дуңгыз баласын әрҗәгә салган да өч тапкыр шунда төшереп менгергән. Һәр очракта: «Дуңгыз китте, сарык килде. Дуңгыз китте, сарык килде. Дуңгыз китте, сарык килде», – дип кабатлаган. Шуннан дуңгызны суеп, шашлык пешереп ашаган...

Улым, менә шушы хикәятне онытма син. Исемен үзгәртсә дә, фамилияңне, динеңне алса да, әрмән ул барыбер әрмән булып кала. Теләгәнеңне эшлә. Калганын үзең хәл ит.

Әтине игътибар белән тыңларга тырыштым. Бер мизгелдә башымда Дездемонаның әтисе Отеллога әйткән сүзләр ялтлап китте: «Төнлә дә, көндез дә саклан, Мин алданган күк алданма!» Нигәдер әтинең сүзләре Отелло фаҗигасен исемә төшерде. Вазген турындагы хикәятне тулысынча аңлап бетермәсәм дә, күңелгә шик керде. Ни белән бетәр бу... белмим.

Иртән без Шушаник белән ЗАГСка киттек, гариза калдырдык. Ул минем фамилиягә күчәсен әйтте. Шул ук вакытта исемен дә алмаштырырга теләде. Баштарак ризалашмадым.

– Шушаник, миңа синең исемең ошый. Эндәшкән саен Шушаны исемә төшерә. Алыштырма.

– Ахмед...

– Мине һәрчак Эхмеджан дип атый идең түгелме? Ни үзгәрде соң әле?

– Бүлдермә мине, Ахмед. Шушаник дип, әти кушкан миңа. 906 елда хакимлек иткән Сюник династиясе хакименең хатыны Ашота Сюни хөрмәтенә. Синең сүздә дә хаклык бар. Шушага да бәйләп карарга мөмкин.

Хәзер инде әһәмияте юк, мин Сюсан булачакмын. Сюсан Мамедова. Матур яңгырый бит, ә?

– Әйдә, үзең теләгәнчә ит, алайса.

Бер ай үтеп тә китте. Безне рәсми теркәделәр. Шушаник Сюсан Мамедовага әверелде. Паспорт алыштырганда, милләтен азәрбайҗан дип яздырды. Әтисе, энесе белән Гадруттан кайткач, кияве буларак, мине үз фатирына теркәде. Үзләре прапискадан төшеп, банктагы акчаларын алып, янә Гадрутка кайтып киттеләр. Озатканда, күршеләр елап хушлашты. Ә Шушаник Манучарян, Сюсан Мамедовага әйләнеп, әтисе фатирында торып калды. Әтисенең миңа – азәрбайҗанлыга яздырган фатирында.

Айлар үтте. Сюсан мөселман диненә күчте. Хиҗаб киде. Улыбыз туды. Сюсан теләгәнчә, аңа, Әрменийе дигән борынгы төрки кабилә исеменнән Әрмән дип исем куштык. Моңарчы ишеткәнем дә юк иде, әлбәттә. Китапханәдә актарынып, ул моңа дәлил дә табып кайтты. Һәм мин ризалаштым. Яңа исем иде. Төрк Мен бар бит, нигә Әр Мен булмасын икән? Иң мөһиме: улыбыз чын ир-егет булып үссен. Милли күтәрелеш елларында, митингларда бу исем матур яңгырады. Мине мактаучылар да табылды хәтта.

Ул елларда Сюсан бөтен күрше-тирә әрмәннәргә ярдәм итте. Куркыныч янаганда, фатирыбызга яшереп торды. Җәйдән җәйгә генә кирәк дип тоткан дачабыз да бункерга әверелде. Ә әрмәннәрдән бушаган фатирларны эзләп килгән качаклар хатынымны хиҗабтан күреп, гафу үтенеп, кире борылып киттеләр. «Якын-тирәдә бушаган әрмән фатирлары юкмы?» дип сораучыларга ул итагатьлек саклап: «Үзебез дә Карабахтан, Шушадан яңа гына күченеп килдек. Шуңа беркемне дә белмибез әлегә», – дип җавап бирде.

Еллар үтте, вакыйгалар берсен-берсе алыштырды. Якын-тирәдә бердәнбер әрмән кызы – азәрбайҗанлы һәм мөслимә – Сюсан Мамедова гына яшәп калды. Әти-әниләр дә, мин үзем дә инде аның кайсы милләттән булуын оныттык. Әмма әтинең теге сүзләре бер дә хәтердән чыкмады.

Сюсан үзен чып-чын азәрбайҗанча тотты. Ике улыбызны да – Әрмән белән Әрсенны төрки рухта тәрбияләде. Зирәк хатын шул...

Мин эштә уңышларга ирештем. Башлыгым белән дә дус яшәдек, гаиләләр белән аралаштык. Хатыннарыбыз да дус иде. Балаларыбыз бер мәктәптә укыды. Башлыкның хатыны Гарангуш исемле. Кайчак ул ялгыш аны Айкануш дип атый. Минем кебек. Кайчак бит Сюсан диясе урынга «Шушаник» дип куештырам. Ул шул чакта куллары белән авызымны каплый: «Балалар ишетә күрмәсен», – ди.

Беркөнне без Санкт-Петербургка сәяхәткә киттек. Чик тикшерүе аша үткәндә, аэропорттагы миграция хезмәте хезмәткәре балаларыма кул сузып:

– Хай, Армен, Россиягә рәхим итегез! – дип эндәште.

Мин шаккаттым. Алар балаларның яртылаш әрмән икәнен каян белде икән?

– Армен түгел, Әрмән.

– Сезнеңчә генә Әрмән ул – эрменнәр, ә русча, әрмәнчә Армен була. Әрмән, Бөек Әрмәнстан. Сәлам, Арсен.

– Арсен түгел, Әрсен.

– Нинди аерма күрәсездер? Ярар, үтегез.

«Хай»ның инглизчә «исәнме» дигән сүз икәнен мин соңыннан гына белдем. Димәк, инглизләр дә әрмәннәрдән килеп чыккан. Уйга калдым. Кая карама – шунда әрмән. Миграция хезмәте кешесе дә әрмән иде, шуңа балаларның яртылаш әрмән булуларын сизгән дә инде ул. Тик ничек? Кан авазымы бу? Алар бер-берсен тиз таный шул. Хиҗаб аша да.

Мин иреннәремне тешләдем. Шушаник, әрмәннәрдән йөз чөергән булып, азәрбайҗанга, мөслимәгә әверелгәндәй кыланып, азәрбайҗан исеме дип, балаларга әтисе – Армен, энесе – Арсенның исемен кушканмы? Әтисенекен генә түгел, дәүләтенекен, милләтенекен! Азәрбайҗан дәүләте эчендә үз дәүләтен булдырган. Безнең илдә Әрмән, Әрсеннарны карап үстерүче мондый булдыклы затлар күпме икән? Алар нәфрәткә яки бирешүчәнлеккә лаекмы? Балаларда кем каны көчлерәк ага: әтиләренекеме, әллә әниләренекеме? Алар өчен ана теле кайсысы? Ватаннары?

Шушаник миннән: «Азәрбайҗан егетенең әрмән кызын яратуына ышанасыңмы?» дип сораганда, ник: «Әрмән кызының азәрбайҗан егетен яратуына ышанасыңмы соң?» дип сорамадым икән? Белмим, андый мәхәббәткә ышангандырмы-юкмы, әмма мин аның үз халкына, милләтенә булган чиксез тирән мәхәббәтенә инандым.

Бөтен дөньяда, барысы да Шушаниктан туган яртылаш төрки, яртылаш әрмән балаларын үзләренеке итеп санаячаклар. Төркиядә алар – Әрмән, Әрсен, Россиядә, Украина, Америка, Әрмәнстанда, Прибалтикалда – Арсен, Армен булачаклар. Ахыр чиктә, мәгънәсе «әрмән», «әрмәнстан» «Армения»не белдерәчәк.

Югыйсә «Әрмән» дигән исемне аларга без – азәрбайҗаннар биргәнбез. Совет илендә үз дәүләтләрен төзесеннәр дип, Әрменийегә борынгы төрки җирләрне бүләк иткәнбез. Урысча да, инглизчә дә ул «Армения» дип атала, «Арменииан» төрки исем белән тиңдәш. Дөнья картасында «Мин – хай, ә дәүләтем – Айастан» дип тавышланып әйтүчеләргә без: «Сез – әрмәниләр, гасырлар дәвамында безгә кайгы китерүче», дибез. Шул сәбәпле чынбарлыктагыга караганда да, бу халык борынгырак күренә. Без аларны әдәби әсәрләребезнең геройлары итәбез. Азәрбайҗан егетенең әрмән кызына булган мәхәббәтенә дан җырлыйбыз. Әмма әрмән кызының азәрбайҗан егетенә булган сөюенең, үз халкына, милләтенә мәхәббәте янында, исәпкә дә алып тормаслык бәләкәй һәм вак икәнен күрсәткәнебез юк. Үзебезнең шәхси файда, омтылышларыбыз өчен әрмәнне дә туганым, дип атарга әзербез. Әрмән хатын-кызларының үз милләте, аның киләчәге хакына, төрки ирен уртак түшәктә «сөйгәнем» дип иркәләве янәшәсендә безнең томаналык шулкадәр көлке тоела.

...Чик сакчысы паспортыма мөһер суга. Мин әтиемнең «Шушаникка өйләнәм», дигәч, суккан мөһерен искә төшерәм. Ниһаять, күзләрем ачылды. Әмма соң инде... Әтинең сүзләрен онытырга теләп, күңелем түрендә тар гына кабер казыйм. Үзалдыма өч тапкыр:

«Шушаник китте, Сюсан килде. Шушаник китте, Сюсан килде. Шушаник китте, Сюсан килде...» дип кабатлыйм...

*Русчадан* **Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА** *тәрҗемәсе.*

# ТЫНЫЧСЫЗ ХИССИЯТ БАЛКЫШЫ

Әдәбият белемендә кат-кат расланганча, чын шигъриятнең нигезен тәшкил иткән бәрәкәтле җирлектә сәнгатьнең башка төрләренә баглы элементлар да бар. Шигъри телне өлешләп шәрехләгән чакта әүвәл музыкальлек хасияте калкынып куя. Аһәңлелек... Бездә «көйләм шигыре» төшенчәсе тикмә-тиккә генә яшәп килми. Әйе, тезмә әсәрне сүзләр белән тыгыз бәйләнгән көйгә, шагыйрь йөрәгенең аерым ешлыктагы кайтавазына тыңлаучылар хаклы. Шигърият музыкадан аерылгысыз. Гадәттә, әлеге табигый үзенчәлекне нечкәләп аңлаучы каләм әһелләре үзләренең сәләт мөмкинлекләрен бүтәнчә шәкелдә киңәйтергә омтыла. Шагыйрь Наил Касыйм – менә шундыйларның берсе. «Сүзләрдән белмәссең хәлемне, /Аңларсың, тыңласаң җырларым...» Ике гармоник башлангычның уртак рухи максатка үзара көчәеп тоташуын авторыбыз «Синең өчен җырлыйм» исемле әсәрендә шулайрак күрсәтеп үтә. Гомумән, назымны тулыландырган музыкага мөнәсәбәтен ул үз иҗатында әледән-әле белдерергә ярата.

*Нинди сихри музыка!*
*Кузгата ул хәтер катламнарын,*
*Үткәннәргә бүгенгене ялгый,*
*Киләчәкнең тоям атлауларын.*
*Тылсымнарга һәм назларга –*
*Иядер син мең үзлеккә!*
*Моңлы күңелемне дәшеп торган*
*Зур бер дөнья син, музыка!..*

«Бу гаҗәеп музыка»

Гаҗәбә, үзендә дә аһәңлелек оеткысын яшәткән шигырьне махсус рәвештә көйгә салып, бүтән төрле яңгырашлы рухи кыйммәтләр тудыру соклангыч могҗиза кебек тоела. Акыллы затлар дөрес искәрткәнчә, җирдә музыкасыз тормышны бөтенләй күзаллап булмый. Әле язу уйлап табылмаган ерак заманда да зур потенцияле кавем тезмә үрнәкләрне телгә кертә. Милли профессиональ музыка барлыкка килмәгән кадими чорларда да бу кыйтгалар халык һәвәслеге белән җырга әйләнеп киткән. Шушындый искитмәле борынгылык ачыла. Аңлашылганча, әлеге тирәнлек алдында шәхси җаваплылык кичергән авторлар гына ошбу жанрны сәнгатьчә үстерүдә күркәм уңышка ирешергә мөмкин. Ифрат олуг таләп. Монысын Наил дә бик яхшы беләдер. Юкса Татарстанның халык язучысы Гариф Ахунов аңарга өлкәннәрчә ныклы ышанычын багламас иде. «Күңелдәге мөһим фикеремне әйтми калдыра алмыйм, – дип белдерә ул. – Арча төбәгеннән үсеп чыккан 30 әдип янына тагын берәү – җырчы шагыйрь Наил Касыйм да кушылды. Үз-үзенә даим таләпчәнлек күрсәтүче, халыкчан нигездә иҗат итүче егетебез җыр поэзиясенә инде үз сүзен, үз моңын, үз табышларын өстәргә өлгерде».

Белүебезчә, олы сәнгать турында һәрьяклап уйланучылар матурлыкны шигърият чишмәсе итеп таный. Һәрхәлдә, кулына каләм алырга теләгән шәхес ошбу хакыйкатьне

тирәнтен аңларга тиештер. Моның өчен озаклап әзерлек үтү лазем. Бөек Тукаебыз, әнә, вәгазьчедәй әйткән: «Балаларымызның күзе гүзәл нәрсәләр күрергә вә борыннары да хуш вә татлы исләр иснәргә ияләшсен». Мәшһүр якташының бу акыллы киңәшен Наил Касыйм да үзенчә хуплый. «Бар дөньям чистара, пакьләнә,/ Чәчәкләр белән сөйләшсәм», – дип тәмамлый ул «Чәчәкләр өләшәм» исемле лирик шигырен.

Шөкер, Наил Касыймга чәчәкләр телендә озаклап сөйләшергә, гомумән, матурлыкны күңеленә яшьли үткәзеп үсәргә язган. Аның туган авылы Ашытбаш табигый гүзәллектән мәхрүм түгел. Арча районының шушы соклангыч төбәгендә барысы да – урман, болыны да, елга, күле дә бар. Әле кечкенә чакта Наил үзенең әнисе дөньяга килгән Иябашка баргалап йөргән, Кырлай белән чиктәш авылда Апушның аяк эзе калган сукмаклар буйлап узган. Илаһи хозурлык! Газиз әбисенең катгый күзәтчелеге астында сәйран кылучы хиссиятле малай хәтта Габдуллаҗанны сагынып сулкылдаган мәгълүм инештә дә коенгалап алган. «Бәлки, әлеге инешнең суы тәнгә сеңеп калгандыр... Шигырь язу теләге биредә уянмады микән?!» Балалык елларын Наил Касыйм әнә шулай хәтергә төшерә. Ул туган җирен данларга һәрвакыт җайлы форсат таба. «Казан арты» дигән шигырьдә дә шул горурлык хисе аңкып тора.


Наил Касыймов классик шагыйребез Сибгат Хәким белән. 1986 ел.

*Казан арты! Синдә яше-карты*
*Шигырь сөйли, җырчы, гармунчы.*
*Санап кына бетерерлек түгел –*
*Берүзеңнән күпме язучы!..*

*Казан арты, бар соң нинди серләр*
*Синең ямьле, нурлы җиреңдә?*
*Әллә монда чәчеп үстерәләр*
*Шагыйрьләрне, моңны, җырны да?!*

Әлбәттә, әлеге дә баягы матурлык эстетик җәһәттән үтә катмарлы. Безгә аны яшьли тоя белү кирәк. Өлкәннәр киңәш иткәнчә, иң камил зәвык дәресен әүвәле табигатьнең үзеннән ал. Шушындый сабак кешене иксез-чиксез фикерләү офыгына алып чыга, аннан инде омтылышлы затны акыл-рух культурасы биеклегенә күтәрә. Шигърият телен сурәтле итеп саныйбыз икән, ошбу һәвәслекне дә җир-анадан өйрәнү хәерле. Гармониялелек... Монысы назым өчен гаять зарур хасият. Гармония үрнәге дә – шул табигать дөньясында. Тумыштан берелер күзәтүчәнлек үзеннән-үзе уйлануга этәрә. Кәгазьгә хисләр түгелә. Бәгырь телгә килә. «Сүзләр җитми хисем аңлатырга, / Йөрәгем бит сөйли барысын!..» Шагыйрь Наил Касыйм «Йөрәгемне аңла» исемле әсәрендә, мөгаен, югарыда тасвир кылынган халәтне үзенчә аңлатырга телидер.

Бүгенге заманда шигъриятькә килүнең кат-кат тапталган сукмагы шәйләнә: урта мәктәп, филологик факультет, газета-журнал редакциясе... Кырлайда белем алган Наил дә яшьли әдәби иҗат белән шөгыльләнә башлый, «Ялкын», «Яшь ленинчы» кебек матбугат басмаларында үзенең тәүге шигырьләрен чыгаруга ирешә. Берчак Казаннан әдипләр килә. Беренче шигырьләре үк өлкән каләм әһелләрендә өмет уяткан егетне атаклы университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегенә барырга өндиләр. Әмма туры сүзле Наил Касыймов «Төзүче булам!» дип кырт кисә. Бәлки, сөекле әтисен шактый иртә югалту гаме аның күңелендәге үҗәтлекне шулай ташытып куйгандыр. Шагыйрьлек таҗын кигәч тә ул әлеге темага кайткалый.

*Әти иртә китте, әни калды,*
*Кулга тотып биш яшь баласын.*
*Олы малай... Мин тәртәгә кердем:*
*«Ярдәм булсын, әни армасын!»*
«Тормыш арбасы»

Дөресен генә әйткәндә, төгәл фәннәр буенча югары белем алучы заттан шәхсән үзем бернинди риясыз рәвештә көнләшеп куям. Иҗат өлкәсендә андыйлар байтак. Билгеле, сәнгать белән фән арасына тимербетон дивар корып булмый. Образлы фикерләү ягыннан аерылып торган Владимир Маяковский шигъриятгә математик формулалар төгәллеген тикмәгә генә күрмәгәндер. Аналитик мәкалә язу барышында да шул математика сиңа үзенчә булышачак. Кыскасы, Наил Касыймовның Казан төзүче инженерлар институтына укырга керүе адашып йөрүгә тиңләрлек ниндидер гайре табигый хәл түгел. Гадәттә, мондый шәхес үзләштергән белгечлеге юнәлешендә дә, шулай ук әдәбиятта да иркенләп эшли. Аңа төрле вазыйфалар башкарырга туры килә: төзелеш оешмаларының берсендә өлкән инженер, сәүдә тармагына караган учреждениедә директор, Татарстан дәүләт телестудиясендә өлкән редактор, шәһәр мәдәният идарәсе башлыгының беренче урынбасары, юллар төзү идарәсе башлыгы урынбасары, ТР Мәдәният министрлыгында бүлек мөдире... «Вакыт тап тагы моңлы җырга!» «Яшәү яме» дип исемләнгән шигырендә кисәтүле төстә өндәп белдергәнчә, өлгерлеген раслаган зат үзенең каләменә дә һәрдаим тугрылык саклый.

Сүз дә юк, югары уку йорты лекцияләренә йөргән чорда Наил Касыйм архитектура серләрен дә өйрәнә. Биналар салуның башка сәнгать төрләре белән бәйләнеше кызыксыну халәтендәге үсмердә ихлас гаҗәпләнү хисләре уята. Архитектураны «катып калган музыка» итеп күрү, ихтимал, аның хиссиятен әүвәл әлеге институтта дулкынландыргандыр. Америка архитекторы Франк Райтның үз коллегаларын шагыйрьгә тиңләве дә ят тоелган һөнәрне сайлаучы егетнең гамьле күңелен озаккача дәртләндерә. Кара, биредә дә әдәби иҗат өчен кирәкле, дөресрәге, һәркемгә хаҗәт күпьяклы белем бирелә ләбаса. Төзү маһиры математика, тарихны яхшы белергә, ирекле рәвештә рәсем дә ясый алырга, кайвакыт фәйләсуфча фикер йөртергә дә тиеш. Гүзәл әсәрдәй кабул кылыначак корылмага гармония аеруча мөһим өлешен кертә. Шәкел гадилеге дә зур әһәмияткә ия. Автор стиле исә күзгә бәрелеп торсын... Күрәбез, «шигырь җене» йогынтысында яшәгән студент техник вузда да файда таба. Өстәмә китаплар да күп мәгълүмат сеңдерә. Аның әзерлеге тирәнәя төшә. Әгәр беренче җырлары ук уңыш казанган икән, димәк, каләм әһеле рухи җирлектә тәҗрибә тупларга өлгергән. Шушы жанрның классигына әверелгән Гөлшат Зәйнашева да яшь дустының кинәт танылып китүенә игътибар бирә: «Наил Касыйм – тормышчан шигъри образны ике-өч строфалы җыр текстында оста үстереп, тулы бер тәэсирле картина тудырырга сәләтле шагыйрь».

Янәдән кабатлап әйткәндә, җыр-моңның төкәнмәс чишмәсе халкыбыз күңеленнән башлана. Безнең ихтыяҗ да бик күптәннән мәгълүм. Шушы уңайдан таныш ядкарьнең («Ай җаный, вай җаный») аерым җөмләсе хәтергә килә: «Сезгә нинди җыр кирәк?» Әлеге сорау һәрчак актуаль. Кайтаваз күк яңгыраган сөаль яңа авторларга да кагыла. Җавап бер генә – яхшы җыр кирәк! Андый әсәрләр рухиятне сафландыра, аң-зиһенгә шифалы йогынты ясый. Күңелгә утыручан юшкын да шул җырлар ярдәмендә юыла. Йөрәкнең түреннән чыккан аһәңле сүзләр адәм баласына затлылык өстәргә сәләтле... Шагыйрь Наил Касыйм белән әңгәмә корганда һәрвакыт диярлек фикерләр уртаклыгы тантана итә. Үтә четерекле мәсьәләләрнең дөрес чишелешен эзләгән чакта дустым «Кем коткарыр?» ише шигырен укып куяр.

*Уйларымнан теләп арынырга,*
*Чыгып киттем айлы кырларга.*
*Күпме яшәп, кыргый калган адәм(?!) –*
*Җавап эзли күңел шуңарга...*

*Аңладым мин моңнан моң туганын,*
*Кешелеккә таптым юл туры, –*
*Кыргыйлыктан безне моң коткарыр,*
*Бар ышаныч синдә, ай нуры!*

Җырның ертыгы юк, дип искәртә халык. Вәләкин ертык-пыртык хәзер бөтен дөньябызны тутырды. Җырның сәнгатьчә асылын аңлап бетермәүче һәвәскәрләр эстрадабыз мәйданында күзгә күренеп ишәя бара. Өлкәнрәк әдипләр көрсенеп әйткәнчә, сүзе килсә – көе килми, көе килсә – сүзе килми. Музыка сөючән күңелгә берничек тә тәэсир итмәгән нәмәрсәне тыңлаган чакта русча башкарыла торган бер җырның шундый кушымтасын искә төшереп куясың: «Кому это надо – / Никому не надо; / Кому это нужно – / Никому не нужно». Нота да белмәүче ниндидер көйчегә «буш сүзләр җыелмасы» биреп, ансат кына танылып китәргә теләүче кәсепчеләр күпчелек статусын алды. Алар арасында берничә йөзләп текстны әмәлләүче рифмачлар да байтак. Исәп тутырырга язылган йөзләрчә «шлягер»ның ике-өче гавамда яшәп калса икән. Бу җәһәттән Наил Касыймга катгыйлык катыш таләпчәнлек хас. Үз милләтенең зәвыгын бозуга илткән вак-төяк максатлар табигать гармониясен тоеп үскән шагыйрьгә бөтенләй ят. Иҗади хезмәттәшлектә тудырылган җырларның тыңлаучы мәхәббәтен казануы, һичшиксез, матурлыкка ияләнгән калебнең ихласлы иҗтиһатына турыдан-туры бәйледер. «Түгелде хисләр, түгелде – / Иң саф, якты хисләрем!..» Исеме күрсәтелмәгән әлеге шигырь юлларында да бу принципка тугры калуны сиземләргә мөмкин.

Табигый ки, сәнгатьнең теге яки бу төре һәрбер иҗатчыда шәхси караш тудыра. Аерым жанрның серләренә төшенү дәрәҗәсен дә шул шәхсияткә муафыйк эчке мөмкинлекләр билгели. Гаять әһәмиятле булып саналган тел-өслүп үзенчәлеге дә бит нәкъ менә шушындый юнәлештәге эзләнүләр нәтиҗәсендә барлыкка килә. Музыканың кече формасына әйләнеп кайтсак, кайбер сөйләшүләрдә сораулар да бирелгәли: ни соң ул җыр? Әлбәттә, Наил Касыйм да аны үзенчә шәрехли. «Төсләр тупланышы салават күперен хасил итә, хисләр ташкыны исә җыр тууга этәрә, – ди ул. – Кеше самими кичерешләрен аңлатып бетерә алмаса, ничектер ихтыярсыз каләм белән кагәзьгә үрелә. Бер күңелдән ташып чыккан тойгылар отыры көчәя башлый, шагыйрь сүзләренә композитор, җырчы, тамашачы ихлас хисләрен өсти. Алкышлап кабул кылынган уртак хиссият казанышы тора-бара моңга сусаган киң дөньяга тарала... Төшенүебезчә, җыр ул – хиснең балкышы!»

Гадәттә, шагыйрьнең беренче әсәре күпләрдә кызыксыну уята. Ә Наил Касыймның тәүге җыры нинди теманы үзәккә куйган соң? Аның сәрләүхәсе үк бик аңлаешлы сөйли: «Ак яулыклы әнием». Озакка сузылачак эшчәнлек шушындый бисмилладан башлана. Толлык хәлендә биш баласын аякка бастырган Фәүзия ханым, шиксез, мондый өлгедәге музыкаль мәдхиягә бар яктан да лаек. Композитор Луиза Батыр-Болгари тарафыннан көйгә салынган җырны халык алдында әүвәл мәртәбә Искәндәр Биктаһиров башкара. Яңа әсәрдән миллион тыңлаучы үзенең әнисен танып ала. «Ак яулыклы...» Автор нигә әле шундый исем кушкан? «Бездә күпчелек хатын-кызлар ак яулыкны олыгайгач кына бәйләргә күнегә, әнине исә кечкенә чагымда ук акбүзле кыяфәттә күрә идем, – дип хәтергә төшерә ул. – Ак яулык бит ул – татар халкының традицион символы, чисталыкка өйрәткән сафлык билгесе».

*Ак төсләрне әллә күп сөйгәнгә,*
*Чәчләрең дә бүген ак синең.*
*Күңел күгемдә син – якты кояш,*
*Ак яулыклы әнием минем!*

Гыйбрәтле мисаллар күрсәткәнчә, һәр җырның да үз тәкъдире бар. Кече шәкелдәге әсәрләр туктаусыз язылып тора. Бәгъзеләр бу эшчәнлекне конвейерга да куйгалый. Әмма француз сәясәтчесе Поль Лафарг хаклы: «Тәкъдим кылынган җыр яңа мода буенча тегелгән күлмәк түгел, аны халыкка көчләп тагу гайре табигый хәл булыр иде». Шөкер, Наил Касыйм шигырьләренә иҗат ителгән үрнәкләрнең күпчелеге

төрле-төрле зәвыкка ия җәмәгатьчелек сынавын уңышлы үтте. Әйтик, моннан 30-35 еллар элек әйләнешкә кергән «Ак яулыклы әнием», «Су буенда учак яна», «Гүзәл җирем», «Туй күлмәге», «Авылым тавышлары», «Алтын балдак», «Кайтуыңны сагынырмын», «Ай Дунай!», «Соңлама!» кебек җырлар хәзер дә җанга якын. Шагыйрь Наил Касыймның әсәрләренә иң беренче игътибар итүче күренекле композиторларыбыз Луиза Батыр-Болгари, Рәшит Кәлимуллин, Резеда Ахиярова, Вадим Усманов, Ганс Сәйфуллин, Зөфәр Хәйретдинов булды. Аның җырларын Хәйдәр Бигичев, Зилә Сөнгатуллина, Венера Ганиева, Айдар Фәйзрахманов, Зөһрә Шәрифуллина, Асаф Вәлиев кебек талантлы җырчыларыбыз бик теләп үз репертуарларына кертте. Дөрес, әлеге исемлек дәвамлы. Аларны үзара рух-ташлык бәйләгән. Әйе, мондый сәнгатьтә тандемлык зарур.

Элгәрләр тәгъбирен кабатлап әйткәндә, ай белән көн уртак, җыр белән көй уртак. Кече синтетик әсәрләргә алынган сәнгатькяр аһәңле бергәлек серләрен яхшы белә. Әмма зуррак талант потенциалына ия каләм әһеле аерым калып кысаларында гына чикләнеп кала алмый. Үзеңә ирек бирү мәслихәт. Татарстанның халык шагыйре Сибгат Хәким, мәсәлән, төрле иҗади карашлар булуына ишарәли. «Яңа җыр халык күңеленә керсә генә, аны кузгатса гына үз максатына ирешә, – дип искәрткән ул. – Моның юллары байтак. Шәхсән үзем махсус рәвештә текст язуга караганда мөстәкыйль шигырьдән төртеп чыккан җырны якынрак күрәм». Аннары аксакал тезмә шәкелдә катгыйлык катыш нәтиҗә чыгара:

*Җыр язмышы кош язмышы кебек,*
*Бер тирәдән үтә юллары, –*
*Йә ул кайчак җиргә егылып төшә,*
*Күтәрелә яки югары...*

«Җыр язмышы»

Тәкъдиргә рәхмәт укырлык. Беренче җырлары төрле концерт залларында ешрак яңгырый башлаган чорда Наил Касыйм Сибгат ага фатирында иркенләп гәпләшү бәхетенә ирешә. Остаз аңа җыр текстының шигырь рәвешендә дә яши алырга тиешлеге турында сөйли, газиз халкыбыз тормышына баглы лирик әсәрләр иҗат итүгә зуррак игътибар бирергә куша. Күренә ки, командирлык вазифасын онытып бетермәүче фронтовик әдип яшь каләмдәшенең көч-куәтен яңа биеклекләргә юнәлдерә. Олуг затның астарлы сүзләре Наилнең хәтеренә уелып кала. Аларның тирән мәгънәсенә төшенү өстәмә дәресләр үзләштерүгә бәрабәр. Гүяки мөхтәрәм якташы аны һәрдаим милләт улы булып көрәшергә, һәдия кылынган талант мөмкинлекләрен тагы да киңрәк ачарга чакыра. Югарыда аерым өземтәсе китерелгән мәкаләсендә өндәү билгесе куеп, ул татар шигърияте варисына үзенең әманәтен тапшыра шикелле: «Шагыйрь күңеле белән халык күңелендә яткан уртак хисне тап син, шуны әйтә бел!»

Хыялый Пегас-ат канатлы дөлдөл рәвешендә күзалланса да, аны иярләүче затлар җирдәге тормыштан аерылмаска бурычлы. Әдәбият белгечләре аңлатканча, шигърият әүвәл мәгыйшәт кыйммәте булып санала, аннары гына ул сәнгать дәрәҗәсенә күтәрелә. Аны халык аңыннан юдыру мөмкин түгел. Каләм милләттән читләшә алмый. Хәтта тәҗрибәле һәвәскәрлек югарылыгында язылган җиңелчә шлягерлар да күп очракта гавамны рухландырган «социаль барабан» вазыйфасын үти. Элгәрләр кадерләгән туфракта ныклы кыяфәттә басып торган Наил Касыйм да үз иҗатында яшәү мәгънәсенә баглы мөкатдәс гамьне әледән-әле сиздерергә омтыла. Байтак шигырь башлары да шул максатка хезмәт итә: «Гүзәл җирем», «Сүнмәс җыр син, Татарстан!», «Халкым»... Ошбу әсәрләрнең лейтмотивы уртак. «Исеме зур, эзле Җир шарында», – дип олылый шагыйрь газиз халкын. Тукай феномены мисалында да ул сакраменталь бәйләнешне күрә. «Кырлайга кайту» багышлавында, әнә, ачыктан-ачык әйтеп бирелә:

*Ятимлеге аның – язмыштандыр,*
*Бөеклеге ләкин – халыктан!*
*Тукай үзе халкын үксезлектән*
*Йолып алыр өчен калыккан!*

Аһәңсазлар әйтергә яратканча, саф күңелдән җырлый алу үзе олы бәхеткә тиң. Саф күңелдән... Әлбәттә, әлеге гаять әһәмиятле таләп каләм ияләренә дә кагыла. Катгый инанганлык җирлегенә тоташкан ихлас уй-гамьнәр генә кеше акылының галәми киңлекләренә үтеп керергә мөмкин. Ә Наил Касыймның экспрессив әсәрләрендә эчкерсезлек аеруча калку чагылыш таба. Аның җырга тартылуы да шул самимилек хикмәтеннән киләдер. Кайчак һәркемгә мәгълүм хакыйкатькә дә үз мөнәсәбәтеңне белдерергә кирәк була. Гомумән, шәхси асылыңны чынлап сиздергән очракта сәмави илһам кошы телеңне чишәр. Менә шундый мул ихласлыктан турылык та ерак йөрми. Болар табигый төстә мәгънәви тирәнлеккә, композицион җыйнаклыкка ирешү әмәлләрен ача... Ошбу сыйфатларның барысы да сүз сәнгате өчен мөһим. Алар Наилгә дә бик килешеп тора. Моның нәкъ шулай икәнен әдәби тәнкыйть тә таный. «Наил Касыйм – гаять нечкә күңелле, тирән хисле лирик шагыйрь, – дип язды Мансур Вәлиев. – Ул бөек элгәрләре салган юлны лаеклы рәвештә дәвам итә, бүген халыкны даим борчыган иң җитди мәсьәләләрне игътибар үзәгенә куя. Автор безгә җиткерергә теләгән фикерләрен матур-матур образлар аша аңлата белә, үзенчә фәлсәфи нәтиҗәләр дә ясый».

Шагыйрьне күкләр белән бәйле хыялый затка тиңләсәләр дә, ул чынбар тормыш шартларын исәптә тотып яшәргә бурычлы. Шигъри күзаллау дөньяви уйларга тоташкан очракта гына безнең могҗизалы лира үзенең миссиясен үтәргә мөмкин. Каләм әһелен күзәтүчәнлек тә киң офыкларга алып чыга. Игътибарлы караш шулай калыплаша. Фикер иясе вазифасын да башкарырга теләүче шәхес мондый кыйммәтләрнең зарурлыгын бар тирәнлегендә аңларга тиеш. Буш назымчының киләчәге юк. Сафсата шигырьгә бөтенләй килешми. Ә менә Наил Касыймга санаулы сүзләр кыскалыгы хас. Аның әсәрләре күңел кайтырлык дәрәҗәдә озынга сузылмый, образлы зиһенләүдә ул тыгыз синтагмаларны якынрак күрә. Лаконизм дигәннән... Автор әлеге принципларны һәрвакыт якларга омтылуын «Әрсезләргә» исемле багышлавында да сиздереп уза: «Бу тормышта кайчак бер китап та / Дәрдмәнд булыр өчен бик җиткән!»

Битараф булмаган тынгысыз шагыйрь һәммә нәрсәне игътибарлап күзәтә. Шулай ул язар өчен хаҗәт җимне дә туплый. Әлбәттә, тормышның күп кенә күренешләре каршылыклы хисләр дә уята. Сизгер йөрәк күпне тоя. Кайвакыт кешенең бөтенләй кирәкмәс гамәле яшәеш симфониясен ямьсез диссонанска китерә. Чынлап та, бездә эчке гармония җиткелекле түгел әле. Үзеннән-үзе аңлашылганча, аек башка сыймаслык хәлләр кабатланса, иҗатчының җаны үзенчә аваз бирә. Туктаусыз кызыксынган күңел призмасы аша гади әйберләр дә зурайтып күрсәтелә. Әнә, Наил Касыйм басуда йөргәндә дә зур мәгънә бирерлек нәтиҗәләр ясый

*...«Икмәк булса, җыр да булыр!» –*
*Әйтеп тә соң карыйсыз...*
*Моңсыз кырлар икмәк бирмәс,*
*Кала күрмик тургайсыз!*

«Тургай»

Чынбарлык шуны күрсәтә: үзеңчә язу рәвеше ягыннан аерылып тору каләм әһеленә алай җиңел генә бирелми. Әгәр тотрыклы тел-өслүбеңне чынлап булдырырга телисең икән, әүвәл үзгә хасиятен сиздерткән холык-фигылеңне тыңларга өйрән. Гамәл кылу алымын гәүдәләндергән стиль рухи сыйфатлар җирлегеннән башлангыч ала. Кеше гап-гади хат җибәрергә ниятләсә дә, ул ап-ак кагазьдә бөтен натурасын ача. Шигырьне

йөрәк тибешенең график сурәтләнешенә тиңләү буп-буш нигезгә корылган купшы чагыштыру түгелдер. «Кабатланмам, кабатланмам!» – диеп, / Кабатланмас җаным газаплана...» Исеме куелмаган бер шигъри парчасын Наил Касыйм әнә шулай төгәлли. Аңлашылганча, китерелгән юлларның авторы да үз «почеркы» турында уйлангалый. Ә аның иҗатында үзенчәлекле билгеләр күп. Аларның кайберләре хакында алдарак әйтеп үтелде. Мондый аерымлык шагыйрьнең лирик үрнәкләрендә дә, җыр сәнгатендә дә калку чагылыш таба. Вөҗүде теләгән өслүпне сакларга омтылу «Күңелем каршында тезләнде» (1996), «Күңелем кояшы» (2013), «Су буенда учак яна» (2020), «Тыңлар идем тавышыңны...» (2020) кебек китапларда аеруча ачык күренә. Шәхеснең эчке табигатенә муафыйк төстә барлыкка килгән әдәби ысул, гадәттә, үтә катлаулы тормыш хикмәтләрен дә гади кимәлдә төшендерергә булыша. Наил бусын да бик яхшы тоя. «Хисләремне туплап, такыя үрәм», диелә «Аңла мине...» әсәрендә. Ассызыклап белдергәндә, әлеге такыяләрнең һәммәсендә дә Наил Касыймның келәймәсе шәйләнә.

Шунысы күзгә ташлана: Наил Касыймның шигъри лексиконында «каршылык» сүзе байтак очрый. Бу табигый, шау-шулы гасырларны кичкән тормышыбыз үзе тоташ каршылыклар аша йөгерүне хәтерләтә. Әйе, шигырь иң яхшы тәртиптәге иң яхшы сүзләрдән тора. Аның каравы җиребездә тәртипсезлекләр артуга бара. Нишлисең, һәрбер сынау кешелеккә каршылыклар алып килә. Әнә, Наил Касыйм «И, хатын-кыз!..» әсәрендә хәтта гүзәл затларны да бу дөньяның «каршылыклар белән тулы зур сере» итеп күрә. Монысы артык борчу тудырмый. Адәм баласының мәхәббәте дә үз драмаларын күрсәтергә хирыс. Халык өстенә туктаусыз ябырылган авырлыклар исә үтә кырыслыгы җәһәтеннән беренче урынга чыга. Алар сизгер музаны гомерлек утка сала. Наил Касыйм да шул хәлдә яши. Әле кирәкмәс ыгы-зыгылар оештыру аркасында да күп көчебез бөтенләй диярлек әрәмгә китә. Түбәндә китереләчәк исемсез шигырен язган чакта, мөгаен, Наил Касыйм шундый вазгыятьне истә тоткандыр.

*Кыйналды күңел, кыйналды –*
*Кыйнады ялган, нахак.*
*Акны кара диючеләр*
*Күземә бәрде һәрчак...*


*Кыйналды күңел, кыйналды –*
*Түзәргә кирәк – беләм.*
*... Яшәве авыр дөньяда*
*Шагыйрь йөрәге белән!..*

Барча каршылыкны җиңеп, каләм киләчәккә атлый. Кайчак ул «Тузанлы юл» шигырендә сурәтләп үтелгәнчә, ышанычлы вөҗданына катгый сораулар да биргәләп куя: «Мин дөрес бараммы?» Әлбәттә, юнәлешең туры, хаклык тарафдары! Сөекле халкың белән бергә булганда, мәсләкне бутау куркынычы һичкемгә янамас. Сине безнең милләтебез үзенеке итеп саный. Һәрбер яңа җырыңны тыңлаучы отып кала. Лирикаң күңелдәге уй-гамьнәрне уята. Күпме композитор синдә рухи иҗатташын күрә. Танылган җырчылар арасында да шул абруеңны югары тотасың. Янәдән Сибгат аганы хәтергә төшереп әйткәндә, «Әйбәт җыр бары шагыйрь, композитор һәм башкаручының бердәм януында гына туа...» Шулай иҗтиһат кылган Наил Касыйм, сүз дә юк, рәсми дәрәҗәдә олылап хөрмәтләүгә лаек. Аңарга гаделәтле рәвештә «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем, ТР Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең Һ.Такташ исемендәге әдәби премиясе бирелде. Әле өстәлеп торыр. Элгәрләр тавышын көчәйтеп яңгырат. «Тургай» әсәрендәге ишарәтне бимазалы зиһенебездә саклыйк: «Куакларга посып түгел, / Ул күккә менеп җырлый!»

Шулай биектә калсаңчы, тургай!

**Зиннур МАНСУРОВ,**
*Татарстанның халык шагыйре*

# ДӘВАМЧЫСЫН КАЛДЫРЫП КИТТЕ



Аңа әле нибары җитмеш кенә яшь тулган булыр иде. Ни кызганыч, сөйгән эшеннән аерылу, бу хәлне үзе өчен шәхси фаҗига итеп кабул итү аның гомерен кыскартты. Сүзем танылган тәнкыйтьче, әдәбият галиме, шагыйрь һәм күренекле нашир Мөдәррис Вәлиев турында. Шәхси фаҗигасенә әверелгән эшеннән аерылу дигәнем аның матбагачылык, наширлек хезмәте белән бәйле. Илдә башланган үзгәртеп кору нәтиҗәсендә яңадан үз эшчәнлеген башлап җибәргән милли «Мәгариф» нәшриятының ябылуы аның директоры булып эшләгән Мөдәррис Вәлиев өчен чын мәгънәсендә фаҗигагә әйләнде шул. «Мәгариф» нәшрияты ябылгач, Мөдәррис «Мәгариф-Вакыт» дип аталган шәхси нәшриятын ачты. Татар мәктәпләре өчен дәреслекләр, методик әсбаплар, кулланмалар чыгаруны дәвам иттерде. Ләкин милли дәреслекләр чыгару Татарстанда дәүләт ихтыяҗы булудан туктаган иде инде. Фәннәрне предмет буларак, татар телендә укыту гына түгел, туган тел һәм әдәбият дәресләрен укыту вакыты да кыскартылды. Элекке дәреслекләргә ихтыяҗ бетте, аларның күләме кискен кимеде. Нәтиҗәдә, милли дәреслекләр чыгара торган «Мәгариф» нәшриятының да кирәге калмады. Бу бөтен мәгариф хезмәткәрләре өчен, милләтебез өчен гаять зур фаҗига иде югыйсә. Мөдәррис Вәлиев исә моны аеруча кискен кабул итте.

М.Вәлиев китап бастыру, матбагачылык эшендә азу теше чыгарган гаять зур белгеч иде. Ул китапны эчтәлеге, эчке бизәлеше, тематикасы, нинди мәсьәләләрне күтәргән хезмәт булуына карап, аның полиграфик эшләнешен укучы игътибарын үзенә җәлеп итәрлек итеп әзерләүне зур осталык белән оештыра белә иде. Әсәрләренең затлы китап рәвешендә дөнья күрүен теләгән һәркем – язучы булсын, галим-голәма булсын, барысы да «Мәгариф» нәшриятында басылып чыгуын тели һәм көтеп ала иде. Бу җәһәттән, матбагачылык эшендә Мөдәррис Вәлиевкә тиңнәр наширләр арасында бик аздыр.

Гомеренең зур өлешен мөхәррирлек, наширлек эшенә багышлаган Мөдәррис Вәлиев үзенең иҗат юлын шигырьдән башлап җибәрә.

Ул Татарстанның Әлки районы Мәүләшә (рәсми документларда Яңа Камка) авылында 1953 елның 30 маенда туа. Мөдәррис ике айлык кына чагында егерме сигез яшендә әтисе сугышта алган яраларыннан үлеп китә. Малайны әнисенең Татар Мулласы авылында яшәүче әтисе Габделмәгыйзь Маннапов гаиләсе тәрбиягә алып үстерә. Бу – шагыйрь Шамил Маннапов туган гаилә. Шигырьләр яза башлауда малайга Шамил абыйсының тәэсире зур булгандыр. Алай дисәң, Мөдәррис Әлки район газетасына биргән бер интервьюсында «Шамил абыйның шигырь белән мавыкканын мин шактый соң белдем», – дип әйтә. Ә иҗатының башлангычы хакында сораганда: «Әби миннән кайсысы – армиядә, кайсысы укуда булган улларына хат яздыра иде. Ул еш кына шигырьгә күчеп китә, бу халәт, акрынлап, миңа да йоккандыр, күрәсең», – ди. Димәк, язу сәләте аңа әнисенең әнисеннән килгән.

Мөдәррис әнисе туган авылда – башлангыч, Алпар авылы мәктәбендә урта белем ала. Башлангыч мәктәптә укыган вакытта шигырьләр яза башлаган малай, Казан дәүләт

университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга кергәч, Салих Маннапов тәхәллүсе белән яшь шагыйрь булып танылa. Мин университетка укырга кергәндә, ул инде дүртенче курста укучы студент һәм булачак яшь әдипләрне тәрбияләүче «Әллүки» түгәрәгенең җитәкчесе иде. Соңгы курсларда укыганда, ул шәриктәшләре арасында беренче рецензияләре республика матбугатында күренә башлаган өметле яшь тәнкыйтьче булып танылды. Тулай торакта без кара-каршы күрше бүлмәләрдә генә яшәгәнлектән, еш аралаша идек. Җитмәсә, ул – үзе шикелле үк яшь, инде әдипләр арасында талантлы каләм иясе булып танылган, без бүген Шәүкәт Гаделша дип белгән Шәүкәт Сибгатуллин белән бүлмәдәш. Әле яңа гына мәктәп тәмамлап килгән унҗиде яшьлек малайны, мине дип әйтүем, менә шушы ике егет үз канатлары астына алдылар, төпле киңәшләрен бирделәр, үзләре тирәсендә булачак әдип итеп тәрбияләделәр дип саныйм. Университет дипломы алганнан соң «Татарстан яшьләре» газетасында эшли башлаган Мөдәррис мине, журналистика бүлегенең өченче курсын гына тәмамлаган студентны, җәйге каникул вакытында үз янына, мәктәпләр һәм югары уку йортлары бүлегенә практика үтәргә эшкә чакырды. Алдагы ике курстан соң студентлар төзүче отрядларында эшләп чыныгу алган ташчы буларак, мин төзүче отрядлар тормышын яктырту буенча комсомол өлкә комитетына эшкә урнашкан идем. Газетага да урнашу бу эштә минем өчен бер дигән практика, булачак һөнәрем өчен тәҗрибә мәктәбе булды. Уку елы башлангач та мин газетада эшләвемне дәвам иттердем. Ә Мөдәррис мәктәпләр һәм вузлар белән бергә газетада республика әдәби тормышын яктырткан, шулай ук яшь әдипләребез иҗатына багышланган язмалары белән чыгыш ясый иде. Шул ук вакытта инде өлкән әдипләребезнең иҗатын өйрәнеп, саллы-саллы мәкаләләр язды. Төрле басмаларда урын алган әлеге язмалары белән аны 1982 елда, әле бер китап та бастырып чыгармаган килеш Татарстан Язучылар берлегенә кабул иттеләр. Бу вакытта инде ул «Татарстан яшьләре»ннән «Казан утлары» журналына күчеп, аның әдәби тәнкыйть һәм фән бүлеге өлкән редакторы булып эшли иде. Берлеккә кабул итү комиссиясендә ул вакытта әдәбиятыбыз корифейлары булып танылган Сибгат Хәким (комиссия рәисе), Рафаэль Мостафин (әдәби тәнкыйть секциясе җитәкчесе), Нил Юзиев, Атилла Расих, Туфан Миңнуллиннар аның иҗаты турында этрафлы сүзләрен әйткәннәр.

«Китабы, ишетүемчә, 1984 елда басылып чыгачак. Кульязмасы кабул ителгән, нәшрият планына кертелгән. Ләкин китап чыкканны көтеп тору мәҗбүри түгелдер, дип уйлыйм. Тәнкыйтьче кешенең китабын чыгару – шактый кыен мәсьәлә ул. Иптәшнең мәкаләләре матбугатта еш басылып тора, иҗат багажы безгә таныш. Шулай булгач, бернинди дә киртә булмаска тиеш», – дип әйтә үзенең йомгаклау сүзен ул вакытта Туфан Миңнуллин.

Комиссия тәкъдимен Язучылар берлеге идарәсе дә бердәм хуплый.

«Өметле яшь тәнкыйтьчеләр әдәбиятка сирәк килә. Мөдәррис – шундыйларның берсе. Миңа Мөдәррис Вәлиев мәкаләләрендә әдәбиятның сәнгатьчеллеген тою сыйфаты ошый. Яшь тәнкыйтьче фикерен үз вакытында, кыю әйтеп чыга белә...» – дигән тәнкыйтьче Фәрваз Миңнуллин ул утырышта. «Тәнкыйтьтә бүген ике юл ачык аерыла: язучылар тәнкыйте һәм академик-гыйльми тәнкыйть. Мөдәррис Вәлиев шушы ике юнәлешнең уртасыннан, аларны берләштереп бара: әдәби яктан тәэсирле, фәнни яктан анализлы итеп яза», – ди Тәлгат Галиуллин.

Күрәсез, ул вакыттагы әдәби тәнкыйть өлкәсендә ат уйнатучы агайлар Мөдәррис Вәлиев йөзендә үзләренә лаеклы алмаш күрәләр, аңа зур өметләр баглыйлар.

Башта тәнкыйть бүлеге өлкән редакторы булып эшләгән М.Вәлиев бераздан «Казан утлары»ның баш редактор урынбасары вазифасын били һәм шул елларда журналның йөзен билгеләүдә, әдәбиятыбызның матбугатта чагылышын күрсәтүдә төп рольне башкаручы кешеләрнең берсенә әверелә. 1989 елда исә ул, гомумән дә, әдәбиятыбызны дөньяга таныту, язучыларыбызның әсәрләрен укучыларга илтеп җиткерү үзәге булган Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррире вазифаларын башкаручыга әйләнә. Ә

тагын ике елдан, китап нәшриятыннан аерылып чыгып, мөстәкыйль нәшрият булып яши башлаган милли «Мәгариф» нәшриятының җитәкчесе итеп билгеләнә. Үзгәртеп кору җилләре алып килгән милли күтәрелеш рухы белән канатланып, Татарстан мәктәпләрен генә түгел, татарлар яшәгән барлык төбәкләрне дә милли дәреслекләр белән тәэмин итү өчен тырышлык куя башлады һәм зур уңышларга да иреште. Россиянең төрле төбәкләрендә тупланып яшәүче милләттәшләребез «Мәгариф» нәшрияты әзерләп чыгарган дәреслекләрдән һәм укыту әсбапларыннан, кулланмалардан файдалана башлады. Нәшрият болар белән генә дә чикләнмичә, актив рәвештә балалар әдәбиятын пропагандалау белән шөгыльләнә. Ел саен классик әдипләребезнең балалар өчен язган әсәрләре белән бергә бүгенге язучыларның китапларын да бастырып чыгара. Бигрәк тә яшь язучыларның беренче китапларын бастыруга игътибар бирә.

Кайда гына эшләсә дә, нинди генә урын биләсә дә, Мөдәррис иң элек әдәбият белгече, тирән белемле редактор булып кала бирде. Ул хәтта директор булып утырган килеш тә, нәшриятта басыла торган китапларның җентекләп редакцияләнүен таләп итә һәм үзе дә редактор булып кала иде. Инде шактый вакыт «Мәгариф» нәшрияты директоры булып эшләвенә карамастан, күп кенә әдипләр аның йөзендә беренче чиратта редактор күрә иде. Әйтик, Әмирхан Еники, 2000 елда Татарстан китап нәшриятында чыга торган күптомлыгының баш редакторы нәкъ менә Мөдәррис Вәлиев булуын теләп мөрәҗәгать иткән. Аның бу үтенеч хатын бу урында тулысы белән китерергә булдым.

*«Мөхтәрәм Мөдәррис әфәнде!*

*Сезгә зур бер үтенечем бар: Сез чыгачак беренче томның (сүз Татарстан китап нәшриятында чыгарга тиешле биштомлык хакында бара. Р.Х.) «баш редакторы» булсагыз иде. Бу бик мөһим, бик кирәк. Бигрәк тә китапның үзе өчен...*

*Сезне республикада белмәгән кеше юктыр. Китап эчендә Сезнең исемегез булуы ул китапның дәрәҗәсен күтәрәчәк... Хәзер «баш редактор» дигән вазифа бармыдыр, юкмыдыр – мин ачык кына белмим, әмма Сез беренче томның «баш редакторы» булырга тиешсез. Бу, ихтимал, соңгы теләгемдер, ул үтәлергә тиеш.*

*Ихтирам белән, Әмирхан Еники.*

*10 январь, 2000 ел».*

М.Вәлиевнең 1984 елда басылып чыккан беренче китабы ук Шәйхи Маннур исемендәге премиягә лаек булса, шуннан соң бер-бер артлы чыккан тәнкыйть мәкаләләре, китаплары өчен ул Язучылар берлегенең тәнкыйть өлкәсендә бирелә торган Җамал Вәлиди исемендәге премиясен алуга ирешә. 2003 елда яшь язучылар иҗатын пропагандалау өлкәсендәге хезмәтләре өчен аңа Муса Җәлил исемендәге Республика премиясе бирелде. 2004 елда ТР Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең Абдулла Алиш исемендәге премиясе белән бүләкләнде. Мөдәррис Вәлиевкә республика дәрәҗәсендә бирелгән соңгы мәртәбәле бүләк – 2020 елда лаек булган Гавриил Романович Державин исемендәге премия. Ул аңа әдәби тәрҗемә өлкәсендә башкарган хезмәтләре өчен бирелде.

Әйе, Мөдәррис Язучылар берлегенә тәнкыйтьче буларак кабул ителде. Ләкин аңа хәтле үк инде ул поэзиягә үз табышлары, үз аһәңе белән килгән шагыйрь булып формалашкан иде. Ул әле мәктәптә укыган вакытта ук беренче шигырьләре «Ялкын» журналында, «Яшь ленинчы» газетасында чыкканнан соң, Равил Фәйзуллин аларны укып, «Таныш булыгыз: Салих Маннапов» дигән кереш сүз белән «Татарстан яшьләре» газетасына тәкъдим итә. Соңыннан аның шигырьләре яшьләрнең «Идел» альманахында, «Казан утлары» журналында дөнья күрә. 1969 елда, Мөдәррис әле 9 класста гына укып йөргән чакта, ул аның турында менә ниләр яза: «Шигырьләрен игътибар белән күзәтеп, җентекләп укып барам. Миңа калса, яшьли ятим калып та, мәрхәмәтле, игелекле кешеләр куенында үксезлек күрмичә, тулы хокуклы гражданин булып чыныгып үсеп килүче, тырыш укучы, җәмәгать эшләрендә актив катнашучы Салихның күңел түрендә

шигъри талант чаткылары, кешеләргә әйтер сүзе, табигать күренешләренә, кешеләрнең яшәешләренә, гомумән, дөнья хәлләренә карата үзгә бер поэтик карашы бар».

Туксанынчы еллар азагында Мөдәррис, заманында Салих Маннапов тәхәллүсе белән матбугатта чыккан шигырьләрен туплап, үзенең «Яшьлектән хат» дигән беренче шигырь китабын бастырып чыгарды. Равил Фәйзуллин бу юлы да китапка карата битараф калмый. Ул аның әнә шул уналты яшьлек чагында үзе сүз башы язып чыгарган шигырьләрен искә ала һәм яңа китабы турында фикерен әйтә: «Үтә бер кызыксыну белән, үзгә бер халәттә, бер тында укып чыктым мин бу китапны. Кичерешләр дә үзгә иде: яшьлегем искә төште, моңланылды да, үземне эссе чүлдән талгын җилле яшел оазиска кергәндәй хис иттем, нечкә тоемга көйләнгән аерым строфалар сокландырды да, сискәндерде дә... Нәрсәгәдер яңага сусау булган, ахры (гәрчә миңа эшем буенча көнгә 150-200 бит язма укып чыгарга туры килә). Чын мәгънәсендәге профессиональ осталыкка, төгәллеккә сусау».

Тәнкыйтьчеләр бу җыентыкка тупланган шигырьләрне «элитар поэзия» дигән исем белән атадылар.

Мөдәрриснең күңеленә әнисенең әнисеннән күчкән шигырь орлыклары аның кече кызы Гөлназ күңелендә шытым биргән дип әйтеп буладыр.

Студент еллары хатирәсе булып, күңелдә Мөдәррис Вәлиевнең «Идел» альманахындамы басылган бер шигыреннән юллар саклана.

*Әти миңа ат бирде,*
*Иярлә дә чап, диде.*
..............................
*Сикереп мендек,*
*Егылып төштек,*
*Сер бирмәдек ятларга...*

2016 елда Мөдәррис Вәлиев иҗатына һәм тормыш юлына багышланган язмалардан Нурзидә Нотфуллина төзеп чыгарган «Рәхмәт яусын» дигән җыентыкта Гөлназның әтисенә багышлап язган бер шигыре бирелә. Бу көннәрдә исән булса 70 яшен тутырасы каләмдәшем, дустым Мөдәррис Вәлиевкә багышланган бу язмамны Гөлназның шул шигыре белән тәмамлар идем.

* * *

*Әти миңа:*
*«Гомер юлы озын, – диде, –*
*Иярләрсең дә*
*чабарсың, кызым», – диде.*
*Ат бирмәде,*
*бирде шаян уйнак колын.*
*(Шигыремнән чыгып чапса,*
*ни кылырмын?..)*
*Әти миңа:*
*«Колыныңны хәзердән, – ди, –*
*Сабантуйда узышырга*
*әзерлә», – ди.*

*(Мин – оттыра белми торган чабышкы бит,*
*Шул сүздән соң*
*кайгыларга сабыштым бит.)*

*Колын үсә,*
*уйнап хыял болынымда.*

*Беренчелек исе керә*
*борыныма!*

*(Әти анда... тышау ясый*
*колыныма,*
*Миңа таба карап ала*
*кырын гына.)*

*Нишләрмен, дим,*
*тагын шулай тышауласа...*
*(Туктап калам ич,*
*әтигә ошамаса*
*язганнарым, –*
*кулга каләм алмыйм бүтән!*
*Йә, кем инде*
*Тәнкыйтьчедән мактау көткән?!)*

*...Колын үсте*
*һәм булып чыкты...*
*йөк аты.*
*(Каушавыннан*
*әти*
*тавышын югалтты.)*

*Ә мин инде борыла алмыйм.*
*Мин – чабышта!*
*(Кулым*
*атымның ялына чатябышкан.)*

*Мәйдан гөрли...*
................................
*Шунда әти юатуы:*
*«Шигырь, кызым, чаптар түгел, – йөк аты ул.*
*Авыр йөкне тартып*
*үрләр менәсе бар;*
*Тормыш сабан туйларында*
*җиңәсе бар».*

*(Ну, әти!..*
*Кулдан төште китте каләмем...)*
*...Җиңелә-җиңелә*
*җиңәргә өйрәнәмен.*

Мөдәррис китте. Ләкин үз урынына җиңелә белми торган шагыйрә кызын калдырып китте. Кыска гомер юлында башкарган эшләренең дәвамчыларын калдырып китте.

Инде алда әйткәнемчә, Мөдәррис Вәлиев китап чыгару эшендә тиңе булмаган белгеч иде. Мәдәният министрлыгы, Язучылар берлеге, Татарстан китап нәшрияты җитәкчеләре колагына бер киңәш-тәкъдимемне белдерәсем килә. Шөкер, ел саен яңадан-яңа китаплар чыгып тора. «Мәгариф» нәшрияты яшәүдән туктаса да, китап нәшер итү эше бара, тукталмады. Республикада Мөдәррис Вәлиев исемендәге «Елның иң затлы китабы» дигән премия булдырасы иде. Бу аның исемен мәңгеләштерүнең бер чарасы булып торыр иде.

**Рафис КОРБАН**

# ЛЕГЕНДАР МИҢЛЕКАМАЛ

***(М.Әмирнең «Миңлекамал» пьесасындагы төп герой Миңлекамалның прототибының кызы Гәүһәр ханым белән әңгәмә)***

*– Гәүһәр апа, Сез – данлыклы Миңлекамал кызы. Мирсәй Әмирнең әниегезне прототип итеп алган әсәрен бөтен татар халкы белә.*

– Әйе, Миңлекамал Сөләйманова – минем әнием. Үз гомеремдә әниемә охшаган, кыю, үз-үзен аямаучы, сүз кодрәтенә ия, кыскасы, бар яктан да килгән башка хатын-кызны очратмадым дияргә була. Ул чыннан да легендар хатын-кыз иде.

*– Язучы Мирсәй Әмир 1943 елның җәендә ике айга якын Татарстан авылларында йөри. Авыл кешеләренә халыкара хәл турында докладлар сөйли. Халык тормышы белән таныша. Әсәр материалы шул вакытта табыла. Салкын Алан авылына килгән Мирсәй Әмир соңыннан нәкъ менә Миңлекамал апа турында язачагын әйттеме?*

– Колхозга вәкилләр күп килә иде. Без, балалар, Мирсәй Әмирнең исемен дә, аның язучы икәнен дә белмәдек. Өстенә кожанга охшаган соры плащ кигән бер абый, без аны «вәкил абый» дип кенә йөрдек. Әсәр язачагы турында ул әнигә дә әйтмәгән.

*– Мирсәй Әмир «Миңлекамал» драмасын режиссёрга 1944 елның башларында тапшыра. Хөсәен Уразиков әсәр белән танышуга ук аны сәхнәгә куярга алына. Миңлекамал роленә 43 яшьлек Мәрьям Сульваны һәм 38 яшьлек Галия Булатованы билгели. Репетицияләр башлана. Рольне башкарганда, артистларның образга тулысынча керүләрен, хәрәкәтләрендә төгәл эзлеклелекне саклауларын таләп итә. Ул ике состав белән дә бертигез көч куеп эшли һәм дублёрларның берсе икенчесен кабатламавына ирешә. Шул рәвешле сәнгати югарылыкта ике Миңлекамал образы иҗат ителә. Мәрьям Сульваның Миңлекамалы йомшак характерлы, тыйнак, басынкы... Ләкин үз дигәненә һичшиксез ирешә, чөнки ул – көчле ихтыярлы хатын-кыз. Тормышта күпне күргән. Колхоз тормышын яхшы белә, өстәвенә бик нык уйлап, фикерләп эш итә... Галия Булатованың Миңлекамалы – эчке хәрәкәткә ия кеше. Аның җиңел, дәртле хәрәкәтләре акылына караганда, хисләрен өстен итеп күрсәтә. Читтән караганда, ул күбрәк эчке сиземләвенә таяна кебек. Ул да – Мәрьям Сульваның Миңлекамалы кебек үз сүзендә нык торучан, көчле ихтыярлы хатын-кыз.*

*Гәүһәр апа, мин сөйләгәннәрдән чыгып, кайсы артистка әниегезне сәхнәдә тормыштагы кебек күрсәткән дип уйлыйсыз?*

– Әнием басынкы түгел иде. Эш дигәндә, чәчрәп тора иде.

*– Димәк, Галия Булатованыкы... Ә чынлыкта бу образ Галия Булатовага җиңел генә бирелми. Артистка Миңлекамал образының эчке дөньясын күз алдына китерә алмыйча йөдәп бетә. Аның бәхетеннән дип әйтикме, авылдан сеңлесе килә. Чәй табыны янында дәртләнеп, үз хәлләрен сөйли. Артта калган мәктәпне юлга салуын, колхозчылар арасында эш алып баруын... Көз көннәрендә дәресләрдән соң колхоз эшенә йөрүен... Кышларын утын кисүен... Халык арасында ел буе аңлату эшләре алып баруын... Галия Булатова сеңлесенең Миңлекамалга охшавына шакката. Шул рәвешле артистка горур, көчле, каты куллы җитәкче образын иҗат итә. Күп еллардан соң бу вакыйга турында ул «Миңлекамал образы ничек туды» исеме белән 1963 елның сентябрь санында «Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә») журналында мәкалә язып бастыра (15 нче бит).*

*Гәүһәр апа, драмада Миңлекамалны авылдашлары «Җенлекамал» дип атыйлар. Бу кушамат чынбарлыкка туры киләме?*

– Әйе, күп эшләр башкара алганга, «аңа җеннәре булышадыр» дигәннәр...



Миңлекамал Сөләйманова кызлары белән. 1936 ел.

*– «Миңлекамал» спектакленең премьерасы Татар дәүләт академия театрында 1944 елның 27 апрелендә күрсәтелә. Спектакльнең рәссамы Пётр Сперанский була. Премьера зур уңыш белән үтә. Язучы Газиз Иделле «Кызыл Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасының 10 май санында «Миңлекамал» пьесасы турында» дигән мәкалә бастыра. Спектакльгә югары бәя биреп: «...Бүгенге бөек сугыш чорындагы тыл темасына гаять актуаль булган «Миңлекамал» пьесасы автор Мирсәй Әмирнең дә, аны рекордлы кыска срокта сәхнәгә куйган режиссёр – Татарстанның атказанган артисты Хөсәен Уразиковның да, бөтен театр коллективының да уңышы», – дип яза... Тел белгече Латыйф Җәләй шул ук газетаның 14 май санында басылган «Миңлекамал» исемле мәкаләсендә: «Әсәрнең идеясе – гади кешеләр, гади татар хатын-кызлары образларында совет патриотизмын, аның күңел байлыгын, аның нинди зур эшләр башкарырга сәләтле икәнлеген күрсәтү», дип яза... Е.Гаккель «Красная Татария» (хәзерге «Республика Татарстан») газетасының 17 май санында дөнья күргән «Минникамал» дигән мәкаләсендә: «...Отличительная черта Минникамал – её не знающее пределов упорство в достижении поставленных перед собой целей. Это – настоящий полнокровный характер. Основа успеха в том, что автор и театр задались целью показать действительность правдиво, глубоко, во всей её сложности, без лакировки», дигән фикерне куәтли... Тәнкыйтьче Гази Кашшаф «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналының май ае санында «Патриотизм көче» исеме белән мәкалә бастыра. Ул анда: «Мирсәй Әмир иптәшнең «Миңлекамал» драмасы Татар дәүләт академия театрының 1944 елгы репертуарына колач җәеп килеп керде. Ул хәзер сәхнәдә уңыш белән бара, тамашачыларның җылы карашына очрый. Меңләгән хезмәт ияләре аны дулкынланып карыйлар, андагы дөреслекне һәм авторның кыюлыгын күреп канәгатьләнәләр», – дип, югары бәя бирә.*

*Гәүһәр апа, әлеге фикерләр белән килешәсезме?*

– Мәкаләләрендә үз фикерләрен дәлилләп язучылар барысы да бик төгәл әйткәннәр. Син укып күрсәткәндә, «Әнием нәкъ шундый иде» дип уйлап утырдым.

*– 1944 елны Татар дәүләт академия театры җәйге гастрольгә «Миңлекамал» спектаклен дә алып чыга, һәм ул Калинин, Чаллы, Минзәлә, Актаныш районнарында күрсәтелә. Спектакльне һәр җирдә яратып карыйлар. Бу спектакль эстетик тәрбия бирү чарасы гына булып калмый, ә турыдан-туры практик эшкә кулланма рәвешендә кабул ителә. Әниегезнең образы бик күпләр өчен үрнәк мисалга әверелгән. Сугыш чорында моның әһәмияте әйтеп бетергесез зур булган.*

*Гәүһәр апа, әниегез турындагы спектакльне гаиләгез кайчан карый алды?*

– «Миңлекамал»ны уйнарга Казан артистлары Сарманга килделәр. Мин 8 нче сыйныфта укый идем. Димәк, бу вакыйга 1945 елда булган. Фатир хуҗаларым артистларга минем Миңлекамал кызы икәнемне әйткәч, алар спектакльгә мине дә ияртеп бардылар. Әниемне уйнаган артистка апа битенә миң ясаган иде. Көтәм,

көтәм – сәхнәдә эти юк. Кайткач: «Нигә этиемне дә күрсәтмәделәр?» – дип еладым. Нindидер җитди сәбәп аркасында, әнием тамашага килә алмаган иде. Үзе турындагы сәхнә әсәрен ул башка вакытта карады.

*– Галия Булатова сокланырлык чибәр, зәвыклы, искиткеч талантлы актриса булган. Миңлекамал ролен ул югары дәрәҗәдә башкара. Нәтиҗәдә Галия Булатовага Миңлекамалы өчен 1945 елда «ТАССРның халык артисткасы» исеме бирелә, режиссёр Хөсәен Уразиков та шундый ук исемгә лаек була. Пьеса авторы Мирсәй Әмиргә «ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән исем бирелә. 1945 елда Бөек Җиңү көннәрендә дә «Миңлекамал» пьесасы буенча куелган спектакль күрсәтелә.*

*1957 елда Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы гөрләп уза. Анда Мирсәй Әмир әсәре буенча куелган «Миңлекамал» спектакле дә зур уңыш казана. Аның сәхнәдә куелышы түбәндәгечә бәяләнә: «Ценная работа театра – современный татарский спектакль из колхозной жизни – это «Минникамал». Он является большим достижением театра. ...Работа актрисы Булатовой в роли Минникамал заслуживает самой высокой оценки». «...И спектакль этот ценен не только своей тематической сущностью, он интересен тем, что здесь очень интересный образ героини, образ западает в память каждого из нас на долгие и долгие годы».*

*Декададан соң, театр Урта Азиядә Ташкент һәм башка шәһәрләрдә гастрольдә була. «Миңлекамал» спектаклен тамашачылар гадәттән тыш җылы кабул итәләр.*

*Шул елны Галия Булатова «РСФСРның халык артисткасы» дигән мактаулы исемгә дә лаек була. Декададан соң театр Ленин ордены белән бүләкләнә.*

– Галия Булатовадан соң Вера Минкина уйнады әлеге рольне. Иң шәп уйнаган артистка шул булды. Чөнки Миңлекамалның холкын, үз-үзен тотышын, сөйләшүен, хәрәкәтләрен ул нәкъ тормыштагы әниемнеке белән тәңгәл китерә алды. Аның уйнавын әнием дә бик ошатты.

*– Сезнең сүзне раслагандай, театр белгече Дания Гыймранова талантлы, халыкчан актриса турында менә нәрсә ди: «Вера Минкина башкаруында Миңлекамал образы түзем, кыю, фидакяр, нык ихтыяр көченә ия булган һәм, Бөек Җиңүгә зур ышаныч белән яшәп, тылда тырыш хезмәт куйган хатын-кызларга гимн булып яңгырый; бу образ, республика авылларына гастрольләр белән баргач, актрисага очрашып күрешергә туры килгән күп кенә реаль шәхесләрнең (прототипларның) сыйфат үзенчәлекләрен туплаган».*

*Гәүһәр апа, Миңлекамал образы артистка Зөлфирә Зарипова башкаруында да үзенчәлекле килеп чыкты. «Иң көчле образларының берсе – Миңлекамал, – дип яза аның турында театр белгече Ильтани Илялова. – Зөлфирә Зарипова башкаруында Миңлекамал гадәттән тыш батыр йөрәкле, кыю, чая хатын булып истә кала. Ул гражданлык бурычын тирәнтен аңлый, артка калган колхозда рәиснең авыр йөген дәһшәтле сугыш елларында үз җилкәсенә алуның никадәр мөһим һәм авыр икәнен чын йөрәгеннән аңлап, дәртләнеп эшкә бирелә».*

– Һәрьяклап булдыклы әниемә багышлап әсәр язган Мирсәй Әмирдән дә, Миңлекамалны сәхнәдә югары дәрәҗәдә ачып биргән артисткалардан да без тулысынча канәгать калдык. Бу спектакльне әнием телевизордан да карады. Фидакяр хезмәтен шулай бәяләгәннәренә бик шатланды.

*– Миңлекамал апага кагылышлы сорауларымның берсе. Әниегезнең иң күркәм сыйфаты турында әйтә алмассызмы?*

– Аны үтә дә гадел булды дип саныйм. Берничә мисал китерәм. Колхоздан ул берни алмый иде. Без җиргә сеңгән кара мунчада юындык. Киндер ашъяулыкка төрелгән ипи өйдәге югары шүрлектә саклана иде. Сугыш елларында бер телем ипине дә артык ашатмады әни. Без колхоз рәисе балалары булып йөрмәдек. Берсендә Сарман юлында җигүле ат белән куып җитте. Безнең җәяүләп мәктәпкә баруыбыз иде. Ризык салынган төенчекләребезне читән арбасына, ягъни тарантасына куйды да иптәшләремә: «Гәүһәр

яшәгән фатир хуҗасында калдырам, шуннан килеп алырсыз», – диде. Урыны булса да, мине үзенең янәшәсенә утыртмады. Мин дә сабакташларым белән җәяү атладым. Ул чакта әнием турында нәрсә уйлаганмындыр – хәтерләмим. Хәзерге акылым белән әнинең ул гамәлен хуплыйм. Беренчедән, барлык кешеләргә дә бертигез каравын тагын бер мәртәбә раслаган ул. Икенчедән, мине иптәшләремнең кырын карашыннан саклаган.

*– Әниегез көне-төне хөкүмәт эшендә. Өегездә ни хәлләр бар иде?*

– Алты почмаклы өйдә яшәдек без. Әтинең апасы да бездә. Әниемнең әнисе – Рәзифә әбием дә бездә. Аның күзләре күрми. Аңа куырылган борчак чәйнәп бирәбез. Әтинең сүзен тыңлыйбыз: тавышланып, әбине борчымыйбыз. Без, бала-чагалар, үзара тату идек. Миннән ике яшькә олырак Нәкыя апа белән икебезгә бер бишмәт иде. Ул кайткач, мин киеп китәм. Ат чанасына төялеп, чана шуабыз. Әския апа миннән – дүрт яшькә, ә Закирә апа – алты яшькә, Шаһидә апа исә унҗиде яшькә зуррак иде. Закирә апабыз 1924 елгы. Төнлә барыбыз бергә йоклыйбыз. Өй эчендә безнең янда бозау да, бәрән дә яши. Колхозга эш белән килгән вәкил дә бездә куна кала. Әтиебез – сабыр, тыйнак, тәрбияле кеше. Килгән кунакка да, өйдәгеләргә дә игътибарлы. Аның бик матур гадәте бар иде. Кыш көне кошёвкага җылы толып чыгарып куя, аннары капканы ачып, әнине озатып кала. Алда кучер өчен көйләнгән урында, кулына дилбегә тотып, әни үзе урнаша. Артта ике кеше аркасын терәп утырырлык урыны бар. Көймәле ул җиңел чананы «кашавай» дип тә, «кошевой чана» дип тә әйтәләр иде. Әни юлдан кайткач, әти теге толыпны янә өйгә алып кереп, кибәргә элә. Атны җигү-тугару мәшәкатьләре, әлбәттә, аның вазифасына керә. Әнине хуҗалык эшләреннән азат итеп, бөтен җаваплылыкны үз өстенә алган икән ул.

Безнең авыл урман эчендә. Әти Нәкыя апа белән мине урманга алып бара. Печән чабарга үзе белән чалгысын да ала. Без шома көпшә, балтырган, кузгалак җыеп ашыйбыз. Үзебез яланаяк. Аяклар чебиле.

Әтиебез өйдә колхоз өчен тубаллар ясый. Карт ир-атлар һәм егәрле хатын-кызлар, әти кабыктан ясаган шул киң түгәрәк савытны муеннарына асып, чәчүгә чыгалар. Көзен һәм язын тубал белән чәчкән арыш басуын кул тырмасы белән тырмаларга мәктәптәге 5, 6, 7 нче сыйныфларда укучы балалар ярдәм итә... Әтием мунчаладан бик күп итеп бау ишә. Дилбегә өчен, ди. Базардан сатып алсаң, кыйммәткә төшә икән. Әти колхозны шулай тәэмин итеп торды. Аның колхоздагы төп эш урыны янгын сүндерү белән бәйле иде.

Әтием барлыгы җиде баш умарта тотты. Умарталыгыбыз бакча артында гына урнашкан. Шул җиде умартаны ул, кыш чыгарга дип, идән астына кертеп куя. Бал кортлары уянмасын өчен без тавыш чыгармыйча, әкрен генә атлап йөрибез...

Әниебез һәрвакыт колхоздагы мәшәкатьләр белән мәшгуль. Безнең белән аралашырга аның вакыты да калмый. Аралашканда да, үзен бераз корырак тота. Ә әтиебез йомшак табигатьле. Ул безгә карата зур кайгыртучанлык күрсәтә. Төпчек бала булгангамы, ул мине ныграк ярата иде. Берсендә мине келәткә чакырып алды да (балыбыз шунда саклана иде) бал белән сыйлады. Берәр җирем авыртып, зарланырга әнием янына барсам, ул мине әтием янына «озата» иде...

*– Сугыш чорындагы ашау-эчү, кием-салым турында да әйтеп китмәссезме икән?*

– Ризыксыз тормадык. Бер хезмәт көне «1 таяк» дип йөртелә, аның өчен 100 грамм ашлык каралган. Төп ризыгыбыз бәрәңге булды. Табигатьтәге кычыткан, кузгалак, юкә бөресе, балтырган, юа, сәрдә, сарана безнең өчен иде.

Һәр гаиләгә ел саен дәүләткә 40 кг ит, 10 кг сары май, 100 данә йомырка, өстәвенә йон, киптерелгән бәрәңге тапшыру йөкләтелгән...

Киемне халык үзе әзерләп кия. Салкын вакытта кешеләрнең өсләрендә – сырма (телогрейка). Авылда тула басу өмәләре оештыралар. Иң элек йонны эрлиләр (һәр хуҗалыкта биш сарык асрарга рөхсәт ителә иде). Аркау буен, икенче төрле әйтсәк, тукыманың аркылы җебен тигез эрләсәләр, тула тизрәк керешә. Аннары сирәк кенә

итеп сугалар. Өй шартларында сугылган шул тыгыз, калын, тупас постау (сукно) туланың үзе була инде. Шуннан соң махсус читән өстендә әвәләп керештерәләр, тыгызлыйлар. Хатын-кызлар, җиңнәрен сызганып, җырлый-җырлый тула басалар. Тула оек, тула чикмән, тула эшләпә өчен тукыма шулай кулдан әзерләнә. Сәкегә дә тула палас җәя идек.

Аякка чабата киябез. Аны юкә яки карама кайрысыннан үрәләр.

Сугышчылар өчен өч бармаклы бияләйләрне, оекбашларны берәрсендә кич утырып бәйли идек. Аларны һәм җылы киемнәрне зур тартмаларда, «кыр почтасы» номерын күрсәтеп, фронтка җибәрәләр иде. Фронттагылардан өчпомаклы хатлар килгәч, бик шатлана идек. Рәхмәт хатлары бездә горурлык хисләре уята иде.

*– Колхоз рәисе Миңлекамал апа нинди иде?*

– Безгә дә, колхозчыларга да сүзне ике тапкыр кабатламый. Бер әйттеме – үтисең.

*– Колхоз рәисе итеп куюларын ул үзе сораганмы?*

– Юк, сорамаган. Аның гадәттән тыш активлыгын күреп, 1931 елда Салкын Алан авылында яңа төзелгән колхозга рәис итеп куялар. Хөкүмәт эше белән бик өшәнгәч, үзе теләп китеп бара: атлар карый, сыер сава. Авылдашлары соравы буенча 1940 елда тагын колхоз йөген тарта башлый.

*– Драма әсәрендәге Миңлекамал, авылдашлары киңәшен тотып, райком секретаре Гыйльманов кабинетына сугыш аркасында артта калган «Яшел алан» колхозына үзен председатель итеп билгеләүләрен сорап килә. Ул ил язмышы өчен борчылганга күрә шул адымны ясый.*

*Авылда эшче куллар бик нык кимегән, авыл хуҗалыгы кораллары җитешми... Икмәк өчен көрәштә халыкны батыр йөрәкле, тәвәккәл Миңлекамал җитәкли алган да инде.*

– Дөрес. Тормыштагы әнием дә батыр йөрәкле һәм бик тәвәккәл иде.

*– Гәүһәр апа, бистәбездә яшәгән Рауза апа Шиһапова – сугыш чорында Сарманда оешкан театр коллективы белән спектакльләр куеп йөргән кеше булган. Әниегез турында аңардан да сорашкан идем. Салкын Аланда алар еш булганнар. Рауза апа бик теләп, ерак хатирәләрен яңартты. Сәнгатьне аңлаучы Миңлекамал апа артист халкын һәрчак ачык йөз белән каршы алган. Фатирларга бүлеп керткән. Фатир хуҗалары артистларны ул биргән азык-төлектән аш-су әзерләп көткәннәр. Колхоз рәисе Миңлекамал апа кичен спектакль карарга килгән. Игътибар белән караган. Сәхнәгә менеп рәхмәтен әйткән. Үтемле итеп, мәгънәле итеп сөйли белгән. Һәрвакыт игътибар үзәгендә булган. Акыллы кеше икәнлеге әллә каян күренеп торган. Авылдашлары булдыклы рәис белән хаклы рәвештә горурланган. Миңлекамал апа һәр кешенең гозерен үтәргә тырышкан. Төрле юлларын табып ярдәм иткән, әмма эшгамәленә хәрәм кертмәгән. Гади итеп киенгән. Чиста өс-баш белән йөргән. Аны бөтен кеше белгән. Аны үрнәк итеп күрсәткәннәр. Сөйкемле, батыр йөрәкле Миңлекамал апа шул заманның герое булган. Ул ил өчен эшләгән. Рауза апа миңа шушыларны сөйләгән иде. Аның рухы шат булсын. Амин!*

– Әйе, әни куйган максатына ирешүче, изге ниятле җитәкче иде. Сугыш чоры булгач, икеләтә-өчләтә артыграк тырышлык куярга туры килгән инде аңа.

*– Сугыш хәбәрләрен ничек белә идегез?*

– Телефон юк, радио юк, электр юк. Бары тик 1944 елда гына безнең ишегалдына тартмалы радио куйдылар. Авыл халкы фронт хәбәрләрен шуннан тыңлый иде. Икенче елны зур тартмалы радио кайтардылар, аны авыл клубына урнаштырдылар.

*– Әниегезнең тормыш юлы, гаилә хәле турында да сөйләшеп алыйк әле.*

– Әнием 1902 елның 10 июнендә Баткак авылында Миңлехан бабамның ярлы гаиләсендә туган. Аның бертуган абый-апалары – Әхмәтҗан, Әхмәтхан, Миңлеҗамал. Сәкинә исемлесе алты яшендә вафат була. Рәзифә әбием – Минзәлә өязенең атаклы

Бикташев бай нәселеннән. Аның бик кыйммәтле хәситәсе – күкрәк бизәмәсе бар иде. Андагы көмеш тәңкәләр, кыйммәтле ташлар күз явын алырлык матур. Хәситәгә йөзек тә беркетелгән. Аның кашы астында камыт энәсе күзе кадәрле генә тишек бар. Шуннан караганда, бер кырыенда – Мәдинәдәге мәчет, икенче кырыенда Мәккәдәге мәчет рәсеме күренә. Кызганыч, ул затлы хәситә юкка чыкты. Рәзифә әбиемнең чулпысын Салкын Алан авылы мәктәбендә музей ачылгач, шунда бүләк иттем. Бабам Бохарай байларында кучер булып эшләгән. Юка киенгәнлектән, салкын тидергән һәм авырып вафат булган. Әнием алты яшендә этисез калган. Ул Теләнче Тамак авылындагы атаклы мәдрәсәдә төпле дини белем алган. Укытырга хокук бирә торган таныклыгы да булган аның. Беркөнне, мәдрәсәдә укучы кызларның бауга кер элгәннәрен күреп, Нигъмәтулла хәлфәләре аларның ничек эшләгәннәрен күзәтеп тора. Өч кыз арасыннан Миңлекамал исемлесе юылган-чайкалган керләрне селкеп, матур итеп тигезләп элеп бара. Егет үзенә тормыш иптәше, җәмәгате итеп нәкъ аны сайлый. Әнием унбиш яшендә шул авыл мәчетенең мулласы Нигъмәтуллага кияүгә чыккан. Чынлыкта яңа карашлы булуын, мәдрәсәдә дөньяви фәннәрне укытуын өнәмичә, «хәлфә» дигән сылтау белән ирен сәнәкчеләр үтергәннәр. Бер гаепсезгә шаһит китүчеләр күп булган. Тол калган 20 яшьлек әниемнең сабыйлары да озын гомерле булмаган. Хаммамы да, этисе вафатыннан соң дөньяга килгән Ләйләсе дә авырып үлгәннәр.

Урта Кәшер авылына кунакка барган әнием тәрәзә аша бер атчыны күреп ала. «Бу кем?» – дип сорый. Биш бала белән тол калган Нәбиулла турында сөйләп бирәләр. Үзеннән 26 яшькә өлкән кешегә ул үзе теләп кияүгә чыга. Без, этием белән әниемнең дүрт кызы, этинең беренче хатыныннан туган балаларны үз туганнарыбыз дип белеп үстек. Нуриулла, Ярулла, Бибисара, Бибисабира, Шаһидә исемле абый һәм апаларыбызның үги балалар икәнен без үсеп җиткәч кенә әйттеләр.

*– Салкын Алан авылына сезнекеләр ничек килеп чыкканнар соң?*

– Алпавыттан алган яңа җиргә 1924 елда Урта Кәшер, ә биш елдан соң Имән авылы кешеләре күчеп килгән. Яңа авылга исемне дә үзләре уйлап тапканнар: «Салкын Алан» дип атаганнар. Безнекеләр җирне чишмә кырыеннан алганнар. Үзләре әлеге матур җирне башкалар үзләштерер дип шикләнгәннәр, шуңа күрә юлга кузгалганнар. Сөләйман бабамның уллары – этием Нәбиулла, аның энесе Заһидулла һәм авылдашлары Малик Салихов өсләренә – калын толып, аякларына чаңгы киеп, 12 чакрым араны үткәннәр. Теге чишмә буенда кардан шалаш ясаганнар. Үзләре белән алып килгән каткан ипине чишмә суында җебетеп ашаганнар. Ике үр арасындагы иңкү урында булган ул чишмә. Учак ягып җылынганнар. Шул рәвешле үзләренең булачак авыллары урынында – чишмәле аланда кыш чыкканнар... Этием чишмә башын һәрвакыт тәртиптә тотты. Кулыннан көрәк, балта төшмәде. Сукмакны да хасиятләп торды. Табигать байлыгы тупланган урман да якында гына. Эти чикләвек җыярга ярата. Аны ишегалдында таш белән ватып ашыйбыз. Эти теш белән чикләвек ваттырмый иде. Ул утырткан бәрәңгеләр эре булып үсә. Мичкә бәрәңге тәгәрәтәбез. «Вәкил абый» да эти кулындагы эре бәрәңгене күреп шаккаткан иде. Әни эштән кайтып керми. Шуңа күрә безнең арада сирәк була иде.

*– Гәүһәр апа, эти-әниегез тату яшәделәрме?*

– Чын дөресен әйтәм: шылт иткән тавыш та чыкмады. Икесе дә намазда. Ураза да тоталар. Әнием намазларын, яшереп, арыш басуында укый икән. Этигә шулай дип әйтә иде.

*– Сез иң матур авылда яшәгәнсез.*

– Табигать матурлыгына хезмәт уңышлары үрелеп барды. Басудан ашлыкны ындыр табагына үз вакытында кайтарып урнаштыралар. Әлбәттә, аны сугу эше кыш көненә кала. Ашлык тулысынча ташылып беткәнгә, башка авыллардагы шикелле җир өстендә кышка калган бөртек ашап, «кан чире»ннән үлүчеләр бездә булмады. Чөнки әнием авыл кешеләренә даими рәвештә аңлату эшләре алып бара. Колхозчылар да аның сүзен тыңлыйлар, бердәм булып, тырышып эшлиләр.

Әни җитәкләгән «Политотдел» колхозы республика буенча икенче урынга чыкты. Тагын бер елдан, ягъни 1944 елның 10 мартында, ТАССР Верховный Советы Президиумы грамотасы белән бүләкләнделәр. Әни Казанга съездга барды. Аннан иләк һәм бер алма алып кайтты. Ул алманы бүлеп ашадык. Шул елны әнием Хәмит Маликов белән берлектә җиләк-җимеш бакчасы ясады. Авылыбыз тагын да матураеп китте.

*– Әниегез колхоз рәисе булып кайчанга чаклы эшләде?*

– Ир-атлар сугыштан кайткач, җитәкчелек дилбегәсен әнием аларга тапшырды. Ләкин үзе, артта калган хуҗалыкны алга чыгарырга дип, туган авылы Баткакка «Авангард» колхозы рәисе итеп билгеләнә. Аннары Иштирәктә шул ук эшне башкарды. Әни һәрвакыт җаваплы урыннарда эшләде. 1952 елда аны Имән авыл советы рәисе итеп куйдылар. Салкын Алан шул авылга карый иде. Сарманда район зоотехнигы булып эшләде. Авылларда йөреп, өйгә атнага бер тапкыр гына кайта иде.

*– Миңлекамал апа үзенең хезмәт җимешләрен татыдымы?*

– Хезмәтенә күрә хөрмәте дә булды. Сарман райкомы тарафыннан махсус билгеләнгән персональ пенсиясенә чиксез сөенде. Әлмәттән бер бүлмәле фатир бирделәр аңа. Аны Җәлил бистәсендәге ике бүлмәлегә алыштырды. Җәлилне бик яратты. Без бергә яшәдек. Җәлилдә ветераннар советы әгъзасы иде. Ире сугышта һәлак булган ялгыз анага, пенсионерга фатир алуда булышты.

Әнине мәктәпкә очрашуларга чакыралар иде. Әңгәмәләрен бик күп тапкырлар магнитофон тасмасына яздырып киттеләр. Укучылар өйгә сыйныфлары белән киләләр иде. Сөләйдән, Чуар Абдулдан, тирә-як авыллардан гел килеп тордылар.

Спектакльләргә, концертларга чакыру кәгазе бирәләр иде әнигә. Ул дусты Җамал апаны үзе белән алып бара иде.

Әнием балаларына, оныкларына сөенеп яшәде. Закирә апам – табибә, Әския апам – хәрби киемнәр тегүче, Нәкыя апам – китап сатучы, мин химия һәм биология укытучысы булып эшләдек.

*– Әниегезнең үрнәк итеп куярлык тагын нинди яклары бар иде?*

– Заман белән бергә атлау хас иде аңа. Гәҗит укый, радио тыңлый, телевизор карый. Намазларын калдырмый, уразасын тота. Мәҗлесләрдә Коръәнне мәкам белән, ягъни көйле тавыш белән моңлы итеп укый. Моны фәкать Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы өчен эшли, сәдака акчасын хуҗаларына яисә бала-чагаларына биреп кайта.

Туганлык җепләрен саклауга бик күп көчен куйды. Авылдагы өйне саткач, шуның акчасына СССРны иңләп-буйлап чыбык очы туганнарыбызга кадәр барлап чыкты. Уфа, Мәскәү, Ленинград, Иркутск, Чита, Тольятти, Ухта шәһәрләрендә һәм Үзбәкстанда булып, дөнья гизеп кайтты.

Үзлегеннән укып, латин шрифтын һәм кириллицаны, шулай ук зоотехник белгечлеген үзләштергән.

Сәнгать һәм фән кешеләре белән аралашып яшәде. Зирәк фикерле әниемә юмор хисе, шаян сүзләр кушып сөйләшү дә чит түгел иде. Ялган катнаштырмыйча, турысын әйтеп, ачык һәм аңлаешлы итеп сөйли иде.

Дәү әни буларак, җеп эрләп, йон оекбашлар бәйли иде.

Һәм, әлбәттә, оныкларының «Миңлекамал» әсәре белән таныш булуларына шатланып, үзенең данлыклы Миңлекамал булуы белән горурланып яшәде.

Кадерле әнием 1983 елның 27 июлендә 81 яшендә вафат булды, ул Салкын Алан зиратында әтием янында җирләнде. Аның турында сөйләгән сүзләребез дога булып ирешсен, рухы шат булсын. Амин!

*Әңгәмәдәш* – **Рухия АХУНҖАНОВА**

# НОМГОН ТАШЪЯЗМАСЫ: XXI ГАСЫРНЫҢ ИҢ ОЛЫ АЧЫШЫ

2022 елның 15 декабрендә Парижда ЮНЕСКОның штаб-квартирасында «Төрки телләр көннәре» кысаларында «Дөнья мәдәниятендә төрки цивилизация: Илтереш Котлуг каһан язулары» дип исемләнгән Халыкара форум уздырылды. Аны Халыкара Төрки академия ЮНЕСКО секретариаты булышлыгы белән оештыра. Форум ике тематик секцияне үз эченә ала: «Төрки цивилизациядә язу культурасы: Илтереш Котлуг каһан», «Төрки телләр глобаль дөньяда: саклау һәм үстерү мәсьәләләре».

Астана, Баку, Бишкәк, Ташкент, Будапешт шәһәрләрендәге мәгълүмати чараларны йомгаклап, әлеге Форум Төрки халыклар мәдәнияте өчен XXI гасырның иң олы ачышы – Номгон язулары хакында дөньяга хәбәр итте.



*Монголиянең Орхонгой районы Номгон үзәнлегендәге археологик экспедиция урыны.*

2022 елның августында Монголиянең Орхонгой районындагы Номгон үзәнлегендә Икенче Төрки каһанлык идарәчесе Илтереш Котлуг каһанга (б.э. VII гасыры) ташһәйкәл комплексы табылу турында хәбәр ителә. Археологик экспедиция 2019 елны Халыкара Төрки академия һәм Монголия Фәннәр академиясе тарафыннан оештырыла.

Тикшеренү төркеме составында Халыкара Төрки академия президенты Дархан Кыдырали, Академия галимнәре Напил Базылхан һәм Нурболат Бөгенбаев, Монголия Фәннәр академиясенең Археология институтындагы Археологик тикшеренүләр үзәге директоры академик Дамдинсурэнгийн Цэвээндорж (1949–2022), әлеге үзәкнең тикшеренүчеләр төркемен җитәкләгән профессор Алтангэрэлийн Энхтур, археологлар Цэрэнхандын Буянхишиг, Гончигийн Батболд һәм Нарантуяагийн Цэнгэл, Мунхсайханы Уганбаяр булганлыкны әйтергә кирәк.

Ташһәйкәлнең гомуми мәйданы 49х41,5 м. Аның тирәли, көнбатыштан көнчыгышка таба, оваль формадагы чокыр казылган, балчыгыннан калкулык өелгән. Һәйкәлнең көнбатыш ягында уртасында уентылы таш куб, кеше сыннары, ике баласын ияртқән арыслан фигурасы һәм ике сарык сыны табыла. Капкадан көнчыгышка таба 51 балбал тезелгән. Аларның 5-сендә Ашина ыруының билгесе – тау кәҗәсе символы уелган. Күрәсең, эчтәге төп юлга керамик чынаяклар һәм кирпечләр түшәлгән була: аларның калдыклары археологларны табыну урынына (барык) кадәр китереп җиткерә.

Барык каршында ташъязманың өске өлеше һәм ташбака рәвешендә уелган нигез табыла. Ташъязмада ике яктан – борынгы төрки рун язуы, өченче якта – согыд

әлифбасында язу сакланган. Галимнәр текстта «Тәңре», «Төрк», «Котлуг», «төмән» (төмән – ун мең кешелек гаскәр) кебек сүзләрне аерып алалар. Аннары сакланган өлешне укыйлар. Алар фикеренчә, сыер елының тугызынчы аенда куелган таш – «Төрк» сүзе уелган иң борынгы артефактлардан булып чыга. Тел белгечләре бу табылдыкның борынгы төрки язу тарихын үзгәртәчәген, бигрәк тә ташъязмадагы согыд һәм брахми хәрефле язулар бабаларыбызның язма мәдәниятен кабат өйрәнеп, нәтиҗәләр чыгарырга кирәклеген күрсәтә дип белдерделәр.

Археологлар әйтүенчә, комплекс Күлтәгин һәм Билге (Билгә) каһан һәйкәлләре белән бер өслүбтә төзелгән. Язуның өске өлешендә ике бүре башы уелган, гәүдәсе аска таба сузылып төшкән бу җанвар аждаһаны да хәтерләтә. Нәкъ шундый ук билгеләр Таспар, Күлтәгин, Билге каһан, башка шәхесләр хөрмәтенә куелган һәйкәлләрдә очрый.

Фәндә Илтереш Котлуг каһан – Орхон-Енисей ташъязмаларыннан яхшы таныш булган Күлтәгин һәм Билге каһаннарның атасы, Төрки каһанлыкны тергезүче буларак мәгълүм.

Тарихка күз ташласак, башында Ашина ыруыннан булган каһан торган I нче Төрки каһанлык VI гасыр ахырында (581 елда, кайбер чыганакларда – 603 елда) Көнбатыш һәм Көнчыгыш Төрки каһанлыкларга таркала. Көнбатышының үзәге Җидесуда урнаша, җирләре Алтайдан Кырымга кадәр сузыла, Көнчыгышының үзәге хәзерге Монголиянең Урхун елгасында була, Алтайдан башлап, Бөек Кытай стенасына кадәрге җирләрне били. Әмма башта Көнчыгыш Төрки каһанлыгы, 651 елда Көнбатыш Төрки каһанлыгы кытайлар тарафыннан тар-мар ителә.



*Баз каһан куйдырган һәйкәл фрагментлары.*

682 елда төркиләр Илтереш (Илтерес) каһан җитәкчелегендә үзләренең мөстәкыйльлеген торгызалар. II Төрки каһанлык тарихы Илтерешнең улы, гаскәр башлыгы Күлтәгин, аның өлкән абыйсы Билге яки Мәгыйлән каһан, аның киңәшчесе Төнйокык каберләре өстенә корылган ташһәйкәлләрдә сакланган.

Билге каһан үлгәннән соң тәхет өчен көрәш башлана һәм 747 елда II Төрки каһанлык җимерелә, Уйгыр каһанлыгы барлыкка килә. Урта Идел, Кама буйларындагы бабаларыбыз төзегән Болгар дәүләте дә, Азов буендагы Бөек Болгар (630–660), Түбән Иделдәге Хазәр (650–970), Кыпчак (XI гасырның икенче яртысы – XIII гасырның башы), шәрыктагы Уйгыр (745–840), Кимак (750 –1035), Урта Азиядәге Төргеш (698–766), Карлук (766–940), Карахани (942–1210), Угыз (756–1055), Газнәви (977–1186), Сәлҗүк (1037 –1194) кебек дәүләтләр дә шушы уртак нигездә оешалар.

Әлбәттә, фәнни әдәбиятта «Орхон-Енисей язмалары» дип аталган ташһәйкәлләр табылу VI-VII гасырларда яшәгән төрле төрки кабиләләрнең тарихын яктыртып җибәрә. Рун хәрефле язмалар хакындагы беренче хәбәрләр XVII гасыр ахыры – XVIII гасыр башларында ук пәйда була. Бу елъязмада 1696-1697 елларда Себернең атлас-картасын төзүче Семен Ремезов (1642–1720), 1713–1722 елларда Себердә әсирлектә яшәгән швед офицеры Ф.И. Страленберг (1676–1747) исемнәре аерым урын тота. 1889 елда археолог һәм этнограф Н.М.Ядринцев Төньяк Монголиядәге Орхон елгасы үзәнендә рун язулы өч таш багана таба. Аларның икесе Күлтәгин һәм Билге («Билгә» дә диләр) каһан хөрмәтенә куелган таш баганалар булып чыга. Казан белән бәйле галим В.В.Радлов Төньяк Монголиягә оештырган экспедицияләр яңадан-яңа ачышларга

китерә. 1893 елның 15 декабрендә Дания галиме В.Томсен Дания Король академиясе утырышында рун хәрефләрен укуын игълан итә. 1894 елның 19 гыйнварында академик В.В.Радлов Күлтәгин кабер ташы язмасын тәрҗемә итеп тәмамлый. С.Е.Малов 1951 елда – Күлтәгин һәм Тоньйокык, 1959 елда Билге каһан ташъязмаларын русчага тәрҗемә итеп бастыра.

XX гасырның икенче яртысы һәм XXI гасыр башында бу өлкәдә иң зур хезмәт куйган галимнәр арасында С.Г. Кляшторныйны аерып күрсәтергә кирәк. Гомере буе экспедицияләрдә йөреп, ул әлеге кыйммәтле мирасны системалы өйрәнү нигезен сала. 2002 елда «История татар» исемле күптомлы хезмәтнең беренче томында Орхон-Енисей һәйкәлләре текстлары татар әдәби теленә Ф.Ш.Нуриева тәрҗемәсендә кертелә.

Орхон-Енисей истәлекләрен С.Г.Кляшторный табылу урыннары (Төньяк Монголиядә, Орхон, Тола һәм Селенга елгалары буенда; Енисей елгасы үзәнлегендә; Лена елгасы һәм Байкал күле бассейнында; Алтай тауларында; Көнчыгыш Төркестанда; Урта Азиядә (Җидесу һәм Фирганә үзәнлекләрендә); Көнчыгыш Европада (Дон һәм Дунай елгалары буйларында) табылган язмалар); һәм этник-хронологик яктан (Көнчыгыш Төрки каһанлык; Кыргыз дәүләте; Курыкан кабиләләр союзы; Көнбатыш Төрки каһанлык; Монголиядәге Уйгыр каһанлыгы; Көнчыгыш Төркестандагы Уйгыр дәүләте; Бәҗәнәк кабиләләр союзы һәйкәлләре) дип төркемли. Аларны жанрлары ягыннан аера.

Күлтәгин, Билге каһан һәм Тоньйокык истәлегенә куелган ташларда Төрки каһанлыклар тарихы калкулана. Күлтәгин язмасы, хәтта иң беренче төрки язучының исемен дә безнең көннәргә китереп җиткергән: Йоллыг тәгин ул.

Күлтәгин ташындагы Зур язмада Илтереш каһан Тәңре улы буларак күрсәтелә: «Төрки халык юкка чыкмасын, халык булсын» дигән. Атам Илтереш каһанны, анам Илбилгә катунны югары күтәргән, күкләр биеклегенә хас дәрәҗәгә ирештергән» (11 нче юл).

Илтереш каһан төрки халыкка мөстәкыйльлек яулый: «Атам каһан шулай кырык җиде ел яу йөреп, егерме җиде сугышта катнашкан. Тәңре ярлыкаганы өчен иле булганнарны иленнән мәхрүм итте, илсезләндерде, каһанлыклары булганнарны каһансызландырды. Дошманнарын бастырды, тезлене – чүктерде, башлының – башын идерде. Атам каһан илне төзекләндереп (15 юл), идарә эшләрен торгызгач, үзе үлеп китте. Атам каһанга багышлап, Баз каһан балбаллар куйдырды» (16 нчы юл).

Шул рәвешле, XXI гасырда табылган ташһәйкәл – Баз каһан куйдырган истәлек булып чыга.

Халыкара Төрки академия Номгон фәнни экспедициясе нәтиҗәләре буенча җыентык бастырып, аны төрки дәүләтләрдә таныту эшен планлаштыра. Монголиядә төрки дәвер һәйкәлләрен өйрәнүне дә дәвам итү күздә тотыла. Әйтергә кирәк, Татарстан археологлары да мондагы казу эшләрендә актив катнашалар. Монголия фәннәр академиясенең археология һәм тарих институты белән бергәләп Уйгыр каһанлыгының төньяк башкаласы Байбалыкны һәм төньяк җирләрдәге башка ташһәйкәлләрне өйрәнү кызыклы нәтиҗәләргә китерә. Мисалга, уйгыр каһаннары күмелгән Моюн-Чура үзәнлегендәге татарстанлыларның тикшеренүләре (2017–2019) моңа кадәр билгеле булмаган яңа курган ачылуга китерде. Селенга үзәнлегендәге (Билге каһан ташһәйкәле табылган урын) җирләү комплексларын өйрәнү дәвам иттерелә. Татарстан Фәннәр академиясенең А.Х. Халиков исем. Археология институты директоры, ТФА мөхбир-әгъзасы А.Г. Ситдыйков Париждагы форумда болар хакында да сөйләде.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*академик, филология фәннәре докторы.*

# ТАТАР СӘҮДӘГӘРЛӘРЕ ИСЛАМ ДИНЕН ТАРАТУ СИСТЕМАСЫНДА

## *(XVIII гасырның икенче яртысы – XIX гасырның беренче яртысы)*

### Вакыфлар

Мәчетләрне без табыш китерми торган вакыфларга тиңлибез. 1833 елга Мәхкәмәи шәргыя округында аларның саны 3133 җитә, чирек гасырдан, 1858 елда һәммәсе 3554 мәчет хисаплана *(Загидуллин И.К. Исламские институты в Российской империи: Мечети в европейской части России и Сибири. Казань, 2007. С.143).*

XVIII гасырның икенче яртысы – XIX йөзнең беренче яртысында Ш.Мәрҗани хезмәтендә теркәлгән вакыфның бер төре – байлар тарафыннан кулъязма дини китапларны, Коръәнне мәчетләргә бүләк итү. Әйтик, XVIII гасыр ахырында Бәрәскәнең таш мәчетен салдырган сәүдәгәр Ибраһим бине Йосыф бине Әснай бине Исәнкол бине Борнагол Казанның беренче мәчетенә вакыф итеп кулъязма Коръән тапшырган (386-387 б.). Туган авылында таш мәчет төзеткән Баязид бине Госман бине Габделкадыйр әл-Кышкари, шулай ук, мәчеткә «Мишкятел-мәсабих» исемле китап бүләк иткән (387 б.).

Татар сәүдәгәр катламы вәкилләренең дини активлыгының тагын бер мөһим юнәлеше булып XIX гасырның беренче яртысында мәчетләргә күчемсез милек вакыф итүне атарга кирәк.

Казан шәһәренең 1 нче гильдия сәүдәгәре Гобәйдулла Юнысов 1830 елда шәһәрнең 1 нче җәмигъ мәчете файдасына ике сәүдә урынын яздыра. Аларны арендалаганнан килгән табышның бер өлеше – мәчетне карап, төзекләндереп тору һәм «дәүләт йөкләмәләрен үтәү» өчен, икенче өлеше руханилар файдасына дип тәгаенләнә.

1841 елда Тараның 1 нче гильдия сәүдәгәре Айтынкин шәһәрнең 1 нче җәмигъ мәчетенә 30 мең сум ассигнацияләрне (8541 көмеш сум) вакыф итеп банкка сала.

1845 елда сәүдәгәр Габделхаликъ Ибраев Стәрлетамактан 5 чакрым ераклыкта, Эстәрле елгасы буендагы 90 дисәтинә 1480 сажин сөрүлек җирен шәһәр мәчетенә – ягарга утын, идәненә җәяргә намазлыклар, намаз бүлмәләрен яктыртырга шәмнәр һәм лампадалар сатып алу, ә калган суммаларын үзе төзеткән укыту комплексына тоту өчен бүләк итә (еллык гомуми керем – 120 сум). Ул төзеткән мәдрәсә комплексында бер таш һәм бер агач уку биналары, таштан салынган кухня һәм ишегалдында казылган кое кергән. Табышның 1/10 өлеше шушы вакыф белән идарә итүче мөтәвәллигә бирелә. Байның бүләге хакимият тарафыннан 1849 елда рәсмиләштерелә.

1848 елда Мәскәү җәмигъ мәчетенең вакыф йортын сатудан кергән акча (159 сум 90 тиен) Мәскәү шәһәре саклау кассасына салына *(Загидуллин И.К. Вакуфы в имперском правовом пространстве // Ислам и благотворительность: Материалы Всероссийского семинара «Ислам и благотворительность» (Казань, январь 2005 г.). Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2006. С.44–102).*

Бу рәсми исемлек тулы булмаса да, мәчетләргә күчемсез милекне вакыф итүчеләр бик аз булуы аңлашылып тора. Димәк, 3 мең мәчетне карап тотуда электән оешкан традицион алымнар өстенлек иткән: 1) мәчет төзегән мөселманнарның балалары,

нәселләре киселгәнче яки кулларыннан маллары киткәнче, ата-бабалары төзеткән бинаны карап, төзәттереп торганнар; 2) гыйбадәт йортлары мәхәллә халкыннан җыелган сәдака хисабына, 3) мәхәллә рухание акчасына, яисә 4) берәр байдан ялынып, акча сорап алу хисабына төзекләндерелгән, җылыту өчен утын белән тәэмин ителгән; 5) алынучы булмаса, авыл кешеләре яисә авыл җәмгыяте чыгымнарга барган.

## Мәдрәсәләр төзү һәм укыту системасы коруга ярдәм

1740–1761 елларда Идел-Чулман буйларында хөкүмәт тарафыннан уздырылган чукындыру кампаниясе мөселманнарның көчен генә түгел, җәмгыятьнең «йомшак» якларын да ачып сала. Шул ачыклана: авыл җәмгыяте чукындыруга каршы абызлар җитәкчелегендә бер йодрык булып каршы торган очракта да, әгәр аның бер әгъзасы зур сынау белән очрашканда, аннан котылып калу өчен чукынса, бу хәл авыл җәмгыятенең конфессиональ бөтенлеген җимергән, балаларының чукынган булуына, авылга православие руханиеның килеп йөрүенә юл ачкан. Үз чиратында, чукынып, гомерлек рекрут хезмәтеннән котылып калган кеше урынына икенче авылдашы алынган, бу дәүләт йөкләмәсеннән авыл җәмгыяте барыбер котылып кала алмаган. Шул сәбәпле, һәрбер игенчене иманлы, динле итеп тәрбияләү мәсьәләсе килеп туган. Авылларда халык сайлап куйган абызларның дини эшчәнлегенең бу яктан сыйфатсыз һәм йомшак икәнлеген, формаль булуын яңа чукынганнарның саны раслап торган.

Нәкъ менә шуңа күрә, чукындыру кампаниясеннән соң Идел-Чулман буйларында көн күргән мөселманнар тарафыннан ясалган иң мөһим нәтиҗә – төбәктә дини белем бирү системасын булдыру кирәклекне аңлау була. Бу хакта Газиз Гобәйдуллин болай дип яза: «Сәүдәгәрләр һәм аларның илһамчылары руханиларга һәрничек булса да, татарны татар итеп тота торган юллар кирәк булып, ул да булса татарны чукындырмый, мөселман итеп асрау иде. Шуның нәтиҗәсендә татарларда мәдрәсә вә мәктәп ачарга омтылыш туды» *(Гобәйдуллин Г. Тарихи сәхифәләр ачылганда. Сайланма хезмәтләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 187 б.).*

Әлбәттә, бу вакытта ук Көньяк Кавказда укып кайтып, мәдрәсәләр ачып, шәкертләргә белем бирүчеләр юк түгел, ләкин алар аз булган. Биредә XVIII гасырның беренче яртысында Пётр Iнең салым сәясәтеннән һәм чукындырудан качып, Көньяк Урал төбәгенә күченүләрне һәм берничә дистә елда йөзләрчә яңа торак пунктлары барлыкка килеп, халыкның ныклап үрчи башлавын да истән чыгармаска кирәк. Укыту системасының үзәгендә исә дин әһеле торган. Шул рәвешле, татар җәмгыяте алдына гыйлемле руханилар әзерләү бурычы килеп баскан.

«Казан татарлары статистик һәм этнографик нисбәтләрдә» (Казан, 1843) китабын язу максатында Карл Фукс каладагы татар мәдрәсәләре белән якыннан кызыксына. Шәһәр ахуны аңа: «Без галим мулла булырга теләүчеләрне укырга Бохарага җибәрәбез», – дип сөйли *(Фукс К. Күрс. хезмәт. 130 б.)*. Ахунның сүзләреннән күренгәнчә, зиһенле шәкертләрне тирән дини белем алырга дип, Урта Азиягә җибәрү шәһәр руханиларының (һәм байларының) татар мөселман җәмгыятен гыйлемле дин әһелләре белән тәэмин итү буенча махсус проекты булган икән. Чөнки гыйлемле рухани гына гыйлемле шәкертләр әзерләячәк һәм мөселманнар тормышында килеп туган мәсьәләләрдә чыганаклар буенча дөрес хөкем чыгарачак. (Шәкертләрне Бохара мәдрәсәләренә остазлары вәгазьләп җибәргәннәр икән, димәк, алар укырга китәчәк яшь кешегә, байларны җәлеп итеп, матди ярдәм дә оештырган булырга тиешләр, дигән уй килә). Әлбәттә, Бохарага Г.Курсави, Ш.Мәрҗани һ.б. кебек үз теләкләре белән укырга китүчеләр дә аз булмаган.

Шул рәвешле, Бохарага барып, укучылар саны шактый күп булып, сәүдә кәрваннарында килүчеләрне каршы алу, урнаштыру буенча махсус кешеләр шөгыльләнә башлаган. Бу хакта Габделбарый Баттал-Таймас болай дип яза: «Төньяк төркиләрнең яшьләре ерак заманнардан белем алу өчен ислам илләренә, шулай

ук Бохара мәдрәсәләренә укырга бара торган булганнар. Бу җирләрдә мөселман яшьләрен укырга чакыру, урнаштыру, ярдәм итү буенча даими рәвештә эш алып бара торган булганнар. Укырга килгән талиблар аерым мәхәллә булып яшәгәннәр, аларның үз имамнары да булган. Шул имам аларны мәдрәсәләргә урнаштыру белән дә шөгыльләнгән. Белем алгач, мәдрәсәне тәмамлагач, алар үз якларына кайтып, күп очракларда мулла булганнар, ә кайберләре үзләре укыган мәдрәсәләрдә мөдәррис булып та калганнар. Бу традиция XIX йөзнең ахырларына хәтле шактый актив дәвам иткән» *(Габдулла Баттал-Таймас. Муса Ярулла Биги: тормышы, эшчәнлеге һәм әсәрләре / төрек теленнән тәрҗемә итүче һәм басмага әзерләүче Ә.Кәримуллин. Казан: «Иман» нәшрияты, 1997. 8-9 б.)*.

Россия империясе Хива, Бохара һәм Коканд ханлыкларын басып алгач һәм үзенә буйсындыргач, Идел-Урал төбәгендә яшәгән мөселманнар өчен андагы мәдрәсәләрнең әһәмияте нык кими. Ягъни татар яшьләренең читкә дини белем тупларга баруы – мәшһүр уку йортлары һәм остазлар булуга бәйле була.

Биредә шунысын ассызыклап үтү мөһим: авыл мәхәлләсе, беренче чиратта, үз мәнфәгатьләрен кайгыртып яшәгән һәм башкалар ихтыяҗларын үтәргә аның кызыксынуы да, матди ресурслары да булмаган.

Әлбәттә, алыпсатарлар, туганлык һәм төбәкчелек традицияләренә буйсынып, туган авылларында да башлангыч мәктәп биналары да төзеткәннәр. Шулай да аларның татар милләте үсешенә керткән әһәмиятле роле мәдрәсәләр комплекслары төзү белән бәйле. Бу очракта алар мөселман җәмгыятен кайгыртучылар һәм аны үстерүче иганәчеләр буларак чыгыш ясаганнар.

Казанда 1771 елны – Апанай һәм Ахун, 1780 елны Әмирхан мәдрәсәләре ачылганлыгы билгеле.

Мәдрәсәләрне гыйлемле муллалар, сәүдәгәрләр белән килешеп булдыралар. Ш.Мәрҗани татарларның борынгы мәдрәсәләре турында да язып калдырган. Биредә сүз Кариле (1768 ел), Бай Оланнар (1757 ел), Орнашбаш (XVIII гасыр азагы), Ашыт, Мәчкәрә, Казаклар (1779 ел) авылларындагы дини уку йортлары турында бара (*Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Казан, 1989. 238, 282, 285 б.)*. Акрынлап, аларның саны нык арта.

Калаларда һәм авылларда мәдрәсә биналары төзү турында мәгълүматлар күп сакланмаган. Булганнары игътибарга лаек. Әйтергә кирәк, торак пунктында гыйлемле остаз эшләмәсә, төзелгән мәдрәсә гади бина булып калган. Шул ук вакытта байның тиешле дәрәҗәдә кайгыртуы булмаса, мөгаллим-мөдәрриснең – яшәү, шәкертләрнең белем алу һәм торак шартлары начараю дини уку йортының эшчәнлегенә тискәре йогынты ясаган.

Мәчкәрә авылында мәдрәсә 1758 елдан билгеле. Биредә мөдәррис Габделхәмид Түнтәри заманында Казанның булачак 1 гильдия сәүдәгәре Габдулла Үтәмешев (1832 елда вафат) шәкерт булып йөргән. XIX йөзнең беренче утыз елында Мәчкәрә мәдрәсәсенең даны үсүгә уку йортын, шәкертләрне һәм мөдәррис-хәлфәләрне кайгырткан Габдулла байның өлеше зур була *(Медресе и мударрисы на территории Татарстана в XVIII – начале XX в., учебная литература и методы обучения: учебное пособие / А.Ю.Хабутдинов, Р.Р. Сафиуллина. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2017. С. 44)*.

XIX йөз башында Югары Курса авылы мәдрәсәсе дә сәүдәгәр Габдулла Үтәмешев хисабына тотылган *(Шунда ук. 36 б.)*. Аның хатыны биредә 1812 елга кадәр укыткан Габделнасыйр Курсавиның сеңлесе була. Габдулла байның бер улы Муса Бохарага барып та укый *(Мәрҗани Ш. Күрс. хезмәт. 388 б.)*.

Ташкичү бае Баязид бине Ибраһим Кышкар авылыннан ятим бала тәрбияләп, Бохарага җибәреп укытып кайтара. Гыйлемле мөдәррис булып җитешкән үги улы Шәмсетдин бине Габдерәшид бине Госман бине Габделкадыйр өчен Баязид бай таштан

ике катлы мәдрәсә бинасы салдыра. Шәмсетдин 1820 елларда хаҗ кылырга китә һәм Каһирәдәге Әл-Әзһар университетында фарсы телен укытырга кала. Бирелә 7 ел эшләгәч, 1832 елда вафат була. 1821 елдан Ташкичүдә 2 нче мулла булып, Баһаветдин Мәрҗани (1856 елда вафат була) хезмәт итә башлый. Аның улы Шиһабетдин Баязид бине Ибраһим төзеткән мәдрәсәдә укый *(Медресе и мударрисы на территории Татарстана в XVIII – начале XX в., учебная литература и методы обучения: учебное пособие. С.49)*.

Казан губернасында 1831 елны төзелгән Халык мәгарифе министрлыгына буйсынмаган уку йортлары исемлегендә ачылган елы, шәкертләр һәм укытучылар саны күрсәтелгән 14 мөселман уку йорты хакында мәгълүмат бар. Аларның кайберләренең кем хисабына тотылганы да күрсәтелгән. Байлар Сабасындагы 1760 елда ачылган мәдрәсә (40 шәкерт) крестьян Биктимер Габдерәхим хисабына көн күргән, Көек авылында 1782 елдан эшләүче мәдрәсә (76 укучы) Казан сәүдәгәре Апанаев кайгыртуында яшәгән. *(Махмутова А.Х. Восстановление и развитие системы образования татар-мусульман во второй половине XVIII – первой половине XIX вв. // Образование и просвещение в губернской Казани. Вып.4. Сб. статей. Казань: Институт истории им.Ш.Марджани, 2012. С. 132).*

1816 елны Казанның баш халык училищесы укытучысы А.Пятов шәһәрдәге биш мәдрәсә белән таныша, университеттагы училище советына язган хисабында болай дип белдерә: шәһәрдәге татар уку йортлары уртак бер тәртиптә оешканнар. Бер гыйлемне сөйгән татар бае мәдрәсә өчен йортын иганә итә. Ә мәхәллә мулласы шунда мөгаллимлек итәргә алына. Бу хакта ишетеп, уку йортына шәкертләр җыелган. Уку йорты иганәләр хисабына яшәгән. *(Махмутова А.Х. Күрс. хезмәт. 131 б.).*

Казандагы Әҗем мәчете мәхәлләсе мәктәбе бинасын 1795 елда сәүдәгәр Назир Әҗем улы төзеткәне билгеле *(Медресе и мударрисы на территории Татарстана в XVIII – начале XX в., учебная литература и методы обучения: учебное пособие. С. 54)*. 10 нчы җәмигъ мәчете каршындагы мәдрәсәне 1776 елда (кайбер мәгълүматлар буенча 1808 елда) эшмәкәр крестьян Яхья Максутов төзетә *(Шунда ук. 82 б)*.

Шәһәрнең 5 нче җәмигъ мәчете каршындагы Сәгыйт мәдрәсәсе бинасы 1808 елда мәхәллә мөселманнары һәм сәүдәгәр Бикбау Хәлфин тарафыннан төзелә һәм 1815 елда зурайтыла *(Шунда ук. 74 б.)*. 1нче җәмигъ мәчете мәдрәсәсенә яңа бинаны 1837 елны 1 нче гильдия сәүдәгәре Гобәйдулла Юнысов төзеп бирә *(Шунда ук. 62 б)*. 4 нче җәмигъ (Зәңгәр) мәчет мәдрәсәсенең уку бинасы 1810–1826 еллар аралыгында бертуган сәүдәгәр Арсаевлар тарафыннан корыла *(Шунда ук. 81 б)*. Иске Татар бистәсендәге 1798 елда ачылган 2 нче мәхәллә мәчете мәдрәсәсенең чыгымнарын 1831 елда сәүдәгәр Габидулла Рыдин күтәргән *(Махмутова А.Х. Күрс. хезмәт. 132 б.)*.

Чистай шәһәрендә 1846–1893 елларда имам-хатыйп булып Югары Сасна авылында туып-үскән сәүдәгәр улы шәех Мөхәммәтзакир Камалов тора. Аның хатыны Әсманың әтисе Хәсән бине Муса бине Ягъкуб әс-Соснавый киявенә атап таштан 1847 елны ике катлы мәдрәсә һәм яшьләргә яшәр өчен йорт җиткерә. «Камалия» мәдрәсәсе шулай барлыкка килә *(Медресе и мударрисы на территории Татарстана в XVIII – начале XX в., учебная литература и методы обучения: учебное пособие. С.86)*. Чистай шәһәре мәчетен дә Хәсән бине Муса төзеткән *(Мәрҗани Ш. Күрс. хезмәт. 392 б.)*.

Йомгаклап әйткәндә, XVIII гасырның икенче яртысы – XIX йөзнең уртасында мөселман дини җәмгыятенең иң зур казанышы һәм нәтиҗәсе урта дини белем системасын төзү була. Бу өлкәдә татар эшмәкәрләре, сәүдәгәрләре үзләреннән лаеклы өлеш керткәннәр.

## Казанда Коръән һәм дини китаплар бастыру

Коръән һәм дини китаплар бастыру да дини активлыкның матур үрнәге булып тора. Китап бастыру татар зыялылары һәм сәүдәгәрләренең уртак максатчан эшчәнлеге, үҗәтлеге һәм мөселман җәмгыятен мәгърифәтле, диндар һәм гыйлемле итү өчен тырышлыгы нәтиҗәсе иде.

Билгеле булганча, Коръән Санкт-Петербургта 1787, 1789, 1790, 1793, 1796, 1798 елларда нәшер ителә. Император Павел I тәхеткә утыргач, прапорщик Габделгазиз Туктамыш улы Бурашев гаризасын канәгатьләндереп, аңа типография ачарга рөхсәт бирелә. Ләкин Сенат бу карарны юкка чыгаруга ирешә. Шуннан соң Бурашев Сенатка гариза юллый һәм гаризасына беренче чиратта бастыру өчен догалар язылган «Әлифба» һәм Коръәннең җидедән бер өлеше күләмендә аятьләр сайлап тупланган «Һәфтияк» кульязмаларын терки. Димәк, 1797 елда ук татар элитасы үзе өчен беренчел һәм иң кирәкле китаплар исемлеген ачыклаган булган.

1798 елда Павел I Казанга килгәч, татар сәүдәгәрләре императордан типография ачарга рөхсәт бирүне үтенеп сораганнар.

Ниһаять, 1800 елны Бурашевка типография ачарга рөхсәт ителә. Шул ук елны башкаладан ике бастыру станы, гарәп шрифтлары һ.б. кирәк-яраклар Казанга кайтарыла һәм гимназия карамагына тапшырыла. Бурашев, типографияне арендалаудан тыш, хәреф җыючыларга һәм корректорга хезмәт хакы түләп торган.

1801 елны догалар язылган «Әлифба» һәм «Һәфтияк шәриф» бастырып чыгарыла. Шулай итеп, 1801 ел – мөселман мәктәпләре өчен басма әлифба дөнья күргән ел булып тарихка кереп кала. 1802 елны бу уку әсбабы «Әлифба, Иман шартлары белән», соңрак «Иман шарты» дигән исемнәр белән бастырыла.

1802 елда «Пиргули китабы» һәм «Устуани китабы» татарча басылып чыга.1803 елда Казанда Коръән 2 өлештән һәм 10 өлештән торган китаплар итеп нәшер ителә.

Бурашев 1802 елда «Сөбат әл-гаҗизин» («Гаҗизләр ныклыгы») исемле XVIII гасырдан башлап Идел-Урал төбәгендә халык арасында киң таралган, суфи әдәбият үрнәге булган хезмәтне дөньяга чыгара. Аның авторы – Урта Азиягә күченгән Идел буе татарлары нәселеннән Суфи Аллаһияр. Китапта Мөхәммәд пәйгамбәр үрнәк итеп, шигъри сүз сәнгате белән укучыларда югары әхлак тәрбияләү максаты куела.

Бурашев 1802 елда нәшер иткән «Фәүзат эн-нәҗат» исемле фарсы теленнән тәрҗемә ителгән ярым тарихи әсәрнең азагына үз белдеге белән мөфтигә тикшерергә җибәрелгән кульязмада булмаган шигыйлар турындагы 3 бит текст өстәп бастыра. Карл Фукс бу адымны китап күбрәк сатылсын өчен дип бәяли *(Фукс К. Күрс. хезмәт. 134 б.).* Нәтиҗәдә Бурашев 1803 елда типография белән җитәкчелек итүдән читләштерелә. Китап исә, соңгы өч битен кисеп алып, сатуга чыгарыла.

Бурашев 1803 ел өчен китап бастыру һәм типографияне тоту акчасын да кертмәгән була. Шундый кыен чакта китап бастыруны туктатмау максатында Казан сәүдәгәрләре арасында иң бай кешеләрнең берсе – Йосыф Апанаев (1770–1825 елдан соң), мулла Калмәтев һәм Габелмәҗит Бакиров типографияне арендалаган өчен бурычны түлиләр һәм, әгәр Бурашевның киләчәктә матди мөмкинлеге булмаса, аның поручителе булырга вәгъдә бирәләр. Шулай итеп, 1804-1805 елларда рәсми кәгазьләрдә Бурашев исеме торса да, чынлыкта китапларны сәүдәгәр Йосыф Апанаев бастыра һәм типография чыгымнарын каплап бара. *(Каримуллин А.Г. Күрс. хезмәт. 112 б.).*

Ниһаять, 2 нче гильдия сәүдәгәре Йосыф Апанаев 1806 елның 20 апрелендә гимназиянең Азия типографиясен үзе файдалану турында килешү төзүгә ирешә. Бу килешүдә Юнысның поручителе булып аның туганы, шулай ук 2 нче гильдия сәүдәгәре Муса Исмәгыйль улы Апанаев (1766–1827) катнаша *(История Казани в документах и материалах. XIX век. Кн.5. Культурная жизнь города. Авторы-сост. И.К.Загидуллин, Л.М.Свердлова, Н.С.Хамитбаева, Л.Ф.Байбулатова, Х.З.Багаутдинова / Науч. ред. И.К. Загидуллин, отв. ред. Н.С.Хамитбаева. Казань: Татар. Кн. изд-во, 2014. С. 371).*

Й.Апанаев наборщик һәм корректор хезмәтләре өчен элекке күләмдә акча биргән, бастыру өчен кешеләр яллаган, нәшер итү өчен кирәк кадәр кәгазь, кара, хәрефләр кайдырган, типография урнашкан бинаны тоту өчен елга 100 сум, шулай ук казнага 200 сум түләгән. Һәр китапны кимендә 1200 данә бастыру шарты да куелган *(Кореева Н.А. Күрс. хезмәт. 197 б.).*

Ул 1806–1809 елларда югарыда аталган китапларны кабат-кабат бастыра һәм алар янына ике яңа китап өсти: «Рисаләи Мөхәммәдия» һәм Урта Азиядән кергән чыгтай әдәбияты үрнәге, 72 битле «Кыйссаи Сәйфелмөлек». Соңгысы мәдрәсә-мәктәпләрдә дәрес китабы итеп кулланылмаган; халык аны бары «Хикәят китабы» буларак укыган.

Килешү вакыты тәмамлангач, Апанаев үзенә татар типографиясе ачарга рөхсәт сорап, берничә тапкыр мөрәҗәгать итеп караган, ләкин һәр юлы хакимияттән тискәре җавап алган *(Кореева Н.А. Күрс. хезмәт. 197 б.).*

1810 елда Апанаев типографиядә 3 мең данә әлифба бастырырга рөхсәт сорый. Ләкин, шрифтлар тузган булу сәбәпле, тискәре җавап ала *(Каримуллин А.Г. Күрс. хезмәт. 118 б.).*

1812–1829 елларда Азия типографиясендә татарлар заказы буенча 7, элеккеге исемлектәге 48 китап нәшер ителгән.

Апанаевтан соң гимназия җитәкчелеге, табыш артыннан куып, китап бастыруга зур суммалар сораган. Шуңа күрә Коръән һәм башка дини китапларга фәкать байлар гына заказ бирә алган. Ә бастырылган продукцияне сатып, акчаны кире кайтару вакыты озакка сузылган.

1829 елда гимназия типографиясе университетныкына (биредә типография 1809 елда ачылган була) кушыла *(Каримуллин А.Г. Күрс. хезмәт. 118, 119, 120, 121 б.),* әмма биредә дә китап бастыру кыйммәт була. Бер Коръәнне бастыру 4 сум 89 тиенгә төшә. Заказ биргән сәүдәгәр аны 8 сумнан 18 сумга кадәр бәя куеп саткан.

1832 елда Казанның иң бай 1 гильдия сәүдәгәре Гобәйдулла Юнысов (1776–1842) 10 мең данә тираж белән «Әлифба» һәм ике тапкыр Коръән бастыра (гомуми тиражы 6600 данә). Гобәйдулла бай калын, ялтыравык, ак, яхшы кыйммәтле кәгазьдә алтын белән бизәлгән затлы сафьян тире белән тышланган Коръән бастыра. Изге китап Мәкәрҗә ярминкәсендә 25әр сумга сатыла *(Каримуллин А.Г. Күрс. хезмәт. 123-124 б.).*

1812–1829 елларда типографиядә ел саен икешәр дини китап нәшер ителә (аларның исемлеге үзгәрми).

Казанда шундый затлы Коръән нәшер итү бай йортларының интерьерын яңартып җибәрә. К.Фукс зал бүлмәсендәге өстәлләрнең берсендә Казанда бастырылган Коръән һәм башка затлы итеп бастырылган Коръәннәр һәм башка дини китаплар тора дип яза *(Фукс К. Күрс. хезмәт. 25 б.).*

1841 елда Казанда Людвиг Шевицның, 1843 елда 3 нче гильдия сәүдәгәре Рәхимҗан Сәгыйтовның, 1843-1844 елларда Шаһи Яхинның шәхси типографияләре эшли. Шәхси типографияләр дини китапларны бастыру бәясен нык төшерергә мөмкинлек бирә *(Каримуллин А.Г. Күрс. хезмәт. 149 б.).* Нәтиҗәдә, капиталлары аз булган шәхесләр дә китапларга заказ бирә башлаган. Әйтик, Казан земство мәхкәмәсе тәрҗемәчесе Рәхмәтулла Әмирханов 1839–1843 һәм 1845-1846 елларда Университет типографиясендә 87 мең 800 данә, нигездә, дини әдәбият бастырып ала, шул исәптән ел саен Коръән һәм Һәфтияк шәрифен (һәммәсе 30 200 данә) нәшер иттерә.

XIX йөзнең беренче чирегендә бай сәүдәгәрләр булган Йосыф Апанаевның, Гобәйдулла Юнысовның, Сәет Борһановның 1841 елда, дини китапларны бастыру бәясе төшкәнчегә кадәр, шәхси типографияләр ачып, зур чыгымнарга барып, Коръән һәм дини әдәбият нәшер итүләрен һәм татар мәктәп-мәдрәсәләрен, укый белүче дин кардәшләрен дини әдәбият белән тәэмин итүләрен махсус әйтеп китү мәслихәт.

Шулай итеп, XIX гасырның икенче чирегендә бай сәүдәгәрләр белән янәшә бу мәйданда кечерәк сәүдәгәрләр Рәхимҗан Сәгыйтов (1843 елны үзе шәхси типография ача), Хәсән Корташ улы Исхаков, Миңлебай Әхмәт улы Габдерәшитов, Гобәйдулла Габделсаттаров, Габделсалих Насыйр улы Медведев һ.б. пәйда була. Китапларны, шулай ук, мещаннар Мортаза Катенин, Мортаза Максутов, Ибраһим Медведев, Мортаза Давыдов, Исхак Уразов, Мөхәммәдьяр Козлов, Шәриф Фәризов, мәдрәсә шәкертләре Байморат Габделвахитов һәм Байморат Мусин, сәүдә белән шөгыльләнүче крестьяннар

Гарәфетдин Габделфаварис, Казан өязе Борки авылы кешесе Шакирҗан, Лаеш өязе Алан авылы игенчесе Нәҗметдин Мөхәммәдьяр улы һ.б. нәшер итәләр. Кайберәүләр китап бастырырга заказны, үзләренең бабалары үрнәгендә, йомышлы татар дип атап бирәләр: Салихов, Г.Вәлидов, мулла Минхин, Фәйзуллин шундыйлар исәбендә. Хөкүмәттә хезмәттә булганнар да китап бастыра: колледжский секретарь Йосыф Богдан улы Ибраһимов, университет укытучысы Гали Мәхмүтов. Китап бастыручылар арасында беренче татар хатын-кызы Гайниҗамал Гобәева була *(Каримуллин А.Г. Күрс. хезмәт. 160 б.).*

Аларның күпчелеге китап бастыруга акчаларын, табыш алудан бигрәк, халыкны мәгърифәтле һәм белемле итү өмете белән биргәннәр дип уйларга кирәк. Кайберләре бу хакта үзләре нәшер иткән китапларга язып калдырганнар. Утыз Имәни хәзерләгән «Кыйссаи Йосыф илә Зөләйха» китабының беренче басмасында шундый юллар бар: «Ушал «Йосыф китабы» Казан өязе Яңа Кишет авылының Рәхмәтулла угылының хәраҗәте илән нәфгы гыйбаде мөслимин өчен, укыяннардан догаи хәер өмит итеп, Казан университетының Азиатский табгыханәсендә хәзинәлектән басма улынмыштыр, Шәһре Казан, 1839 елда вә гарәбия илән 1254 сәнәдә» (*Мәһдиев М.С. Шагыйрьнең бишеге // Мәһдиев М.С. Сызып ак нур белән...: шәхесләребез тарихыннан: фәнни-публицистик мәкаләләр [төз. Г.Хәсәнова]. Казан: Татар кит. нәшр., 2014. 182 б.).*

К.Фукс 1830 еллар ахырында Казанның Иске татар бистәсендәге 4 мәдрәсәдә шәкертләр укыган кайбер әсәрләрне санап чыга: «Әлифба, Иман шартлары белән», «Һәфтияк», шулай ук Казанда нәшер ителгән «Пиргули китабы», «Устуани китабы», «Сөбат әл-гаҗизин», «Фәүзат эн-нәҗат», шулай ук сәүдә итәргә өндәүче Мөхәммәд Биргәвинең китабы *(Фукс К. Күрс. хезмәт. 127, 128)*. Күрәбез, Казанда нәшер ителгән дини әдәбият шәкертләрнең дә уку китапларына әверелгән икән.

1845–1851 елларда университет типографиясендә «Ләтаиф Хуҗа Насретдин» (Хуҗа Насреддин турында анекдотлар) (1845), «Кыйссаи Кисекбаш» (1846), «Ахырзаман китабы» (1847), урта гасыр фәлсәфәчесе әл-Газзалинең (1058-1111) «Айуга ал валәд» (1847), Таҗеддин Ялчыголның «Рисаләи Газизә» (1850), XII гасыр суфи шагыйре Бакырганиның «Хәким ага китабы» (1846), урта гасыр ядкаре «Бәдәвам китабы» (1846), «Мәликә китабы» (1846) һ.б нәшер ителә *(Каримуллин А.Г. Күрс. хезмәт 143 б.)*. Күрәбез, бу репертуар гади халык укысын һәм дини-әхлакый тәрбия алсын өчен сайланган.

1841 елны Рәхмәтулла Әмирханов «Гөррәлек» исемле беренче татар календаре бастыра. 1845 елда башлап, университет типографиясе шамаилләр, дини-дидактик әсәрләр, Мөхәммәд пәйгамбәр тормышы турында 2-6дан 24 биткәчә китапчыклар бастыра башлый. Бу юнәлеш 1860–1870 елларда тагын да көчәя. *(Каримуллин А.Г. Күрс. хезмәт 147-148 б.).*

Шулай ук, муллаларга милек һәм мирас бүлгәндә куллану өчен ярдәмлекләр булыр дип, 1848 һәм 1849 елларда «Шәрхе фикъһе әкбәр» (имам Әбү Хәнифәнең фикъһе буенча шәрехнамәсе) һәм «Шәрхе фикъһе Кәбир» (Кәбир тарафыннан төзегән фикъһе шәрехнамәләре) нәшер ителүне атап китү урынлы булыр *(Каримуллин, 144 б.)*.

Заказчылар исемлеге арту җәмгыятьтә китапка һәм китап укырга ихтыяҗ артуны аңлата. Ә заказчылар тиз арада китапны сатып, акча эшләү мөмкинлеге алган. Казанда басылган Коръән һәм башка дини китаплар, товар буларак, Мәкәрҗә ярминкәсендә китаплар сата торган кибетләр урнашкан «урамда» сатылган. 1840 елны Мәкәрҗә ярминкәсенә сатарга һәммәсе 40 мең сумлык китаплар алып киленгән булса, шуларның 1 мең сумын татар китаплары тәшкил иткән *(Кореева Н.А. Торгово-промышленная деятельность татарского купечества Казанской губернии в последней четверти XVIII – первой половине XIX в. Казань ОСП «Институт татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ», 2019. С. 199.)*.

Казанда нәшер ителгән дини китаплар, шулай ук, Россиянең башка ярминкәләрендә,

Бохара, Хива, Сәмәрканд базарларында сатылган, илнең көньяк-көнчыгыш чик буйларында урнашкан меновой дворларда Урта Азия товарларына алыштырылган. Әйтергә кирәк, чит илләргә дини әдәбият кына түгел, Казанда басылган башка материаллар да чыгарылган. 1812 елда татар сәүдәгәрләре Бохарада һәм Сәмәркандта Россия хөкүмәте кушуы буенча Казан типографиясендә нәшер ителгән, инглиз табибы Дженнерның чәчәк авыруына каршы вакцинацияләү алымын тасвирлаган китапчыгын таратулары билгеле *(Ислам и религиозный активизм в Республике Татарстан. С. 19).*

1861 елны Эчке эшләр министрлыгы Россиянең мөселман илләре сәүдә әйләнешендә империядә нәшер ителгән ислам дине китаплары күпчелекне тәшкил иткәнен билгеләп үтә, бу товарны татар сәүдәгәрләренең Бохара һәм Хива ханлыкларына кәрван юллары белән, шулай ук ярминкәләргә күпләп сатарга алып баруларын ассызыклый *(История Казани в документах и материалах. XIX век. Кн.5. С. 387).*

Шулай итеп, 1841 елга кадәр, ягъни шәхси типографияләр ачыла башлаганчы, Казан уку йортлары җитәкчеләре гимназия һәм университет типографияләрендә мөселман дини китабын бастыруга бик югары бәяләр куеп эш йөрткәндә, берничә сәүдәгәр, җаваплылык алып һәм зур чыгымнарга барып, Коръән, «Һәфтияк шәриф» һәм башка дини эчтәлектәге китапларны бастырганнар. Бу фидакарь затлар шул рәвешле мәктәп-мәдрәсәләрнең һәм, гомумән, дин кардәшләренең белем алуга, уку китабына булган ихтыяҗын канәгатьләндерергә тырышканнар. Аннан соңгы елларда да сәүдәгәрләр башка заказчылар белән бергә китап бастыру өлкәсендә зур хезмәт куйганнар.

Казан каласының биредә 1849 елда Ш.Мәрҗани мулла булып урнашып, хезмәтләр яза башлаганчы ук Россия империясендә һәм мөселман дөньясында дини үзәк, Коръән һәм ислам китаплары нәшер итәлә торган кала булып танылудан гыйбарәт. Басма китап товарга әверелеп, киң таралыш ала һәм китаплар нәшер итүдә махсуслашуга, эшнең сыйфаты яхшыруга уңай йогынты ясый.

Төрки телдә язылган китаплар татар телен басма телгә әверелдерә, халык арасында кулланылыш даирәсен киңәйтә, укучылар санын арттыра, бөр төрле уртак рухи һәм әхлакый кыйммәтләр, дини менталитет формалаштыруга һәм мәдәни яктан берләшүгә уңай тәэсир итә. Басма сүз татар мәдәниятенең һәм халык авыз иҗатының бер өлеше буларак формалаша башлый. Алар укый белгән кешегә дини йолаларны һәм ислам турында белемне мөстәкыйль үзләштерү мөмкинлеге тудырган, халык арасында ислам дине нигезләре, Мөхәммәд пәйгамбәр турында мәгълүматның киңрәк таралуына ярдәм иткән.

Китап бастыру репертуарының дөньяви әдәбият белән баетылуы, 1841 елдан календарь бастыру рәвешен дә алуы, ә илдә либераль реформалар башлангач, татарларың туган телләрендә вакытлы матбугат ачуны сорап язулары, шул рәвешле, басма сүзнең халыкны берләштерүдә яңа дәрәҗәгә чыгуы.

## Йомгак ясап карыйк

1. XIX гасырның беренче яртысында шәһәрләргә, нигездә, актив, һөнәрле, эшмәкәрлеккә омтылган крестьяннар күченгән. Татар эшмәкәрләре һәм сәүдәгәрләре шәһәрләрдәге татар-мөселман җәмгыятьләренең үзәген тәшкил иткән. Татар урамнары күбәйгәч, бистә хасил иткән. Һәр шәһәрдә булган бер яки берничә бай эшмәкәр бөтен җәмгыятьнең ихтыяҗын канәгатьләндереп, мәчет, мәктәп-мәдрәсәләр төзегәннәр, үз хисапларына руханилар тотканнар. Шулай итеп, сәүдәгәрләр капиталлары татар шәһәрләренең һәм бистәләренең кучемсез милеген булдыруга, аларда дини-мәдәни һәм житештерү структурасын һәм җәмәгать биналарын төзергә дә сарыф ителгән. Бу шәһәр җәмгыятьләренең татар иҗтимагый фикере һәм милли мәдәният үсешендә, милли берләшүдәге роле Россиядә модернизация башлангач тагын да калкурак күренәчәк әле.

2. Урта Азия базарларына татар сәүдәгәрләре салган кәрван юллары шәкертләр өчен Бохара, Сәмәрканд мәдрәсәләренә баруның төп каналына әверелгән, аларга ияреп, кала-салаларга, мәдрәсәләргә дини әдәбият кайткан.

3. Сәүдәгәрләр, Урта Азиядә укып кайткан голәмалар белән хезмәттәшлек итеп һәм алар ачкан мәдрәсәләрен матди яктан кайгыртып, Идел-Урал төбәгендә руханилар әзерли торган укыту системасын төзүдә зур өлеш керткәннәр.

4. Урта Азиядән укып кайткан голәмалар һәм алар хәзерләгән муллалар русча белмәгән, ә аз санлы татар дворяннары земствовалар ачылганчы халык мәнфәгатьләрен кайгырту өлкәсенә битараф булган шартларында татар байлары, сәүдәгәрләре хәйриячелек өлкәсендә эш-гамәлләре белән дин кардәшләре арасында төбәк әйдаманнары булып танылганнар. Алар хакимият белән сөйләшкәндә, үзләрен шәһәр мөселманнары мәнфәгатьләрен яклаучылар буларак кына түгел, ә бөтен татар-мөселман җәмгыятенең вәкаләтле вәкилләре дип күрсәтә башлаганнар.

5. Казан байлары Коръән, әлифба, дини эчтәлекле китапларны нәшер итү, тарату һәм сатуда, халыкны уку китаплары белән тәэмин итүдә матур нәтиҗәләргә ирешкәннәр. XIX гасырның беренче яртысында Казанда туган телдә күпләп дини китаплар бастыру һәм дөньяви китаплар нәшер итә башлау XVIII гасырда Идел-Урал һәм Көнбатыш Себер төбәгендә оешкан дини автономияне дини-мәдәни автономиягә әверелдерә.

Бу ни дигән сүз? Беренче чиратта, дини китаплар татар телен халык арасында исламны үтемле вәгазьләү чарасына әверелдергән. Шул рәвешле безнең төбәктә вәгазьләү өч телдә алып барылган: гарәп, фарсы һәм татар теле. Беренче икесен муллалар, муллазадәләр, өлкән шәкертләр генә белсәләр, туган телдәге текстлар һәр язу таныган кешегә дини һәм әхлакый темаларга багышланган әсәрләрне үзлегеннән укырга мөмкинлек биргән. Ягъни басма татар теленең дини тәгълиматны үзләштерүдәге роле арта барган. Илнең иксез-чиксез киңлекләрендә мәхәлләләр булып яшәүче татар җәмгыятьләренә барып җиткән басма китаплар мәктәп-мәдрәсәләрдә укытуны яхшыртырга, шәкертләргә мөстәкыйль мәгълүмат үзләштерүне җиңеләйткән.

Иң мөһиме – бердәм әдәби тел ислам дине белән берлектә татарларның төрле социаль катламнарын һәм иң еракта урнашкан төркемнәрен яңа дәрәҗәдә берләштерүгә юл ачкан. Ягъни басма әдәби татар теле дини һәм милли бердәмлекнең символына әверелә барган.

Ул да түгел басма китаплары булмаган күрше төрки кавем-кабиләләрнең элиталары шушы әдәби телне формалаштырган татар мәдәни кырына кергәннәр. XIX гасырның икенче яртысында – XX йөз башында дөньяви китапларның саны һәм күләме арткач, бу өлкәдә яңа дәрәҗәдә сыйфат үзгәрешләре күзәтелгән. Нәтиҗәдә, 1917 елның азагында Уфада эшләүче Милләт мәҗлесе «төрки татар милләте» составына йөз елдан артык шушы басма әдәби телне кулланып яшәүче татарларны, мишәрләрне, башкортларны һәм нугайларны кертә *(Давлетшин Тамурбек. Советский Татарстан. Казань: «Жиен», 2005. С. 188)*.

**Илдус ЗАҺИДУЛЛИН,**
*тарих фәннәре докторы*

*Мөхәммәт Садриның тууына – 110 ел*

# БЕЗДӘН СОҢ ДА ЯШӘП КАЛАЧАК



Шагыйрь, Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре Мөхәммәт Садриның (1913–1999) тууына – 110 ел.

Шагыйрь 1913 елның 31 маенда Казанның Яңа Татар бистәсендә туа. 1921 елгы ачлык вакытында ата-анасы икмәк эзләп, Урал ягына чыгып китәләр һәм юлда ачлыктан үләләр. Казанда калган җиде-сигез яшьлек Мөхәммәтне дәү әнисе ятимханәгә тапшыра. Тормышы бераз көйләнгәч, оныгын янәдән үз янына алып кайта, мәдрәсәгә укырга бирә. Анда бераз укыгач, Мөхәммәт яңа оештырылган совет мәктәбенә күчә. 1927 елда, дәү әнисе вафат булгач, мәктәп җитәкчеләре ятим баланы кабат балалар йортына тапшыралар. 1928 елда ФЗӨ мәктәбендә слесарьлык һөнәрен үзләштерә. Заводта эшләгәндә, М.Садри каләм тибрәтә башлый. Иҗатының чишмә башы Татарстан радиосы белән бәйле, дисәк, әллә ни арттыру булмас. «Ул вакытта шагыйрь Хәсән Туфан анда эшли иде, – дип яза ул үзенең истәлекләрендә. – Мин исә Вахитов исемендәге заводта яшь слесарь. Шигырьләремә беренчеләрдән булып тәнкыйтьче Гомәр Гали игътибар итте. Шулай беркөнне ул мине радиокомитетка алып китте. Хәсән ага мине көтелмәгәнчә җылы кабул итте. Язганнарымны игътибар белән укып чыкты. Күпмедер гомер узды. Китап кибетенә керсәм, аптырап киттем, аптыраудан өнсез калдым: киштәдә «Җыр башлана» дигән китап тора, авторы – Мөхәммәт Садри. Хәсән абыебыз минем шигырьләрне туплап, нәшриятка илткән, аларны редакцияләп, Афзал абый Шамов булышлыгы белән китап итеп тә чыгарган»...


Мөхәммәт Садри – поэмалар, шигырьләр, җырлар, ике йөздән артык очерк, әдәби тәнкыйть һәм публицистик мәкаләләр авторы. Үз вакытында аның әсәрләре укучылар тарафыннан көтеп алына һәм тиз арада популярлык казана.

Мөхәммәт Садри – фронтовик шагыйрь. Ул 1941 елның июлендә Ватан сугышына китә. Каты яралана. 1943 елның көзендә, алты ай госпитальдә дәваланып чыккач, М.Садрины Беренче Украина фронтында татар телендә чыга торган «Ватан намусы өчен» газетасы редакциясенә оештыручы-хәбәрче итеп җибәрәләр. Шагыйрь-сугышчы шушы фронт газетасында эшләүче татар язучыларыннан Р.Ишморат, Г.Хуҗи, Г.Бакировлар белән берлектә Украина җирләрен, Польшаны азат итүдә, Германиядәге сугышларда, Берлинны алуда, Праганы азат итүдә катнаша.

1946 елда гаскәри хезмәттән кайткач, М.Садри ике елга якын Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең җаваплы секретаре булып эшли, 1956 елдан ул профессионал язучы сыйфатында фәкать әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә.

Мөхәммәт Садрины без әле бүген дә халык тарафыннан яратып тыңлана торган популяр җырлар авторы буларак та беләбез. Укучылар игътибарына тәкъдим ителә торган программа «Казан утлары» журналы сайты өчен махсус төзелде. Ул Ирек Баһманов язмасында Мөхәммәт Садри шигыре белән ачылып китә. 1988 елда радионың яшь мөхәррире Зиннур Хөснияр Бөек Җиңүнең 43 еллыгы уңаеннан фронтовик шагыйрьләрнең шигырьләреннән әдәби композиция әзерли (режиссёры – Фәрит Җәләй, тавыш операторы – Асия Бикбау). Әлеге шигырь шушы тапшырудан алынды. Аннары сез Мөхәммәт Садри шигырьләренә иҗат ителгән берничә җыр ишетерсез.

# АРАБЫЗДА КЕБЕК ӘЛЕ ДӘ



Актёр, режиссёр, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Айдар Хафизовның (1943–2020) тууына – 80 ел.

Ул ярты гасырга якын театр сәхнәсендә милләткә хезмәт иткән зур актёр иде. Шушы вакыт эчендә ул дистәләрчә кабатланмас образлар иҗат итте. Тамашачылар күңеленә ул Шәриф Хөсәеновның «Әни килде» спектаклендәге Сәйяр, Аяз Гыйләҗевнең «Китмәгез, тургайлар»ында – Азамат, Нәкый Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин»ында – Җиһангир хан, Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр»ендә – Газраил, «Хушыгыз»ында – Шәһит һәм башка образларны камил дәрәҗәдә гәүдәләндергән чын мастер буларак кереп калды. Әдәбият тәнкыйтьчесе Әлфәт Закирҗанов әйтүенчә, Айдар Хафизов үзен төрле амплуадагы рольләрне уйный алучы, бай сөйләм теленә ия артист итеп таныта, тыныч характеры, үз-үзенә һәм коллегаларына таләпчәнлеге, шул ук вакытта тирән белем, тырышлык, эзләнүчәнлек аны Камал театрының әйдәп баручы артистларының берсе, яшьләрнең тәҗрибәле остазы һәм оста оештыручы режиссёр итеп таныта. Артист булуны үзеңә зур җаваплылык алу дип саный һәм иҗат гомерендә шуңа тугры булып кала...

Айдар Хафизны без татар әдәбиятын пропагандалау эшенә зур өлеш керткән шәхес дип тә әйтә алабыз. Татарстан радиосы фондында язучыларыбызның иҗат кичәләрендә яздырып алган тапшырулар саклана. Алар арасында Айдар Хафиз тавышы кергән язмалар байтак, кичәләрнең кайберләрен ул үзе алып барган, бик күбендә язучыларның шигъри яисә чәчмә әсәрләрен сәхнәдән яңгыратучы нәфис сүз остасы буларак катнашкан.

Айдар Хафизов радионың үзенә килеп, әдәби-драматик тапшырулар әзерләүдә дә актив катнашты. Равил Фәйзуллин, Нияз Акмал, Фәннүр Сафин шигырьләре әле дә аның язмасында эфирга чыга.

Ул республикабызда төрле вакыйгалар уңаеннан оештырылган әдәби-музыкаль кичәләрнең, бәйрәмнәрнең режиссёры булып та танылды. Аның кулы тигән чаралар үзләренең мавыктыргыч, шул ук вакытта гаҗәеп зәвыклы булулары белән аерылып торалар иде. Сүз уңаеннан, «Казан утлары» журналының беренче саны чыгуга – 90 ел, Татарстан радиосының 80 һәм 85 еллыкларына багышланган тантаналы кичәләр нәкъ менә Айдар Хафизов режиссёрлыгында үткәрелде һәм халык тарафыннан яратып кабул ителде.

Журнал укучылар игътибарына тәкъдим ителә торган радиотапшыру 2018 елда эфирга чыккан иде. Шул елның 27 ноябрендә Камал театры сәхнәсендә Айдар Хафизовның иҗат кичәсе үткәрелде, аңа берничә көн кала журналист Раил Садри аның белән әңгәмә үткәргән иде. Тапшыру иҗат портреты жанрына якын тора. Анда актёрның балачак хатирәләре, язмыш юллары, сәхнә тормышы шактый тулы чагылыш таба, ул катнашкан спектакльләрдән өзекләр бирелә. Әйдәгез, QR-код ярдәмендә безнең сайтка кереп, шушы язманы тыңлыйк. Тыңлаганда игътибар итми калмассыздыр: Айдар Хафизов әле һаман да арабызда кебек. Уйлап карасаң, ул чыннан да шулай, чөнки рухи тормышыбызда ул калдырган мирасның урыны зур.

*Сәхифәне «Татарстан» радиосының шеф-мөхәррире*
**Нәсим АКМАЛ** *алып бара.*

## ТУКАЙ КӨННӘРЕ

Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның туган көнен республикабызда һәм шулай ук башка төбәкләрдә зурлап билгеләп үттеләр. Ул көнне иртән Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов шагыйрьнең Казан үзәгендәге һәйкәленә чәчәк салды. Чәчәк салу тантанасында ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, ТР Рәисе Аппараты Җитәкчесе Әсгать Сәфәров, Казан шәһәре мэры Илсур Метшин, ТР Дәүләт Советы депутатлары, ТР хөкүмәте әгъзалары, республикабызның әдәбият-сәнгать әһелләре, галимнәр, җәмәгатьчелек вәкилләре, башкалабыз кунаклары, студентлар, мәктәп-гимназияләр укучылары катнашты.

* * *

М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында Туган тел көненә һәм Габдулла Тукайның тууына 137 ел тулуга багышланган тантана булды. Анда Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенең быелгы лауреатлары – шагыйрь Шәүкәт Гаделша, декоратив паннолар авторы Наилә Кумысникова, архитектор Фирдәвис Хановны котлады, аларга диплом һәм күкрәк билгесе тапшырды. Тантанада шулай ук Флёра Гыйззәтуллинага һәм Наил Касыймовка «Татарстанның халык шагыйре» дигән исем бирү турында да игълан ителде. Рөстәм Миңнеханов аларга дәрәҗәле исемнең махсус билгесен тапшырды. Аннары сәхнәдә республикабыз сәнгать осталарының чыгышларыннан торган тамаша булды.

* * *

Г.Тукайның туган көнендә шагыйрьнең Татар дәүләт опера һәм балет академия театры янындагы һәйкәле каршында Шигырь бәйрәме үткәрелде. Анда Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла Г.Тукай премиясенең быелгы лауреатларын котлады. Ул шулай ук Флёра Гыйззәтуллина белән Наил Касыймовка «Татарстанның халык шагыйре» исеме бирелүен әйтте. Бәйрәмгә җыелган халыкны ТР мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин сәламләде. Аннары «Татар гармуннары» ансамбле җыр-моңнарын ирештерде. Шигырь бәйрәмендә Татарстанның халык шагыйрьләре Рәдиф Гаташ, Газинур Морат, Наил Касыймов, шагыйрьләр Ләбиб Лерон, Халисә Мөдәррисова (Башкортстан), Халидә Гыйләҗева (Санкт-Петербург), Рифат Җамал, Нәҗибә Сафина, Рәмис Аймәт, Хәбир Ибраһим, Фәүзия Солтан, Рүзәл Мөхәммәтшин, Дания Нәгыйм, Булат Ибраһимов, Рифат Сәлах, Фәнил Гыйләҗев, Ләйлә Хәбибуллина, Алинә Хәбибуллина, Г.Камал театры артисты Илдус Әхмәтҗанов, җырчылар Резеда Галимова, Георгий Ибушев, Илгиз Мөхетдинов, шигырь сөйләүчеләр конкурсында җиңүче укучылар Зифа Сафина, Сөмбел Гобәева, Казан театр көллияте укучылары (профессор Рәүф Нуриев шәкертләре) чыгыш ясады. Бәйрәмне Татарстанның халык шагыйре Зиннур Мансуров алып барды.

* * *

Габдулла Тукайның туган көне алдыннан Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла җитәкчелегендәге делегация (Татарстанның халык шагыйрьләре Рәдиф Гаташ, Газинур Морат, әдәбият галиме Фоат Галимуллин, Башкортстаннан шагыйрә, прозаик, драматург Халисә Мөдәррисова, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин, аның урынбасары Вакыйф Нуриев, язучылар Камил Кәримов, Рәдиф Сәгъди, шагыйрә Сания Әхмәтҗанова, Татарстан Кинематографлар берлеге рәисе Илдар Ягъфәров, «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгының баш мөхәррире Рәмис Латыйпов, журналист Зилә Мөбарәкшина) Арча районына сәфәр кылды. Сәфәр шагыйрьнең туган авылы Кушлавычтан башланды. Каләм әһелләре театральләштерелгән тамашаны карады, музейда булды. Кунаклар Тукайның әтисе Мөхәммәтгариф каберен зиярәт кылды. Аның рухына дога багышланды. Тукайны шагыйрьнең бюсты янында да искә алдылар. Аннары язучылар Яңа Кырлайга юл тотты. Монда аларны Арча районы башлыгы Илшат Нуриев каршы алды. Г.Тукай һәйкәленә чәчәкләр салынды. Монда да бәйрәм театральләштерелгән тамашадан башланды. Халыкны И.Нуриев белән Р.Зәйдулла сәламләде. Кушлавычта да, Яңа Кырлайда да Рәдиф Гаташ, Фоат Галимуллин, Халисә Мөдәррисова, Сания Әхмәтҗанова чыгыш ясадылар. Аннары Әтнә татар дәүләт драма театры һәм арчалылар тарафыннан әзерләнгән концерт булды. Аны шагыйрә Гөлүсә Баттал алып барды.

* * *

Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рифат Җамал, Татарстанның халык язучысы Нәбирә Гыйматдинова, язучылар Ринат Мөхәммәдиев, Рәфкать Кәрами, Данил Салихов, Хәбир Ибраһим, Гәүһәрия Хәсәнова-Мәһдиева, Галия Гайнетдинова, Айсылу Имамиева, Амур Фәлах, әдәбият галиме Ләйлә Минһаҗева Балтач районы Сасна Пүчинкәсе авылына кайтып, Габдулла Тукайның әнисе Бибимәмдүдә каберен зиярәт кылды. Монда аның рухына дога багышланды. Кунакларны район башлыгы Рамил Нотфуллин кабул итте. Язучылар Бөрбаш, Субаш, Куныр мәктәпләрендә булдылар, иң күп китап укучыларны котладылар.

* * *

Арча районы Яңа Кырлай мәктәбендә XII республика «Тукай укулары» булып узды. Анда «Казан утлары» журналының татар әдәбияты үсешендәге роле» номинациясендә жюри әгъзалары журналыбызның әдәби бүлек мөхәррире Рафис Корбан һәм язучы Рахман Шәфигуллин иде. Алар җиңүчеләргә «Казан утлары» журналының быелгы саннарын һәм үз китапларын бүләк иттеләр.

## ҮЗБӘКСТАНГА СӘФӘР

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла төрки шагыйрьләрнең Үзбәкстанда үткән «Мумтаз шигърият» фестивалендә катнашты.

## ИДАРӘ УТЫРЫШЫ

Татарстан Язучылар берлегенең чираттагы утырышы булды. Берлек рәисе урынбасарлары Илсөяр Иксанова, Факил Сафин (язучыларның Чаллы бүлеге җитәкчесе) ике утырыш арасында башкарылган эшләргә хисап тотты. Аннары Г.Тукай көннәрен үткәрү, Туган тел көненә багышланган чаралар турында сөйләшү булды. Утырышта Гүзәл Галләмова, Алинә Хисамиева Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителде. Идарә әгъзалары Миләүшә Әхмәдуллинаны үз сафларына шәрәфле әгъза буларак алдылар. Утырышны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла алып барды.

## ИЛДАР ЮЗЕЕВНЫҢ ТУУЫНА – 90 ЕЛ

Чаллыда Илдар Юзеевның тууына 90 ел тулуга багышланган тантаналы чара узды. Быел аның исемендәге әдәби-иҗтимагый премия җирле шагыйрьләр Әлфия Ситдыйкова белән Рәшит Бәшәргә, Башкортстаннан Хисаметдин Исмәгыйлевка, премия дипломы спонсор Фәрид Бәшәровка тапшырылды. Чарада Казаннан Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рифат Җамал, Татарстанның халык шагыйре Зиннур Мансуров, язучы Әхәт Мушинский, драматурглар Хәбир Ибраһим, Мансур Гыйләҗев, шагыйрьләр Фәнил Гыйләҗев, Дания Нәгыйм, Ләйлә Хәбибуллина катнашты. Чаллылардан берлекнең җирле бүлек рәисе Факил Сафин, «Мәйдан» журналының баш мөхәррире Лилия Фәттахова, шагыйрьләр Лилия Гыйбадуллина, Айрат Суфиянов, Айзирә Имамова мәйдан тотты.

Шулай ук «Мәйдан» журналында үткәрелгән «Бу заман шундый заман ул...» әдәби бәйгесенә дә йомгак ясалды. Повесть номинациясендә Рәмис Латыйпов – беренче, Закир Әкбәров – икенче, Айзирә Имамова – өченче, хикәя буенча Наилә Харисова – беренче, Фатыйма Гыйльметдинова – икенче, Гөлүсә Батталова өченче урынга лаек булды.

## РАФИС КОРБАН КИТАПЛАРЫ

Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең концерт залында шагыйрь, прозаик, драматург Рафис Корбанның яңа китапларын («Ике роман», «Алиш», «Тәүбә көне», «Рафис Корбан балаларга», «Туган нигез») тәкъдим итү кичәсе булды. Әлеге әсәрләр турында галимнәр Рүзәл Юсупов, Фоат Галимуллин, Миләүшә Хәбетдинова, Равил Рахмани сөйләделәр. Кичәдә Клара Хәйретдинова, Рөстәм Насыйбуллин, Илгиз Закиров, Азат Тимершәех, Азат Хөсәенов, Резеда Төхфәтуллина, Газинур Фарукшин, Нурзадә, Фәридә-Алсу, Фәрит Мирзануров Р.Корбан сүзләренә язылган җырларны җырладылар.

## ХАТЫЙП МИҢНЕГУЛОВКА БАГЫШЛАП

Казандагы 11 нче татар гимназиясендә әдәбият галиме Хатыйп Миңнегуловның күпьеллык гыйльми һәм иҗтимагый эшчәнлегенә багышланган «Дөньяда сүзебез бар» дип аталган IV Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе булды. Анда галимнәр Тәлгат Галиуллин, Фоат Галимуллин, Татар халык шагыйрьләре Рәдиф Гаташ, Газинур Морат чыгыш ясадылар.

11 нче гимназиядә галимнең музее да ачылды.

## ПРЕМЬЕРА

Рөстәм Галиуллинның «Көзге кайтаваз» пьесасы буенча куелган спектакль премьерасы (режиссёры Фәрит Бикчәнтәев) өч көн Г.Камал театрында аншлаг белән барды. Хезмәттәшебезне яңа иҗади уңышы белән котлыйбыз!

## КОТЛЫЙБЫЗ!

29 май – әдәби тәрҗемәче **Азалия Бадюгинага** 90 яшь.

*Сәхифәне* **Вакыйф НУРИЕВ** *әзерләде.*

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: рассказ М.КАБИРОВА «Батыр из другой деревни»,
роман М.АМИРХАНОВА «Воительница», роман Х.ИСМАГИЛОВА «Заколдованный круг»;
стихи Г.МУРАТА, Ф.ХАРРАСОВОЙ, Ф.НИЗАМОВОЙ.
«Новые имена»: стихи Г.ФАХРЕТДИНОВОЙ.
«Литературный конкурс «Учитель – прекрасный человек на земле!»:
повесть Р.РАХМАНА «Простые истины».
«Литература родственных народов»: рассказ М.ГАБИЛОГЛУ «Эрмен-Армен –
любовь Шушаника».
Перевод с русского языка Ф.ЗАМАЛЕТДИНОВОЙ.
«Литературная критика»: статья З.МАНСУРОВА.
«Память»: статьи Р.КУРБАНА, Р.АХУНЗЯНОВОЙ.
«Наука»: статья Д.ЗАГИДУЛЛИНОЙ.
«1100 лет со дня принятия Ислама в Поволжье»: статья И.ЗАГИДУЛЛИНА.
«Бесценные голоса»: статьи к 110-летию М.Садри и 80-летию А.Хафизова.
Рубрику ведет Н.АКМАЛ.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Площадь Свободы в городе Казани. Фото И.АБРАМОВОЙ;
Ильгам Гумеров, заведующий Центром письменного наследия ИЯЛИ АН РТ,
кандидат филологических наук. Фото А.АРАХАМИЯ.*

# IN THIS ISSUE:

«Prose and Poetry»: story by M.KABIROV «Out-of-village Batyr»,
novel by M.AMIRKHANOV «The Warrior Girl», novel by Kh.ISMAGILOV «The Enchanted Circle»; poems by G.MURAT, F.KHARRASOVA, F.NIZAMOVA.
«New Names»: poems by G.FAKHRETDINOVA.
«Literary competition «Teacher is a wonderful person on earth!»:
story R.RAKHMAN «Simple Truths».
«Literature of kindred peoples»: story by M.GABILOGLU «Ermen-Armen -Shushanik's love.
Translation from Russian by F.ZAMALETDINOVA.
«Literary criticism»: article by Z.MANSUROV.
«Memory»: articles by R.KURBAN, R.AKHUNZYANOVA.
«Science»: article by D.ZAGIDULLINA.
«1100 years since the adoption of Islam in the Volga region»: article by I.ZAGIDULLIN.
«Priceless voices»: articles to the 110th anniversary of M.Sadri and the 80th anniversary of A.Khafizov.
The rubric is conducted by N.AKMAL.
Diary of social and cultural life.
On our covers: Freedom Square in Kazan. Photo by I.ABRAMOVA;
Ilgam Gumerov, Head of the Center for Written Heritage of the Institute of Language, Literature and Arts, Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan,Candidate of Philological sciences. Photo by A.ARAKHAMIA.

---

*Тышлыкның беренче битендә:* Ирек мәйданы. *И.Абрамова фотосы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* галим Илһам Гомәров. *А.Арахамия фотосы.*